ISSN 0206–4189
Индекс 73210
12+

# Казан утлары

3.2015



# БУ САНДА:



## Гүзәл СӘГЫЙТОВА
## «Кара Пулат» серләре

«Кара Пулат» — «Зөһрә», «Алтынчәч», «Шүрәле» кебек эпос, риваятькә корылган татар музыкасы ядкарьләренең варисы, соңгы елларда тарихның төрле чорларын яктырткан «Ак бүре», «Алтын Урда», «Алтын Казан» музыкаль әсәрләр циклының дәвамы кебек. «Кара Пулат»та традицион әкиятләргә хас ак һәм кара көчләр көрәше сурәтләнә».

140

## КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ



## Гомәр ДАУТОВ
## «Моңнар булып кайтырмын»

«Ефимны арбага күтәреп салулары булды, егет телгә килде. Халык өнсез калды: Ефим кычкырып «Сарман»ны җырлый иде. Фельдшер, үзенә үзе ышанмыйча, иелеп авыруның йөзенә карады: юк, аңсыз. Әмма җырлый!
— Да, — дип кепкасын салып, маңгаен сөртте әле генә көрәк сорап кычкырган ир, арба кузгалып киткәч, — да! Безнең белән авылда әрәм булып ята бу егет. Яшен суккач та җырлый алган кешене күргәнем юк иде әле…»

55

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Клара БУЛАТОВА. Җуелмаслык эзләр сакланыр. *Шигырьләр.* ....3
Камил КӘРИМОВ. Тургайлы болытлар. *Роман-элегия.* ....8
Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Югалыр күк бу мизгел. *Шигырьләр.* ....50
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Һәм үзебез – тарих көзгесе... *Шигырьләр.* ....98
Луиза ЯНСУАР. Дөньянык ы үтәр – бездән дә... *Шигырьләр.* ....120

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Гомәр ДАУТОВ. Моңнар булып кайтырмын. *Документаль бәян.* ....55
Хәмидә ГАРИПОВА. Тозак. *Бәян.* ....103

*100нче бит:* Газинур МОРАТ. Музалар тын тормасын дисәк... ....100

**СӘНГАТЬ**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Директор *(Шамил Закировның тууына 70 ел).* ....126
Аида АЛМАЗОВА. Фәрит Яруллин һәм аның даирәсе *(«Шүрәле» балеты куелуга 70 ел).* ....130
Гүзәл СӘГЫЙТОВА. «Кара Пулат» серләре. ....140

**ХӘТЕР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Юксыну. ....145
Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....168
Илдар ХӘЙРУЛЛИН. Кабатланмас шәхес. ....172

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Иңдә – җиһан... ....149
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Сафлыкка манылган әсәрләр. ....153

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Заман прозасында – чор сулышы. *(Д.Заһидуллина, М.Вәли-Барҗылы, Г.Насыйбуллова, Л.Бәдертдинова, Г.Мансурова катнашында «түгәрәк өстәл»).* Рамил ХАННАНОВ әзерләде. ....156

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

БАТУЛЛА. Мәгънә. ....174

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....176

**АК ҖИЛКӘН**

Рамил ХАННАНОВ. Тәүге карда ак эзләр... *Хикәя.* ....180
Хикәя яза аласызмы? *(Флёра МӘРДАНОВА, Алёна ФӘХРЕТДИНОВА, Гүзәлия ТАРХАНОВА, Әдилә НУРХӘМӘТОВА хикәяләре).* ....182
«Танымыш » дәресе. ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....124
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.02.2015, график буенча 27.02.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-500. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Клара
Булатова

# ҖУЕЛМАСЛЫК ЭЗЛӘР САКЛАНЫР

## Ике бөртек умырзая...

Жирдә сугыш бара,
әмма язга
Ни катнашы жирдә бар аның?
Ике бөртек умырзая чыккан,
Кар астыннан сузып сабагын.
Әле сугыш.
Кырык бишнең язы,
Кояш төшкән КП артына.
Урта яшьләрдәге бер генерал
Умырзая өзә сак кына.
Умырзая урман гөлләренең
Иң тәүгесе әле, иң яше.
Умырзая өзгән генералның
Танда үлгән тормыш иптәше.
Казанда да госпиталь бар иде,
Мөмкин иде тылда калырга.
Тик Мәрьяме үзе теләп килде
Фронттагы ире янына.
Дүртенче ел сугыш походларын
Үткән иде алар ингә-иң.
Ник табигать шундый хәсрәт бирде
Умырзая шыткан көннәрең?!
Кайгы — кургаш.
Күпне күргән бу баш,
Эчкә йота ир-ат күз яшен.
Солдат кабере куенына салды
Генералның тормыш иптәшен.
Ә дөньяда тормыш дәвам итә,
Шушы язда килер җиңү бар.
Яуда үлгән солдат каберенә
Умырзая куя генерал.

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә; «Язлар алда», «Әрну», «Каурый канат — җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» һәм Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

## Ә мин беләм

Бу дөньяда
яшәү яме өчен
Күпме көч куюын кешенең
Үз иңнәрем белән татыдым мин,
Үз йөрәгем белән кичердем.

...Кояш көлеп торган җәйге көндә
Көтмәгәндә аяз ил күген
Кара болыт килеп каплаганны
Күрдеңме син?
Ә мин, мин күрдем.

Туфрагыңа дошман аяк баскач,
Туган йорттан сөрелеп йөрүнең
Газапларын шул чак җаның аша
Кичердеңме?
Ә мин кичердем.

Бомба шартлап, чигенү юлларында
Гөнаһсызлар юлы өзелүен,
Балалар һәм картлар егылуын
Күрдеңме син?
Ә мин, мин күрдем.

Яралылар исән калсын өчен,
Яшь кызларның каннар бирүен,
Үзләренең һушсыз егылуын
Күрдеңме син?
Ә мин, мин күрдем.

Хәлдән таеп арган эшчеләрнең
Станокка бөгелеп төшүен,
Цехларыннан, ләкин китмәүләрен
Күрдеңме син?
Ә мин, мин күрдем.

Авыр иде, ләкин үттек аны,
Җиңеп үттек бердәм ил белән.
Җиңү безгә җиңел килмәгәнне
Беләсеңме?
Ә мин, мин беләм.

Әйе, беләм.
Чөнки аның өчен
Туган халкымниләр бирүен
Үз иңнәрем белән татыдым мин,
Үз йөрәгем белән кичердем.

Тормыш матур.
Аның матур торуын
Тели халык бөтен җир белән.
Тыныч көннең нинди кыйммәт булуын
Беләсеңме?
Ә мин, мин беләм!

## Хәтер

Яз җиттеме, һаман
балачакның
Шул бер көне калка хәтердә:
Сандыгыннан эзләп алып, әни
Алсу тасма такты чәчемә.

Ул үзе дә ал күлмәген киде,
Алсуланды йөзе берочтан.
Бу — Май иде,
Бу — 45 иде,
Әти кайткан иде фронттан.

Гомер үткән,
дистә еллар үткән,
Язлар киткән язлар артыннан.
Ә тарихта безнең буын гомере
Шул алсулык белән балкыган.

## Сез дә яшьләр идегез

Сез дә яшьләр идегез,
Янып эшләр идегез.
Ил чакырды.
Эшне куеп,
Өскә шинель кидегез.

Урылмаган иген калды
Басуларны тутырып.
Кузгалдыгыз, югалдыгыз
Вагоннарга утырып.

Өйләр көтте еллар буе
Кайтыр көннәрегезне;
Карталардан барны карап
Кайда йөргәнегезне.

Бәйрәм инде,
Җиңү килде,
Ил өметенаклады.
Кемнең кулы,
кемнең аяк,
Кемнең башы кайтмады.

Кайтканнар да берәм-берәм
Китә,
юкса иртәрәк.
Шул сугышта алганнармы —
Киселүгә бер сәбәп.

Сафларыгыз сирәгәйде,
Бу бәйрәмгә менә сез
Инде төркем-төркем түгел,
Бөртек-бөртек киләсез.

Ә шулай да бу буынның
Һәр бөртеге — бер дөнья.
Армиябез тарихының
Җанлы бите сез монда.

Бүген безгә — оныкларга,
Сездән мирас иң элек —
Сез саклаган Ил иреге,
Без яклаган иминлек.

## Каеннар яшь иде...

Каеннар яшь иде,
алар да яшь иде,
Авылдан хушлашып киткәндә.
Кайтмаслар икәнне белделәр микәнни?
Каеннар сыкранды үткәндә.

Озата бардылар,
кул болгап калдылар:
«Онытма!»
«Исән кайт!»
«Җиңеп кайт!»
Җилләрдә җилфердәп тибрәнде каеннар,
Кызларның теләген кабатлап.

Каеннар яшь иде,
алар да яшь иде...
Каеннар картайган, саргайган...
Ап-ак бәс түгел дә,
сыкылар күренә,
Чигәләр сизелеп агарган.

Яз арты яз үтә,
Яз арты яз үтә,
Җәй житә, җәй житә аннары,
Бу күңел ни көтә?
Бу күңел ни көтә?!
Кайтмаска киткән бит ярлары.

Каеннар саргайган,
чигәләр агарган.
Күңелләр, әйтерсең, япь-яшьләр.
Һаман да сөяләр,
һаман да көтәләр
Ярлары кайтмаган кәләшләр.

## Юк, кайтмасын ул чор!

Менә тагын июль ае керде,
Җәйге ямьгә урман төренде.
Күз ачтылар кырда ромашкалар,
Җир җиләге пешеп өлгерде.

Әни бүген җиләк җыеп кайтты,
Шул кадәрле каян табылган!
Бар да эре, тәмле булып пешкән...
Ерак калган бала чагымнан
Бер хатирә күз алдыма килде:
Июль көннәренең берсе,
«Иннек тау»га менеп җыеп төштек
Таштай каты җиләк бөресен.

Әни шуны, компот итеп түгел,
Аш урынына салып кайнатты.
Шикәр салып түгел, ачы сулы
Җиләк белән йөрәк ялгаттык.

Әти күптән китте яу кырына,
Дошман килгәч иле өстенә.
Авыру ана янында дүрт бала,
Беребездән-беребез кечкенә.

Без күрмәдек бомба ярылуын,
Ишетмәдек туплар тавышын.
Тик кичердек әтисен сугышка
Озатып калган бала сагышын.

Татып үстек сугыш газапларын,
Төзәлсә дә инде яралар...
Жуелмаслык эзләр салынып калган —
Һай, килмәсен алар янадан.

Әни ятты озак больницада,
Озын җәйләр буе авырды.
Апабызга, унбер яшьлек кызга,
Күчеп калды тормыш авыры.

Больницалы район үзәгенә
Тору өчен күчеп килдек без.
Әни яткан бүлмә тәрәзенә
Көн дә барып йөри идек без.

Тәрәзәдән әни, яшереп кенә,
Суза иде үзенең өлешен.
Шул икмәкне, санап һәр валчыгын,
Ашый идек дүртәү бүлешеп.

Бервакытны апам әйткән иде:
(Әле дә талый йөрәк итемне.)
Булырмы, дип, бирәр, түшкә терәп,
Каерып кисәр көннәр ипине!..

Берни дә юк иде:
    он да, тоз да...
Сугыш алган иде барын да.
Алабута күмәче дә тозсыз
Пешә иде бик күп чагында.

«Юк» дигәнне мин аңламый идем,
Беркөн сорап елый башладым.
Кара алабута күмәчемне
Күз яшемә манчып ашадым.

Килмәсен лә ачтан шешенүләр
Бүгеннән соң үсәр буынга,
Песи борчаклары ашап йөрү
Жимерелгән читән буенда.

...Үткәннәрнен күбе онытылса да,
Төзәлсә дә илем ярадан,
Жуелмаслык эзләр сакланалар...
Юк, килмәсен ул чор янадан!

Камил
Кәримов

# ТУРГАЙЛЫ БОЛЫТЛАР

РОМАН-ЭЛЕГИЯ

— Очрашуга киләсегез барын онытмадыгызмы?

Телефондагы кыз бала тавышы бер кат исәнлек-саулыкны сорашты.

Мөгаллимнәре кушканны төгәл үти торган аспиранттыр инде, аспирант булгач, бик яшьтер, яшь булгач, чибәрдер әле үзе, теләсә кем фән белән мавыкмас. Елмаеп сөйләшүе колакка ук сизелә хәтта.

— Онтасым юк үлгәндә дә... — Җырны ахырынача әйтеп бирүдән чак тыелып калдым. — Менә куен дәфтәремә көне-сәгате язылып куелган: «12 ел, 4 апрель, 14 сәгатьтә. 208 аудитория. Студентлар белән очрашу».

— Студентлар гына түгел, педагоглар да! Профессорлар Тәлгат Нәбиевич, Фоат Галимуллович, Флёра Сәгыйтовна, әле академик Рүзәл Юсупов та керең утырам, диде. Берүк соңга калмагыз, яме!

Аспирант кызның яшьлек галәмәте инде бу, тәҗрибәлерәгә туры килсә, олы шәхесләрнең фәнни дәрәҗәсен санап тормас, исемнәрен дә — Фәлән абый дип кенә әйтеп үтәр иде.

Алай... Җитди имтихан көтә икән мине иртәгә. *«...Хөрмәтле галимнәр, кыйммәтле студентлар, исәнмесез?! Мин бүген аеруча дулкынланам. Буш сүз түгел бу — чынлап та дулкынланам. 1981 елның гыйнварыннан башлап кайда чыгыш ясаганымны теркәп барам.*

*Бүген минем 974нче очрашуым. Кызганыч ки, дүрт ел буе Язучылар оешмасының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы аша оештырылган «Казан язы», «Әдәби җомга» һәм төрле «Әдәби-музыкаль кичәләр»дә катнашуларым, шулай ук Татар дәүләт филармониясенең лекторий бүлегеннән йөзләгән авылда берүземнең генә икешәр сәгатьлек кичәләр үткәреп йөрүләремнең исәбе-хисабы юк. Бер уйласаң, мин инде тамашачы алдында бөтенләй дулкынланмаска тиеш... Дулкынлануымның сәбәбе бик җитди... Моннан кырык биш ел элек мин дә Пединститут студенты булырга хыялланган идем. Әйтегез әле, сездә хәзер конкурс шартлары ничегрәк — бер урынга ничә абитуриент килә? Кызлар өчәү, малайлар бер ярым дисезме? Мин имтихан тапшырган елны татар теле бүлегенә бер урынга үндүрт кеше килгән иде! Шуның өстенә — мәктәпне медальгә бетерүчеләр ярты исемлек, ә алар үзләре яраткан бер фәннән «5»ле алсалар, шундук укырга кергән булып исәпләнәләр иде. Рус теленең язма эшеннән «3»ле алгач, конкурстан төшеп каласымны алдан ук белеп, бүтән имтиханнарда катнашып тормадым инде. Авылга кайтып киттем... Тугыз ел үткәч кенә,*

*Ахыры. Башы узган санда.*

*ниһаять, студент булу бәхетенә ирештем... Казан дәүләт культура институтының көндезге бүлеген тәмамлаганда миңа утыз яшь тулган иде. Хәер, биографиямне сөйләргә дип килмәдем, төрле белешмәләрдә, күп санлы мәкаләләрдә, хәтта энциклопедия битләренә дә язылган инде бу хакта... Бүгенге дулкынлануымның сәбәбен генә әйтергә телим. Кайчандыр укырга керә алмыйча, боегып кайтып киткән пединститут аудиториясендә, бүген студентлар һәм педагоглар каршында чыгыш ясыйм!.. Дулкынлансам да гаеп итмәссез, мин хыялларым тормышка ашканчы тырыштым...*

*Беренче шигырьләремне, хикәяләремне тотып газета-журналларга, Язучылар оешмасының консультация бүлегенә килеп кергәч, мин андагы язучы абыйларга сокланып, игътибар итүләреннән горурланып, эш урыннарыннан көнләшеп кайта торган идем. Кайткач та, исемнәре белән илгә танылган, әсәрләре дәреслекләргә кергән шагыйрьләр белән кул биреп исәнләштем, сөйләшеп тордым, якыннан күрдем дип авылдашлар алдында мактана торган идем...*

*Шулайрак килеп чыкты инде: хезмәт кенәгәмдә иҗади язмышымның үзенә күрә бер сюжеты бар. Соңгы утыз биш ел эчендә мин үземнең беренче әсәрләрем басылган барлык редакцияләрдә эшләп карадым: Балтачның район газетасында; «Яшь ленинчы» редакциясендә; яшьләрнең «Идел» альманахында; Язучылар оешмасының пропаганда бүлегендә; «Чаян» журналында һәм «Казан утлары»нда. Инде күнелем булды...»* — дип көзге каршында үз-үземә дәрес биреп, иртәгесе очрашу өчен репетиция ясап утырам. Кечкенә хикәяләремне кыскартып, канатлы җөмләләремне иләп, шәкертләр бирергә мөмкин булган сорауларга алдан ук җаваплар әзерлим. Очрашуга «Казан утлары»ннан дүрт кеше барабыз. Иҗади бәйге дигән сүз инде бу. Сер бирергә ярамый. Миңа алкышлар күп-күп... бик күп кирәк! Һәм иң мөһиме: тезгенне бушатмаска — Равил Фәйзуллинны бүлдермәскә, Рәдиф Гаташны үртәмәскә, Марат Закирны кимсетмәскә, зарланмаска, гаилә белән мактанмаска, нульдән түбән юмор ычкындырмаска...

Очрашу нәкъ мин уйлаганча үтте. Артык журналларны төяп килгән идек, имзалар куеп өләштек. Яшьләр арасында «Уен» дигән китабымны тотып йөрүчеләр күренгәләде, аларына да автограф бирдем. Киемнәребез калган бүлмәгә алданрак чыга торыйм дип кузгалган идем, юлыма бер кыз аркылы төшеп, кулындагы «Уен»ны миңа сузды.

— Кул куйыйммы, исемең ничек? — дигән булам.

— Кул куймагыз, автограф языгыз, әнием Рәшидә исеменә. Мин үзем сезнең романны журнал вариантында укыдым инде. Ә бу китапны әнием сорады.

Күрмәгән-белмәгән кешегә автограф язулары җиңел дисезме?!. «Рәшидә, Рәшидә...» дип кызның әнисен зурлап нидер уйлап чыгармак булам... фикерем оешмый гына бит.

— Исегезгә төштеме?! Югары Ослан районы... Сез Рәшит Әхмәтҗанов, Мәхмүт Хөсәен, Риф Гатауллин белән очрашуга килгәнсез... Районның Мәдәният бүлегеннән мәктәпне яңа гына бетергән бер кыз сезне каршы алып...

— Рәшидәме?!!

— Ниһаять...

— Син Рәшидә кызы булып чыгасыңмы?!.

— Әйе. Сирень минем исемем. Кызлар Сиринә дип йөртә.

Һушымны җыя алмый торган арада, Рәшидә кызы миңа шундый итеп сынаулы караш ташлап өлгерде ки, хәтта сискәнеп киттем. Кырын каравында, туп-туры төбәлгән күзләре, миннән, һичшиксез, җавап көтә иде. Беләм мин ул сорауны.

Мактанчык уйлар белән иләсләнеп, үземне-үзем гөнаһлы итәр хәлем юк — тимәдем мин ул кичне Рәшидәгә, тимәдем! Шабыр тиргә батып кочаклашып йокладык, яшермим анысын, әмма тимәдем. Әгәр тия калсам, хәзер минем алда унтугыз яшьлек туташ түгел, ә утыз яшьләрдәге ханым басып торган булыр иде...

Автограф язу тагын да катлауланды. Әгәр моннан утыз ел элек икәүләшеп кичкән төнне сагынып язсам, китап, һичшиксез, Рәшидәнең өенә кайтачак, моңарчы тыныч кына яшәп яткан гаиләдә гауга чыгарырдай хыянәт булып яңарачак.

— Ручкаңны бир әле, — дидем мин, бераз уйланырлык вакыт сорагандай.

— Үзегезнеке белән яза күрегез, зинһар! — диде Сирень, сүзендә нык торып.

«Әдәбият сөюче кыз үстерә алган өчен Рәшидә ханымга олуг хөрмәт белән автор...» дип тагын нәрсәдер өстәп куйдым.

Ни ул, ни мин кузгалып китә алмыйча торабыз икән. Инде аудитория бушый язган. Соңгы кешеләргә ияреп чыгуның җайлы ягы бар — тавышны тыймыйча кинәнеп сөйләшәбез.

— Яңа роман язып ятасыз дип ишеттек бүген.

— Соравына күрә генә җавап бирдем.

— Әгәр төгәлләсәгез, каян белим икән?

— Журналда чыкса гына инде.

— Күрмичә калуым да бар. Имтиханнар вакытына туры килсә. Ә сез миңа шалтыратып хәбәр бирерсез, телефон номерымны язып алыгыз, әйтеп торам...

Ул арада коридорда икәнбез инде. Кесәләремә тыгылып, куен дәфтәремне эзләргә тотындым. Житмәсә хезмәттәшләрем көтеп тора, аларны күргәч, бөтенләй каушадым, дөрес анламаслар, минәйтәм.

— Ә, — диде кыз кабаланып, — номерым бар сездә, бүген деканат исеменнән сөйләшүче кеше мин идем ич. Тәлгат Нәбиевичтан белештем дә шалтыраттым...

Очрашу озаккарак сузылды күрәсең, редакция шофёрының чырае төкселәнгән. Журналга эшкә килгәннән бирле, унике ел буе беләм инде мин аны, көтәргә яратмый. Бер уйласаң, аның да эш урыны «Казан утлары» бит инде. Ә ул, иртәме-төшме, безнең машинадан коелганны көч-хәл түзеп көтеп тора да кай тарафкадыр китеп олага. Баш мөхәррирнең: «Иртәгә иртән Аккош күленнән килеп алырсың», — дигән әмеренә дә кузгалып киткәч, яртылаш ачылган ян тәрәзә аша гына җавап кайтарып өлгерә: «Беләм!»

Әйе, ул барысын да үзе белә, тик без генә аның кем икәнен белеп бетермибез, машинасында бик сөйләшмибез.

Лифт көткән арада бераз җиңел суларлык вакыт булып алды.

— Абыйлар, безнең арада бүген бик бәхетле кеше бар! — диде Марат, миңа текәлеп.

— Әйе, дустыбыз автограф язганда дулкынланды хәтта! Мин ул кызны кайдадыр күргәнем бар кебек, яулыкка төрелгән газиз башкайларын кыңгыр салып сөйләшүе бик тә таныш. Исеме ничек әле бахырның? — диде Рәдиф абый, үзе әйткәнгә бигүк ышанмыйча гына.

— Белмим. Сорап өлгермәдем. Ул бит әнисе исеменә язарга кушты.

— Анасын белгәч, шул җиткән инде, — диде Равил абый, сишәмбе көнге Фәйзуллин укуларында гына кузгала торган тамак төбе тембры белән.

— Марсель Галиев намазга баскан дисәләр ышанырмын, әмма дә ләкин «Казан утлары» дигән мәктәпнең 147нче сыйныфында унике ел буе бергә

утырган партадашымның чибәр кыз күргәч исемен сорамый калуына ышаныр хәлем юк! — Марат хәзер безгә ияреп сәхнәгә еш чыга, шуна күрәдер, соңгы елларда теле тармаклана башлады.

— Әнисе Рәшидәне бик яхшы хәтерлим. Ә кызын беренче тапкыр күрәм.

— Син, стипендияләрдән алимент түләгән кеше буларак, юридик яктан җавапны бик дөрес тотасың, энекәш! — диде Равил абый, үги ана яфрагыдай салкын кулы белән аркамнан сөйгән булып.

— Минеке түгел ул! Әнисен күрмәгәнгә утыз еллап бар бит инде. Ә кызына әле унтугыз гына. Өченче курста укый, — дип ашыга-кабалана акланырга керештем.

— Табигатьтә төрледән-төрле катаклизмнар, феноменаль күренешләр очрап тора, хөләпәләр. Белмим, күрмәдем, минеке түгел дип кырт кисеп әйтмәгез. Әйе...

Лифт унынчы катка менеп җиткәнче көлештеләр.

Тик мине сагыш басты... Сагыну сагышы...

Күнел түрендә тәрәзәсез-нисез бер караңгы бүлмә хасил булган. Һич көтмәгәндә-уйламаганда унтугыз яшьлек кыз минем җилкә аша үрелеп кенә шул бүлмәдә капылт ут кабызды. Инде яп-якты куышта шау чәчәкле келәм җәелгән идәндә кырын ятып, Рәшидә минем китапны укый... Бүлмә дигәнем кинәт Идел ярына әверелде. Җир шары яралганнан бирле кояш баешын үзенә көтеп алган Ослан тавында кинәт Рәшидәле таң атты. Утыз ел буе эңгер-меңгердә оеп яткан хатирәләр көн яктысына чыкты.

Йа, Хода! Йөз дә кырык җиденче бүлмәнең стена чаклы тәрәзәсе Югары Ослан ягына карап тора ласа! Унынчы каттан баксаң, бөтен җиһан уч төбендә. Мин бит уникe ел буена һәр эш көне саен шушы тәрәзәдән кояш баешын күзәткән кеше. Ник моңарчы күнел күзем Ослан тавына барып җитмәгән дә Рәшидәне эзләп тапмаган?!.

***

Өйдәгеләр мине шикләнебрәк каршылады.

— Әтиегезнең иммунитеты какшады, — диде Нуриәхмәт кызы. — Күрегез, студент кызлар яныннан тәмам авыруга сабышып кайтып керде. Элгәре болай ук бирешми торган иде...

— Су сипсәң, шайтан таягы да чәчәк ата, — дигән булам.

— Бал корты көне буе күпме чәчәккә куна, тик эшен онытмый дип әйтә идең элгәре.

Минем белән утыз ел яшәп, тәки шагыйранә әйткәләшергә өйрәнеп бетте. Элгәре син үзең дә студент идең шул, дип аклануга күчсәм гаилә учагына чүмечләп керосин сипкән ише булыр — янгын чыкмагае.

Чыраемдагы әзер елмаюны югалтмаска тырышып кына кухняда чәй кайнаганны карап утырам. Кунак көтә торган телевизорда тигезсез мәхәббәт турында сериал бара. Хатыны юл һәлакәтендә үлгән олигархның буй җиткән кызы бар. Эш эзләп килгән бер авыл кызы боларга гувернантка булып урнаша. Әлбәттә, сериалның ахырында кавышачак инде болар... Экранда төсләр камаша, вакыт алышына, артистлар үзгәрә... һәм олигарх самосвал йөртүчегә, гувернантка Рәшидәгә әверелә. Ә аның кызы экраннан үрелеп миннән автограф сорый. Әле дә ярый шулчак чәйнек борынындагы гармун теле кычкырып мине гаилә хәлемә кайтара...

Мин эшкә җәяү йөрергә яратам. Нибарысы ярты сәгатьлек юл. Шушы ярты сәгать эчендә кесә телефонына өч хәбәр килде:

«Әни төне буе сезнең китапны укып чыкты».

«Әти берни сизенми әле».

«Көндез әнигә шалтыратып алыгыз».

Кәефем күтәрелде. Бер китабым өчен жаным тыныч — үз укучысын эзләп тапты! Өч мең данә тираж белән басылып чыккан иде, әле аңа укучыларны эзлисе дә эзлисе...

«Рәшидә!!!»

«Исемемне ару өзгәләнеп әйткән буласың. Кызым автограф сорап дәшмәсә, минем дөньяда барлыгымны белмәс идең дә әле, дамы?»

«Искә төшкән саен эзләп чыксам, азагы ни белән бетәр? Ирең бар, кызың. Рәшидә, синең кыз мине... икебезне... каян белә?»

«Кыз бала әнисенә сердәш бит ул. Әни, беренче мәхәббәтең турында сөйлә әле, дип мазаласа, гел сине телгә ала идем».

«Рәшидә, без бит бер генә төн көрешеп калдык».

«Аның каравы төне мач килде!»

«Хәтерлисеңме шуны? Утыз елга бер төн...»

«Үткән гомерне искә төшергәндә юмарт инде без — елларны дистәләп кенә саныйбыз, дамы?!»

«Кайтарасы иде шул төнне!»

«Күрешик соң. Мин каршы түгел».

«Гаиләңә ишетелсә?»

«Мужигым алдында үзем җавап тотармын... Ә син аны беләсең. Теге төндә самосвалы белән Осланны ду китереп безне эзләп йөргән шофёр!.. Ул синнән кыюрак булып чыкты. Куып йөри торгач, тәки мине үзенеке итте».

«Ризалаштыңмы?!»

«Аларын күрешкәч сөйләшербез, дамы?»

«Рәшидә, сез Осланда үз өегез белән яши идегез».

«Яр буеннан эзләсәң — табарсың. Кесә телефоныңны сүндермә. Навигаторың булырмын».

***

— Иртәгә китәм мин!..

— Ә ник бүген үк түгел?!.

Алай артык кычкырып әйтмәгән идем шикелле. Идәндәге келәмне чистарткан жиреннән ничек ишетеп өлгергәндер?! Күңеле китек чакта аның күзләре дә ишетә.

Нуриәхмәт кызы кисәк кенә тузан суырткычны сүндерде — төймәсенә басып түгел, уттан өзде. Фатир эченә тәпәннән яңа бал акканы да ишетелерлек бөркү тынлык урнашты. Нинди сәер тынлык, гомердә булмаганны: ишегалдына кереп оялаган дистәләрчә машина кабынмыйча кемнедер көтеп тора; кырык дүртенче фатирдагы күршеләрнең диварын атна буе дөмбәсләгән шахтёр чүкеше туктап калды; илленчедәгеләрнең «Бимка»лары өрмичә түзә; илле икедәге кунак оныкзал буйлап урындык этеп туйган; кырык биштәгеләр дә ызгышмый хәтта... Ун катлы йорт халкы, үзара сүз куешкандай тынып, Нуриәхмәт кызының җавабын көтә бугай.

— Бар инде, бар! Гомер буе китәм дип хыялландың! Яшьрәкләрне тапкансыңдыр. Әйтәм аны... Чаллыдан кайтканнан бирле җаныңны кая яшерергә белмичә йөрисең.

— Югары Осланга җибәрделәр, язылу эшләре белән. Бер атнага.

— Бер атнага?! Булмаганны! Ник алай озакка?

— Анда тираж бөтенләй кимегән.

— Тагын кемнәр бара?

— Үзем генә... Алдан ук җитәкчеләр белән сөйләшеп, очрашулар оештырып куйдым.

— Синең эшең түгел ич ул. Пропаганда бүлегең кая?

— Алар башка районга чыга.

— Һм... Балтач—Ослан... Сина кала инде... Алдан ук сөйләшеп куясың икән, очрашулар оештырырга.

Һәм Нуриәхмәт кызы янә тузан суыткычны җибәреп, минем моннан егерме ел элек «Чаян»да эшләгән чакта талонга алган Монголия келәменә ябырылды. Тырмалый — тетмәсен тетә!.. Шуны гына көткәндәй, ишегалдына чүп-чар төяп китә торган «КамАЗ» килеп керде, аннан өркеп, чебен тимәс чер итәрдәй чит ил машиналарының сигнализацияләре дәррәү кутәрелде. Аларга шахтадан күмер чыгару, бала елату, бәкедә кер чайкау, лифт ишегең акылга утырту өше көндәлек эшләр килеп кушылды.

Нуриәхмәт кызы ышанмады.

Безнең өйдә исемнәре телгә алынмаска тиешле районнар, калалар-салалар, илләр-җирләр бар. Магаданны телгә алсам, Нуриәхмәт кызының кан басымы күтәрелә; Ростов, Оренбург, Астрахань, Башкортстан дип сөйләп китсәм, шундук ике колагын томалап күрше бүлмәгә чыгып китә; Балтач, Чүпрәле, Баулы, Югары Ослан дисәм, мәктәп еллары белән тулган альбомыннан фотолар актарырга тотына; Актанышны, Әгерҗене искә төшерсәм, Нуриәхмәт кызы кухняга чыгып, без кавышканчы ук ашыгыбрак язган хатларымны кычкырып укырга керешә, ул аларны миннән яшереп саклый, психологик корал итеп куллана; әгәр Аксубай районын мактап куйсам, аны бизгәк тота башлый... Географик атамаларны көн саен санап һава торышын адресларга бүлгән синоптикларны җене сөйми аның. Хатын-кыз исемнәре тирәсендә хәл тагын да катлаулырак... Кызыбызны роддомнан алып кайткач, ике атна буе исем куша алмадык, гаиләдә гражданнар сугышы чыга язды. Ахыр чиктә, «Алсу» дип, чамадан тыш киң таралган исем бирергә туры килде.

Язылган романнарым, повесть-хикәяләремнең санын исәпкә алсак — алга таба персонажларны прототипларыннан яшереп бетерер өчен Гомәр Саттаровның исемнәр китабы бик кысан хәзер...

Ошбу әсәремдә, вакыйгаларның чынбарлыгына хилафлык китермичә, исемнәр вә атамаларны үзгәртмәскә тырышып, мәгәр урыннарын саташтырып кына сурәтләрмен. Беренчедән, Нуриәхмәт кызының кәефен кырмас өчен булса, икенчедән, мине бәхетле итәргә тырышкан, янадан-яна әсәрләр язарга рухландырган сөеклеләрем алдында хөрмәтемне сакларга телим.

Югары Ослан димәктән...

Казанга якын авылларга иҗади сәфәргә чыгуның әллә ни романтикасы юк, көнендә үк юлга җыенасың, бер, күп дигәндә ике урында ашык-пошык очрашу үткәрәсең дә кире кайту хәстәре белән кабаланасың. Кунып китегез дип үгетләүче җитәкчеләр еш очрый торган иде, чын күңелдән хәтта! Сиксәненче елларда ук инде умарта аланында, карурман уртасында, җәйләү атавында обком түрәләрен юындырып җибәрә торган сыйлы мунчалар колхоз саен иде, барыбызга да җитә. Тик, «Оргсинтез» заводының моржасыннан җилфердәгән факел яктысында кунып калган язучыларның күбесе хатын алыштырды.

Ослан ягының матурлыгы — аның якынлыгында!

Тапталмаган, таушалмаган, урланмаган, нефть һәм газ торбалары күрергә мәхрүм булган садә манзара! Ослан ягы — таулы як. Андагы тауларның җаны бар, табигатенең кочагы бар!

Текә ярга дулкын чарлап аккан чал Идел, Ослан итәгенә килеп сыенгач, күзгә күренеп яшәреп ала. Казан каласының Осланлы офыгы бар...

«ОМ»иктан төшкәч, пристаньдагы халыкны күздән кичереп, язучылар төркемен каршы алырдай кеше күрмәдек, гадәттә, ул райкомның Өченче

секретаре йә пропаганда бүлеге мөдире, һич югы берәр инструкторы табыла иде. Үзләренә киләсе кунакларның исемлеген алдан ук белгәнгә күрә, алар китапларыбызны актарып, фотоларыбызны ятлап, титулларыбызны әз-мәз чамалыйлар да. Юк, андыйлар күренми, әрсезләнеп райком бинасын үзебезгә эзләргә туры килер, дип торганда, әллә кайдан гына бер кыз пәйда булды.

— Сез Казаннан килгән писательләр бит, дамы? — Кыз, үзе болай бик яшь күренсә дә, үсеп буйга житкән, тик тавышы гына үсмәгән, балалыкта калган шикелле, әмма һәр сүзе көйгә салынган кебек җырланып чыга.

Мин сабырлыгы төкәнгән язучылар белән таныштырырга ашыктым.

— Бу абыегыз — сугыш ветераны, отставкадагы майор-артиллерист, шагыйрь...

— Мәхмүт ага Хөсәен, дамы?

— Әйе, унике китап һәм ике йөздән артык җыр авторы Мәхмүт Хөсәен мин! — диде түгәрәк шагыйрь һәм күрешкәндә кызның кулын үбеп тә өлгерде. Алга таба кызый танышуны үз кулына алды.

— Сез, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов буласыз, дамы?

— Әйе, чибәрем, нәкъ өстемә бастың!.. Китабым әлегә җидәү генә. Ир башына кыз җитәр, шигърият башына җыр җитәр дигәндәй, җырларым да чутсыз түгел. Затлы нәрсә күп булмый ул. — Рәшит абый да үпмәкче булып кызның кулын озак ычкындырмыйча торды, тик үпмәде, чөнки ул беренче түгел иде инде. Шушындый нәфислеккә авыз тидерде, кабахәт, иртән елкы ите белән кабыклы бәрәңге ашагандыр әле үзе.

Мәхмүт абый елмаеп тик торды, үпкәләмәде, чөнки ул колакка каты иде.

— Ә Риф абый Гатауллин безнең якташыбыз. Җырларын бик яратабыз. Беренче очрашу бүген аның туган авылы Яңа Болгарда уза. Әнисе бәлеш пешереп сезнең барыгызны да көтеп тора. Иртәгә Кызыл Байракка китәсез, өченчесе — соңгысы — район үзәгендә саубуллашу кичәсе. Беренче секретарь да сезне шул көнне кабул итәчәк, чәйләп озатачак... Кайсыгыз бригадир сезнең?

— Мин! Танышмадык ич әле...

— Гафу итегез! — дип минем белән ялт кына күрешеп алды. Рәхәтләнеп кулын да тота алмадым. Каушадымы — исемен дә әйтеп өлгермәде. — Юл кәгазьләрегезне, договор, путёвкаларыгызны хәзер үк биреп куегыз. Кичке очрашуга килгәндә кул куйдырган, пичәтләре сугылган булыр. Дамы? Әйдәгез, биеккә меник, сезгә дигән «Кубань» автобусы пристаньга төшә алмый, ул тауны бик авыр менә. Тигез юлда хутлы йөри. Авыллар арасы ерак түгел. Кайсыгызга ярдәм итим? — дип ул Мәхмүт абый кулындагы йөкне алмакчы иде — өлгермәде, ике йозаклы, буаз кәҗә чаклы юан кара сумка минем кулга күчте:

— Мә, бригадир, оештыруың ташка үлчим, шулай булгач, үзең күтәр инде моны, — диде дә Мәхмүт абый, үзе, ике кулын яшь киленнәрчә селтәп, кыз артыннан ашыкты. Үзе шигырь сөйли:

И, кешелек, күр менә —
Татар шагыйрьләре үр менә!

Бер кулымда үземнең дипломат, икенчесендә Мәхмүт абыйның кургаш сумкасы.

Иделебезнең текә яры, бистә тигезлегенә менеп җиткәнче, шактый мышнатты. Бригадир башым белән олы шагыйрьләрдән алгарак чыга алмасам, кызның ихтирамын казанырмын димә.

— Сезне кем дип белик? — дидем мин, сулышыма ут капканын сиздермәскә тырышып.

— Рәхимә түгелме? — дип катышты Мәхмүт агай.

— Рәхимәләрдән туя белмәден инде. Сина ул хәтлек Рәхимәләрне каян төткәрмәк кирәк? — дип аркылы төште Рәшит Әхмәтҗанов.

— Рәшидә мин, — диде кыз, сорау бирүчеләргә борыла төшеп. Районның Культура бүлегеннән. Мәктәпне быел гына бетердем. Берәр ел эшли алсам, Культура институтына конкурссыз гына керергә направление бирәбез, диделәр.

— Культура институтына?! — Бик күптәннән сагынып йөргән сабакташымны очраткандай, сөенечемнән тавышым катырак чыкты ахрысы. — Мин ул институтны әле узган ел гына тәмамладым, режиссура бүлеген.

Рәшидә атлыйсы жирендә катып калды. Болай кинәт итеп үр менгәндә генә туктап буладыр... Ул урынынннан кузгалмыйча гына мина таба ыргылгандай итте.

— Чынлап?! Дамы! Ә үзегез язучы булып эшлисез...

— Сәхнә — әдәбият бишеге инде ул, анда укысаң, үзең дә яза башларсың әле.

Рәшиданең күз карашына күз тимәсен... Бу минутта минем аны гел сөйләштерәсем, игътибарын үземә генә җәлеп итәсем килде.

— «Да-мы», дип сөйләшәсең, әллә син мишәр кызымы?

— Әти-әнием Дрожжанойдан, Түбән Чәке авылыннан күчеп килгәннәр. Югары Осланда авыл өе сатып алганнар. Район үзәгендә үз өебез белән яшәп ятабыз.

— Күчеп килгәннәрме, әллә шикәр чөгендере игүдән качып киткәннәрме? — дидем мин, Рәшиданең елмаясын алдан ук белеп.

— Житәкче кызыбызга бәйләнмә, иптәш, — дип Мәхмүт Хөсәен кызны култыклап алды. — Житәкче булып үссен өчен, аны зур абзыйлар житәкләп йөрергә тиеш!

— Әйе! Бригадир булдым дигәч тә, син безнең турыда кайгыртырга тиеш! — дип Рәшит Әхмәтҗанов та кызның беләгенә үрелде. — Мин — Рәшит, син — Рәшидә! Шәп янгырый.

Идел кичкәннән бирле сүзсез барган Риф Гатауллин түзмәде:

— Абзыйлар! Әнә, райком тәрәзәсе күренеп тора, жибәрегез Рәшидане, бигүк яхшы түгел бит.

Композиторның кинаясен күбрәк үз исемемә кабул иттем, юкса, Рәшидане күргәч, Югары Ослан бистәсенә ник килгәнемне дә оныта яздым инде.

Ул безне «Кубань» автобусына утыртты да, кичке очрашуга чаклы саубуллашып, административ бинага таба ашыкты.

Кузгалып китүгә үк мин тизрәк кич житкәнне көтә башладым.

Без «Кунак өе»ндә хәл алган арада, Югары Осланның жиләкле тауларын яшенле янгыр коендырып китте. Болытларның кара-күчкылланып төрелгән өемендә яшен чаткылары аеруча хәтәр чатный. Шунысы сәер: хәвеф Иделнең икенче ягына чыкмый, гел шушы якта гына йөри, Казан ярында чалт аяз...

Күк күкрәве ераклаша башлагач, Рәшит абый куркуын җиңеп, тәрәз пәрдәсен кәгазь калынлык кына ачты да кәефен бозды.

— Мондый быкырдыкта безнең «Кубань» гараждан да чыга алмас. Көнебез әрәм булды, — диде дә пружиналы караватка гөрселдәп ауды.

***

Китап сөючеләр белән очрашу Риф Гатауллинның туган авылы — Яңа Болгардан башланып китте. Кич житкәнче үк Рәшидә без урнашкан кунак өе янына «УАЗ»ик белән килеп туктады. Халык клубка бик соң жыелса да, ашыгырга кирәк, диделәр, көчле янгырдан соң егерме чакрымлап ябышкак

юл көтә икән, әле алданрак килеп, «Волга» колхозының председателе белән күрешеп, юл кәгазьләренә мөһер суктырасым бар.

Югары Осланнан кузгалганчы ук мәрәкә купты, безне озата йөрүче Рәшидә шофёр белән янәшә утырган иде, димәк, машинаның өч кешелек арткы кәнәфиенә дүрт мужик сыярга тиеш икәнбез.

Мәхмүт Хөсәен аклана ук башлады:

— Минем аяк контуженый, үзегез беләсез, снаряд өстемә төшеп, күмелеп калган кеше. Казып чыгаргач, аягымны кисәселәр иде... Кистермәдем. Унтугыз яшьлек егет ул чагында, пнимаешь...

— Беләбез инде, беләбез, кырыкмаса-кырык тапкыр ишеттек бу әкиятеңне, — дип кәефсез йөзен Казан ягына борды Рәшит Әхмәтҗанов.

— Белсәгез инде, алдыма кеше утырта алмыйм.

— Минем дә... блондин малаемның тездән төшкәненә бишбылтыр инде.

Мәхмүт абый урын бүлүне шул арада үз өстенә алды. — Алайса, Рәшит, әнә Кәримовның алдына утырырсың.

Мин Рәшит абыйның яшене сукканчы, тизрәк җавап бирергә ашыктым.

— Ирләр кочаклап баручылары без түгел...

— Риф Гатауллинны кешечә алып барырга кирәк, ни дисәң дә, аның туган авылына җыенабыз. Берәвебез артык. Казанга «ОМ»ик җөреп тора.

— Вәт, вәт, Мәхмүт абый, син кал. Берүзең ике кешелек урын алып торасың.

— Мин калсам, чыгышыгыз «фшыйк»... Синең шигыреңне авыл халкы вообще тыңламый. Кәримов юморы белән генә ерак бара алмассыз!..

— Агайлар, минем договорларга кул куйдырасым бар. Кайтып китсәм, шефлык күрсәтеп йөриячәксез.

— Ишетергә дә теләмим. Мин бераз акча эшләргә дип чыктым. Блондин малаема туфли аласы бар...

Сөйләшү шушы урында тупикка килеп терәлде.

Әлбәттә, Язучылар союзының пропаганда бүлегендә эшләп, мондый гына әйткәләшүләрне ишеткән бар анысы. Дәвамлы бәхәс түгел ул, ничек кабынып китсә — шулай тиз сүнә дә онытыла. Безнең арада, утызга җитеп, дошманына да тавыш күтәрмәгән егет бар бит әле.

Риф Гатауллин, үзенең баритон тавышын сабыр көйгә салып кына, Рәшидәгә нәрсәдер аңлатты да Мәхмүт Хөсәенне алгы рәткә утыртты... Инде «Кәҗә, бүре һәм кәбестә» әкиятендәгечә килеп чыкты: Рәшидәне кем алдына утыртырга?.. Шобага саласы юк. Бу урын алыш уенының азагы ни белән бетәсен төшенгәнсездер инде: Рифне туган ягында бөтен кеше таный, аңа яхшы түгел; Рәшит абый рәхмәт әйткәндә дә үтенне сыта торган карашы белән кызны өркетеп өлгерде.

Болытлар артыннан киттек. «УАЗ»ик өчен авыл җирендә юл өзеге дигән борчу бөтенләй юк ахрысы, буксовать итми, салуламый, бары тик тизлекне генә арттырып йә киметеп, йомшарган юлның көенә ятарга тырыша.

Рәшидә, алдыма кырын утырган килеш, бер кулы белән арткы утыргыч бөгәлҗәсенә, икенчесе белән шофёр ягына таянып, үзенчә гәүдәсен күтәребрәк бара иде, көчәнүе озакка җитмәде. Кулы арды булса кирәк, бераздан ул бөтен авырлыгы белән миңа калды.

Бөтенләй чит кеше белән трамвайда янәшә туры килсәң дә, өч-дүрт тукталыш арасында аңа ияләшә башлыйсың — танышу, эш урынын йә телефонын сорау да берни тормый. Самолётларда янындагы юлдаш күршең кунакка йөрешерлек гаилә дустына, тумачаңа әйләнә ала. Ә син утырган поезд, мәсәлән, соңгы станциягә барып җиткәнче, купедагы чибәркәй төн эчендә

синең хатыныңны алыштырып торырга мөмкин. Әлбәттә, ятларны ягымлы сүз якынайта — монысы бәхәссез! Ләкин без шул тиклем тыгыз утырганбыз ки — Рәшидәгә ни генә пышылдасам да, ул юлдашларымның колак төбендә булачак. Сораштырып, өметләнгән җавапларны көтеп уфылдавым, яшьлегенә сокланудан; чыгарылыш кичәсендә киелгән күлмәгенең сихерләвеннән һәм миңа әлегәчә таныш булмаган ислемай исенә исерүдән туган ымлыкларым ижади дусларым арасында хөсетле үртәү генә тудырачак. Юл сикәлтәләренә җайлашкан машинаның тигез тибрәтүе Рәшидәнен сылу гәүдәсен, һаман саен ныграк якынайтып, куеныма отыры җайлаштыра барды. Йа, Ходай, сабырлык бир...

Минем сулышым ешайды бугай, моны Рәшит абый шундук сизеп алды:

— Кыен түгелме, бәгърем?

— Юк, — диярга ашыкты Рәшидә.

— Синнән сорамыйм, сеңлем, урының бик җайлыдыр. Утыргычыңа әйтәм: бик кыен түгелме, Кәримов?!

— Кыен да, рәхәт тә! — Кызны үпкәләтмәс өчен, сүзне уенга борып маташтым. — Сауна ләүкәсендә утырган кебек.

— Шулайдыр шул. Бик тирләмә инде яме, болай да яңгырдан соң бөркү... — Һәм Рәшит абый, елмаю мускулларын сикертеп, үз юморына теләктәшлек эзләгәндәй, Риф Гатауллинга карап алды.

Ләкин туган авылына, бөтен нужасы белән ялгыз әнисе кулына калган нигезенә мәртәбәле кунаклар — әйтергә кирәк, күренекле шагыйрьләр ияртеп кайту Рифнең күңел тынычлыгын бераз чемердәтеп бара иде.

Яңа Болгар зур авыл түгел, аларның колхоз үзәге Матюшинода булып чыкты. Идарә йортына кереп киткән җиреннән Рәшидәне югалттык, ни үзе чыкмый, ни председатель янына безне чакыручы юк. Ялыгудан бигрәк, кысылып утыргач, аяклар оеган иде. Әкренләп җиргә коелдык.

Яңгыр болытларын озата баручы җилләр дулап алганмы — кин урамнар бераз сурыккан... Чирәмнән чирәмгә кучә-кучә мәктәп яшендәге ике малай кибеттән кайтып килә иде, кулларында бөкесе ачылган лимонад. Мәхмүт Хөсәен аларны күргәч никтер бик сөенде.

— Егетләр! — диде ул, сәхнә уртасына чыккандай горур басып. — Сезнең авылның Рәхимәсе бармы?

Һәм шагыйрь муенына тагылырга тиешле бантигын «төзәтеп» алды.

Малайларның «юк!» диярга теләп иңбашы сикертүен өнәмәде шагыйрь.

— Рәхимәсез авыл булмый. Сез аны бүген кичкә концертка чакырыгыз. Мин аңа багышлап поэма иҗат иттем! Үзегез дә килегез, мин сезнең өчен махсус язылган «Чебиләр»не укырмын.

Малайлар «чеби» яшеннән узган иде шул инде. Тере шагыйрь белән сөйләшкәч, кәефләре күтәрелде.

— Э-э-э... Ни бит, бер Рәхимәне беләбез. Әйдәгез безнең арттан.

Тәки ияреп китте Мәхмүт абый, аяк киеме пычраныр дип тә уйламый. Хәер, сәхнәгә чыгар өчен ул җәен-кышын үзе белән гел концерт туфлие йөртә.

Рәшидә идарә йортыннан җүнле хәбәр белән чыкмады. Күрше Кызыл Байрак авылына яшен төшкән, өч йорт пожарникларның күз алдында янып кара күмергә әйләнгән. Житәкчелек шул тирәдә ди.

Хәвефле хәбәрдән соң бер минутка гына тынлык урнашып алды. Тынлыкны Риф бүлдерде.

— Үлем-китем юктыр ич?!.

— Юк-юк! — дип юатырга ашыкты Рәшидә. — «Скорый» чакырырлык та сәбәп юк, диделәр. Көндез авыл халкы уяу була бит ул.

— Очрашуны башка көнгә күчерерләр микән?

— Син нәрсә инде, Риф, траурлык сәбәп юк, диделәр ич сиңа. Без, шагыйрьләр, мәхәббәт җырчысы гына түгел, хәсрәтленең күнелен юатучы да! Бел шуны! Шагыйрьләр пулялар яңгыры, артиллерия уты астында сугышчыларга шигырь укып йөргән.

— Дөрес әйтәсез, Рәшит абый!

— Аңлавына рәхмәт, Рәшидә сеңлем...

— Сугыш дигәннән, фронтовик шагыйрегез кая?

— Рәхимәле өйгә китте...

Мәхмүт абыйның гәүдәсе саллы, баскан җирендә чокырчык кала, эзеннән барып таптык. Авыл уртасында агач өйләрне кысрыклап утырган таш пулат янында иде. Янында гына түгел, ә рәшәткә эчендәге бакчага ук барып кергән. Хуҗабикә, төшке ялга кайтканмы, урталай бөкләнеп суган түтәленнән чүп утый. Мәхмүт Хөсәен ана кызыгып карый, «Рәхимә» поэмасын укый. Җайсыз позада калуы сәбәпле, хуҗабикә гәүдәсен яшерергә тырыша, тик дустыбыз ярамаган ягыннан килеп һаман саен аңа якыная төшә. Оятсызлыкта гаепләргә ашыкмыйм, сугышчан «Кызыл Байрак» һәм «Кызыл Йолдыз» орденнары кавалеры, батарея командиры Мәхмүт Хөсәен 1944 елның декабреннән бирле колакка каты, шуңа күрә башкаларны да ишетеп бетермидер дип уйлыйм. Аның поэмасын үз авызыннан күп тыңладык. Ә монда, суган түтәлен сәхнә итеп, тыңлаучы белән сөйләүченең бергә-бер калуы үзе үк мавыктыргыч тамаша иде.

Рәшидә, кечәге мәктәп баласы, пропагандист эшендә күп дисәң бер айлап стажы бардыр, авыл житәкчеләренең кайда, нинди өйдә һәм кем белән яшәвен белеп бетерми икән. Аның каравы, шофёр егет ул яктан бик тәҗрибәле булып чыкты.

— Колхоз председателе хатыны Рәхимә апа бу, — диде ул, кырт кисеп. Әллә кисәтергә теләде, әллә ашыгырга кушуы иде, аңламассың.

— Кит инде, кит, ялгыз яшим дигәч тә, һәр итәккә бәйләнеп, безнең авторитетны төшереп йөрмәсә...

Рәшит абыйның бу сүзе миңа хөкем карары булып ишетелде, җилкапкадан кердем дә, «учительская» бүлмәсенә чакыртылган бала ише, жиненнән жилтерәтеп алып чыктым. Ул машина янына килеп баскач та поэмасын укып бетермәгән иде әле. Рәшит Әхмәтҗановның теләсә кайсыбызны көлүеннән шып туктата ала торган фантомас карашын күргәч кенә үпкәләп телсез калды.

Мәхмүт абый «Рәхимә» поэмасын тулаем яттан белә. Авылларга килеп төшкәч, Рәхимәләрне эзләттерә, тапсалар, аны алгы рәткә утыртып, гел күзенә карап кына сөйли. Беренче тапкыр тыңлаган кеше өчен үзенә күрә бер спектакль кебек килеп чыга. Алексеевски бистәсендә өч Рәхимә килгән иде. Мәхмүт абый каушамады, мәктәп яшендәгеләрен сәхнәгә чыгарып утыртты да багалмадай Рәхимәне прототип итеп залда калдырды.

Яңа Болгар авылында «Рәхимә» поэмасы укылмады. Председатель хатыны Рәхимә килмәгәнгә түгел, сәбәбе башкача иде. Авылына күрә клуб бик кечкенә булып чыкты. Соңрак килгәннәргә урын калмас дип, тамашага сусаган халык бик иртә җыелган, сиксән кешелек зал бик тиз тулган. Без килеп төшкәндә инде ишек төбендәге чират үзе бер җыенлык иде. Риф Гатауллинның урынсыз калган якташлары мәсьәләне бик тиз хәл итте: тавыш көчәйткечләрне чыгарырга, әдәби-музыкаль кичәне урамда, ягъни клуб ишеге төбендә генә үткәрергә!

Җылы яңгырдан соң черкиләр котырган. Бер кулын микрофон тотса, икенчесе сәрви куагы белән кыйнап тора. Шигырь китабын җилпеп сөйләүче Рәшит Әхмәтҗановка сәрви куаклы пионеркалар булышты. Иң аянычы

— Мәхмүт Хөсәен үзенең чыгышын кыскартырга булды, «Рәхимә» поэмасы бүген программадан төшеп калды. Черкиләр жинде, бер сәгатьтә очрашу төгәлләнде дә.

Председатель чәй мәҗлесен Риф Гатауллиннар өендә әзерләткән иде. Ләкин ашау-эчүнең көе китте, тост әйтәбез дип нинди генә матур фикер башласак та, азагы кишер кыргандай итеп шатыр-шотыр кашыну белән бетте.

Ослан аша китүче соңгы «ОМ»икка житешерлек вакыт бар иде әле. Без, алдан сүз куешкандай, уртак фикергә килеп, шоферны ашыктырдык: Казанга кайтып юынып-тәзәнеп, ин мөһиме: черки дарулары төяп киләбез янәсе...

Рәшидә тагын язмышына буйсынып алдыма утырды. Мин анын муен тирәсендәге ислемаен иснәп бетергән идем инде. Бу юлысы, мыегымны кытыклап барган купшы чәченнән тәүге тапкыр чирәмгә аяк баскан каз бәпкәсе исе килә кебек иде. Мин моны иске өебезнен сәке астында ояда утырган ала казыбызга ел саен жиде-сигез бәпкә үстерергә булышкан малай буларак әйтә алам...

Пристаньга бик тиз илтеп куйдылар. Шофёр егет гафу үтенде дә китеп барды, Казан кунакларын бүген үк зурдан кубып озатып кую анын көнлек бурычына кермәгән иде, билгеле... Идел өстендә, жылы, тигез, әмма көчле жил ярга дулкын ишә. Жил шундый тыгыз иде ки, Риф Гатауллин, дирижёрлык хәрәкәтләре ясап, ул жилне хәтта тотып-тотып ала иде. Мөгаен, ул шушы минутларда Фәннур Сафиннын «Ялгыз көймә» шигырен күнеленнән генә көйгә салып азаплангандыр...

— Ник син әниен янында гына калмадын? — дидем мин, композиторнын рухи халәтен ачарга теләп.

— Осланга авылыбыздан килеп житкәнче, Казанга барып кайтуы жинелрәк. Әнием үпкәләми, бик еш күрешәбез.

Ул арада, дулкыннардан шап-шап сөелеп, сүрән утлы «ОМ»ик күренде.

— Берүк иртәгә соңара күрмәгез инде, — диде Рәшидә, — мин хушлашмый торам, сезнең әле тагын ике көнлек эшегез калды.

— Борчылма, Рәшидә, — дидем мин, бөтенебез өчен жавап биреп, — райком белән килешенгән чараны үтәми калганыбыз юк.

— Гафу итегез, — диде ул, мине ут яктысынарак борып, — күлмәк якагызда минем чәч. — Инде ярым пышылдауга күчеп өстәп куйды: — Өйдәгеләрегез күрсә, әллә ни уйлар.

Һәм Рәшидә, жиләк жыя торган бармаклары белән сак кына үрелеп, үзе генә күргән чәчне жилгә очырды.

— Ә мин бүген Ослан тавында калыр идем.

Рәшидә жавап бирмәде.

— Минем авылда сөйгән кызым бар иде. Өйләре тау башында иде... Мин килгәч йөгереп төшә торган иде...

Йа, Хода! Ни-нәрсәгә дип сөйлим инде боларны?

— Таулар күп инде ул. Бөтенесенә дә менә алмассыз.

Рәшидә әлеге сүзләрне житди итеп, ышанып әйтте. Кеше күнелен күрер өчен генә үз эшендә ясалма елмаюга, дежур мөлаемлыкка, монафикълыкка өйрәнеп өлгермәгән садә бала иде әле ул.

— Әйт, Рәшидә, калыйммы?

— Үзегезгә карагыз...

«Әйе» дә түгел, «юк» та түгел — менә шундый билгесез жавап.

Түгәрәкләнеп килгән тәүлекнен соңгы рейсы шул. Гадәттәгечә, причалда ашыгу-кабалану сизелә. Билет сатучы ханым, бүтән пассажирлар юклыктан файдаланып, әллә кайчан ук кассаны бикләп китеп барды. «ОМ»икнын килеп

тәрәлгәнен дә көтмичә, аркан ыргытып ярга бәйләү хәстәренә керештеләр. Әле безнең төркем кереп урнашмаган да килеш басманы күтәрергә дип ябыштылар. Соңгы кеше мин идем: калам-калмыйм, калам-калмыйм, дип икеле-микеле атлаганда, гәүдәм чайкалып куйды. Юк, егылмадым, шул уңайдан Рәшидәгә таба борылып карадым. Япа-ялгызы басып калган. Яр читендә аны текә таулы дөм караңгылык көтеп тора.

— Үзең генә ничек кайтасың хәзер?! — дип әйтүем булды, ярдан аерылган басмадан сикерүем булды. Шуны гына көткәнме, «ОМ»ик, балластан котылган һава шары кебек җиңеләеп, тизрәк кузгалу ягын карады. Арканны көчкә ычкындырып өлгерделәр.

Дусларны Рәшидә белән икәүләп, кул болгап озаттык. Алар палуба җепсәсенә тезелешеп, нидер әйтә, тик мотор гөрелтесе, отыры көчәя барып, тавышларын күмә. Үртәүдән авыз чалшайтып, ирен сикертүләреннән генә чамалыйм — сөгенү сүзләре гел ике иҗекле...

Осланның олы урамы гына якты, калган тыкрыкларда лампалы баганалар берән-сәрән генә. Икебез янәшә атлагач, кайсыбызның кемне, кая озата баруын аңларлык түгел — Рәшидәнең өенә кайтуымы бу, әллә ул мине кунак йортына илтәме? Яктылыкның чигенә җитеп, кире борылгач кына аңладым, без урам әйләнәбез икән...

— Осланда гел шулай тынычмы?

Биш мең кешесе дә чыгып качкан диярсең?

— Халык телевизор каршында, Мәскәү Олимпиадасын карый.

— Безнең шагыйрьләр дә шуңа күрә ашыкты инде Казанга. Башка вакытны командировкадан куып та кайтарып булмый үзләрен.

— Кунак йортыбызда кулда йөртә торган «Юность» телевизоры бар иде.

— Куен дәфтәре хәтлек кенә аклы-каралы экранга карап утырасылары килмәс шул, хәзер бит төсле телевизорлар күбәйде.

— Берәр айга алданрак килгән булсагыз... Монда кичләрен бик күңелле... Бөтен сандугачларның оясы Ослан ярында, карты-корысы, баласы-чагасы Идел ярына төнге кошларны тыңларга җыела.

— Ә бүген тып-тын...

Ник әйттем, әллә кайдан гына каршыбызда машина гөрелтесе уянып, Рәшидә белән икебез өчен генә хөкем сөргән серле тынлыкка әрсезләнеп бәреп керде. Әнә, ул якыная, аның саен тавышы белән уты көчәеп, туп-туры безнең өскә килә.

— «МАЗ-пятьсот!» — дидем мин бик белдекле кыяфәт белән, гәрчә машинаның үзен әлегә якыннан күрмәсәм дә.

— Әйе шул, — диде Рәшидә, раславында мине дә уздырып, әйтерсең лә гаражда диспетчер булып эшли!

— Мин хет «ГАЗ-МАЗ»ларны буровойда эшләгәннән бирле беләм. Ә син машиналарны ничек аерасың?

— Казаннан автоколонна килде. Юл салырга таш ташыйлар.

— Егетенме?

— Читкәрәк чыгыгыз! — диде ул, кинәт беләгемнән тартып. — Дуамал малай ул, йә бәрдереп китәр. Иптәшләре күптән машиналарын сүндереп ял итә, ә ул мажара эзләп йөри.

— Егетеңме?! — дидем мин кабат. Баягы соравымны ишетмәмешкә сабышты кебек тоелган иде. — Эзли торган мажарасы синме?

— Юк! Исемен дә белмим хәтта! Белергә дә теләмим. Юл төзүчеләр килгәннән бирле тынгы юк. Мин ул кызны беркемгә дә бирмим, барыбер үземнеке итәм, дип әйтә ди. Дискотекага да «МАЗ»ы белән йөри, өй түренә дә шул машинасы белән килеп баса.

— Сон, ГАИга хәбәр итәргә кирәк.

— Аларның эш сәгатьләре чикләнмәгән, исерек килеш йөрмәсәләр, тия алмыйлар.

— Алайса акылга утыртырга кирәк. Казаннан группировщикларны жыеп килим дә...

— Шул гына житмәгән иде... Бөтен районга даным китсенме. Рәхмәт, яклар өчен әти-әнием дә бар минем. Килеп кулы белән орынганы юк, конфликт ясарлык сәбәп күрмим.

— Димәк, егетең инде, ялындырып йөрүен үзенә дә ошыйдыр. Андыйларны күргәнем бар. Әнә, Сәвия дигәне, жәһәннәмгә алып китсән, кияүгә чыгам дигән иде. Магаданга барып життем. Эшкә урнаштым. Килмәде. Медицина институтының өченче курс студенты Олегны укуын ташлатып, Уфага чыгып качкан. Кире кайттым.

— Күптәнме инде бу хәл?

— Жиде ел элек.

— Шуннан бирле ялгыз йөрисезме? Сөйгән кызыгыз да юкмы?

— Бар. ЗАГСка гариза яздык.

— Ә үзегез минем белән сандугач сайратып йөрисез.

— Ну мин бит сезнең кунак кына.

Ул арада теге «МАЗ» безне куып житте. Бу юлысы инде төтенле жилен жилкәгә бәреп тормоз бирде. Ачудан кулкам[1] кабарса да сиздермәдек, исебез китмичә генә атлавыбызны белдек. Аннан соң ярыш башланды... Ул алга чыкты, көтеп алды... Без алга чыктык... Узып китте... Туктады. Кабинасыннан төшмәде... Без узып киттек. Юл алыш уены чамасын югалтты. Хәер, моны уен дип әйтү бигүк дөреслеккә туры килмәс, уен шаярудан узды. Хәвеф белән янап, мине жиңелергә мәжбүр итмәкче. Арабызга кереп аерырга, шул рәвешле сайрап торган төнгә дә, Рәшидәгә дә хужа булып калырга тели... Ә көч сынаш дәвам итә... Мәскәү Олимпиадасы бер читтә торсын! Уеннарның мондый төре тарихта юк та әле — машина белән кеше ярыша! Стартка чыкканыбызга инде ярты сәгатьләп бар, финишка өметләнәсе юк. Йә ягулыгы белән двигателе сүнгәнче узышабыз, йә Рәшидәне биреп котылам... Һәм хурлыгымнан Казанга кайтып китәм дә кояш баешын үзенә сыйдырган Ослан тавына тәрәзәмнең пәрдәсен корып куям. Үз гомеремдә минем әле тик бер генә тапкыр таңны каршылаганым бар... автор һәм башкаручы Назлыгөл белән. Икебез жыр язарга тиеш идек — яңа көннең тууы турында. Ул миннән шигырь көтә, ә мин һаман сузам, яңа көнне шигырь итеп күз алдыма китерә алмыйм. Назлыгөлнең иреннән аерылып торган чагы иде. Өч ел буе «Иделкәем» ансамбле белән бергә гастрольдә йөрдек... Шулай, Минзәлә районының Бикбау авылында концерт иде. Концерттан соң тиз генә фатирга кайтасы килмәде... Ык буена төштек. Кама елгасы Чаллы белән Минзәлә тирәсендә диңгезгә әверелеп ала. Бикбау авылы нәкъ менә шушы «диңгез» белән Ык кушылган жиргә урнашкан. Елга тамагындагы тымызык камышлар арасына аккошлар ияләшкән. Төннәр серле, сихри, аһәңле икән монда. Назлыгөл минем канатлы атның йөгәнен өянкегә бәйләп куйды, таңны көтәбез, иртәгә үк жырыңны язган бул, диде... Кама төбеннән кояш чыга башлады. Офык ягтысында үзәнлектә Актанышның Адай авылы пәйда булды... Үмәни күлләре белән. Сагышка күмә, газаплый, үксетә, үкендерә икән мине Таң нуры... Жырның исеме «Фани дөнья» булды. Назлыгөл аны сәхнәдә жырламады, оранжировкалар ясап, студиядә яздырды да миңа бүләк итте... Һәм янадан ире янына кайтып китте. Мин таң атканны күтәрә алмыйм. Мин таңнарга ышанмыйм, ниләр алып киләсен белмим. Яна

[1] Кулка (диал.) — үпкә.

көннең билгесезлек белән тулы вәгъдәләре мине сөендерми. Ә кояш баешы миңа көн саен кирәк. Ул — чынбарлык, ул — дөрес, ул — ышанычлы! Ул — үтелгән юл!

Ослан тавында таң атканны көтәргә ярамый. Әнә, әрсез машинаның фаралары ерагайган арада төн түрендә офык сызыгы яктырып ала.

Ярты сәгать чамасы сүзсез калганбыз икән. Рәшидә мине кинәт култыклап алды, аның тән калтыравы хәтта үземне дә дерелдәтә кебек. Нәсел кушаматыбызның «Корыч»лыгы исемә төште.

— Тәрәзәсен таш бәреп ватам хәзер, — дим...

Утыз яшьлек мужик, шушы — дискотекалар сикертәне алдында, фара яктысыннан котыла алмаган кыр куяны шикелле, юл беткәнче чабарга тиешме мин хәзер?..

Бу кадәресен әйтеп тормадым, тавыш таралу тизлеге белән уйлап кына өлгердем. Шулай да юл читенә үрелгәләп таш эзләгәндәй иттем. Рәшидә монысына ышана калды.

— Сез хулиган мәллә? Ул да бит кунак егет.

— Кунак булса — минем кебек тыйнак булсын. Ну, мотальщиклар урамда арматура күтәреп чыга башлагач, шофёрлар кул астында көпчәк салдыра торган монтажка йөртә башлады, ди... Допустим... Мин дә малай-шалай түгел... Буровойда йөз егерме килолы штангаларны[2] берүзем сөйрәп ыргакка эләктерә идем... Буа районында Чувашстан язучыларын каршылаганда, партком секретаре — сиксән алты килолы Елена Ивановнаны кулымда күтәреп, мангал тирәли әйләндем. Ышанмасаң, Александр Калган, Григорий Луч, Эндип Васси — сезгә дә килерләр әле, сорарсың. Алар да шаккатып кул чапканнар иде ул чакта.

Рәшиданең тән калтыравы бермә-бер кимеде. Беләгемә чытырдатып ябышкан кулы кайнарлана төште. Ә мин — киң җилкәле, «Корыч» бәдәнле, чыныккан сөякле мужик — иягемне күккә чөеп, күргән мажараларымны отыры ишәйтә тордым...

— Культура институтының рабфагына кергәч, мин Кындырлы урманындагы аланда су станциясе операторы булып эшләп алдым. Төнлә эшлим, көндез укыйм дигәндәй. Шулай, Октябрь бәйрәме алдыннан кичке сигезләрдә постка киттем. Тимер юл тукталышына җитәрәк, урман эченнән алты малай килеп чыкмасынмы: берсе городки таягы күтәргән, берсендә чылбыр кисәге, берәвендә сыгылмалы күсәк, калганнарының уң кулы кесәдә... Алла сакласын... Шундук уратып алдылар, кем кайсы җиремә сугасын алдан ук чамалап, гәүдәмне бүлештеләр бугай. Ашыкмыйча гына, тәмен белеп, җиренә житкереп дөмбәсләргә телиләр болар. Сыгылмалы күсәк тотканы тәмәке кабызды. Чандыр гәүдәлесе, түгәрәк эченә кереп, яныма ук килеп басты да үрелә-үрелә йөземә карый: «Синә ничә яшь, каян кайтып киләсең, сумкаңда нәрсәң бар?» — дигән була. Үзе әкренләп башын ия, сәламләве түгел, беләбез бу алымны — ташбашы белән ияк астыма сыламакчы... Алдан сизенеп, читкә тайпылып калдым, шулай да кашагасы белән аскы иренемне «сыйпап» өлгерде. Башланды җәза, мәрхәмәткә өмет юк. «И Хода, ярдәмеңнән ташлама!» — дип пышылдарлык кына мизгел бар иде, шул житте. Тәмәкесеннән күршесенә ут күчергәндә, сыгылмалы күсәге култык астыннан шуып төште. Мин ялт кына үрелеп алган хутка, әүвәл «Ташбашка» әҗәтемне кайтардым, аннан городки таягы күтәргәненә сыладым, чылбырлысы качмакчы иде, сыгылмалы күсәкләре белән бер генә селтәндем. Кире борылып: «Я же тебя не трогал, я же тебя не трогал!» — дип, әллә биш тапкыр әйтте шунда, аңа бүтән тимәдем. Калганнары чәчелде. Базык гәүдәлесе урман ешлыгына ышыкланып качмакчы иде, аны

[2] Штанга — бораулау торбасы.

куа киткән булып үзем дә караңгылыкка кереп чумдым... Сыгылмалы күсәк дигәнем экскаваторларда кулланыла торган чыдамлы шланга өзеге икән, әле ярый тимерле ягы минем кулда калган, мотальщикларны йомшак ягы белән генә тәрбияләгәнмен, юкса үзем исән калам дип кеше үтерүең бар. Ходай саклады инде, фәрештәләр теге шланганы минем кулга тоттырмаса, бу минутта Рәшидә исемле кыз янында тагын кемнәр йөрер иде икән?!

— Алты мотальщиктан исән-сау котылганны бер шофёрдан гына качып калалмыйсынмы?

— Үзем генәме? Юк! Аксубайлылар әйтмешли, низашто!

— Икәүләшеп югалыйк. Тагын килеп житәчәк ул...

Һәм Рәшидә, карышмасымны белеп, мине утсыз тыкрыкка ашыктырды.

Аулакта калгач, олы юлда безне эзләп арлы-бирле чапкан машинаны читтән карап торуы баштарак кызык кебек иде, тиз туйдырды.

— Мин сине хәзер өеңә озатып куям да... Аннан кунак йортына китәрмен, эзләп таба алсам... Таба алмасам, көн ачылганны көтәрмен. Яктыда адашмам.

— Аңлавымча, ситуациябез бик мактанырлык түгел: сез төне буе адашып йөриячәксез, ә мине капка төбендә, гадәттәгечә, «МАЗ» белән көтеп торалар... «Нишлибез?» — дигән сорауга җавап бер генә: сезне кунак йортына озатып куям да, аннан соң...

— Аннан соң мин сине өеңә озатып куям. И, йөрибез шулай, Ослан буйлап, Казаннан шагыйрь абыеңнар килеп төшкәнче.

Шайтан таягына да янгыр кирәк, дигәндәй, печән чабып өймәсәк тә, тәүлеккә якын сузылган сәяхәт алҗытты, җиңел сөякле абзагыз әкренләп йокы әсиренә әверелеп бара иде инде. Рәшидә үзе дә көн саен тау ягында таң аттырып йөрүчеләрдән түгелдер. Атлар гына аягүрә йоклый, ә колыннар хәтфә үләнле түшәк эзли. Рәшидәне тай белән чагыштырырга җөрьәт итмим, бүген көне буе диярлек сынап карап йөрдем — холкы, самимилеге, гадилеге һәм балалыгы белән колын әле ул, колын!

Шушы авылда яшәгәч, Рәшидә өчен бу тыкрыклар таныштыр инде, караңгы дип тормый, адымнары ышанычлы. Аяк астына карап кына, бик сакланып атлавымны сизепме, кулымнан тотты да, нәни энекәшен балалар бакчасына илткән дәү апа кебек җитәкләп, мине кунак йортына алып китте. Иҗат төркеменең «бригадиры» буларак, шөкер, ачкыч минем кесәдә.

Осланның кунак өе озынча зур буранын баш-башына ике парадный ишеге уелган, Казан калае белән ябылган гөмбәз түбәле, бер катлы йорт иде. Партия чорына хас стиль буларак, һәр административ бинаның арткы ишеге бар. Урам ягына караган парадный ишекләрендә гөрҗи чаклы йозаклар эленеп торса да, эчтә «шайтан түе» гөрләп торырга мөмкин. «Кергәләп йөр...» дип әйтте ди йозак бер ачкычка... Ләкин, кесәдәге ачкыч караңгыда ниһаять арткы ишекнең йозагын эзләп тапты, дигәндә генә урам ягында тагын фара яктысы уйнаклый башлады. Кунак йорты каршында тизлеген сизелерлек киметсә дә туктамады үзе... билгесез тарафка безне эзләп китте.

Рәшидә:

— Тизрәк керегез, ишекне эчтән бикләп куегыз! — дигәндә үзе өй эчендә иде инде. — Ут яндыра күрмәгез тагы! — дип тә кисәтеп өлгерде.

Әйе шул, аңышмыйчарак торып, кинәт ут кабызып өлгерсәм, тирәбездә бөтерелгән хәвефне ачык йөз белән каршылау кебегрәк булыр иде. Һәм шуның өстенә, җиде күрешүгә торырлык, алыштыргысыз газиз, хисләр өермәсеннән генә торган серле төн яктылыкка бәрелеп челпәрәмә киләсе иде.

Мәчеләрне төнлә шәп күрә, диләр, күзләре караңгыга тиз ияләшә торгандыр.

Мин дә, электр чәйнегенә су салдым, суыткычны ачып, райком кушуы буенча тутырылган күчтәнәчләрне өстәлгә чыгарып тездем.

— Коньяк эчәбезме? Әллә виномы?

— Юк, юк, юк! Чәй генә.

— Ярар, ярар, ярар! — дидем мин дә, өч тапкыр кабатлап. Әйтеп кенә каравым. Таң алдыннан салган килеш өенә кайтып керсән, әти-әниеннең коты очар.

— Алар минем кайчан чыгып киткәнне, кайчан кайтканымны санап утырмыйлар. Житмәсә мин әле бүген Казан шагыйрьләрен көйләп йөрим... Просто үземнең әле моңарчы бер тамчы да эчкәнем юк.

— Чыгарылыш кичәсендәге бер бокал шампан шәрабын исәпләмәгәндә... Шушы күлмәгең изүенә күбекләрен чәчрәтеп...

— Әйе шул... Ә каян белдегез?.. Икенче көнне башым авыртты.

— Шампан шәрабы — күбекле сыра бит инде ул... Мин дә кайчандыр аттестат алган идем. Нәкъ синең кебек — беренче тапкыр шампан салып бирделәр. Икенче көнне минем дә баш авыртты. Шуннан соң ун ел буе авызыма бүтән бер грамм да хәмер капмадым дияргә була.

— Ун ел буе?..

— Чынлап инде. Ну, алай да ике тапкыр тәүбәмнән яздырдылар: беренчесендә Ростов өлкәсендә, бораулау осталары мәктәбендә укыганда, курсант егетләр белән бәхәскә кереп; икенчесендә Нуриәхмәт кызының авылына кунакка кайткач: берәр чире бардыр моның, шуңа эчмидер, итит-митит, дип бөтен Әгерже «чыш-пыш» килгәние.

— Тәмәке дә тартмыйсыз инде?

— Өйрәтүче кеше булмады.

— Нәкъ минем әти кебек икәнсез.

— Алай ук дип әйтеп-әйтмә инде, Рәшидә. Безнең яшь аермасы ун класс арасы гына.

— Сез дөрес анламадыгыз, мин бөтен әйбәт кешеләрне дә әтием белән чагыштырам. Берүк үпкәли күрмәгез...

— Үпкәләргә вакыт юк... Әнә, тагын таш ташучы егетең килә. Безнең кай тирәдә югалганны сизенә ул. Син бар, юрган астына кереп кач.

— Ә сез чыгып китмәгез, берүземне калдырмагыз.

— Юк инде, сине аңа бирмим! Һәрхәлдә — бүген... Ят та йокла, таң аткач уятырмын.

Рәшидә, миңа берсүзсез буйсынып, тәрәзәле стена буендагы киң караватка барып чумды.

Күңелемнең юраганы — юл өстендә...

Ул, фара нурларын тәрәзәгә төбәп, кунак йорты каршына килеп туктады. Кабинадан төште, ишеген япмады. Машинасы эшләп калды, ә үзе, яктырткан якны сукмак итеп, туп-туры парадный ишегенә юнәлде.

— Рәшидә! Башыңнан бөркәнеп ят! — дип чак әйтеп өлгердем.

Бикле йозакка ышанмыйча арткы яктагы ишекне каерса йә тәрәзәне ватып керә калса дип, өй эчендә берәр таяныч булырдай саклану әмәлен эзлим. Әһә! Әнә, бильярд өстәлендә, ике кий ята! Ялгышмасам, ул таякларның эченә тимер кендек кагыла бугай, фил сөягеннән эшләнгән унбиш шары да «эшкә» ярап куяр. Кыскасы, телефоннан шалтыратсак, милиция килеп житкәнче самооборона тотарлык корал бар монда. Вәләкин... Ах, шул ләкин дигән киртә... Егет кесәсендә ниләр йөртәдер — анысы нәмәгълүм, тик кулында корал-мазары юк, ярдәм чакырам дип ашыгырга ярамый. Әдәби кичәләр оештырып йөрисе урында, милиция беркетмәләре күтәреп кайтсаң... Һәм Язучылар союзының ачык партия жыелышында персональ эшеңне тикшерсәләр

— беренче китабымны чыгару хыялларын ун елга архивка ыргытасыларын көт тә тор аннары...

Ул, ялган йозак дип уйладымы, күгәнендә шалтыратып бәргәләп алды. Ачылмагач, тәрәзәдән-тәрәзәгә күчеп, өй эченнән безне эзләде. Әллә йортның нигезе артык биек иде, әллә Рәшидә яткан карават бик тәбәнәк булып чыкты, егет эзләгәнен тапмады. Мин кийга таянган килеш кием элгече янында һөҗүмгә әзерләнеп басып торам.

Ул кабаланып кесәсенә тыгылды, тәмәке кабызды һәм ашыгып-ашыгып тартты. Төпчеген сүндермәгән килеш аяк астына ыргытты, очкыннары чәчрәде хәтта. Ниһаять, фара яктысында югалды, өй эчендә шәүләләре генә биешеп алды...

Машина гөрелтесе сизгер тынлыкка китеп олаккач, мин караваты кырыена утырып, Рәшидәнең йөзен ачтым, тирләп пешкән иде ул.

— Тының беткәндер... курыктынмы?

— Минем өчен сез куркырга тиеш.

— Кыз балага кул күтәрергә ирек бирмәс идем анысы. Ярый инде, конфликтның азагы тыныч хәл ителде. Бүгенге көннең соңгы сынавы булгандыр, мөгаен.

— Көннең яңасы башланды инде. Төнге берләр тирәсе. Таң атсын да кайтып китәрмен... Ой! — дип кинәт сикереп торды Рәшидә, — күлмәгем бөгәрләнеп бетә! Әти-әни алдында ничек акланырмын? Борылып торыгыз!

— Күзгә төртсәң дә күренмәслек дөм...

— Мин сезне күрәм бит. Борылыгыз. Йә күз тидерерсез.

— Караңгыда күз тими, Рәшидә...

Бераз читкәрәк китеп баскан булдым, тик борылмадым. Бәлкем әле, бүгенге мажараларны күз алдыннан кичереп, кайчан да булса берәр хикәя язармын. Күр әле, нинди илаһи, садә һәм соклангыч минутлар: минем күз алдымда унсигез яшьлек кыз бала күлмәген сала! Утыз яшемә житеп, гомеремдә беренче тапкыр: язмыш мине сафлык янәшәсендә иркәли; кабатланмас очрашуны суза; сүрелгән хыялларымны йокысыннан уята; тыелгысыз ләззәтне йөгәнләп газаплый; 1968 елның 31 декабрь төненә ишарә ясап тагын бер кат сыный. Бүген минем яшьлегемнең беренче төне. «Яратам» дигән сүз тел очымда гына тора, шуны бик якын килеп колагына пышылдыйсым килә... Беренче тапкыр...

Әнә, урындык аркасына элеп җәелгән ак күлмәктән бер яктылык бөркелеп, юрган эченә кереп качты.

Мин ат түгел, аягүрә йоклый алмыйм. Минем дә иртәгә, ягъни бүген, шушы киемнән халык алдында чыгыш ясыйсым бар.

Караваты кырына килеп тезләндем. Кунак йортының идәне линолеум икән, ялангач теземә салкыны йокты, тәнемдәге бөтен кайнарлыгым йөрәк тирәсенә тупланды.

— Бу Сезнең урын идеме? Башка караватка күчеп ятыйммы?

— Юк, юк, Рәшидә... — Тавышым үзеннән-үзе пышылдауга күчте... — Миндәренә янагым гына тиеп торсын... Бераз гына...

— Сез олы кеше, нәрсә эшләгәнегезне беләсездер инде.

Ул каршы дәшмәгәч, мин батырая төштем. Пружиналары сыгылып торган караватны бишек итеп тирбәтә башладым.

— Гомерем буе шушылай тирбәтер идем.

— Балалыктан чыктым шул инде... Күптән. Алай гына, юмалап, йокыга китәрмен микән?..

— Кулыма алып: «Әлли-бәлли... бәү», — дип көйләр идем.

— Сиксән алты килолы Елена сыман итепме?

— Менәтерәк, вәт! Мин синең аланга бүген көне буе борчак чәчтем, җыеп аласыларым бар икән әле...

— Һәр сөйләгән сүзегез хәтеремдә...

— Шулай укмы?! Каян килгән хәтер дәфтәре... Хәзер мин сине... — дидем дә, Ослан күгендә йолдыз атылган арада юрган астына кереп югалдым. Югалмадым, чалкан яткан Рәшидәнең күкрәгенә башымны салдым. Ә ул, кинәт кенә сынын катырып, җәя кебек киерелде. Мин юрган астыннан ук сыман очып чыгарга дучар идем. И, Ходам, кодрәтеңнән ташлама, син миңа бүген бик күп мәрхәмәтле булдың, тагын бер генә тапкыр ярдәм ит... тагын бер генә, моннан ары сине хатын-кыз мәсьәләсендә борчымас идем...

Сүз галиҗәнапләре!.. Ялварулы, ягымлы, иркәләрдәй, горурлыкны әсир итәрдәй җылы сүз кирәк иде бу минутта.

— Рәшидә, курыкма, тезләрем тунды, җылынам гына, күңелемдә сиңа карата һичбер усаллык юк... Кызыгу, ымсыну, нәфесем бар, тик синең ризалыктан башка нәфесемә ирек бирмәм, үз-үземне тыярмын!..

Бу төн минем өчен өн түгел, төштә күргәннәрдән берәүгә дә зыян юк. Уянганчы тизрәк иркәләнеп, сөеп калыйм...

...Кылы тартылган җәя әкренләп кире язылды.. Угы атылмады — садакка салынды...

— Сез зур кеше инде... Нәрсә эшләгәнегезне беләсездер!..

— Беләм, Рәшидә, беләм, шуңа күрә дә түзәм!..

Джунгли бишегендәге ике маугли кебек ятабыз...

Сөйләшүне бу киеренкелектән алып җинелрәк халәткә күчәсе килә. Тибрәнеп карарга иде исәп, ләкин бер талпынудан ук караватның төбе идәнгә тиде.

— Менә, Рәшидә, инде икебез бергә сиксән алты кило булдык.

Ул, сулышын вак-вак кисәкләргә бүлеп, көлемсерәгәндәй итте. Ә миңа шул җитә калды — нәфесемә тагын ут капты. Дәртемне уенга борып, кыз аркылы унга-сулга авам, янагымны шудырып, тәненең тыелган урыннарыннан йөрәк тибешен тыңлыйм, колачлап буй-сынын үлчим, тау булып күтәреләм дә өстенә ишелеп төшәм, тыны беткәнен сизеп сулыш бирәм. Инде тау итәм һәм ул минем гәүдәмне каплый. Мин аның аркасын кашыйм. Тау алыш китте... Ике арада бәхетле нарасыйлар киеп туа торган йөзлектәй йокы блузкасы гына.

— Рәшидә, бәлки риза булырсың, җимешем?..

— Юк. Көлмәгез миннән...

— Нинди көлү?!. «Юк!» дигән сүзне җенем сөйми, мескенәйтә, сындыра ул митне.

— Гел җиңәргә генә өйрәндегезме?

— Җиңү түгел бу, җимешем, җинелеп сөю! Хәер, кыз-баланы — тыйнаклык, егетләрне куркаклык саклый...

— Нуриәхмәт кызы белән ЗАГСка гариза биргәнсез, ә үзегез мине үгетлисез.

— Өченче гаризабыз бу... Язылышыр вакыт җиткәч кенә бара да кире алып кайта. Инде ЗАГСта эшләүчеләр дә таный башлады үземне, тагын килдегезмени, диләр.

— Ник ялындыра соң?

— Мәскәүдә егете бар. Кечкенәдән йөрешкәннәр. Каникулга кайткалаган. Гел хат алышалар. Араларына кердем бугай... Сиздермичә генә көндәлегеннән укыдым. Рәшидә, утызга җиттем инде, әле һаман да тормышымны көйли алганым юк. Әгәр дә ризалашсаң, бүген үк язмышымны яңадан яза башлар идем.

— Рәхәттә яшисез, шагыйрьләр... Әдәби кичәләр оештырып, авыл саен матур кызларның башын әйләндереп, гел романтик дөньяда...

— Мин шагыйрь түгел, мин — прозаик!

— Гафу итегез, Кәрим абый, минем белән романыгыз барып чыкмады инде.

— Үзең нишләрсең икән, жимешем? Районыгызга кунак килгән саен, партия сина озатып йөрергә кушар. Гел шушы кунак йортында каршы алу-озату мәжлесләре үткәрерсез. Килгән берсе башынны әйләндерер.

— Мин барыбер укырга китәм.

— Киләсе елга... Бераз эш күрсәт, дип сине ник районда калдырганнарын беләсеңме?.. Белмисең. Ә мин беләм.

— Ник?

— Чибәр син! Чибәр кызларнын тансык чагы... Казаннан кунакка килүче оешмалар күбәйде... Бүгенге мажараларны кая куясын: әле кичен генә сине машина куып йөрде. Әрсез шофёрдан качып, минем куеныма килеп каптын. Бер төн эчендә бит ул! Ә бер ел эчендә ниләр булмас дисен? Хәер, син ятимә түгел, яклаучыларың янында...

Ярый ла шушы тиклем үгетләүләремне ишетми калган. Рәшидә орышудан елап алжыган сабый бала кебек сулкылдап йокыга киткән иде. Сөйгән егет урынына дәгъвалаган абзагыз ясле тәрбиячесе хәлендә калды.

Тәрәзәләрдән таң нуры булып шәфкать керде. Өйләр урамы-урамы белән яктыга чыга башлады. Аяк астында сукмак ачылганда, без аулак ызан буйлап Рәшидәләрнең өй түренә килеп житкән идек инде. Күз бәйләш уенындагыча, баскан урынында бөтереп, күлмәген күздән кичердем: бөгәрләнмәгән, тап тимәгән, нәкъ клубка чыккандагыча бөтен. Уяулы-йокылы хәленнән файдаланып, үбеп саубуллашсам да ярый иде, мәгәр кызыгын тапмадым. Ирексез гәүдәсен кочаклап, чигә чәчен генә «пәп!» иттем...

Кирәк бит, әй, төн белән көн урын алышкан шушы мәлдә, чытаеп оеган тынлыкны тетрәндереп, тагын теге «МАЗ» кабынды!.. Ул кызнын кайтканын сагалап черем иткән күрәсең. Уяулыгын югалтмаган юньсез! Безне ышыклар өчен, нәкъ шушы минутта гына өй түренә үсеп чыккандай, колачлы тупыл кәүсәсен абайлап алдым. Сыендык шуна, башка чарабыз юк.

Ул, двигателен үкертмичә генә эшләтеп, тормозларына һава жыйды, каеш щёткаларын уйнатып тәрәздәге чыкны сөртте, һәм кичәге яңгырдан яшәргән йомшак чирәмлектә тирән эз калдырып китеп барды... Тәки жиндек!

Кызыл Байрак белән Татар Макылы авылларында безне фатирларга урнаштырдылар. Чыгыш ясаганнан соң, Осланның кунак өенә кайтып йөрешле булмады. Рәшидә шулай оештыргандыр ахрысы дип уйладым...

Аның: «Юк!» — дигән сүзен кабат ишетмәс өчен, мин Ослан юлын сәфәр картасыннан бөтенләйгә сызып ташлаган идем.

***

Һәм менә, күпме еллар узгач, мин тагын Ослан ярына килеп төштем. Рәшидәнең каршы алырга килмәслеген беләм, телефоннан шулай кинәштек. Тау башында мине сары төстәге «Калина» көтеп тора иде. Рульдә — Рәшидәнең бердәнбер кызы Сирень иде. Ул, үзе белән янәшә утырырга кушып, алгы ишекне ачты. Әнисе белән күрешергә килүемне әтисенә хыянәт итү дип кабул итми бугай, белә торып, елмаеп исәнләште.

— Кисәк кенә жил кузгалды, дулкыннар тәгәрәшә. Идел өстендә күнелегез болганмадымы? Дингез авыруы юкмы сездә?

— Юк, минем бернинди дә авыруым юк, — дидем, анынча елмаерга тырышып. — Соңгы елларда сагыну өянәге генә борчый башлады.

— Исән кеше сагына белергә тиеш, дип әйтергә ярата безнең профессор Тәлгат Нәбиевич.

— Димәк, мин бик исән икән әле...

— Менә монда карагыз әле, — диде ул, алгы тәрәзә өстендәге көзгегә ымлап. — Замри! Гафу итегез, зинһар, ни, берүк селкенмәгез! — Һәм Сирень көзгедән үзенең сурәтен дә эзләп тапты. — Гаилә альбомы өчен нинди шәп фото! Мин сезгә охшаган бит, әйеме?

— Апак, ни сөйлисең?.. Әгәр миңа охшасаң, синә ким дигәндә утыз яшь тулган булыр иде. Әниең белән без тик бер генә тапкыр күрештек. Ишетәсеңме, бер ге-нә... Минем гомергә синең яшьлек тә сыйган...

— Бер генә төн!

— Ә син аны каян беләсең, Сирень-Сиринә?

— Без әни белән бик якын подругалар. Бер-беребездән тел яшермибез. Сез әнигә орынмагансыз да хәтта! Шуның өчен дә әни ул төнне миңа кыйсса итеп бик еш сөйли. Филология факультетына керүем дә сезнең тирәгә якынаю өчен иде. Әни гомер буе сезне сагынып яшәде. Ник аны эзләп килмәдегез? Казаннан ерак ара түгел бит, Кәрим абый?

— Әниең «юк!» дип өздереп әйтте.

— Гафу итегез, «ярар!» дип әйтердәй кызлар «Досуг»та гына була... Сез киткәннән ун ел үткәч кенә кияүгә чыккан әле ул. Мин аның соңарып пешкән җиләге.

Мин инде ник килгәнемә үкенә башладым. Сиреньнең күрештерү теләге студент дуслары белән уйланылган авантюра гынадыр кебек тоела. Ләкин, Иделне бер кичкәч, бу тамашада ахырынача катнашырга туры килә.

— Кызык, чакырылмаган кунак шикелле утырам. Кая алып барасыларын белмим.

— Кая булсын, өйгә!

— Өйгә?!. Юк инде, сеңлем, әтиең каршына басып җавап тотарга җыенмыйм.

— Һәй, Кәрим абый, сез бигрәк беркатлы кеше икәнсез, шуткыны да күтәрмәгәч... Ә үзегез сатирик булып йөрисез...

— Әнә шул — мин юморист, дип йөрүчеләр шаяртуны аңламый да инде.

— Ярар, өйне барып җиткәч күрерсез. Киттек...

Үзгәргән, һай үзгәргән Югары Ослан, бер урамлы саладан таш челтәрле калага әверелгән. Йортлары биек, еш, әмма Казандагыча тыгыз лабиринт түгел. Кояшы тәрәзә саен гадел бүленгән. Саф һавасы туктаусыз җилләнеп тора.

Билгесез тарафка инде шактый озак барылды. Бистә урамнарында артык куып булмыйдыр шул. Рәшидә белән күрешү минутлары ныграк якынайган саен, ашкынулы күңел дә вакыт агышын акрынайтып, тизлекне киметкәндәй итә.

— Сирень, бу машинаның кызылы юк идеме соң? Әллә Рәсәй президентына теләктәшлек йөзеннән сары «Калина»ны махсус сайладыңмы? Сары төс — баланның өлгермәгән чагы бит.

— Егетемнең әтисе бүләк итте. Килен булып өлгергәч, кызыл «Мерседес» алып бирермен, диде.

— Бу очракта сөйгән егетемнең, дип өстәргә кирәктер.

— Сөю... Мәхәббәт!.. Бер төнлек ләззәт өчен гомерлек газап китерә торган сүзләр бу! Мин әни язмышын кабатларга теләмим! Бер-береңне ошатсаң — шул җитә. Яратуны уйнарга да була. Гафу итәрсез, сезнең тәҗрибә каршында мин өйрәнчек кенә әле. Артык телемә салынып барам түгелме?..

— Сиринә, мин сине яшәргә өйрәтергә җыенмыйм. Язмышның эталоны юк.

— Кәрим абый, ник үз хутыгыз белән килмәдегез. Машинагыз юк мәллә?

— Бар. Бик борыңгы «Жигули» инде ул. Казанның елга портында калдырдым. Әниең алдында күренергә оялдым.

— Китапларыгыз чыгып тора, романнарыгыз басыла, гастрольләрдән өзелгәнегез юк. Сезнең кебек солидный язучыга иске «Жигули»да йөрүне позор дип саныйм мин.

— Мин дә шулай саныйм. «Болгар-Авто»га утильгә тапшырам. Салонда чем-кара «Форд-фокус» күреп кайттым. Тәвәккәллим. Иске-московыдан, үткән-сүткәннәрдән, элеккеге хаталардан котылырга исәп, яшәргә комачаулый башладылар.

— Узган гомерне утильләштерү кебек янгырый.

— Апак, син бик образлы сөйләшәсең түгелме?

— Үсәбез, Кәрим абый. Укытучыларыбыз талантлы.

Шулвакыт без озынча бурадан күтәрелгән, ике парадныйлы, биек тәрәзәләре урам ягына карап торган таныш... бик таныш йорт янына килеп туктадык. Машинаның ачык сары яктысыннан түрбакчадагы тырнак гөлләре ачыла төшкәндәй булды.

— Сиринә! Бу бит элеккеге кунак өе.

— Әле һаман да кунак өе... Торучысы гына юк. Идел аша күпер салынгач, килгән кунак тиз китә хәзер.

— Күреп әтиегезгә җиткерсәләр. Әниеңә сүзе булыр.

— Юкка борчылмагыз! Алар күптән аерылышкан инде. Минем хакка гына бергә яшиләр... Барыгыз, әнине көттермәгез. Мин «шухер»да торам.

— Әллә нинди жаргоннар беләсең син, апак.

— Жаргон түгел, яңа диалект. Барыгыз, барыгыз!.. Сиксән алты килолы Рәшидәң янына ашык!

— Сиринә, син китмичә тор, яме... Мин әниенне просто күреп кенә чыгам.

— Вәт, комедия! — дип көлгәндәй итте Сиринә һәм, магнитолага диск батырып, җыр эзләргә керешге. Ниһаять, эзләгәнен тапты.

Бу юлысы мин парадный ишегеннән кердем. Сары «Калина» ирләр тавышы белән:

Сиңа барам, сиңа барам,
Барган саен ерагая бара арам...

дип җырлап калды.

***

Өйлә вакыты.

«Казан утлары» журналы редакциясенең 147нче бүлмәсе.

Дүрт стенабызның берсе — тәрәзә, ел саен, «Коммунистик өмә» вакытында гына юыла, шуңа күрә дә аның тоташ пыяласы көйләнмәгән телевизор экраны кебек, урамдагы сурәтләрне томан аша күрсәтә.

Август челләсе.

Тәрәзәне ачсаң, кояшлы якта сагалап торган җил, коридор ишеген каерып, яраң һаваны суырып ала да шайтан өермәсенә әверелеп, бүлмәдәге кулъязмаларны туздыра башлый. Кояш «батарея»сеннән котылам дип пәрдәне корсаң, хәреф танымаслык караңгы төшә.

Бухгалтерыбыз: бераз акча бар, сезгә кондиционер кирәкме, әллә суыткыч алыйкмы, дигәч, без телевизор сорадык. Проза бүлеге өчен Табигать кочагындагы һава торышына караганда, сәяси климатны алдан белеп тору мөһимрәк.

Мансур Вәлиев, тәрәзә янына килеп басты да, унынчы каттан Әгерҗенең Баржылы авылын күрергә теләгәндәй, күзлек пыяласын сөртеп киде.

— Механизаторларга аш китерәләр хәзер...

— Мансур абый, ашханәдән әле генә тәмләп ашап мендек бит.

— Кырдагы ашка җитми инде, Марат.

— Абзыйлар, яшьлегем өчен сездән гафу үтенәм, кырга чыгып «похлёбка» чөмерергә туры килмәде. Өйдә пешкәне дә ярап тора безнең ишегә. Кайтып ике тәлинкәне каплап куям да... Обедтан соң эшкә килеп тормасам, ни диярсез икән?

— Үзенә кара.

— Синең эшеңне без эшләмибез, Марат, — Мансурны мин дә хупладым. — Яшьлегеңдә яшәп кал.

— Әйе, 147нче бүлмә тиз картайта ул, абыең (монысы мин инде, ягъни мәсәләң) килгәндә Галиябануның әтисе яшендә генә иде, ә хәзер, әнә пенсиягә әзерләнә...

— Интонациягез бер дә ошамый әле миңа, абзыйлар.

— Отпуска вакыты җитте.

— Суң, Мансур абый, син бит инде болай да җәен-кышын «Аккош күле» дачасында яшисең. Ялга китсәң дә, шул урманыңнан чыкмыйсың. Аннары, эшкә килсәң дә, дачана кайтсаң да, баш мөхәррирең нигез күршең. Эшең белән ялыңның аермасын күрмим.

— Урманда планёркалар юк: «Тираж, тираж! Син күпме яздырдың?!» — дип җикеренмиләр.

— Ярый, абзыйлар, мин киттем! Ашханәдәге мосафирлар кердә башлаганчы чыгып сызыйм.

Безнең бүлмәдә тынлык — бик тансык күренеш. Иртәнге якта, баш мөхәррир кабинетын мәхкәмәгә әверелдереп, көйсез авторлар йөренә. Кулъязмам кем кулында, ник озак ята, ун ел инде басылганым юк, дигән шелтәләргә күбесенчә проза бүлеге җавап тота. Көн уртасында инде йокысын туйдырып, тамагын ялгап, һава суларга дип чыккан олпатлар һәм гонорар эзләп килгән активлар, юл унае хәл белешеп чыгар. Кич җитәр-җитмәс үзебезнең эшләрне көтә башлыйбыз. «Кызыл почмак» без.

Әлегә Мансур Вәлиев белән икәү генә. Бергә-бер калсак — ул тәнкыйтьче, мин — язучы!

— Бу романың озаккарак сузылды...

— Әкрен языла. Моннан көне буе күз алҗып кайта. Үзең беләсең, мин төнлә генә яза алам, таң атканчы утырсам, иртән торып эшкә барулары газап.

— Элек, редакциядә эшләгән язучыга атнасына бер иҗат көне бирелә иде. Ул көннәрдән отгул җыеп, иҗат йортларына китәргә дә рөхсәт итәләр иде.

— Партия без язганнарны укый иде. Ә медианерлар эксперименттан бушамый.

Монысы мәгънәсез сөйләшү, дигәндәй, тәнкыйтьче кул селтәде.

— Исемен таптыңмы әле? — диде ул, тагын яна роман тирәсенәрәк килеп. — Исем сюжет корырга ярдәм итә ул.

— «Язылмаган поэма», — дип карадым.

— Артык купайтылган исем.

— «Вакыт машинасы» ничек?

— Тапталган.

— «Хисап көне» барамы?

— Дини догма синең амплуа түгел.

— «Мин иртәгә яшим» дип әйтеп әйтсәм?

— Чыктым аркылы күпер кебегрәк. Кушаматың «Корыч» булгач: «Корыч ничек чыныкты...» дияр идең, кабатлану килешмәс.

— «Тургайлы болытлар»ны куясым килмәгән иде.

— Киресенчә, таушалмаган исем. Әгәр поэтикасын саклый алсан — хуплыйм.

— Минем биографиянең поэтикасына караганда романтикасы күбрәк булды бугай.

— Алар икесе дә тугандаш сүзләр... Романтика дигәннән... Сәвияне күрәм дип Уфага ашкынган иден. Сөйгән кызыңны кырык елдан соң очратып гайрәтен чиккәндер. Күрешүең дә бөтенләй кирәк булмагандыр әле. Ул вакыйганың финалын язма син... Мина гына сөйләсән дә ярый. Чынында ничегрәк бетте соң?

— Уфаның «Юбилейный» залына килеп төштек. Концерт башланырга бер сәгать кала афиша янында басып тора.

— Сәвияме?.. Таныдыңмы соң?

— Үзе инде. Йөзеннән таныдым. Гәүдәсе генә үзенеке түгел.

— Кырык елдан соң нәрсә көттең?..

— Көтмәдем. Сорау гына бирдем: «Магаданга ник килмәдең? — дидем. Агач балбал кебек басып тора. Биш минутлап үткәндер, ниһаять: «Нихәл?» — дип әйтә алды.

— Танымагандыр ул сине...

— Минеме?!. Таныды! Гаебен танымады. Авылга кайтып егылыр идем, ди. Юлга акча сорап килгән иде ахрысы.

— Артистлар автобусы белән алып кайтыгызые.

— Аныммы?! Өстендәге бумази күлмәге Сәвия белән бергә бөгәрләнеп беткән, баш астына салып йоклатканнар диярсең. Чәче дә искергән — парикка охшаган... Афиша янында калдырып, кул селтәп китеп бардым. Мединститутның өченче курс студенты белән Чаллыга чыгып качканын ишеткәнем бар иде. Нишләп йөри ул Уфада! Бәхетен кора алмагандыр инде. Минем тирәдә бәхетсезләр күбәя башлады.

— Бәхетлеләре безгә күренми генә аның... Бу вакыйганың азагын язып тормасаң да була.

Бүлмәбезгә тагын чеглә тынлыгы урнашты. Мин язылачы вакыйгаларны алдан чәчми тордым. Мансур үзеннән өстәп сөйлисе киңәшләрен яшереп калдырды.

Аксакал яшендәге журналыбызның шушы 147нче бүлмәсендә мина кадәр бер взвод язучы эшләп киткән инде. Эше барның ашы барын да беләбез. Бу бүлмәнең, элеккедән килгән йола буларак, ашханәдән менгәч — өч кенә минут черем итеп алу йоласы бар икән. Кем эшләгән — шул йоклаган... Шулай, бервакыт, 147 нче бүлмәдә Әхәт Гаффарның яна романын юганнар... Төшке аш вакыты булган. Рәшит Әхмәтҗанов белән Шамил Маннапов, өстәлгә кулларын куеп, башны кырын салганнар... Уянып китсәләр... сәгать кичке жиде тулып узган ди. Уникe катлы йортның кешеләре кайтып бетеп, вахтёр бөтен утларны, шул исәптән лифтны да сүндереп куйган ди...

Бу вакыйганы безгә Мансур сөйләде, сөйләгәндә буыла-буыла көлде... Сизеп торабыз, үзе дә шунда булган... Бергә эшләгән еллары туры килә...

Әнә хәзер дә башын кул өстенә салып, сәке чаклы өстәлендә урын ипли. Пенсияне тикмәгә генә бирмиләр, мин дә оеп барам... Маратны гына йоклата алмыйбыз... Ярар ашыктырмыйк аны, олыгайсын бераз. 147нче бүлмә тиз картайта ул...

Өч минут та үтмәгәндер, ишек шакыдылар.

Йә Гәрәй, йә Гомәр, йә Саттардыр... алар вакыты... Юк, Вакыйф Нуруллин булып чыкты. Кергәне юкка бишбылтыр, ишек шакуын шуңа

танымадык. Аягүрә каршыладык үзен. Мин аны моннан 40 ел ук элек, туган авылымның М.Вахитов исемендәге колхоз премиясенә лаек булганы өчен хөрмәт итәм.

Хәл-әхвәл сорашулар күп вакыт алмады. Мансур эш темасына күчте.

— Вакыйф абый, яңа әсәр алып килдегез мәллә? «Һәлакәт»егездән[3] соң утыз ел үтте. Сез укыла торган повестьлар яза беләсез. Яңасын көтәргә хакыбыз бар.

— Егетләр, миңа хәзер артык өмет тотмагыз. Бөтен өмет сездә инде. Сагынып кына кердем. Ни дисәң дә,шушы бүлмәгә уналты ел гомеремне биргәнмен. Әнә, энекәш минем урында утыра, өстәлем дә шул ук. Романнарыңны укып сөенәм, энекәш.

«Минем урында утыра», дигәнче, сүзгә катышмый гына түзгән идем, әйтәм инде...

— Вакыйф абый, укып чыккач шалтыратмыйсыз бит.

— Вакытыгызны алып, вак-төяк белән борчып торасым килми инде.

— Ә элек миңа хатлар да яза идегез. Хәтерлисез микән? «...Әйдә, кулыңнан килмәстәй эш белән шөгыльләнгәнче, коеларыңны яхшырак казырга тырыш...» 1971 елның мае...

— Егетләр, бер-беребезгә ачу сакламыйк. Заманы болай да катлаулы. Ертып ташла син ул хатны.

— Вакыйф абый, мин кәгазьне хөрмәт итәм.

— Ә бәлки, шул хатны язмаган булсам, син әле язучы була алмас идең! — диде ул, сүзне кирегә борып.

— Анысы өчен рәхмәт! — дидем мин дә, аркасыннан сөеп.

Маннур Саттарның әкрен генә кереп килүе Вакыйф Нуруллинны ашыгырга мәҗбүр итте.

Отставкадагы майор Саттаровның 90 яше тулган көннәр бу. Озын гомерле ветераннар барын беләбез. Бишьеллык сугышны кичеп, яраланып-дәваланып кайткан фронтовик агайның үз-үзен җиңел йөртүенә дәияләндек. Ләкин, 90 яшенә җиткән бабакайның, көн саен килеп, җәмәгать ашханәсендәге ризыкны ашый алуы безнең өчен гайре табигый хәл булып күренә иде.

Хәзер ул безгә кичә ахшам вакытында чыгарган яңа такмакларын укый башлый. Әнә, орден-медаль планкалары астында күкрәк кесәсенә тыгылды... Хәзер куен дәфтәрен ала да... юк, бу юлысы, социализм байрагы кебек комач кызыл һәм әле уртага бөкләнеп тә өлгермәгән яңа таныклык күрсәтте. Ниһаять, Язучылар берлегенә кабул иткәннәр үзен... почётлы әгъза итеп. Сабыйларча сөенә, җанашым. «Почётлы язучы», «Почётлы академик»ларның кем икәнен беләбез инде... Кәефен төшереп, сөенеченнән мәхрүм итәргә теләмибез.

— Маннур агай, бүген такмакларың юкмыни?

Маннур агай сугыштан кайтканнан бирле турая алмаган имән бармагының траекториясен миңа төбәп:

— Исемә төшерүегез өчен рәхмәт! — диде дә чәчәкле тукымадан тегелгән сеткасының тотка төенен чишеп, дермантин папка чыгарды, анысын ачып, шигырьләр төпләмен җыйнап торган целлован пакетны шудырып укырга әзерләнде.

— Яльчик күле буенда ял итеп кайттым, шунда яздым. Җәмгысе 32 штук. Һәммәсе дә бер кыз турында.

Рөхсәтебезне сорап тормыйча гына укый да башлады.

[3] «Һәлакәт» — повесть исеме.

Әгәр, Жир шарында цивилизация яңа гына яралып, Маннур агай кешелекнең иң беренче чичәне булып танылса, мәхәббәт турындагы бу шигырьләр гавам телендә дастанга әверелер иде... Ләкин, соңгы меңьеллыкта шагыйрьләр күп туды шул.

— Газетада басылып чыккач, үзебез укырбыз, болай кызыгы бетә, — дип туктатырга мәҗбүр булдым. — Кемгә багышлап яздың соң? -- дим.

Һәм Маннур агай орденсыз күкрәк кесәсеннән Ләйлә Дәүләтованың төсле фотосын чыгарды.

— Яраланган лейтенант Саттаровның гомерен саклап калган украин кызы Изольданың рәсемен югалттыңмы әллә?

— Сезнең соравыгыз бик дорфа һәм урынсыз... — диде ул, икенче кесәсеннән Изольдага кулын сузып.

Әйе шул, Изольда югала алмый. Ул аның фотосын, тышына мәңгелек календарь бастырып, ике мең тираж белән таратты.

— Маннур агай, 1978 елның 11 июне атнаның кайсы көне булган?

Ул Изольдалы календарьга карамыйча гына, күңеленнән ниндидер саннар пышылдады да, һавадан алып, миңа кирәкле көнне әйтеп бирде:

— Чәршәмбе! Һич шикләнмәгез.

Агайның күңеле булды. Шигырьләрен пөхтәләп янә чүпрәк капчыгына салды.

— Извините за огорчение, я вынужден вас покинуть!

Күңеленә якын кешеләр белән ул гел шулай саубуллаша...

Маннур Саттаров чыгып киткәч, 147нче бүлмәдә нафталин исе булып сагыш таралды... Бурлин чегәне вәгъдә иткән 96 яшьлек чагымны күз алдыма китергән идем — җаным өшәнеп, бөтен гәүдәмә каз тәне чыкты. Әгәр мәхәббәтенне искә төшерә алырлык хәтерең булса, иң озын гомер дә таман гына икән... 90 яшьлек бабай да мәхәббәт турында шигырь язгач, «Тургайлы болытлар»ым нәрсә турында булырга тиеш соң?.. Мәңгелек календарьның июнь чәршәмбесе — ул минем Нуриәхмәт кызы белән танышкан көнем...

Утыз ел бергә яшәп, аның турында бер хикәям дә юк хәтта! Мәхәббәт турында зурдан кубып язар өчен, автор сөйгәне белән кавышмаска, югалту газабы кичерергә, гомер буе кемнедер сагынып яшәргә тиешме? Туксан алты яшемәчә Нуриәхмәт кызы белән яшәп кала алсам, мин аның турында бернәрсә язмасам да риза!..

***

Иртәгә туган көнем...

Бүген мин әле бер яшькә яшьрәк...

Кешенең хәтер дәрьясы виртуаль архив сыман. Бала чактагы яңа дәфтәргә таныш йөзләр, рәнҗү-сөенечләр, жете хисләр отыры языла бара. Яши-яши вакыйгалар шултиклем күп җыела ки: архив шүрлегенә сыймый башлый; күңел төпкеленә чумәлә булып өелә; кирәкле-кирәксез мәгълүматлар белән күмелә; тузанга бата, онытыла... Көннәрдән бер көнне, көтмәгәндә генә, күптәнге дустыңны очратасың да аның белән бәйле хәлләрне исенә төшерергә тырышасың... Черем итеп яткан истәлекләренне кемдер кереп тузгытырга тиеш. Әгәр кеше, гомеренең соңгы көннәрендә япа-ялгыз калса, хәтер сандыгында нинди хәзинә барын беләлмичә тәки китеп барыр иде.

Яратмаган кешең белән яшәү — ялгызлыкның бер төре...

Хатирәләр белән шыплап тулган архивымны тәртипкә саласым бар.

Минем өчен бик тә кадерле булган ядкарьләр башка бүтәннәрнең альбомында саклана...

***

Өй тулы кеше, ә мин ялгыз бугай.

Аркылысы-буйга икешәр колачлы аш бүлмәсендә түгәрәк табын корып гаиләбез чәй эчә. Өстәл кыл уртада, утырган жиреннән үрелеп кенә, плитәдәге табадан сарымсаклы сыр ягылган баклажан телемнәре өстәргә була. Эремчек пилмәне дә кул сузымында гына, салкын куастан шулпаланган яшелчә ашы, зәйтүн маена чыланган яшь помидор салаты да күз алдыннан ерак китмәгән. Урта дингез ярыннан талир тәнкәләр бәрабәренә кайтартылган ожмах жимешләре, минем туган көнемә пешеп өлгергән эре сортлы жиләгебез янында мескен булыбрак утыра. Сизенгәнсездер инде, мине әкрен-әкрен генә үлән ашаучылар тагарагына ияләштереп маташалар. Итне дә, йөзем кәмешкәсен дә качып кына авыз итәргә туры килә.

Түгәрәк өстәлнең дә түре бар, тирән эчле урындыкта балбал кеби утырам. Улым белән киявем, кызым белән киленем түтәл ризыгыннан мөкиббән китеп, жимеш суы белән кәефләнеп, минем аркылы сөйләшәләр. Әниләре — Нуриәхмәт кызының урындыгы буш — ул әле туктый алмый: илтә, куя, юа, алыштыра, турый — йөзендәге елмаюын югалтмаска тырыша, компьютердагы музыканы көчәйтә.

Шау-гөр, кәеф-сафа, бәхет-сәгадәт, идиллия...

Түгәрәк өстәл тирәсендә дөньябыз түгәрәк...

Ник соң әле күңелемнең күләгәле бер почмагында гаиләмә сиздермәскә тиешле жирсү, юксыну, үкенүгә хас өзгәләнү посып ята?!. Мин шушы түгәрәк уртасында тагын кемне күрергә телим? Әллә мин сагынуларсыз яши алмыйммы? Кемне сагынсам да барыберме? Шушы сагынулар миңа тапкан-табынганымның кадерен белеп кенә яшәргә комачаулады, ялгызлыкта биклэп тотты. Ялгызлыкның бик тә сәер халәте иде бу... Инде Зәмзәмия ягында калган Яна ел төнен, Люба, Сәвия, Рәшидә белән күрешүләрне кәгазьгә төшергәч, хатирәләр сандыгым бушап калды. Мин аларның исемен виртуаль архивтан сызып аттым. Зиһенем ачыла төште. Һәм агач утырту, бала үстерү, өй салу ыгы-зыгысында йокымсырап яткан көнчелек шәүләсендә яна бер коткы уянды: Нуриәхмәт кызы да үзенең Мәскәүдәге егетен сагына торгандыр лабаса?!. Икешәр атна тоташтан ерак араларда гастрольдә йөргән чакларым булды, бер-берсен эзләрдәй хәлгә житкән яшьлек дусларын күрештерер өчен бөтен шартын китереп торганмын түгелме?..

Үз-үзеннән сорау алу — көнчел кешенең котылгысыз өянәге...

Бу дөньяда кайсыгызның бәхетле кеше күргәне бар? Әйе, бәхетсезлеккә дучар булмаган һәркем үзен башкалар белән чагыштырганда бәхетлерәк дип исәпли ала. Зәмзәмия, Сәвия, Рәшидәләр белән күрешү — очраклы хәл генәме? Әллә итәгеннән баласы төшкән, сөте кипкән хатын-кызның алга таба яшьлеген сагынып яшәве табигать салган физиологик жәзамы? Язмышларында кискен борылышка дучар булганнар икән — моңа мин гаеплеме? Язмыш мәхәббәт артыннан йөриме? Әгәр дә мин, эзләгәнемне таптым дип яшәп калсам, ул кызларның берәрсен бәхетле итә алыр идем микән? Бәлки чынлап та, бүгенге тапкан-табынганымнан ваз кичеп, романтикалы иртәгесе хакына яңадан башлап карарга кирәктер, әйтик, Зөһрә белән?!.

Нигә әле ул мине эзләми?..

Түгәрәк табын артында утырган килеш, бу кадәр сорауга ничек җавап табып бетермәк кирәк?!. Уйларымны улым бүлдерде.

— Әти... Әти! Безнең янга кайт әле... Туган көнеңә җыелган идек бугай...

— Әтиең безне ишетми, кесә телефонына шалтырат син аның. — Нуриәхмәт

кызының мине иркенләп битәрләргә исәбе. — Хыялланган җирләренә китеп барса, һай рәхәт яшәр иде ул... Ну, андый бәхет тәтемәс ана!

— Сезне уйлап утырам ла мин, — дигән булам, ә үзем, учымда кызган телефонны кая куярга белмичә, өтәләнәм. Сүзне кирегә борам. — Әйе, балакайлар, почта тавыннан чана шуган эше генә выжылдап үтеп китте гомер: әниегез Нуриәхмәт кызы белән үткән гомер утыз серияле кино кебек кенә булды: утыз тапкыр помидор утырттык; утыз тапкыр суган чәчтек; «Башкорт сылуы» дигән утыз яшьлек алмагачның алмасыннан как койдык; Дөбъяз артындагы тармаклы сызадан утыз чиләк җир җиләге җыйдык; утыз ел рәттән Әгерҗе Сабан туена кайтып килдек; язучы һөнәренә өйрәнер өчен утыз ел буе редакциядә кеше кулъязмасы төзәттем... Менә шундый, гап-гади арифметика! Саннарны бергә кушып санасаң — түгәрәк бәхетнең сагышлы суммасы килә дә чыга. Туган көннәргә дә ияләшеп беттем инде. Теләкләрегезне яттан беләм, кайсыгызның нәрсә бүләк итәсен дә әйтеп бирә алам, әниегез алдан ук сөенчесен алып тора. Рәхмәт анысы, зарлана димәгез инде, бу арада боегу басты, гел алга барасы урында, никтер гел артка борылып карыйсым килә... Әйдә, улым, әйт тостынны!

— Тост түгел. Тост ул — шаяртып котлау гына. Мин чынын әйтәм. Син оптимист кеше, моңаеп утыру килешми сиңа... Сизәсеңме, әти, ерак юлга чыкканда, мин гел сине ияртергә тырышам. Чит илләргә хатын белән икәү генә бара алабызмы? Рәхәтләнеп! Әгерҗегә кунакка җыенсагыз да, гел ияртергә тырышабыз, җәйге ялларыбыз гел сезнең янда үтә... Хәтта яшенле яңгыр килсә дә, сиңа елышабыз. Үзебезнең аерым фатирыбыз була торып та күп көннәрне сездә кунып калабыз... Ни өчен дип уйлыйсың?

— Мин булган җирдә гел әниегез бар — шуңадыр. Соңгы елларда тәмам шеф-поварга әверелде. Коридорга таба исе таралса, күрше-күлән рецепт сорап керә башлады инде. Күбәләкләр — гөлгә, күгәрченнәр җимгә куна...

— Юк, әти! Алай гына түгел ул... Оренбург якларында Чирәм җир сөргән көннәреңне исеңә төшер әле... Бурлин[4] чегәне сиңа 96 яшькә җитәрсең дидеме?

— Әйе, яздым ул турыда. Чегән карчыгы әйткәннәрнең бик күбесе рас килде.

— Димәк, гел синең янда булсак, без, теләсә нинди хәвефтән дә котылып, гел исән-имин яшәячәкбез! Син безнең бәхетнең гаранты! Монысы — тост...

— Күтәренке йөкләмәгезне кабул итәм. Күңелнең нечкәргән чагы — купшы сүзләргә дә сөенә... Әйдәгез, тост өчен, үзем ясаган йөзем төнәтмәсен бер күтәреп...

— Юк, әти, куеп тор, рюмка сиңа килешми дә. Сүзем бетмәде әле... Туган көнеңә бүләк тапшырасыбыз бар. Менә мин үземне әни карынында чакта ук хәтерлим... Сезне ишетә идем. Җиде айлык чагым булды микән, ятам шулай рәхәттән йокымсырап: урын җылыда, тамак тук, якты дөньяга чыгарга ашыгасы юк — авырлыгым җитенкерәми. Әни белән синең сөйләшүеңнән уянып киттем. Гадәттәгечә үзеннең бала чагынны сагынып утырасың.

Улым, шушы урында бүленеп, кесә телефонын чыгарды, төймәләренә баскалап тамагын кырды да Мәскәү каналының «Могҗизалар кыры» тапшыруындагы Якубович тавышы белән: «Приз в студию», — дигән әмер бирде. Кыңгырау тавышына килен сикереп торды да чакырылган кунакларны каршы алырга дип ишеккә таба йөгерде... Һәм бала караваты чаклы кәгазь тартманы җиңелчә күтәреп, ике кыз килеп керде. Талымсыз әтиләренә ике «курчак»

[4] Бурлин — Казакъстанның Оренбург өлкәсе белән чиктәш районы.

чакыртуны өнәп бетермәстән, Нуриәхмәт кызының йөзендә кинәт кенә нуры сүнеп алган иде дә, ләкин пардан киенгән кызларның кызыл футболкасында «Ваш дом» дигән кибет язуын күргәч, янадан балкыды.

Кибетчеләрне озаткач, улым уенны янадан дәвам итте.

— Әти, тартмада нинди бүләк дип уйлыйсың?

— Зурлыгына караганда урын-җир кирәгедер, — дидем мин, кибет исеменнән чамаларга тырышып. Ләкин малай алга таба санаган нәрсәләрне дә «юк»ка чыгарды.

— Бер төргәк күлмәк... унике галстук... туксан алты яшемә чаклы житәрлек юка оек... нужәли шыплап тутырылган кульяулык инде?!.

— Юк, юк, юк!.. Исенә төшер, башлангыч мәктәптә...

— Беренче укытучым Сафура ападан җавап хаты! Мин инде аның адресын эзләп табып, өч ел элек хат язган идем, кире кайтмады. Концерт белән киткән артист дусларым аркылы күпме сәлам җибәрдем, җавабы юк...

— Әти, бераз якын киләсең, ну бик тирәнгә чумасың... 1961 ел... IV класста сезгә «Табигать белеме» дигән фән керә башлады... Кояш, ай, йолдызлар турында дәрес бара. Сафура апаң өстәмә сораулар бармы, дигәч син: «Бу прибор ничә сум тора?» — дип сорадыңмы?

— Әйе... Яңа акча белән күпмедер, әйтә алмыйм, — диде... Телескоп иде ич ул... Күк йөзе язучының хыял дингезе инде ул.

— Миңа да Рушан исемен йолдызлардан алып кушкансың... Шуларны исәпкә алып... әнә тартманы ач!

Чәчәкле-чуклы кәгазь белән тышланган бүләкне сакланып кына ачам... Бәллүр кандилны төргән кебек иркәләп салганнар. Сүткән саен күңелем тула бара... Телескоп!.. Сафура апам кулындагысыннан ун, йөз тапкыр артыграк көчле электрон телескоп... Ну улым, мин — мыеклы сабыйга өмет итмәгән уенчык бүләк итеп сөендердең!.. Юынгычка барып битне сафландырып алырга туры килер... күздән яшь бәреп чыкканны сизә күрмәсеннәр...

Өйдәгеләр мәш килеп, телескопны көйләп өчаягына бастырган арада, кече бүлмәдәге кәнәфидә бераз уйларымны барлап алдым.

Укытучы — һөнәр генә түгел, укытучы — язмыш ул!..

Сафура апа Шәледә безне генә укытып чыгара алды... Аннан билгесез тарафка китеп югалды. Ул китте, бәет калды. Хәзерге акылым белән шәрехләп тә мин аның язмышын аңлата алмыйм. Безне уку елының ахырына житкәнче үк ташлап китәргә тиеш булган бит ул. Каян килгән аңа шултиклем рухи көч?!

1960 елның көзе кышка авышкан иде инде. Октябрь бәйрәме үтүгә җиргә кар ятты. Урамнарга юл төште. Сугым вакыты житте. Сафура апа белән Хәким абый да Тау иле авылыннан бер тай сатып ала. Ләкин аранга ябып, бер ай чамасы симертелгән сугымлыклары киртәне җимереп чыгып кача. Иртән солы бирер чак житкәндә генә сизеп алалар. Хәким бертуган абыйсы белән киңәшкәч, болар күп уйлап тормый, тайны эзләргә чыгып китә. Аларга Хәкимнең җиңгәсе дә иярә. Сафура апа өйдә генә көтеп кала. Әгәр ул да ияргән булса... зур хәвеф тә буласы түгел икән.

Салкында көне буе эзләргә туры килсә дип, җиңгәчәй, кабымлык тутырган сумка төбенә ике шешә «җылыткыч» та төреп сала. Питрәч урманын айкап, ат эзеннән Тау Иленә таба бара торгач, болар олы юлга килеп чыга. Нәкъ шул вакытта Күн авылының Якуп исемле бер бәндәсе җигүле чанада кайтып килә икән. Туктаталар моны. Исәнләшеп-нитеп хәл белешеп тору юк, безнең тайны кая куйдың гына, диләр. Ә Якуп агай, хәлнең ни дәрәҗәдә житди икәнлеген абайламый кала, сорауны уенга борып өлгерә: «Шәле чегәннәренә саттым...» — ди. Авылның иң күп таралган кушаматын ишеткәч, агайларның ачуы чыга,

житмәсә инде сумка төбендәге ике шешә дә бушатылган була. Чанага сикереп меңләр дә болар, әйдәме дөмбәсләргә... Жингәчәй дә тик тормый, кулындагы сумкасы белән Якупның башын төя. Ә сумка эчендә, ипи кыерчыгы янында каймаклы банка да була... Өркегән айгыр, Күн авылына кайтып житеп, капка төбенә килеп туктаганда, Якуп инде жан тәслим кылган була.

Мин бу вәхшилекне каян беләмме? «Атылган Хәким бәете»ннән. Без, IV «А» классы балалары, ул бәетне кулдан кулга күчереп алып ятладык:

...Бисмиллаһи, вә биллаһи,
Житә Корбан гаете.
Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Атылган Хәким бәетен!..

Башкаларга сабак булсын өчендер, судны авыл клубында үткәрделәр. Хәким абыйны атарга хөкем иттеләр. Бәет чыгарырлык фажига. Сафура апабыз да күрше Күн авылыннан, теге Якуп ана нәсел агачының бер тармагы буенча туган тиешле кеше булган. Педучилищены бетергәч, апаны беренче укытучыбыз итеп безнең мәктәпкә жибәргәннәр. Хәким абый белән кавышып, өч ел яшәгәннәр — балалары булмаган... Бөтен гаепне үз өстенә алып, ул абыйсының күп балалы гаиләсен саклап калган.

Әгәр, алтмышынчы елларда ук үлем жәзасына мораторий игълан ителгән булса, Хәким абыйның кайтканын бөтен классыбыз белән көтәргә дә әзер идек без...

Сафура апа шушы хәсрәтен күтәреп уку елы беткәнче түзде. Кырысланмады, гел үзенчә ягымлы булып кала бирде. Телескопның бәясен сорагач, миңа — салам түбәле черек өйдә өч баласы белән яшәп яткан тол хатынның төпчек малаена — хурлап түгел, үртәп түгел, хәтта шаяртып та жавап бирмәде бит ул. Жәйге каникулга чыккач, ул билгесез тарафка китеп югалды. Соңгы уку көнендә Сафура апам миңа, ни өчендер, уч тутырып көмеш акча бирде. Мин ятимгә аталган юл садакасы идеме бу, әллә телескоп алырлык акча жыярга кушуы булдымы? Үзен күреп сөйләшмичә төгәл генә жавабым юк.

Кырык елдан артык вакыт узгач, ниһаять, Сафура апамның кайда яшәгәнен белдем. 2005 елда мине Питрәчнең «Алга» газетасы юбилеена чакырдылар. Бәйрәмгә район типографиясе белән редакция ветераннарын да чакырганнар иде. Тәнәфестә минем янга алтмыш яшьләрдәге бер ханым килеп басты. Тагын очраклы хәл диярсез инде... Беренче укытучымның бертуган сеңлесе Мәгъмүрә икән ул! Гомере буе шушы редакциядә эшләп тә, монарчы үзенең кем икәнлеген сиздермәгән, Сафура апасының беренче укучысы икәнлегемне белә торып. Шигырем гранкаларын, хикәям юлларын кургашыннан койган, сәхнәләрдә алкышлаган, китапларымны укып барган кадерле кеше, Сафура апамның кайдалыгын сер итеп саклаган. Әлеге дә баягы, минем язмышымда тәкъдиренә язылган котылгысыз «кырык ел» узарга тиеш булгандыр күрәсең.

Сафура апа, бездән киткәч, тагын кырык ел укытучы булып эшләгән. Өч малай үстергән. Бүген ана, беренче укытучым, дип эндәшүчеләр меңләгән кешедер инде. Ләкин мин — иң беренчесе! Кыйгачлап бөкләнгән яшел яулыгын иңенә салган; калын чәч толымын өрфиягә төргән; ирен читендәге миң тамчысын сөртер өчен генә юка яфрагы чаклы яшел кулъяулыгы жиң очында; коңгырт күзле, пакь йөзле; алкасының жем-жем кашы минем күздә уйный. Ябык изүле Сафура апам гел күз алдымда. Ул миңа бик якын иде, чөнки ерактан начар күрүем аркасында мин гел беренче партада — нәкъ аның каршысында утыра идем...

***

Телескопны аягына бастырганнар. Шәһәрнең тутыккан күк йөзендә йолдызлар күренми әле. Ай чыкканны көтәргә туры килер. Галәмгә төбәлгән хыялларны балконда калдырып, тагын өстәл артына тезелештек. Ашап-эчеп тә ардык бугай инде. Тамак туйгач, тәрәзә артындагы вазгыять онытылып тора. Гәүдә авырая, дөньякүләм проблемаларга карата ваемсызлык көчәя, гамьсезлек били. Өч бүлмәдә өч телевизор кабызып, өчкә бүленеп, күңелле ял иттердәй сюжетлар эзләдек. Сайлый алмыйча тагын өстәл артын яуладык.

— Экрандагы сурәтләргә багынганчы, үз гаиләң белән күзгә-күз карашып утыруга ни җитә инде, — диде Нуриәхмәт кызы. Кискән-тураган нигъмәтләрнең барысын да ашатып бетерергә җыена иде бугай. — Әрәм калмасын, иртәгәгә тәме югала инде боларның...

— Яңа ел төне түгел, таң атканчы ашарга димәгән! — Монысы, гәүдә сылулыгы белән горурланып, ботаник ризыкларга мөкиббән киленебез кисәтүе. — Туачак оныгыгыз турында бөтенләй оныттыгыз, — диде ул, глобус өслегенә охшаган көмәнен сыйпап. — Берегез — китапханәче, берегез — китап язучы, шушы көнгә чаклы исем таба алмыйсыз.

— Әти, әти дим, ну, әти!..

Улым «әти» дип дәшкәндә, миңа шундый рәхәт, юри ишетмәмешкә сабышам, кабат-кабат әйтүен телим. Үзем гомер бакый яшәп, бер генә тапкыр булса да «әти» дип әйтә алмадым. Февраль бураннары белән әтине күмеп кайтканда, миңа алты ай, әнигә утыз алты яшь булган. Шәригать кануннары буенча зиратка керергә дә ярамаган ана. Әни, нужа камытын киеп, безнең белән бергә үскән. Үги әтигә дә «әти!» диеп дәшәргә риза идем югыйсә...

— Әти, әти дим, әллә колакка катыландың инде? Тап инде бер матур исем.

Нуриәхмәт кызы минем өчен җавап бирергә ашыкты:

— «УЗИ», кыз бала туачак дип күрсәткәч, эзләве яртылаш җиңеләя инде. Әтиегезнең кем исемнәрен сайларга теләвен беләм: Зәмзәмия, Сәвия, Рәшидә, Рита, Назлыгөл, Зөһрә...

— Ник туктап калдың? Дәвам ит, — дидем мин, әлеге исемнәрне ишетүдән яшерен ләззәт кичереп.

— Әллә тагын яңалары да өстәлдеме?

— Хәзер, өстим: Равил, Рамил, Рафил!.. — дидем дә шып тукталдым.

— Йә, беттемени?! Син минем альбомдагы малай-шалайларны гына саный аласың шул, көнче күбәләк. Безнең гаилә коткысы шушы исемнәр арасында инде.

— Үзең башлагач кына җавап биргән идем... Юктан проблема чыгармыйк, берәүнең дә исемсез калганы юк әле. Әнә, Ай телескоп каршына килеп баскан анда. Сез чәй эчегез. Ә мин Күк җисемнәре белән сөйләшеп алам.

Нуриәхмәт кызы, табын артын гомуми җыелыш белән бутап, шартлы беркетмәне иске карар белән төгәлләргә булды:

— Син, лунатик, әйт әле миңа, машинаңны кайчан утильгә тапшырырга уйлыйсың?

— Әти! Әни дөрес әйтә, оныгыңны шушы ямаулы «шестёркаң» белән алып кайтырбызмыни?

— Беләм. Ишеттем. Тырышырмын. Яңасына заказ бирелгән. Өлгерермен.

Өзек-өзек җөмләләремә җавап итеп, Нуриәхмәт кызы балконга таба кул гына селтәде...

Ай телескопсыз да бик һәйбәт күренә иде. Ләкин ни генә дисәң дә, сөйгән кызымнан килгән хатны тизрәк ачарга ашкынган шикелле, Айдагы «Зөһрә

кыз»ны якыннанрак күрәсем килү теләге күңелне рәхәт кытыклап, ымсындырып тора.

Шәһәр кешесе исемне китаптан эзләргә ярата: тирән мәгънәлесе кирәк, кабатланмасын, русчага тәрҗемә ителгәндә, бик бозылмасын, минем исемне кушканнар дип күрше-күлән, туган-тумача, дус-дошман үсенә күрмәсен... Исем кушуда катнашучы кешеләр саны никадәр күп булса, уртак фикергә килүе шулхәтле үк кыен да. Һәркем үзенең күңелендә качып калган исемне яңартырга маташачак. Менә ичмасам, авылда: кемне хөрмәт итәсең; кем мактаулы; кем батыр; кайсы артистны йә язучыны яратасың — шул исем синең өеңдә яши.

Безнең авылда 47 Исламгали бар, 36 — Сәрия, 12 — Ринат, Илсурлар — урамы белән, берән-сәрән генә дип әйтик, чит илдән ияреп кайткан яңгырау исемле кызлары да байтак. Ә менә Гәрәй, Ибрай, Сәхәбетдин, Низам кебек исем кушуларны авыл советында метрика тутыручылар оныткан инде. Хәер, һәр авыл үзе бер дәүләт бит ул, башкаларга охшамас өчен, кануннарын саклый, йолаларын яңартып тора.

Мин артезиан чишмәләр бораулаган «Бер» районда Зөһрә исемле кызлар бик күп иде. Зөһрә йолдызга, ягъни Венера планетасына зонд төшергән еллар булгандыр ахрысы... Күрше-тирә районнар Кечкенә Париж дип атасалар да, «Бер»нең үзәге бары тик авыл өйләреннән генә тора иде. Күрәсең, шагыйранә кушаматы мәдәният йорты тирәсеннән таралгандыр.

Өч кешелек бригадабызны утын ягып җылыта торган райпо кунакханәсенә урнаштырдылар. Кыскасы, «Париж»да яшәп, авылларга йөреп эшлибез. Ә кич житте исә — «Шерше ля фам»...

Күңел ачып йөрергә исәбем юк, янача тормыш кору турында хыялланам. Минем өчен генә үскән кыз бала «Париж»да качып калмасын... Зәмзәмиядән киттем, Сәвия-алтыным белән араны өздем. Инде өлешемә тияр көмешемне эзлим.

Беренче кичне үк Зөһрә исемле кызга гашыйк булып кайттым. Дөрес, мин әле аның исемен дә, мәктәптә татар балаларына рус теле укытканын да соңрак белдем.

***

Тулган Ай, безнең балкон турысына килеп житкәч, туйганчы күреп кал мине, дигәндәй, әйләнешен акрынайтты бугай, күз алдымда эленеп калгандай тоелды. Телескопны юнәлтүе бик җиңел икән... Йа, Хода! Шушы яшемә житеп, Айның чын йөзен якыннан күрмичә ничек түздем икән соң мин?!. Караңгы җиһанда адашып йөргәннәрнең сукмагына зәгъфран нур салырдай түгәрәк лампа гына түгел ул сиңа... Гади күз белән караганда, Айга тоныкпәрдә корылган кебек. Ә телескоп — ул пәрдәне ачкан: Ай глобусында кабарынкы кратерлар, чүмәлә сыман калкулыклар, хәтта кучәр дип саналырга тиешле баш-башында кар аклыгы да аерым-ачык күренә. Сыный карасаң — Күк капусында Ай Җирнең туграсы кебек тора.

Кечкенәдән, әби-бабайларыбыз сөйләгән әкиятләрне чынга алып үскән малай буларак, Айга карау белән, анда сулы чиләк-көянтәсен иңенә салып Зөһрә кыз йөридер кебек тоела иде. Телескоп белән дә сүнгән янартаулар арасыннан шул унган кызны эзләдем бугай.

Бар ул Зөһрә кыз, тик Айда түгел, Кечкенә Парижда. Ятимлек күрмәгән, әтисе Автономияле республикабызның «Бер» районында дәрәҗәле түрдә эшләгән ныклы гаиләдә үскән. Зөһрә ике сеңелкәшенә туган апа тиешле олы кыз, зур булышчы. Әтиләре еш кына Казанга партия киңәшмәләренә китә, әниләре көне буе райсобес эшендә. Зөһрә сеңелкәшләрен карый, ашарга пешерә,

мунча яга, көянтә-көянтә су китерә. Сонрак, иске нигездән читкәрәк күчеп, яңа өй салып чыгалар. Зөһрә хәзер суны чиләкләп ташымый — кирәккән саен кранны гына ача, мунча мичендә дә газ кергән...

Айда бернинди дә кызлар күренмәгәч, түгәрәк экранда хәрәкәтсез сурәт карап утыру тиз ялыктырды. Үткер күзле торбаны яктырак янган йолдызларга күчереп карадым, алай да тиктормас җанымны җәлеп итәрлек юаныч тапмадым. Өч йөз тапкырга якынайтып кына чиксезлекне тотып буламыни?!. Галәмгә очмаска дучар ителгән милләтнең бер ятиме өчен уенчык кына ич бу телескоп, уенчык машина кебек, уенчык гармун кебек...

Чиксезлектән тайпылып шәһәр төбәсенә күчтем, ләкин йортларның асты өскә килде, җирдәге хыялларны күрер өчен түгел икән бу коры сихер, өйләр түгәрәк түгел шул әле Казанда... «Париж»ны күрер өчен дә балконы төньякка караган фатирга күчәргә кирәк, юкса мин бүген Зөһрә кызны телескоптан баштүбән килеш күрергә дә риза идем...

Нуриәхмәт кызы үзе табын артында телгә алмаса, Зөһрә исеме бәлки тиз генә искә төшмәс иде әле. Болай да инде, юраганны юш китереп, насыйп булмаган ярларымны очрата торам, һәм очраткан берсен бүтән күрешмәслек итеп югалта торам. Үкенмим дә үзе, үксемим дә, үртәлмим дә... Сызып кына барам. Күңелем тәмам бушлык белән тулды.

Зөһрәне кузгатасы түгел иде. Нуриәхмәт кызы белән яшәргә комачауламыйча гына онытылып бара иде инде ул... Имеш...

Хәтеремә хилафлык китереп, үз-үземне алдап маташам түгелме? Язучылар оешмасында гомуми җыелыш йә әдәби ел йомгаклары, юбилей кичәләре үткәрелсә, мин «Париж»дан килгән шагыйрь абый янына утырырга тырышам. Ул гомере буе тик бер урында — районның башкарма комитеты рәисе урынбасары булып эшләде, Кечкенә Парижның «писцовая книга»сын яттан белә. Килгән саен, ашык-пошык кына хәл-әхвәлен сорашкан булам да сүзне Зөһрәләрнең өй түренә борып куям.

«Миңа сәлам әйтүчеләр юкмы?»

«Ник булмасын, бик күпләрдән сәлам сиңа. Кайсысыннан ныграк көтәсең соң?»

«Ну, шул инде, райком секретаре кызы».

«Харис Нигъмәтовичның кызлары-йолдызлары өчәү бит: Чулпан, Айсылу, Зөһрә... Бөтенесе дә чибәр!»

«Зөһрә икәнен бөтен «Париж»ыгыз белә бит инде...»

«Белүен беләбез дә... Сине өметләндерерлек һич кенә дә хәбәрем юк бит, әй... Кияүгә чыкты ул».

«Биюче Рамилгәме? Концертларда гел парлашып бииләр иде».

«Юк, Рамил армиядә, яшьрәк әле ул. Зөһрә диңгез флотында хезмәт итеп кайткан кешегә чыкты. Батыр егет... Үз күзләрем белән күрдем... Бер көчеккә ябырылган бозау чаклы бурзайны, җан тамырыннан эләктереп алып, читән аркылы ыргытты... Берүк юлына аркылы төшә күрмә!»

«Балачактан бирле җен-фәлән белән куркыттылар инде безне...»

«Ярар, үпкәләмә. Шаярттым гына. Син дә бик батыр егет. Безнең районда практика үткәнеңне онытасыбыз юк. Бөтенләйгә төпләнеп калсаң, райком секретаре бердәнбер кызын бирергә риза иде үзеңә... Ә Зөһрәне онытинде...»

Онытырсың Зөһрә йолдызны! Ул минем күңел күгемдә көн саен: таң атканда — бер, кояш батканда — ике — балкып ала хәзер...

Зөһрәне күргәч кенә мин үземнең яшьлегем барлыгын тойдым. Киноларда күреп, китаплардан укып, бәхетле парлардан ишетеп, үзем өчен тудырган

хыялый мәхәббәтнең, ниһаять, чынбарлыгын таптым. Шушы мәхәббәтне күрер өчен, мин ничә еллар буе олы юлда адашып йөргәнмен.

Кече Парижда мин ярты ел чамасы эшләдем. Райпо кунакханәсенә кайтып тиз генә кием алыштырам да мәдәният йортына, ягъни безнең авылдагыча әйткәндә, клубка йөгерәм. Иртәрәк килергә тырышам, чөнки «Париж» яшьләре уенга жыелганчы, буш залда «Гөлбакча» ансамбленең репетицияләре бара. Шыпырт кына керәм дә уты сүнгән тамаша залында югалам. Ә сәхнәдә жырлы-биюле ансамбль. Ничә кеше катнашканын ярты ел буе саный алмадым — мин гел Зөһрәне генә күрдем.

Клубтан кайтам да хат язам. Ул хатны мәктәпкә килеп кыңгырау шалтыратучы дежурный апага калдырам... Кайсыбер көннәрне кулымдагы хатны башка укытучылар тартып ала: «Зухра Харисовна учительскаяда, тапшырырбыз!..» — дип елмаешып, каядыр мәктәп төпкеленә китеп югалалар. Ярты ел буе шулай газапландым. Йөз сиксән көн рәттән жавап көттем, ник бер килсен икән... Клубта көн саен күзгә-күз, кара-каршы очрашабыз, сөмсерен коеп үтеп китә, ә хатларымны кире бирми үзе... Клубтан аны көн саен сәхнәдәш пары Рамил озата кайта. Миннән котылыр өчен генә уйланылган хәйләдер инде, Зөһрәне өенә илтеп куйгач, егет янадан клубка йөгерә...

«Гөлбакча» ансамбле атнага өч тапкыр жыела. Бер генә репетицияләрен дә калдырганым юк. Караңгы залдан сәхнәдәге Зөһрәгә текәләм. Ул мине күрми, ә мин аны, экраны бөтен сәхнәгә жәелгән киң форматлы кино караган кебек, икешәр-өчәр сәгать буе карап утырам. Ул киеме белән дә башкалардан аерылып тора. «Гөлбакча» үзенең беренче юбилеена әзерләнә. Казанның «Халык ижаты» йортыннан кайтартылган костюмнарга инде ун яшь иканлеге биюче кызлар өстендә нык сизелә. Калай шкафта бикләнеп сакланган Арча читекләренен дә чигүле чәчәкләрен жыерчык баскан, балтырлары бушаган. Ә Зөһрәнең хан кызыдай сылу гәүдәсенә килешле киеме бөтенләй үзгә. Аның күлмәкләрен атнасына өч тапкыр яңартып өлгерәләр бугай, читекләре аяк үлчәменә мач килгән, бизәкләре әле яңа гына чәчәк аткан. Талпынып-талпынып биегәндә, калын толымы сүтелеп муенын сыйпый... Һәм чем-кара чәч арасыннан алка энжесе жемелдәп ала. Кемнәрнеңдер беренче укытучысы бит инде бу кыз, дигән жирсүле уй мине тагын да ныграк сокланырга мәжбүр итә, якынайта һәм кызыктыра иде.

Ярты ел буе сер бирмәдем, караңгы тыкрыкларда сагалап торып ялынмадым, хатларыма ник жавап бирмисен, дип сорау алмадым. «Яратам сине, Зөһрә» дигән шигыремне «Париж» газетасында бастырмадым...

Куркаклык түгел бу...

Кызларның «юк» дигән сүзеннән минем күңелем сына.

Аларның «юк!» дигәнен ишеткәнче үк, алдан сизенеп, горур рәвештә кире борылырга, яратуымны кимсетмичә генә вакытында чигенеп өлгерергә тиеш. Кызлар үзләре мине сайласын. Күрешер өчен мин бер адым атласам, сөйгән кызым мина таба ике адым якынаерга тиеш! Һәрхәлдә, мин гел: «Әйе, ярар, риза, яратам!» — дип кычкырып әйтә белгән хатын-кызлар тирәсендә чуалганмын. Жиңел кәсеп белән бәхетле булырга омтылу — шушыдыр инде.

Жете буяуның тиз унганын күп күрдем.

Күңелендәге хикәяләмичә генә яраттырган гашыйклар ышанычлырак икән. Тик мин моны аңлаганда, Бурлин чегәне юраган еллар шактыйга кимегән иде шул. Иртәрәк бәхетле булыр өчен минем белемем житмәгән. Институтка керү кирәк булган.

Студент чагында кичләрен Мех берләшмәсендә эшләп йөргәнемне әйткәнем бар. Айга ике тапкыр Яңа Бистәнең төнге урамнарына Яшьләр

дружинасы итеп тәртип сакларга чыгаралар иде. Берсендә, «Тукай» кинотеатры янына жыйдылар да бишәрләп бүлделәр. Арабызда бер кыз бала бар: юка кызыл пәлтәдән, кызыл бияләйле, кулдан эрләнгән кызыл калфак кигән, аягындагы күн итеге дә кызыл хәтта! Тез өстендә күзгә чалынган колготкие белән муенына сарылган купшы шарфы гына актан. Алга таба жыелсак та, төркемне сакларга тырыштык. «Нихәл, кызыл чәчәк?» — дип күрешә торгач, исемен әйтергә туры килде үзенә — Ләйлә икән. Баулы районынын Сәгъди мулла кызы булып чыкты. Бүрек тегү цехында эшли икән... Яшь каеннарның алтын тәңкәдәй яфракларын таптап, ләйсән карлар өстенә сукмаклар салып, сафура бураннарын гөрләвектән агызып, кунакка да йөрешә башлагач, күңелгә шом керде: менәтерәк — Сафура апабыз безне ташлап киткән елны бу бала әле дөньяга туган гына! Ялгыш, ачылып китеп, язмышымны сөйләп бирсәмме — балакаемның коты алыначак бит! Ничекләр итеп бу сафлыкның бәхетен үзләштермәк кирәк? Болай да инде, нидер сизенә бугай, авыр суладым исә, шундый итеп карап куя — күз карасы аша ут йөгертеп, намусымны өтеп ала. Кыскасы... Мин башка эш таптым.

Соңгы елын укучы студентлар, диплом яклау өчен, кимендә дүрт айга Казаннан китеп тора. Кайткач та инде, диплом алып, мәдәният учаклары кабызу өчен бөтен Рәсәй тарафына таралышасы кешеләр. Киткән берсе, үзенең акча эшләү урынын яшьрәкләргә «бүләк итә». Миңа да Идел буе районының каравылчылар оешмасыннан бер урын эләкте. Иллә дә мажаралы эш булып чыкты. Өч студент, кичке алтыга бүлеккә киләбез. Кайда пост ачык калса — милиция машинасына утыртып, шунда илтеп куялар. Айга ике тапкыр аеруча эш тыгызлана, аванс йә получка алган көннәрдә ярты Казан капкасы ачык кала. Ул чакта без төн чыкканчы, берьюлы жиде-сигез урыннын хәлен белеп йөрибез. Ачык капка дигәч тә, ислемай, сабын, мебель, макарон, шәраб завод-фабрикалары, транспорт хужалыклары, төзелеш чималлары өелгән причаллар бит инде алар. Шулай итеп, мин, көндез укуның беткәнен түземсезлек белән көтеп утырам да дежур каравылчылар янына ашыгам. Әүвәл, күрешергә жае килми, вакытым юк, кебек сылтау табып, «Кызыл чәчәк»нең эшенә шалтыраткаладым, аннан соң бөтенләй «югалдым». Хәйләмне аңламаслык Ләйләме?!. Эзләмәде...

90нчы еллар акчаның тинтәклеге, тауарның кытлыгы белән тенкәгә тиде. СССР «Ура!» кычкыртып таралды, коммунистлар Ленин васыятьләреннән ваз кичте... Шушындый болгавыр заманда шәхси эшмәкәрлек хәрәкәте кутәрелде. Турбинная урамында «Илфар» ширкәте ачылган иде, тире эшкәртеп, затлы кием тегәләр. Ул елларда Татарстан язучыларының әдәби фонд идарәсендә Рафис Корбан эшли иде. Рафис «Илфар» директоры белән дуслашып өлгергән, аның ярдәме белән бик күп язучылар елкылдап торган чәшке бүрек һәм затлы кайры тун киеп алды. «Чаян» журналына жаваплы секретарь булып килгәч, башым зурая төштеме — әллә кечерәк калыпка салганнармы, таман булыр дип сораткан 58 үлчәмем башыма сыймады. Бүрекне алыштырырга дип «Илфар»га үзем киттем.

Борычлабрак әйтермен дип, «Бүрегемне чи тиредән теккәнсез ахрысы, мин кигәнче ике размерга утырган...» дигән жөмләне юл буе авыз эчемнән шомартып килгән идем. Складка керсәм... Сәгъди мулла кызы Ләйлә — әлегәчә адәм башы күрмәгән бүрекләрне, торт сыман итеп, бизәкле кәгазь тартмаларга салып, сүс бау белән аркылы-торкылы бәйләп утыра! Көн саен аралашып торабыз диярсен, мине күреп исе китмәде, елмаеп исәнләшүенә тиклем иске дусларча гына... Миңа икеләтә кыен булып китте. Беренчедән — каршымдагы ханым, унбиш ел үтсә дә, һаман шул жинел сөякле «балакаем» кебек, күзләрендәге сагышлы

карашы гына олыгайган. Икенчедән, мина хәзер: «Теге чакта кая югалдын син?» — дигән сорауга, һичшиксез, җавап тотарга туры киләчәк.

— Өйләнү килешкән сезгә, хатыныгыз камыр ашы күп пешерә бугай.

— Анын каравы син гел үзгәрмәгән.

— Нәселебез белән шундый без.

— Менә сина «Кызыл чәчәк»!

— Түгел шул. Безнең униформабыз көрән төстә.

— Алъяпкычын, мех читеген, кофтан... кайры жилетын... Көрән төс бик килешә икән сина.

— Жинсез кыска туныма исегез китмәсен. Калдык-постык мех кисәкләрен корамалап, үзебез өчен эштә киеп йөрергә дип әтмәллибез. Җылы ул. Сез киләсене белсәм дә салып куймадым әле.

— Ничек инде. Каян белден?

— Язучылар союзыннан заказ алгач та, исеменне күрдем. Тукта, минәйтәм, кызык итим үзен, фамилиян язылган коробкага 56нчы размерлы бүрек салып җибәрдем. «Чаян»га язып чыгарсын әле бер, дидем.

— «Чаян»га язып кемне куркыта аласын ди хәзер.

— Алыштырырга киләсегезне белдем. Гадәттә, затлы киемне покупатель үзе киеп карап ала.

Ләйлә, тәбәнәк коймалы чоланга кереп, минем бүрекне алып чыгып бирде.

— Менә, сезгә атап тегелгәне шушысы. Киеп карагыз.

Сабый бала бүреге тоттырып җибәрсәләр дә рәхмәт әйтергә риза идем. Көзге каршында бүрекле портрет булып басып торуым да «Кызыл чәчәк» янында вакыт үлчәмен озайтыр өчен генә.

— Ләйлә, ник син мина Сез дип дәшәсен?

— «Син» — Кызыл чәчәк янында югалды. Культура институтында укыган кеше миннән яхшыракны тапкандыр, дидем. Анда бит кызларнын чибәрләрен генә сайлап алалар ди.

— Ни сөйлисен, Ләйлә! Мин бит ул чагында хатын аерган кеше идем. Әйтергә оялдым. Әти-әнием дә дөрес анламас иде.

— Ну и җүләр... сез!

— «Яшь ленинчы»да эшләгән елны Туфан абый Миннуллин да мина: «Ну и дурак!» — дигән иде... Үз итеп, сүз унае...

— Мин дурак димәдем... Сезнең авыл кызлары ярты меховой иде. Икебезне бергә күреп, кемлегенне шул көнне үк килеп әйткәннәр иде инде. Яшьлектә кем ялгышмас? Мин-мин, дип йөргән күпме егет сволочь бу дөньяда. Мин сезне бик ошаткан идем. Арабыз өзелгәч, шулкадәр кыен булды. Башка берәүгә дә кияүгә чыга алмам кебек иде...

— Бәхетлеме сон син, Ләйлә?

— Гафу итегез, мин әле генә сезнең бу соравыгызга җавап бирдем инде...

Син, дип саубуллашасы урында, хушыгыз, дип чыгып киттем. Ләйлә белән бүтән күрешергә насыйп булмады. Инде «Илфар» ширкәте ябылды. Теге бүреккә күптән көя төште. Кайры тунга «Чуртым» да юк. Кием шкафынын өске шүрлегендә бөгәрләнгән истәлек булып, янадан модага кергәнен көтеп ята, кисән — кечкенә, кешегә бирсән — кадерле. Унбиш ел гомерем заяга үткәндер кебек тоелды.

Ләйләне искә төшереп алу бүгенгемне ныграк анлар өчен кирәк иде мина. Зөһрәнең горур төстә мине эзләмәве ачуны китерә. Горурлыкны сылтау итеп дәшми торырга була, ләкин кирәген юк, дип кул селтәп булмый.

Мин аны үзем эзлим, горурлыгына зыян китермәм.

***

Туган көнем уңаеннан ТНВ каналы кунакка чакырды, «Кара-каршы»да сөйләшеп утырырбыз, диләр. Темалары бик четерекле икән үзе: мәхәббәт һәм хыянәт! Икегә бүлеп утыртырлар инде: бер якта — мәхәббәт җырчылары, ә икенче якта хыянәтчеләр булыр. Мине кайсы якка каратып утыртасыларын чамалыйм.

Тапшыру эфирга турыдан-туры чыга. Шуңа күрә дә башланасы вакытка бер сәгать алданрак чакырдылар: урыннарга күнегәсе, һәркайсыбызның тавышына микрофоннарны көйлисе. Бәхәс белән мавыгып, темадан читкә китмәс өчен махсус әзерләнгән «дежур» сораулар белән танышабыз. Ялганлар хәлем юк, мин инде экранга күренер алдыннан әллә ни дулкынлану кичермим, сөйләшү дә алай фәнни әңгәмә түгел, менә күрерсез, минем тарафтан барысы да «мажор» булыр... дип кенә торганда, студиягә «Париж» шагыйре килеп керде. Соңарып түгел, район кешесе вакыт запасы калсын өчен иртәрәк йөри, ул, мөгаен, баш мөхәррир бүлмәсендә чәй эчеп, мәхәббәт шигырьләрен сөйләп утыргандыр. Шагыйрь абыйны күрү белән кылт итеп исемә төште — аның телевизордан чыгыш ясаячагын ким дигәндә Кечкенә Парижның ярты халкы беләдер, ул яртының яртысы интеллигенция булыр, ә интеллигенция арасында... Кыскасы, укытучы Зөһрә, бүген тикшерергә дип өенә алып кайткан диктантлар өемен читкә этеп, безнең тапшыруны караячак.

Студиядә бөтен лампалар да кабынса, раштуа суыгы да июль челләсенә әверелә. Ә урамда — минем июль! Шагыйрь абый белән саф һава эзләп чыгып баскан коридор буенча да бөркү җил бәргәләнә. Тел ачкычын майлар өчен, мин шагыйрьнең «Казан утлары»нда чыккан шигырь шәлкемен күпертеп алдым. Мактауга бик исе китми аның, үз каланчасын бик һәйбәт белә.

Ике арада күрешкән саен үзгәрми торган сораулар кабатланды...

«Миңа сәлам әйтүчеләр юкмы?»

«Ник булмасын, бик күпләрдән сәлам сиңа. Кайсысыннан ныграк көтәсең соң?»

«Ярарыгыз инде... Зөһрә йолдыз нихәл анда?»

«Сүнеп бара... Бәхете булмады балакайның. Чибәрлеге башына җитте».

«Ничек инде, башына җитте?»

«Ничек икәнен үзеннән сораша аласың. Чибәр кызларга өметләнеп йөргән егетләренең каргышы төшә бугай ул. Шалтырат».

«Телефонын белмим ич».

«Әтисенең исемен, фамилиясен беләсең, районның белешмәләр хезмәте әйтә дә бирә. Бер түбә астында, әти-әнисе янында өч баласы белән яшәп ята... Ире өшеп үлде бугай. Балалары күреп әйткәндә, Зөһрә чана белән тартып алып кайта иде. Соңгысында күрүче булмаган».

Минем кинәт кенә сорауларым күбәйгән иде. Ләкин студиядә: «Керик әле урманнарга» дигән җыр яңгырады да режиссёр ярдәмчесе безне студиягә ашыктырды.

Тапшыруга дип расланган җавапларым, алдан ук уйланып, үземчәрәк кинаяләнергә тиешле фикерләрем каядыр упкынга очты. Турыдан-туры эфирга чыккан чакта катгый рәвештә тыелган экспромт шаккатыру һәвәсе аның саен ныграк нәфесемне азындырды, күңелгә шайтан керде... Хәзер мин, өйгә — Нуриәхмәт кызы янына кайтасым барын да онытып, Зөһрәгә тиң бәхетсез булып күренергә дә риза идем бугай.

Үзе катнашып караган кеше белә булыр: турыдан-туры элемтәгә чыкканда, баштагы мәлне тамашачылардан сораулар килмичәрәк тора, соңга таба чамасыз

күпкә китә, аларга җавап биреп тә өлгерер хәл юк һәм эфир вакыты да бетеп куя. Тапшыруның ахырында режиссёр киселеп калган сорауларны безгә санап үтә, респондентларның телефоннарын да бирә хәтта. Шалтыратучыларның күбесе җае чыккан саен хәбәрләшергә һәрдаим атлыгып торган таныш әби-бабайлар. Ләкин еш кына көтелмәгән серле исемнәр дә очрый.

Алып баручы кызлар Һади Такташның: «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны яңарта...» дигән юллары белән башлагач, телевизор караучылар баштагы ун минутны өнсез үткәрде, башка каналга күчтеләр ахрысы. Аннан, кунак шагыйрьләребез үзләренең әти-әниләре арасындагы классик мәхәббәт белән горурланып алды. Тагын ун минут узды. Әкренләп дастаннарга күчтеләр... Поэмалардан өзекләр китерү башланды. «Кара-каршы» сөйләшүнең нибары унбиш минуты калгач, реклама вакытында режиссёр алып баручыларның колагына рубриканың ни икәнен пышылдап өлгерде бугай. Ниһаять, күчмә микрофонны миңа бирделәр: «Ничек уйлыйсыз, мәхәббәт — гомумән, нәрсә ул?» — имеш.

Минем күңелдәге теге шайтан чыгырыннан чыккан иде инде, гел киресен сөйләргә тотындым.

«Мәхәббәт дигән нәрсәне шагыйрьләр уйлап тапкан. Чынлыкта андый нәрсә юк. Бер-береңне ошату бар, ияләшү бар. Мәхәббәтләшү — ул никах алдыннан башкарылырга тиешле уен гына, шуңа күрә дә аның гарантиясе тугыз ай гына, кайберәүләрнеке җиде ай да була».

«Алайса көнләшү каян килә?»

«Яши торгач, бер-береңнең малына әвереләсең. Кем инде үзенең малын башкаларга бирергә теләсен. Шуңа күрә дә аерылышканда гражданнар сугышы чыга. Син ташлап качкан хатын белән икенче берәү рәхәтләнеп яшәп кала».

«Сөйгәнеңне югалту мал югалту гынамы? Сезнең югалтып караганыгыз бармы?»

«Минем гомер гел югалтулардан гына тора».

«Анысы язмыш бит аның».

«Язмыш мәхәббәт артыннан йөри, сеңлем».

«Димәк, мәхәббәт бар! Шуңа күрә хыянәт бар».

«Юк, кызлар, мәхәббәт булмаган җирдә хыянәт бар...»

«Ә сезнең хатыныгызга хыянәт иткәнегез бармы?!. Безгә шалтыратучылар бик күп. Ләкин соравыбызга җавап ишетмичә торып телефонны алмыйбыз».

Теге шайтан шундук күңелдән чыгып качты, кызыкка сусаган тынлык белән бергә-бер калдым. Җавап бирмәсәм... кеше көлдерәм дип, адәм көлкесенә калу шушы була инде ул...

«Хатыныма хыянәт иткәнем юк, дисәм, дусларым көләр инде дә... хыянәт иткәнием дисәм — өйгә кайтып керәсем бар... Әйдәгез, җавап шушы урталыкта калып торсын...»

Алып баручы кыз колак аппаратын төзәткәләде. «Алло, тыңлыйбыз сезне. Сез турыдан-туры эфирда. Соравыгызны кыскарак тотарга тырышыгыз. Алло, ал-ло, тыңлыйбыз сезне... Алло... Кызганычка каршы телефон өзелде... Юк, гафу итегез, эфир вакытыбыз беткән. Рекламадан соң хушлашабыз...»

Тапшыру беткәч, «ТНВ»ның иҗат төркеме безне бераз әрләсен әле дигәндәй, тиз генә таралышмадык, һаман нидер көтеп йөрибез. Экранда әйтелмичә, үкенечкә калган фикерләребезне кемгәдер сөйлисе килә. Тимер баскычларны биек үкчәсе белән саный-саный режиссёр ханым төште.

— Әйбәт булды. Үзебезчә инде, — диде дә ул миңа трамвай билеты чаклы гына кәгазь кисәге тоттырды. Телефон номеры иде анда... Ну кем исеме икәне аңлашыла инде!..

Хатларыма бер дә җавабын алмагач, мин телефон номерында аның кулын танымадым. Исемен күргәч кенә: «Зөһрә үзе!» — дип куйдым. Шушы кәгазь кисәге белән кәл арасында пыскып яткан кузларны җилпеп учак тергезәсем килде; җавапсыз калган хатларымның эчтәлеген искә төшерергә тырыштым; Кечкенә Парижга кайтыр өчен автобуска билет бирделәрмени?!. Кыскасы, мин үземне мәхәббәткә лицензия алган хыялый кебегрәк хис иттем. Һәм студиядән тирләп-пешеп чыккан мәхәббәт теоретикларын кызганудан мәрхәмәтсез елмаеп куйдым.

***

Өебезнең почта тартмалары беренче катта. Безнең 48нче фатирныкы ни өчендер нәкъ лифт ишеге каршына туры килгән. Көнгә ике кат актармасаң, реклама гәҗитләре ташып чыга, айга бер сөендерә торган журналлар яртылаш сыймый калып, шук кулларга да ияреп китә. Лифт көткән арада почта тартмасын капшап карау гадәтебезгә сеңгән. Тышкы яктан буш кебек күренсә дә, никтер ачып карыйсы иттем. Автосалоннан хат килгән. Лифтны өнәмичә генә баскычларны санап менеп киттем. Урталыкта туктап, «Автосервис» дип бизәлгән конвертны ачтым. Иске машинам төсендәге чия-кызылын сораган идем, тиз генә булмаячак, дигәннәр. Ак, кара, сары төстәгеләре салонга чыкты, бәяләр артуы көтелә, ашыгыгыз, дигәннәр. «Бәяләр артуы көтелә» дигән сүз безнен ишеләр өчен «Каравыл!» кычкыру белән бер инде ул... Яна машинаның кара төсе дә ярап торыр, ашыгырга кирәк иртәгә... Иртәгә мин иске машинамны утильгә тапшырып, яңа «Форд-фокус»ка утырып, Зөһрәне эзләп китәм...

***

Мин — социализм калдыгы. Егерме елга алдан төзелгән КПСС программасы буенча Илне күтәрүдә катнашкан буын вәкиле. «Утилизация программасы» дигән рекламалар шаукымын күреп, әллә яңадан коммунизм төзүгә кучәбез микән дип сөенгән идем...

Автосалоннар уйлап чыгарган сәүдә уены икәне дә билгеле, алдап-йолдап юмалауларын да беләбез үзе, барыбер алданасы килә, күбрәк алданган саен ныграк ышанасы килә...

Тимер юл тармагына терәп калай койма корганнар. Капка янына килеп туктауга, номерларны салдырып кулыңа тоттыралар да үзләре синең машинаңа утырып кереп югалалар. Ул арада, вакыт әрәм итмичә, дүрт бүлмәле такта чатырның ишек төбенә чиратка басасың, фамилияңне атап чакырып алалар да, домино уйнаган ише, «шалт та шолт» мөһер сугалар. Синең белән сөйләшкән кеше юк, нәрсә эшлиселәре конвейерга салынган. Һәм, соңгы кат шапылдатканнан соң, кулыңа «справка» бирәләр дә: «Менә моны автосалон кассасына тапшырасы. Сау булыгыз! Следующий!» — диләр. Үземнең беркатлылыгыма аптырап, тегеләрнең шомалыгына сокланып чыгып киттем.

Торгынлык чорында 25 меңгә сатып алынган «шестёрканы», унбиш ел буе йөреп туздырганнан соң, тотрыксыз сәясәт чорында 50 меңгә бәялибез, дигәннәренә ничек ышанмак кирәк? Ата-аналарны җыелышка чакыра торган кош теле хәтлек кәгазьне справка дип атап, кече лейтенант йолдызы чаклы гына пичәт сукканнар да — шуны кассага 50 мең сумлык акча дип тапшыр, имеш!.. Ваучерга да, облигация, заем, сертификатка, хәтта лотерея билетына да охшамаган гап-гади кәгазь кисәге бит ул!

Мин «Чаян» журналында эшлим, дип бер-ике сорау бирергә тел кычытып тора торуын, ну ярамый, кесәдә гаиләнең ике еллык бюджеты. Алла

сакласын, иске машинамны да ташлап калдырдым, янасыннан да колак кагуым бар...

Җәйнең бер көне кышның ике көненә тора, дигәндәй, автосалонга килеп җиткәндә, төшке аш турында сүз чыгаручы күренмәде әле.

Кара төстәге «Форд» бик тиз ошады мина: Сәвия белән җыйган шомырт кебек елкылдый; фаралары Рәшидәнең күз явы кебек — ирләрнең күз карашын бик тиз тотып ала; Зөһрәнең толымы кебек күпереп тора... Әле дә ярый, чиякызыл төслесе юк икән, йөрер идең аннары иннек савытында... Менә бу машина белән Зөһрәләрнең капка төбенә кайтып туктасаң да ярый, кемне санламаганын, нинди егетне югалтканын белсен!.. Абау, гап-гади «Форд» янында да нинди мактанчык уйлар били. Ә «БМВ», «Мерседес», «Каделак» кебекләренә утырсаң — җиргә төшә алмассың... Әйе, тирән эчле күн креслога чумып, машинаның минеке булганын көтеп утырам. Сату-алу кәгазьләрен компьютерда җыйган арада менеджер кыз ярты сәгать буе туктаусыз елмаеп торды. Ана карап мин дә авызымны җыя алмадым. Шунысы гына сәер тоелды: ниндидер акция дигән булып, алар мина дүрт кышкы көпчәк бүләк иттеләр...

Абзагыз — 70нче елларда ук «МАЗ»лар, «ГАЗ»лар йөрткән кеше, шулай да шәһәр эченнән үткәндә, яна машинам өчен курку, тыелгысыз сагаю бар иде, рульгә ике куллап ябыштым. Олы юлга чыккач кына, заманча эшләнгән чит ил машинасының яналыгын, куанычын, иркәләп назлавын тоя башладым...

Кечкенә Парижның ярты юлын узгач, ике район арасындагы межада туктадым. Машинам тирәли ике әйләнеш ясадым, көпчәкләренә типкәләдем, кульъяулыгым белән ян көзгеләрен сөрттем... Район җитәкчеләре чәкчәк күтәреп, гармун уйнап, җыр-бию белән язучылар төркемен каршылый торган капка бу. Бүген монда тынлык. Июль кырларына хуҗа булып калган тургайлы болытлар узса да, әле һаман сайрап тора. Әгәр җәяүләп китсәм, алар мине Зөһрәгә чаклы озата барырлар иде...

Әйтерсең лә ике район уртасындагы ачык капкада түгел, ә язмышымның кыл уртасында басып торам... Зөһрәнең тавышын тургайлы болытлар аһәненә кушып тынлар өчен табигать һәм җәмгыятьнең иң гүзәл урыны! Хәзер, хәзер, шалтыратам да әйтәм: «Киләм. Өегезнең кайда икәнен белмим...» Хәзер, хәзер... Киләм дә бөтенләйгә синең янда калам!

Кесәләремне капшыйм, барсетканы (кечкенә сумка) актарам, яна машинамның киез иләнен кармалыйм — телефоным юк! Автосалонда төшеп калганмы? Юк! Мин анда чакта берәү дә шалтыратмады... «Төшеп калган» дигән имеш уйларымны томалап кына торган, исемә төште — мин телефонны гел «Жигули»ның вак-төякләр шүрлегенә салып куя идем. Шунда онытылып калган. Бер көндә күпме вакыйга, күпме яналык! Тәэсирләрдән башың әйләнерлек... Тургайлы болытлар, сүз куешкандай, берьюлы сүнде. Бөтен биографиямне саннарга бүлеп тутырган арадашчымны, үткәнем һәм киләчәгемне үз кулларым белән утильгә илтеп тапшырганмын...

Эш сәгате беткәнче кайтып өлгерим, дип, эленке-салынкы йөргән машиналарны узып, тизлек чикләүләргә кул селтәп, ярамаган борылышларга кереп, Казанга ыргылдым. Ыргылмадым, очтым! Иң мөһиме — кеше таптатма, кызыл утка керма! Калганнары — штраф кына...

Калай коймага килеп терәлгәндә, эңгер-меңгер төшкән иде инде. Шәһәр өстен тоташ болыт каплаганга, кояш баеганны күрмәдем.

Тимер коймa бикләнмәгән әле. Яшел камзул, киндер бияләй кигән ике егет килеп чыкты. Минем телефон мәрәкәсен ишеткәч, рәхәтләнеп көлделәр. Түздем. Әйдә, күрсәтәбез телефонынны, диделәр дә пресслау өстәленә алып киттеләр. Янәсе, әнә бүгенгенең җиде машинасы, үзеннекен таны шуннан... Брежнев

заманындагы төсле телевизор чаклы гына жиде шакмак арасыннан үземнең «вакыт машинасын» күреп алдым: пешкән чия төсендәге кыерчыклары; тузган бусагасын түбә калае белән тышлаганда чыгып калган шөреп башлары; турайтканда чатнаган бампер жыерчыгы — барысы-барысы миннән калган эзләр...

Мал югалту газабы озакка сузылмады. Урам ягына чыгып, калай коймадан ерагайган саен, Жирнең тарту көче отыры кими баргандай тоелды. Әйтерсең лә шушы тимер шакмакка әверелгән иске машинаны телефоны-ние белән моңарчы гел күтәреп йөргәнмен һәм бүген аны вакыт дигән кырыс хөкемдар үзе минем иңемнән төртеп төшергән...

Мин кайтканда, һәрвакыт, ишегалдына карый торган өч тәрәзәбез дә өй түрен яктыртып балкый торган иде. Ә бүген никтер тәрәзәләрнең кояшы сүнгән. Дөм караңгы бүлмәгә килеп кердем. Ут кабызырга ашыкмадым, әүвәл тынлыкны тыңладым. Аннан соң гына, ул-бу юклыкка ышангач кына, бушлыкның сәбәбен ут кабызып эзләдем. Болар минем хыянәтемне каршы алмас өчен, бәхетле бул, дип фатирны бушатып куйганнармы? Нуриәхмәт кызы, улым, әйтсәм әйтим, бишек чаклы көмәне белән килен — өчесе тиң кая барып сыенсыннар?.. Шкафны ачкач, эчемә жылы керде, бар да урынында. Хатын-кыз, кием-салымын төяп бетерә алмаса да, бизәнү әйберләрен калдырмас... Алары да урынында. Менә кайчан кирәк ул кесә телефоны!

Базар тормышының яхшы яклары да бар — сәүдәгәрләр төн уртасына чаклы эшли. Өйдәге утны сүндереп тә тормыйча кибеткә йөгердем. Яңа телефон алып кайтканда, плитәдә онытылып калган чәйнекнең сыбызгысы сызгырмый иде әле.

Яңа «sim»кага иң беренче булып Нуриәхмәт кызының номерын яздым. Чит кеше шалтырата дип сагаеп калган иде. Мин икәнен аңлап алгач, бик тиз кыюланды. Ну, шуннан башланды инде...

Элемтә өзелгәч, кичкә кадәр үземнән хәбәр көткәннәр. Аннан соң: башта үлгәннәр арасыннан эзләгәннәр, хезмәттәш дуслардан сорашканнар, ГАИга килгән хәвефле хәбәрләрне белешеп утырганнар...

Һәр хатынның ирен сүгәргә тиешле лимиты бар, туган көнем аркасында минекенең лимиты сарыф ителмәгән килеш тора иде. Ялгышып яңа телефонымның «громкая связь» дигән төймәсенә басканмын. Нуриәхмәт кызының ачуны китерми торган тембрлы һәвәскәр тавышы фатирны яулап алды: «Ярый әле машинаң эчендә үзең онытылып калмагансың! Кесәң тутырып акча күтәреп йөрдең, без нәрсә уйларга тиеш идек икән? Исән хәбәреңне житкерер өчен переходта хәер сорашып утырган кеше дә телефонын биреп торыр иде. Нинди этлек кылып йөргәнеңне белмибез дисеңме? Яшьлектәге тургайларыңны эзләп йөрсәң, өеңдәге кенәриеңне очырырсың әле. Мәхәббәт шизофрения кебек чир бит ул — язын-көзен яңара торган... Безнең кадерне белмәсәң, хет олпат яшеңне хөрмәт ит, оныгың туарга тора! Базарда бер дә карт ит сорамыйлар, тана йә үгез бозау юкмыни, диләр. Фирдәвес апа Гарипованың соңгы нәсыйхәтен исеңнән чыгарма: калган гомереңне шушы хатының белән яшәп бетер, диде ул сиңа, онытма! И, давай, вакыт әрәм итеп йөрмә — язуыңны бел!..»

Укытучы гаиләсендә үскән Нуриәхмәт кызының һәр сүзе шигар булып бүлмәдән бүлмәгә күчә дә кайтавазы янә жаныма килеп бәрелә; фатирыбыз яшәү гаме белән тула; йокы бүлмәсенә иман нуры күчә; өметем яшәрә... Шушы хакыйкатьне аңлар өчен, үзең ялгышмыйча башкалар тәжрибәсен өйрәнеп кенә бәхеткә ирешеп буламы? Яшьлек жүләрлеге белән, әйе, диярбез... юк шул, юк, диярбез акыл кергәч. Минем язмышка тагын никадәр кешенең язмышы сыйган! Минем бәхеттә — күпме кешенең бәхетсезлеге һәм күпме югалту?!. Яшьлек хатасын төзәтәм, дип тагын күпме хата ясадым.

***

1981 елның көзе. Язучылар оешмасында проза секциясенең чираттагы утырышы. Яшь язучы Разил Вәлиевнең «Яшисе килә» дигән повесте турында сөйләшү көн тәртибенә куелган иде. Түрдә, әдәби консультант Илдар Юзеев янында, секция җитәкчесе Атилла Расих, председатель урынбасары Фәрваз Миңнуллин, җаваплы секретарь Мөсәгыйт Хәбибуллин утыра. «Казан утлары»ның тәнкыйть бүлеге мөдире Мансур Вәлиев, проза секциясенең секретаре Марсель Галиев һәм мин — союзның пропаганда бүлеге уполномоченные, ян өстәл артында утырабыз. Кыскасы, штатный хезмәткәрләр җыелдык, ирекле язучылар никтер килеп җитми әле. Ниһаять, Ләбибә Ихсанова күренде, Кояш Тимбикованы култыклап, бик акрын адымнар белән Фатих Хөсни килеп керде. Мөхәммәт Мәһдиевтән соң шактый гына тынлык урнашты. Повестьның авторы председатель Гариф Ахунов белән Чаллы бүлекчәсенә җаваплы кеше булып расланырга киткән иде, кайтып җитәргә тиешләр. Көтәбез... Секция җитәкчесе, ветеринария фәннәре докторы Атилла Расих, әдәбиятта еш күзгә чалына торган бер хатаны төзәтеп алды. Биянең кулкасы дөп-дөп суга иде, дигән сүз дөрес түгел икән. Айгырның гына «кулкасы суга» икән, ул да әле кулка түгел икән... Көлү озакка бармады, тагын тынлык урнашты... Шунда Кояш Тимбикова «кулка» темасына исе китмичә йокымсырап утырган 73 яшьлек Фатих Хөснинең касыгына төртте.

— Нихәл соң, Фатих абый?

— Нәрсә дисең?

— Кызлар мәсьәләсендә нихәл соң, дим?!

— Ә-ә-ә... аны әйтәсең икән, — Фатих Хөсни утырыштагыларга күз йөгертеп чыкты да, безгә — яшьләр ягына борылган килеш калды. — Егетләр, хатын-кызның бөтенләй кирәге юк икән аның, вакыт әрәм итмәгез, языгыз! — диде.

Мәхәббәт һәм язмыш темасының «Йөзек кашы» булган классик язучы авызыннан шушындый киңәш чыккач, ирләргә кушылып ханымнар да көлгән иде...

Утыз ел үткәч, Фатих абыйның әйткәне искә төште дә, ялгыз фатирыма ямь өстәп, рәхәтләнеп кычкырып көлдем... Мин үзем дә Фатих Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты бит әле...

***

«Бюрократ» кибетеннән күп итеп ак кәгазь күтәреп кайттым.

Яшәлгәнен язып барам...

Язасыларын яши торам...

Килен кыз бала тапты. Ясминә дип исем куштык: буе өч карыш, авырлыгы сигез кадак...

Иртәгә бәллүр биләүне яңа машинабыз белән өйгә алып кайтабыз.

Мин иртәгә яңадан яши башлыйм...

*(Беренче китап тәмам)*



Җәүдәт
Сөләйман

# ЮГАЛЫР КҮК БУ МИЗГЕЛ

## Бәхет–сагыш — бер көянтә

Олаулап татар сагышы...
Бәгыре — челтәр-челтәр...
Халкыма бәгырен ямарга
Бәлки шул сагыш җитәр?
Бәхет акылны тарата,
Канатын кага-кага...
Сагыштан адәм югалмый,
Бәхеткә чыдап кара...

Бәхет-сагыш — бер көянтә, —
Тотрыксыз... уйнап тора...
Язмасын ла интегергә,
Бер кашык сагыш сорап...

***

Һәр җанлының үз әмәле,
Үзенә хас үсү мәле...
    Бамбук үсә өскә, өскә,
    Умырткасын тота көчкә,
Сөямләп үлчи тәүлек.

Үсә имән түбән белеп,
Тамырларын барлый элек,
    Ботакларын җәя санлап,
    Еллар үтә, үсә җайлап,
Яфракларга күмелеп.

...Кипкән яфрак, саргайган сын,
Күккә этә яссы башын —
Биеклекне бамбук даулый.
...Гасырларда имән шаулый.

---

Жәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) — *галим, шагыйрь; ТР Фәннәр академиясе академигы, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты. «Ямаулыклар», «Мин — минсез дөньяда», «Күләгәләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Кеше, сине чагыштырам кое белән,
Сокландыра тирән кое суы белән,
Чыкса-чыгар чылбыр чыны буш коедан,
Мәгънә булмас хәтта өстән су коюдан.
Кешене дә кеше күрәм шунын белән —
Ан-белеме шат йөзенә чыгу белән,
Уй-фикере саф һәм чиста булу белән,
Айкалмаса, кысыла-кысыла тешләренә,
Буш коеда буш чиләктәй теле генә...

## Өмет

Тәнем-җаным җитмәс,
беләм.
Тик, иншалла,
житәр каным, —
Миндә туган рух тамчысын
Чишмә итәр оныкларым.

Тузганак та,
жил дә булмас,
Мин ялгаган өммәт мәле.

Фани дөнья бәгырендә
Сөләйманнар күзәнәге...

***

Мин — диңгез дулкыны,
туз, елга!
Түзегез сугылган ярлар да.
Үзем дә кыйналам ярларда,
үзем дә сыкранам елгада.
Ни кылыйм — сыймыйм ла елгага...

Ни кылыйм — сыймыйм ла елгага...
Төшкәнмен жил куган болыттан.
Мин — дәрья айкарга яралган,
диңгезгә, дәрьяга юл тотам.
Гаеп юк сездә дә, миндә дә...

Гаеп юк сездә дә, миндә дә,
ишкәкле көймәләр,
бигайбә! —
тактагыз тактага тузганда,
кораблар йөртәсе иннәрдә.
Туз, елга, әзенә, күп түзден...

Туз, елга, әз генә, күп түздең,
ишетәм туфан-су тавышын.
...ярларың тын алыр беравык,
жайланыр бервакыт агышың...
Мин — дингез дулкыны,
туз, елга.

***

Жәй.
Иң рәхәте —
жиләк исле
печән чүмәләсе күләгәсе.

Көз.
Талган жанга иң татлысы —
йөрәк кушкан кәсеп күләгәсе.

Кыш.
Мәңгелеккә ялгый
оныклардан төшкән
нәсел күләгәсе.

Яз.
Күңелләрдә шундый якты —
әйтерсең лә дөнья —
к ү л ә г ә с е з.

***

Өзелгәнем,
жирдә эзләгәнем —
язлар сыйдырырлык бөреләр,
кояш сыенырлык күңелләр.

...Жирдә сөрү, көзге сөрү бара,
жем-жем ужым — язга ялгама,
ужым кырын күреп, урап кайтсам,
өзелеп килгән өмет ялгана...

Һәр тамчыда
        чагылмыйдыр
умырзая елмаюлы яз-бикә...
Һәр тамчыда
        күзләмә кояшны...
Шыбыр-шыбыр коя тамчы-яңгыр —
Тып-тып иткәннәре — кояшлы...

Язлар бит ул күктән-күккә ята,
офыкларны этеп як-якка.
Тамчы сыйдырмый дип
        килми каламыни язлар,
сыенырлык бөре бар чакта.

***

Арыш мыегын кытыклап
тибрәнә көмеш рәшә,
рәшә белән, тияр-тимәс,
арыш нидер серләшә.
Кояш нуры чак-чак сыйпый,
чү! болыт, каплый күрмә,
әнә, жил дә исми хәтта,—
югалды Зирекледә.
Бу бит тылсым, могжиза, дип,
Тын тора йөрәк — сизгер,
...тургай жыры кагылса да
югалыр күк бу мизгел.

***

...Жир йөзенә карап
Тәңре уйга талды...

Кара савытына
ап-ак кара салды.
Ак тамчылар, чәчрәп,
төнге күккә тамды.

Кара савытына
яшел кара салды.
Кара кипте, унды,
өмет исе калды.

Кара савытына
зәңгәр кара салды.
Зәңгәр күлләр булып
зәңгәр хыял калды.

Кара савытына
кара кара салды...

...Жир йөзенә карап
Тәңре уйга калды...

## Татар йорты

Татар йортын тымат нигез тота,
Катлы-катлы сарай салырлык.
...Бер катына тулып йоклый татар,
Идәненә жәеп... сабырлык.

Туры басса, түшәм башка бәрә, —
«Бөек» шигырь, «бөек» көйләрдән.
Ә нигә, ди, безгә биек түшәм —
Шуышырга күпләр өйрәнгән.

Биек түшәм кирәк түгел безгә,
«Бөек» түшәм каплый күкләрне,
Өч-дүрт катлы йортлар буладыр дип
Аңына да керми күпләрнең...

Татар түшәменең матчалары —
«Мин-мин» шагыйрь, «мин-мин» түрәсе,
Шул түшәмнән ары күк күрмәгәч,
Такырая бара түбәсе...
И татарым...

***

Бәхетме? —
аяк тавышларын узып,
әни безне каршыларга чыккан...

Бәхетме? —
әни белән без бишебез,
оныклар да шунда, туган йортта...

Бәхетме? —
әниемнең елмаюын күрәм
самавырның жиз йөзендә...

Бәхетме? —
дәшә алам минут саен бүген
«әни» диеп жир йөзендә...

Бәхетме? —
әниненң дә, үземнең дә
«улым» диеп дәшкән чаклар әле.

Бәхетме? —
озын гомер, саулык биреп,
сине, әни, Тәңре саклар әле...

Бәхетме? —
әниненң
...әрләве, сүгүе,
бәрүе, тетүе, дәшмәве...
...бары тик яшәве, яшәве...
бик озак, бик озак яшәве...

## Олы сәфәр

Тәңрегә юл ачылганда
вакыт килеп,
Елмаюга әверелсә
соңгы тының,
Димәк, Тәңре сине юкка яралтмаган,
Бөек мәгънә тулы икән
елмаюың...

...Жиһан куермасы Жиргә иңгән мизгел —
Тәүге сулыш тулы орлык
бу моң-хәят.
Мәхәббәтне хакыйкатькә үрә-үрә —
Жир-сүрәдә язылачак
яңа аять.

Кара жирдән алып зәңгәр күккә кадәр,
Тетелгән жан
мамык булып күпергәнче —
Нәфес аша сузып,
Рух таракта тарап,
Нечкә Акыл кылларына тидергәнче —

Жиһан-тәңгә үрелгәнче нәфис кыллар —
Күпме сугу,
күпме кагу,
күпме гамәл?
Тигезләмә чишә-чишә уза гомер,
Син бәхетле — жан тетүгә тапсаң әмәл.

Үзәгеңә тынгы бирмәп тетелсә жан,
Өч дөньяңны тоташтырса бер көй, бер моң —
Соңгы сулыш тәүге сулыш булыр, Аллам:
Ике дөнья арасында — арадашчың...

Адәм булып
фани Жирдә Син бәхетле:
Елмаясың — чөнки кала салган эзләр,
Жан жепләрен жайлар өчен кулай диеп,
Әзме адәм шул эзләрдә жанын эрләр.

Бакый күккә кушылгач та — Син бәхетле,
Саф нурларга юллар ачык синең аша,
Тәңре нуры — Жан кылларың — Жир уллары,
Бу мәңгелек
булмас иде
синнән башка...

...Бакый юлга сәфәр чыккач, и адәми,
Елмаюдан балкып чыкса
соңгы тының, —
Канатлары булып тәүге сулышыңның
Мәңгелеккә алып керер елмаюың...



Гомәр
Даутов

# МОҢНАР БУЛЫП КАЙТЫРМЫН

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Урманнар артында — балачак

...Кечкенә Фима бернәрсә дә анламый иде. Урамда нindидер ямьсез тавышлар ишетелә, ишегалдына уйнарга чыгучы юк; һәрвакыт ягымлы, һәр теләген үтәргә торучы әнисе дә малайга игътибар итми, йөгерә-йөгерә нидер җыя, нindидер төенчекләр төйни. Әледән-әле күрше апалар йөгерешеп керә, тиз-тиз генә нәрсәдер сөйләшәләр дә тагын чыгып китәләр.

Фиманың әтисе Дмитрий Мерзон исә фатиры һәм гарнизон арасында бәргәләнә иде. Чик буе гаскәрләре белән элемтә юк, бөтен юллар җәяүләп тә, машинага утырып та чигенүче гаскәрләр белән тулган. Кемгә ышанырга, кемне тыңларга белмәссең. Бөтенесе бергә тупланган өр-яңа Т-34 танкларының күбесе, оператив киңлеккә чыга алмыйча, Люфтваффе бомбалары һәм фашист гаубицаларының снарядлары астында янып беттеләр. Яшь офицер ныклы карарга килеп өенә йөгерде.

— Катя, Катерина, — дип кычкырды ул, ишектән керүгә үк кечкенә Фиманы куркытып, — җыен, җыен тизрәк!

Һәрвакыт тыныч иренең болай әсәренгәнен беркайчан да күрмәгән Екатерина Семёновна эшнең җитди икәнен шунда ук аңлап алды.

— Без әзер, — диде ул тыныч тавыш белән, бары тик күзләренең зураеп, йөзенең агарып киткәнлеге генә аның нерв киеренкелеген күрсәтә иде. — Без әзер, нишләргә?

Дмитрий эндәшми генә Фиманы күтәреп алды да икенче кулына агач чемодан һәм берничә төенчекне эләктерде. Екатерина Лиляны житәкләп, кочагына сыйган кадәр төенчекләр алды да ире артыннан ишеккә юнәлде. Кинәт бусагада туктады да бушап калган фатирга борылып карады. Акыллы иде, шуңа күрә бүтән монда кайта алмаячакларын аңлады. Гасырлар дәвамында бөтен дөнья буйлап сибелеп киткән ата-бабаларының генетик дәрәҗәдә формалашкан интуициясе баш калкытты — дөнья кузгалган, дөнья болганган чак, кире кайтулар булмаячак...

Аста көтеп торган машина әрҗәсенә әйберләрне ыргыттылар да Екатерина балаларны кочаклап кабинага утырды. Дмитрий шофёр ягыннан баскычка басты да тимер юл вокзалына юнәлделәр. Бераз баргач, юлны бертөркем кызылармеецлар белән офицер бүлде:

— Тукта, — дип кычкырды ул, еракtan кулларын бутап, — тукта, ... мать!

Дмитрий рульдәге солдатка иелде:

— Туктыйсы булма! Ни булса да, туктама! Юкса атам!

Үзе жиргә сикерде, сикергән уңайга кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды да төркемгә төбәгән килеш машина белән янәшә йөгерә башлады.

— Лейтенант, кит юлдан! Машинада минем гаилә! Ике дә уйламыйм, атам! Кит!

Мондый тәвәккәллекне көтмәгән солдатлар як-якка сибелде. Берүзе калган лейтенант калтыранган куллары белән кобурасына ябышты, өстенә килгән машинадан сакланып, читкә сикерергә мәжбүр булды. Ул арада узып киттеләр, Дмитрий янадан баскычка сикереп менде. Шул минутта ир-атның тормыштагы миссиясен аңлады бугай Фима: ул таяныч, куркыныч килгәндә яклаучы, утка һәм суга беренче керүче, иң төп авырлыкны күтәрүче булырга тиеш икән.

Тимер юл вокзалына баш тыгарлык түгел иде. Дмитрий бөтенләй икенче якка, вагоннар торган платформага таба атлады. Лиляны җитәкләгән Екатерина аның артыннан чак-чак өлгерә иде. Вагоннарның берсеннән кычкырган тавыш ишетелде:

— Дмитрий! Мерзон!

Дмитрий вагоннан иелгән өлкән яшьтәге проводница хатынга Фиманы, аннан Лиляны тапшырды.

— Ну, Катя, — борылып, хатынның инбашларыннан тотып, күзләренә карады. — Аңлыйсың, очраша алмабыз, ахры. Бу — гади сугыш кына түгел. Бу — кешелеккә каршы сугыш.

Екатерина үзенең ныклыгына үзе аптырап тора иде. Мөгаен, аерылышу ачысы соңрак килер, ә хәзер бөтен фикер, бөтен көч балаларны моннан алып чыгып китү бурычына тупланган. Вагоннар дерелдәп бер-берсенә бәрелеп куйдылар да әкрен генә кузгала башладылар.

— Катерина, — дип кычкырды проводница, — нишләп торасың? Каласың бит!

— Барыгыз! — Дмитрийның тавышы хәрбиләрчә кырыс яңгырады. — Катя, балаларны сакла!

Екатерина перрондагы халык арасында бик тиз күздән югалган ире ягына озак карап барды. Аларны икенче, ят тормыш, ят урын, ят кешеләр көтә иде. Ике баласын — Лиля белән Ефимны иярткән яшь ханым тәвәккәлләп билгесезлеккә атлады.

***

Гомере буе татар теленә, татар моңына гашыйк булып яшәгән Ефим Дмитриевич Мерзон — милләте буенча яһүд кешесе. Алабуга пединститутында эшли башлагач, мин әлеге шәхес турында торган саен ешрак ишетеп, аның тормышы белән ныклабрак кызыксынырга тотындым. Үз татарың татарлыктан качканда, аның, яһүд кешесенең, үз балаларын да татарча камил сөйләшергә өйрәтеп калдыруы нинди дер бер феномен булып тоелды. Институтыбыз директоры Елена Ефимовнадан әтисе турында сорашкач, элек аны белгән кешеләр белән аралашкач, кочак-кочак хатирәләр, кассета-кассета язмалар туплана башлагач, минем әлеге шәхескә карата булган ихтирамым артканнан-арта барды һәм кулыма каләм алырга мәжбүр итте дә инде.

Ефим Дмитриевич Мерзонның туган шәһәрен, Көнбатыш Украинаның Винница өлкәсендәге Жмеринканы, гитлерчылар 1941 елның 17 июлендә яулап алалар. Бу урында, беркадәр чигенеш ясап, тарихи белешмәгә тукталып үтәсем килә (Жмеринка геттосы әсире Соломон Крапольский хатирәләреннән): «Жмеринка — Киевтан 200 чакрым ераклыкта урнашкан шәһәр, сугыш вакытында

күпне кичерә. Аны сугыш башлануга бомбага тоталар, ә 1941 елның көзенә Жмеринка геттосы инде чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алына, монда тирә-яктан һәм Румыниядән — чөнки бу территория Румыния юрисдикциясенә әлегә — яһүдләрне куып китерә башлыйлар. Шәһәр коменданты румын кешесе була, ә геттоның үзендә яһүдләрдән жирле үзидарә оештырыла. Күпмедер вакыттан соң аның рәисе итеп доктор Герман билгеләнә. Нәкъ менә шул кеше аркасында Жмеринка геттосында тормыш, башкаларныкына караганда, яшәү өчен уңайлырак була».

«Уңайлырак була...» Чәнечкеле тимерчыбык артындагы тормыш хакында болай дип әйтергә, гомумән, мөмкин микән? Гетто хакында яздым да, бүгенге Украинадагы хәлләрне күз алдына китереп, уйлап куйдым: шайтан чәчкән орлыклар нигә шулай үрчемле була икән? Славянск, Крамоторск, Одесса шәһәрләрендәге канлы вакыйгаларны оештыручылар геттодагы тормыш турында хәбәрдар түгел микәнни? Берәү дә «таяк ике башлы» дип уйламый микән? Якты кояш, иркен жир йөзенә һәркем үз бәхете белән туа лабаса, ул бәхет — яшәү яме — безгә Аллаһ тарафыннан бирелә һәм беркемнең дә аны тартып алу хокукы юк...

Дүрт яшьлек Фиманың (әнисе Ефимны яратып шулай атый) әтисе, танк гаскәрләре офицеры, сугышның беренче көннәрендә үк тревога белән кубарылып, ут эченә керә. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк күктә хакимлек яулап алган кара тәреле авиация баш күтәрергә дә ирек бирми. Тыныч вакытта авызларыннан гайрәтләнеп ут чәчкән комиссарлар, беренче ату тавышын ишетүгә үк, персональ машиналарына утырып, көнчыгышка, үзләре сакларга тиеш булган ил түренә качалар. Дмитрий Мерзон кебек сугышчан офицерларның шактые үзебезнекеләр — паникага бирелгән, куркудан кешелеген югалткан үз солдатларыбыз — тарафыннан үтерелә, кайберләре оборона оештырырга тырышып, дошман пулясыннан һәлак була. Шәһәрдә аңлатып булмаслык ыгы-зыгы: әледән-әле сугышчылар төялгән машиналар үтеп тора, тегендә дә, монда да немецларның десант төшерүе, шәһәрнең чолганышта калуы турындагы ялган хәбәрләр тарала...

***

Фима ниндидер ят тавышларга уянып китте. Баштарак кайда ятканын аңламады, як-якка, өскә карады. Сәер, ятагы селкенми, тирә-якта өзлексез йөренеп торган кешеләр дә күренми. Ә, алар бит инде поездда түгел, кичә кич, күз бәйләнә башлагач, урман уртасындагы бер авылга килделәр.

Малай түшәмгә карады. Агач түшәмдә әллә нинди бизәкләр бар. Озаграк карап ятсаң, эткә дә, төтеннәрен бөркеп чабучы паровозга да охшаган сурәтләр күрергә мөмкин. Болай яту туйдыра башлагач, Фима торып утырды. Чалбарын киеп, иңбашлары аркылы элэктерә торган бауларын кия-кия ишеккә юнәлде. Ишекне ачып җибәрүгә, яп-якты кояштан күзләрен челт-челт йомып, аптырап туктап калды. Кояш инде шактый күтәрелгән, ямь-яшел үлән баскан ишегалдының бер почмагында да күләгә калдырмаска теләгәндәй яктырта. Шәһәрнең соры ташына, тузанына өйрәнгән Фима яшел үләнгә шикләнеп кенә аяк басты.

Киләчәктә зур-зур оешмаларны җитәкләячәк, дистәләгән, йөзләгән автомашиналары булган автотранспорт предприятиеләрен бөтен республика буенча беренче дәрәҗәгә күтәрәчәк, Татарстанның иң күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралашып яшәячәк, Ефим Дмитриевич Мерзон исеме белән бөтен Татарстанга танылачак, әлегә кечкенә малай Фиманың татар җирендә беренче адымнары иде.

Ләкин шулай да Украина кунагын иң гаҗәпләндергәне сәер тынлык иде. Колак шулхәтле күнеккән өзлексез тәгәрмәчләр шакылдавы, кешеләр кычкырышы, паровоз гудогы тавышлары юк, әмма абсолют тынлык дип тә булмый. Һава күз күрмәгән, колак ишетмәгән бөҗәкләр, кошлар тавышыннан яңгырап тора сыман. Ул игътибар белән тыңлана башлады: юк, бу тавышлар моңа кадәр булганнарына карый ниндидер билгеле бер тәртипле матур аһәң белән аерылып торалар. Малай үз тормышындагы бик мөһим, бик кирәкле нәрсәсен тапкандай булды. Ул әле моның табигать музыкасы икәнен һәм әлеге музыканың күңеле түрендә яткан сәләтен уята башлавын, йөрәгендәге иң матур кылларны кузгатып җибәрәчәген аңлатып бирә алмый иде.

Беренче көн тагын әллә нинди тәэсирләр алып килде. Малай ишегалды хуҗасы, төрле төстәге каурыйлардан торган кием кигән әтәч белән сугышты, «га-га» килеп, инде үсеп җиткән, май туплый башлаган бәбкәләрен ияртеп йөрүче казлар, мөгри-мөгри кайтучы сыерлар күрде. Мөгезләрен бик усал кыяфәттә чайкасалар да, аларның бик юаш мәхлуклар икәнен аңлады. Ә менә кәҗә сакалбай усал, әнисе әйтмешли, «вредный» икән.

Алар яши башлаган авыл Башкортстан автономияле республикасының Шаран районындагы Хафиз авылы икәне аңлашылды. Өй хуҗаларының исемнәре Гайсә бабай белән Фәхерҗамал яки, авыл халкы гадиләштереп әйтмешли, Җамал апа икән. Гайсә бабайны малай беренче көннән үк үз итте. Кечкенәрәк буйлы, бераз гына кәкрерәк аяклы, беркайчан да ашыкмый һәм беркемгә дә ачуланмый торган бу бабай Фимага «улым» дип эндәшә. Улым сүзенең нәрсә аңлатканын башта аңламаса да, бабайның ягымлы тавышы, яратып каравы бу сүзнең якын кешеләргә карата әйтелгәнен аңлата һәм малайда иркәләнү хисе уята иде. Ә менә Җамал апа кырыс, эшкә аяусыз. Беркайчан да тик тормый, гомумән, Фима Җамал апаны беркайчан да йокламый, йокының нәрсә икәнен белми дип уйлый башлады. Ләкин кырыс булса да, Җамал апа бик гадел, кайгыртучан. Ашы һәрвакыт вакытында өлгерә, таң тишегеннән гаилә әгъзаларына нәрсә дә булса пешереп куя, тамакларын туйдырмыйча чыгармый. Аяусыз сугыш елларында да бу гаилә ачлыкны бар дәһшәтендә, бар куәтендә татымады. Барысы да Гайсә бабайның мәрхәмәтле һәм игелекле, хатынының гаять дәрәҗәдә эшчән булуы, Екатерина Семёновнаның — ул бу вакытта колхозда хисапчы булып эшли башлаган иде — сакчыллыгы, балалар өчен җанын кызганмавы, авыл халкы һәм йорт хуҗалары белән уртак тел таба белүе аркылы табыла иде. Чөнки гаилә башлыгы, колхоз умартачысы булуы өстенә, үзе дә умарта тота. Рәтен-җаен белеп караганга, кортлар һәрвакыт мул уңыш белән сөендерәләр, Җамал апа исә балны азык-төлеккә алыштыру җаен таба. Ләкин шулай да икмәк кадерле сый булды.

— Бал, бал ашагыз, — диде бервакыт Җамал апа өстәл кырындагыларга, уртага олы табак белән бал һәм юка гына итеп туралган икмәк телемнәре куя-куя. — Балны күп, ипине әз итеп кабыгыз, икмәк бик кадерле.

Беркөн Фима иртән торып урамга чыккан иде, икенче якта тал чыбыгы болгап бер малай йөри. Буйга икесе дә бер чамадарак, ләкин таныш түгел күрше ябыграк күренә. Бер-берсенә бераз маңгай астыннан карашып торгач, малай чыбыгын өстерәп, бу якка чыкты. Шул көнне Фима үзенә Минсәгыйть исемле аерылгысыз дус, ышанычлы иптәш тапты.

Тумыштан авыл малае буларак, Минсәгыйть Фимага бөтенләй икенче дөнья ачты. Яз җитеп, табигать яшелләнүгә, алар урманда. Минсәгыйть юа, күкебаш, кузгалак кебек үләннәрне танырга өйрәтте. Корсак күпкәнче ашыйлар да урман чишмәсенең тешләрне сындырырлык салкын суы белән сусауларын басалар. Өйгә дә җыеп кайталар.

Көннәр җылынгач, буага барырга булдылар. «Күке кычкырды, су керергә ярый», — дип белдерде Минсәгыйть бик белдекле кыяфәт белән. Буа дигәннәре авыл башында икән, инешне аркылы бүлеп куйганнар да шактый гына су җыелган. Монда күбрәк эшкә ярамаган бала-чага мәш килә. Ара-тирә, төшке ашка кайткан яки үтеп барышлый суынып алырга теләгән өлкәнрәкләр дә күренгәли. Кайберләре инде олыларча сүгенеп тә җибәрә, тәмәке тартучылары да бар. Арадан усалраклар бәләкәй малайларны тотып, суның тирән җиренә дә ыргыталар. Тегесе дөньяларны ярып акыра, суга барып төшүгә, бата-калка йөзәргә маташа. Ыргыткан егет-малай үзе китми, карап тора, бата башлауга артыннан ташланып, яшел чирәмле ярга сөйрәп чыгара.

И сугыш чорының иртә олыгайган балалары… Балачакны күрмәгән буын… Ирләр сугышка киткәч, алар җилкәсендә иксез-чиксез ил, хәрби заводлар, игечиге күренмәгән иген кырлары калды. Алар бик тиз җаваплы булырга, теләсә нинди хезмәтне башкарырга өйрәнделәр. «Фронт сызыгы көнбатыш өлкәләрдән генә түгел, ә тылдагы һәркемнең йөрәге аша үтә иде» диюе белән «Кеше язмышларының елъязмачысы» дип танылу алган язучы Ягъсуф Шәфыйков мең кат хаклы. Бу малай-егетләр ризыкның, ярдәмләшүнең бәясен, икмәкнең тәмен — чын тәмен, ризыкның кадерен белеп үстеләр. Алар бер генә нәрсәдән, һәркемгә Ходай тарафыннан бирелгән иң зур бәхеттән — гамьсез балачактан гына мәхрүм булдылар.

Башлангычның югарырак сыйныфларында ук Минсәгыйть белән Фиманың да гамьсезлекләре, Такташ әйтмешли:

Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез дә кара борынлы.
Зурлар кебек, кулны артка куеп,
Йөри идек таптап болынны…

йөргән вакытлары үтә, аларны колхозның җиңелрәк эшләренә җәлеп итә башлыйлар. Җиңелрәк эшләренә, дидем дә туктап калдым: үгез яки ат җигеп көлтә ташу җиңел эшме? Йөгең ишелсә? Киребеткән үгез атларга теләмәсә?

Шунысы бар: колхозда эшләгән көннәрдә тамаклары туя иде малайларның. Ашханәдә әйбәт ашаталар, житмәсә сорап алырга да була. Кич белән Җамал апаның да кырдан кайтучыларга һәрвакыт сөлге белән төреп куелган, шуңа җылы килеш саклаучы ризыгы тора. Фима кайтуга урынга ава. Уч төпләре, көне буе йөргән аяклары кызышып яна, ләкин яшь тән иртәнгә хәтле тагын хәл җыеп өлгерә.

Эшли башлагач, малай ат малының кадерен белергә өйрәнде. Дөресрәге, атны, бу акыллы, затлы хайванны ярата башлады ул. Үгез нәрсә, үгез — үгез инде ул. Куганны да, тартканны да белми, көн үтсенгә тик йөри. Барырга теләмичә туктап калган яки юлга сузылып ук яткан үгезләр тирәсендә елардай булып Минсәгыйть белән күпме бәтерелде алар. Үз вакыты житмичә барыбер кузгалмый ул мәхлук. Ат бөтенләй икенче, кеше акыллары бар диярсең. Хәтта кәефең бармы, юкмы икәнлекне дә сизә ул. Нәкъ кешеләрчә, һәр атның үз холкы бар. Ә ярыш омтылышына нәрсә әйтерсең? Атланып чапканда гына түгел, йөк тартып барганда да үзен узганнарын авыр кичерә ат. Борын тишекләре киңәя, бөтен гәүдәсе белән сузылып тизрәк барырга тырыша, үзе борылып, хуҗасына баш болгап, пошкырып та ала. Булмый бит, янәсе, чамам юк.

Ат бик еш эләкмәсә дә, атланып та, җигеп тә эшләргә туры килгәләде Фима белән Минсәгыйтькә.

— Мин, үскәч, ат караучы булам, — дип белдерде ул бервакыт Минсәгыйтькә. Тегесе көлде генә.

— Хәзер генә шулай дисең, — диде ул, зурларча теш арасыннан «черт» итеп төкереп. — Син укыган, зур кеше булачаксың. Шәһәрдә яши торган.

Күңеленнән риза булмаса да, Фима дустының сүзләрендә хаклык барлыгын тойды. Әйе, Хафиз — бик күңелле, матур авыл, табигате дә искиткеч. Нәкъ Тукайдагыча:

Ул авылны һич онытмыйм, һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр — хәтфәдән юрган иде.

Кешеләре дә әйбәт. Бер-беренә ярдәмләшеп яшәү бу авыл халкының тормыш принцибына әйләнгән. Кайгыда да, шатлыкта да бергә алар. Ләкин авыл тормышы, хезмәте бик авыр. Бигрәк тә әнисен кызгана Фима. Бик чибәр, яшь хатын аның әнисе. Ләкин ул аны сирәк күрә. Колхозда барлыгы илле генә хуҗалык булуга карамастан, хисапчыга эш җитәрлек. Иртүк торып чыгып китә, малай аны күрмичә дә кала, төшке ашка кайткач яки кич белән генә очрашалар. Тиз арада бик матур итеп татарча сөйләшергә өйрәнгәнгә, авыл халкы аны хөрмәт итеп, Катя дип, яшьрәкләр Катя апа дип йөртә.

Беркөнне Фима әнисен көзгегә карап торган хәлдә күрде.

— И Ходаем, — дип авыр сулап битләрен сыпыргалады Екатерина, — бигрәкләр ябык инде үзем.

— Ябыгырсың да, — дип гадәтенчә кырыс тавыш белән эндәште Җамал апа, — ул колхоз эше дип ник шулхәтле бетеренәсең соң? Үзеңне сакла әзрәк.

— Ярар, сакланырбыз да әле. — Екатерина Фиманың җилкәсеннән кочып, бөдрә чәчләреннән сыйпады. — Менә улым үсеп килә, ул саклар, Алла боерса.

Сугыш беткәч тә җинеләймәде әле тормыш. Күз яшенә чыланган, моңсу, сагышлы бәйрәм булды җиңү көне. Ирләре, уллары сугышта ятып калган толлар, аналар үрсәләнеп еладылар ул көнне. Калганнар фронттан кайтучыларны көтеп яши башладылар. Әмма алар аз, бик аз иде.

Екатерина өметен өзмәде. Ирен эзләп кайларга гына язмады ул. Ләкин өметле җавап ала алмады.

— Юктыр инде, улым, — диде ул Ефимга, бер кичне капка төбендә утырганда. — Исән түгелдер әтиең. «Хәбәрсез югалды» дип язалар. Өчәү генә калдык без.

— Ничек өчәү? Гайсә бабай бар, Җамал апа, Мәүлетҗан...

Екатерина моңсу гына елмаеп куйды:

— Алар үзләре, без — син, Лиля, мин — үзебез. Мөгаен, шушында калырбыз инде. — Екатерина бераз тукталып торды. Ефим нindидер мөһим сөйләшү буласын сизеп тынып калды, урынсыз сүз кыстырып, әнисен бүлдерүдән курыкты.

— Әйбәт халык бу якларда, — дип сүзен дәвам итте Екатерина, — син бу халыкның күңелен аңларга тырыш. Үз көчеңә таян, үзеңә генә ышан.

Екатерина урман артына төшеп барган кояшка, көнбатышка карап, тагын тын калды. Караңгылана барган урман офыкта күгелҗемләнеп торган берән-сәрән болытлар белән кушылып, әллә нинди серле күренеш тудыра иде. Ефим олы малайлардан ишеткән әкиятләрне исенә төшерде. Имеш, урманда шүрәле яши икән. Үзе явыз да түгел, ләкин бик тә шаян икән, шуңа күрә кешеләрне кытыклап уйный башлый, ди. Уйный-уйный чамасын оныта икән дә, кеше кытыклanудан көлә-көлә үлеп китә, ди.

— Һәрвакыт чама бел, — дип дәвам итте әнисе, анын уйларын сизгәндәй, — бернәрсәне дә — яхшысын да, начарын да арттырып эшләмә. Усал булсаң — асарлар, юаш булсаң — басарлар, ди. Ә менә урта гына кеше булсаң — ил агасы ясарлар.

— Нигә, әни, эшенне күрсәләр әйбәт бит инде. — Малайның үзен зурларга тиң күреп сөйләшкән әнисе белән фикерләрен уртаклашасы килде. — Әнә бит, мәктәптә әйбәт укыганнарны мактыйлар, бүләкләр бирәләр...

— Уку бер нәрсә, Фима, — әнисенең тавышы әкрен булса да серле һәм катгый иде, — уку бер нәрсә, тормыш — икенче. Син укуда әйбәт бул, кеше эшләгәнне эшлә, кеше кыланмаганны кыланма. Кешенекенә кагылма, үзеннекен бирмә.

Алар ул кичне бик озак утырдылар. Ефим бик олы, серле тормышка кагылганын, әнисенең шул тормышта югалып калмаска, үз урынын табарга өйрәтә башлавын аңлады. Авыл өстенә иңә барган караңгылык бу серне тагын да көчәйтә, колакларны зыңлатырлык тынлык аша галәм сулышы тоелгандай була. Юк, Хафиз авылы белән генә чикләнми икән дөнья, алгысытып, алга чакырып торган олы тормыш бар. Ул әнә урманнар артында, анда зур эшләр башкарыла, әнисе иплән кенә малайга шул тормышка юл күрсәтә, сукмак сала. Тагын бик мөһим нәрсәне аңлады малай: ана ышаналар, ана өметләнәләр. Ул үзенә бик тә кадерле ике кешегә — апасы һәм әнисенә таяныч икән.

Алга китеп булса да шуны әйтик: әнисенең сүзләрен төгәл үтәде Ефим. Иң беренче — татар халкын яратты һәм үз итте ул. Юк, әнисе әйткәнгә генә түгел, дөньяны татар милли менталитеты аша кабул итү рәхәт иде аңа. Характерына туры килә торган сыйфатлар татарларда күп — эшчәнлек, сабырлык, максатчанлык...

Халык аның өчен, беренче чиратта, Хафиз авылы кешеләре иде. Аны да яраттылар монда. Авыр еллар булуга карамастан, үзләренчә яраттылар. Иркәләнүләр, төче сүзләр әйтешү юк, әмма көлтә ташыганда йөгең ишелсә, иң усал малайлар да ташлап китмәсләр, сүгенә-сүгенә төяшерләр, бастырыгын тарттырып бәйләшерләр. Гайсә бабай һәр очракта нишләргә икәнен әйтер, Җамал апаның, кайчан гына кайтсаң да, сиңа дип аерып куйган ашы булыр.

Тагын Тукайга мөрәҗәгать итми булмый:

> Азмы каkkанны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
> Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем...

Музыкаль сәләтен дә татар моңы аркылы тормышка ашырды Ефим. Мәскәү, Питер кебек шәһәрләрдә яшәсә, бәлки нота өйрәнер, пианино, скрипка кебек катлаулы музыкаль инструментларны да үзләштерер, дөньякүләм танылган классикларның атаклы әсәрләрен башкарыр иде. Ләкин тормыш арбасына иртә җигелергә туры килде, сугыш аның язмышына үз төзәтмәләрен кертте, ул аны Татарстан җирлеге, татар дөньясы һәм татар моңы белән бәйләде...

Өч яктан урман белән уратылган авыл уртасыннан болынга, көтүгә чыгып барган малайны күз алдына китерергә тырышам. Кояш ялкау гына күтәрелеп килә, авыл урамын каплаган чирәм өстенә мул булып чык төшкән. Иртәнге салкыннан җилкәләрен җыергалап, әледән-әле иснәнеп куя. Авыл очына чыгып җитүгә, маллар як-якка сибелеп, ябырылып ашый башлыйлар. Малай туктала, борылып өйләр ягына карый. Яшьтәшләре әле йоклыйлар. Их, җылы юрган асты, иске генә булса да йомшак мендәр... Ул башта авыз эченнән генә көйли, аннан эчтән чыккан сагышка түзә алмыйча кычкырып җырлый башлый...

Җыр — юата да, җыр — эшкә дә дәртләндерә ул чорда халыкны. Авыл зур булмаса да, бала-чага күп, мәктәп гөрләп тора. Укытучылар, ирле-хатынлы

Шәйгали абый белән Хәят апа Шәйхрамовлар, мәктәпкә терәп үк салынган кечкенә генә йортта яшиләр. Гомерләре балалар белән үтә. Беренче-икенче сыйныфларны — Хәят апа, өченче-дүртенчеләрне Шәйгали абый укыта.

Мәктәптә яратып укыды Фима. Тышта буран сызгырганда, җылы бүлмәдә серле хәрефләр дөньясында бик рәхәт. Кайчакта гына эссе итеп ягылган мич изрәтеп җибәрә, ләкин янда утырган тиктормас Минсәгыйть һич йоклап китәргә ирек бирми. Нәкъ алда утырган кызның умыртка баганасына яки кабыргасына бөкләнгән бармагы белән төртеп чырыйлатып кычкырту берни тормый аңа. Фима алай булдыра алмый. Ярыша-ярыша атта чабарга, текә ярдан баш белән суга чумарга, урманда иң биек агачның очына ук менәргә дигәндә, берәүдән дә калышмый, ә менә мәктәптә парта арасына кереп утырдымы, ниндидер көч игътибарын укытучыга юнәлтә дә куя. Мөгаен, зыялылык, буыннан-буынга килгән эчке тәрбия укуга, белемгә шундый хөрмәт уяткандыр. Һәрнәрсәнең үз урыны һәм вакыты — шуны генетик дәрәҗәдә аңлау һәм тоемлау тота иде малайны. Шул нәрсә аны гомере буе озата барды, шуңа күрә нинди генә постта эшләмәсен, беркайчан да кул астында эшләгәннәргә йөзен ертып кычкырмады... Ләкин куркалар, хөрмәт катыш буйсыну белән буйсыналар иде аңа.

Сугышлар тынып, халык һәр Ходай бирмеш көнне дәһшәтле кара хәбәрләр көтеп каршыламый башлаган вакытларда, Мерзоннар гаиләсе өчен дә зур яңалык булды. Колхозда исәп-хисап эшләрен бер дә ялгышмыйча, төгәл һәм вакытында үтәп барганын исәпкә алып, идарә аларга гаиләсен ияртеп вербовка белән читкә чыгып киткән кешенең өен бирергә карар чыгарды.

Кем ныграк сөенгәндер: әнисеме, апасы Лилямы, Ефиммы — әйтүе кыен. Гайсә бабай белән Җамал апа, балалары Сәкинә белән Мәүлетҗан бик яхшы кешеләр булсалар да, үз өең — үз өең инде ул. Ефим үзен ир кеше, чын хуҗа итеп тойды. Өй котлап, Гайсә бабай ике умарта бирде. Бирде дигәч тә инде, алар үз урыннарында, түр бакчада калдылар, бабай, гадәтенчә, карап торырга, балын аертып бирергә вәгъдә итте. Шуның өчен Ефим булдыра алганча аңа булышты, Екатерина да әле тегеләй, әле болай ярдәм итеп торды. Гомумән, аерым яшәсәләр дә, алар гел бергә булдылар, бары-югы дигәндәй, уртак, бәйрәмнәрдә бергә табын корып яшәделәр.

Ефим буйга үсте, җилкәләр ныгып, беләкләр калынайды. Монда килгәндә сабый гына иде, хәзер әнә, төптән таза, һәр эшне сытып эшли торган үсмер егет булып килә. Уйламыйча сүзен әйтмәс, әйткәне ныклы булыр. Яшьтәшләре, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, аның сүзенә колак салырга мәҗбүр, чөнки һәрвакыт диярлек хаклы була, теләсә нинди эшнең нинди дә булса файдалы ягын күреп сөйли. Чөнки Ефимның табигый акылы авылның һәм крестьянның практик яктан нигезләнгән фәлсәфәсе белән кушылып, чын мәгънәсендәге дөньяга тормышчан мөнәсәбәт комплексы формалашып килә иде.

Жиңү тормышка әллә нинди үзгәрешләр алып килде. Тормыш кына түгел, кешеләрнең күңелләрендә дә әллә нинди үзгәрешләр булды. Ялгыз калган толларның кайберләре ирләрен көтүләрен дәвам итте, көн эшләде, төн эшләде. Аларны өмет яшәтте, балаларның киләчәге яшәтте. Кайберәүләр, барысына да кул селтәп, агым уңаена йөзә башлады. Андыйлар колхоз эшендә дә көн үтсенгә йөрделәр, балалары да үз көннәрен үзләре күреп, кайда нәрсә тапса, шуны ашап, игелекле кешеләр мәрхәмәте белән яшәделәр.

Сугыш тәмамлану Катяга да йокысыз төннәр алып килде. Бердән, Хафиз авылын күрше колхозга кушып куйдылар да ул хисапчы эшеннән китәргә мәҗбүр булды. Дөрес, эшсез калмады, ул хәзер шәхси хуҗалыклардан сөт җыя, ләкин элекке дәрәҗәдә түгел инде. Физик хезмәткә күнекмәгән ханымга җәйге челләдә, карлы-бозлы янгырда ат җигеп, кырыгар литрлы бидоннар күтәреп

ташу авыр иде. «Балалар» дип тешен кысып эшләде, сер бирмәскә, тормыш арбасыннан төшеп калмаска тырышты.

Икенчедән, күнелендә өмет яшәсә дә, акыллы хатын буларак, Катерина иренең исән булуына ышанып бетмәде. Исән булса, хәбәр бирми калмас иде Дмитрий, андый кеше түгел. Хатыны, улы белән кызы өчен үлеп тора иде. Аңа бик рәхмәтле Катерина, шуңа күрә дә хушлашканда: «Балаларны сакла!» — дип әйткән сүзләрен бер генә минутка да истән чыгармады, ул сүзләрне үтәр өчен барысын да эшләде. Ләкин... «Кечкенә балалар — кечкенә проблема, олы балалар — олы проблема», диләр бит. Әнә, Ефим, Лиля үсеп килә. Үскән саен бит аларның таләпләре дә зураячак, укырга, эшкә урнаштырырга кирәк. Аллага шөкер — шушы урында Катерина эченнән саф татарча «Аллага шөкер» дигәненә игътибар итеп, үзенә-үзе елмаеп куйды — балаларны саклап кала алды бугай, иң куркыныч вакытлар артта калып килә. Ә бит алар кебек читтән килүчеләр күп иде, төрлесенең язмышы төрле. Шушында жир куенында ятып калучы балалар да булды...

Жилдә, кояшта йөреп, авыр крестьян тормышында гәүдәләре тупасланган авыл хатыннары арасында Катерина нәфис-нәзакәтле йөз чалымнары, сылу гәүдәсе белән аерылып тора. Дулкынланып торган кап-кара чәчләре йөзенең аклыгын, дөрес, тигез сызылган чалымнарын ассызыклап, тагын да күркәмләтеп жибәрә. Аны күргән ир-ат заты үзе дә сизмәстән тураеп куя, кепкасын кыеклатып сала, бүген кырынмаган булуына эчтән генә үкенеп ала. Ләкин хатынының күзләрендәге үз бәясен белү билгеләре һәркемне билгеле бер дистанциядә тотарга мәжбүр итә иде. Чибәр хатын-кызның, гадәттә, булганны да, булмаганны да кушып, гайбәтен чәйнәргә яраталар, ләкин Катерина турында авылда авыз чайкаучы булмады. Төрле имеш-мимешләргә юл калдырмавы юкбар сүзгә азык бирмәде.

Ләкин... аһ, тормышта шул ләкиннәр булмаса икән. Авыл тормышы, ни генә әйтсәң дә, авыр. Гайсә бабай ярдәм итә, күз-колак булып тора торуын. Яз көне, бәрәңге утыртыр вакыт житә башлауга, көн саен кереп чыга: «Кызым, жирегез әзерме; орлыгыгыз бармы; әгәр утыртырга житмәсә, бездән кереп алыгыз». Рәхмәт яугыры, үз балалары кебек кайгырта. Әмма аңа гына салынып та булмый, һәркемнең үз тормышы. Хужалыкта ир-ат житмәгәнлеге нык сиздерә.

Шактый озак уйлангач, Катерина тәвәккәлләргә булды. Сугышның башында ук кулын имгәтеп кайткан Хажиев Бастам дигән бригадир белән эшлиләр иде. Авыл зур түгел, көн саен, хәтта көнгә берничә тапкыр аралашырга туры килә. Очрашкан саен бригадир үзенең битараф түгеллеген сиздерергә жай таба, бергә тору хакында житди тәкъдим дә ясады. «Әй, — дип өзгәләнде Катерина, — нишлисең, синең гаиләң бар, балаларың үсә». «Әгәр бергә булмыйбыз икән, — дип үз сүзен сөйләде Бастам, — читкә чыгып китәм. Көн саен сине күреп тыныч йөри алмыйм мин».

Сугыш беткән елны алар бергә тора башладылар. 1946 елны кечкенә өйдә яна туган ир баланың тормыш дәгъва иткән тавышы яңгырады. Хужалыкка да жан керде, койма янартылмаса да, киртәләре алыштырылып, тураеп басты. Өйалды түбәсеннән дә яңгыр үтми башлады. Шулай да ничектер уңайсыз иде кечкенә генә авылда мондый катлаулы тормыш. Бастам элекке хужалыгын да, балаларын да онытып бетермәде, печәнен дә алып кайтты, утынын да әзерләште. Үзенә бер кәлимә сүз әйтүче булмаса да, Катерина аның хатыны белән очрашканда уңайсызлану хисеннән арына алмады.

— И-и, — дип елмайды тегесе, бер жай белән икәү генә калганда шул хакта белдергәч, — гел аптырама, Катя. Гаепләмим мин сине. Нишләтәсең, Ходай биргән чибәрлегең бар, ир-ат жүләр бит ул. Күнеле алгысыган, әллә кайларга

китәм дип сөйләнә иде инде. Анда кайда, нишләп йөргәнен кайлардан беләсең, монда, ичмасам, күз алдымда, ярдәме дә тия. Гаепләмим мин сине...

Ике хатын озак серләште ул көнне. Шушы көнгә җиткергән сугышны каһәрләп елашып та алдылар, балалар, аларның бүгенгесе, киләчәге хакында сөйләштеләр.

Ир белән яши башлагач, Катяны иң гаҗәпләндергәне — Ефимның яңа туган энесе Әнискә мөнәсәбәте булды. Югыйсә, Бастам белән малай бик ачылып китмәде, ике арада нindидер киеренкелек бар иде. Ә менә бишектәге энесе янында сәгатьләр буе утырырга мөмкин. Катяның сиздермичә генә күзәткәне бар: сабый янында Фима яктырып китә, болай да көләргә генә торган күзләреннән очкыннар чәчелә, хәтта кап-кара бөдрәләренә хәтле көлә сыман тоела. Тегесе дә абыйсын бик тиз таный башлады, ябык арба өстендә таныш йөз күренүгә, тешсез авызы ерылып китә, очардай булып кулларын, аякларын болгый башлый, үзе «гы-гы» килеп нидер сөйләнә. Моны күреп торган Катя әллә шатлык, әллә сагыш яшьләрен сөртеп, ишегалдына ашыга...

1949 елны кызлары Әнисә туды. Бала үз бәхете белән туа, ди халык. Яңа кеше яңа шатлык алып килсә дә, үсеп килүчеләрен дә кайгыртырга кирәк — шул уй соңгы вакытларда Катяның күңелендә торган саен ныграк тамыр җәйде. Белеме, дөньяга карашы киң кеше буларак, ул балаларының тормышта үз урыннарын табуын тели иде. Әйе, Бастам хуҗалыкны алып бара, Лиля белән Ефимны җылы сүз белән иркәләмәсә дә, кул күтәреп какканы юк. Дөрес, ул Әнис белән Әнисәне дә артык төчеләнеп ярата белми, характеры шундый. Ул эш кешесе, һәрнәрсәгә «файдалы-файдасыз» дигән практик ноктадан чыгып бәя бирә. Гомумән, авыл халкы шөкер итә белә: дөньялар тынычланганга, көн саен кара хәбәрләр килүдән туктауга, хезмәт көне өчен азмы-күпме иген бирә башлауга ул канәгать. Ләкин һәр кечкенә генә нәрсәгә дә канәгать булып яшәсә, кешелекнең прогрессы тукталып калыр иде. Халык та аска карап шөкер ит, өскә карап фикер йөрт, ди бит.

Катя күреп тора: Лиля да, Ефим да авыл этикасы кысаларында акыллы, ярдәмчел булып үсәләр. Ләкин кинлек, олы дөнья җитми. Тар монда, табигый сәләтне үстерер өчен аралашу даирәсе дә, мөмкинлекләр дә юк. Әхлаклы шәхес булу әйбәт, әмма дөнья шулай корылган инде, җәмгыятьтә үз урыныңны табар өчен кешеләр белән тыгыз аралашып яшәргә, кирәк чакта этешә-төртешә белергә дә, яхшы белем алырга да кирәк. Уку, эшкә урнашу перспективасы булган җир кирәк...

## Канатлар ныгыганда

1951 елны Мерзоннар Хафиз авылыннан 25-30 чакрым гына ераклыкта булган икенче авылга — Татарстан автономияле республикасына караган Урыссу совхозына күченделәр.

Урыссуга күченергә үзен-үзе озак әзерләде Катя. Авылдан бик гаярьләр, бик тәвәккәлләр генә китәргә сәләтле, чөнки гади колхозчының паспорты юк. Ул мәңгегә жиргә береккән. Шулай да кемдер авыл советы рәисен юмалап белешмә ала, кемдер әллә кайлардан эшче куллар эзләп килгән вербовщикның ялган вәгъдәләренә ышанып чыгып китә, кемдер армиядә хезмәт иткән җирендә төпләнеп кала... Хафиз авылы егете Кәрәмулла, колхоз тормышыннан котылып, Урыссу совхозына эшче булып урнаша алганнарның берсе иде.

Кәрәмулла ял көне авылга кайткан саен, Катя аларга йөгерде, совхоз тормышы, яшәү шартлары турында сораштырды. Әйтергә кирәк, урман уртасында утырган Хафиз белән чагыштырганда, Урыссуда олы, интенсив

тормыш кайный иде. Ремонт цехы һәм мастерское, жиләк-жимеш бакчасы, фермалар гөрләп эшләп тора. Хөкүмәт оешмасы булганга, авыл хужалыгы техникасына да кытлык юк. Читтән килеп урнашкан һәркемгә торыр урын бирәләр.

Ә бер атнада Кәрәмулла аны үзе эзләп килде.

— Катя апа, — диде ул, бик мөһим хәбәр әйтәсен сиздереп, — совхозда кара эшкә кеше житәрлек. Менә анда хәзер как раз бухгалтерлар кирәк дип ишеттем. Сез бит эшләгән кеше, белемегез дә бар...

Катя кичне, Бастам кайтканны көчкә көтеп житкерде.

— Китик, — диде ул, иренә хәлне аңлаткач. — Мондагыдан начар булмас. Миңа эш бар, сиңа тем более.

Бастам эндәшмәде, аска караган килеш ашавын белде. Йөзенә карап ни уйлаганын белерлек түгел.

— Жидееллык мәктәбе бар, — дип дәвам итте Катя. — Дүрт бала бит безнең, дүрт бала...

— Юк! — Бастам тәлинкәсен этеп куйды. — Китмим. Үзең теләсә нишлә.

Катя үзен теге вакытта, 1941 елны Жмеринка вокзалындагы кебек салкын кискенлек биләп алганын тойды. Әйе, Бастамны аңлый, ул — теше-тырнагы белән шушы жиргә береккән кеше. Үзе дә бик яратты бу авылны, кара ачлык елларында саклап калган халыкка да бик рәхмәтле. Ләкин тормыш дәвам итә, һәркемнең яхшыракка омтылырга, булган мөмкинлекләрен тормышка ашырырга тырышырга хокукы бар лабаса.

Икенче көнне таң беленә башлаганда, Катя колхоз идарәсендә иде. Колхоз рәисе, фронтовик, хатынның гозерен тыңлагач, беркавым эндәшмичә утырды.

— Ярар, Катерина, — диде ул аннан соң, — сине без тота алмыйбыз. Син ирекле кош, телисең — Урыссуга, телисең — үзеннең ягыңа кайтып китә аласың. Әнә, үзең сөт җыеп йөргән атны алырсың, олаучы бирербез, әйберләреңне җыйна. Илтеп кайтырлар.

Тагын жыену, тагын билгесезлек. Бу юлы берәү дә кумый, дәһшәт булып өстә каракош та бөтерелми. Ләкин кирәк. Әниләренең жыенганын тавышсыз гына карап утырган сабыйларның киләчәге өчен кирәк.

— Аллага тапшырдык, — дип пышылдады Катя, арбадагы төенчекләр өстенә балаларны тезеп утырткач.

Бастам эштә калды. Озатырга да кайтмады. Кич белән буш өйгә кайтып керәчәк. Катя шулай уйланып олау артыннан атлады. Ярар, иренең үз ихтыяры, ул үз язмышын үзе сайлады. Лиляның бик исе китмәде күченүгә. Әллә күрсәтми генә. Биш яшьлек Әнискә арбада бару кызык кына. Әнисә әле вакыйгага бәя бирерлек түгел, кузгалып китүгә, ул кулларын яңагына жайлап куйды да йокыга талды. Катяның йөрәген иң әрнеткәне Ефим булды. Күренеп тора, китәсе килми малайның Хафиздан, ай, килми. Боегып, йомылып калды, хәтта буйга да кечерәеп киткән сыман. Ләм-мим бер сүз дәшми, ләкин күзләрендә чайкалган сагышны күрмәс өчен Катя аңа таба карамаска тырыша. Авыр, бик авыр кичерә бу бала күченүне. Еламый да ичмаса, үз эченә бикләнгән дә арбага тотынып тик бара. Үз иркендә булса, мөгаен, кузгалмас иде.

Береккән жирдән аерылу ачысын Ефим Мерзон беренче тапкыр шунда татыды. Әле алда зуррак давыллар булачагын, ачырак жилләр бәгырьләрне кисәчәген Ефим да, Катя да белми иде. Киләчәктә тауны тауга бәреп эш итүче, йөзләгән кешеләрне житәкләүче Ефим Дмитриевичка жылы кәнәфиләре өчен жаннарын шайтанга сатарга әзер бюрократлар белән көрәшәсе, якты кояш астында яшәүгә хаклы икәнен исбат итеп, Минзәлә,

Чаллы кебек шәһәрләргә барып урнашасы, автотранспорт оешмаларын бөтен республикага үрнәк булырдай дәрәҗәгә күтәрәсе бар. Барысы да алда, барысы да булачак, ә хәзергә әле малай куәт инеп килүче җилкәләрен салмак кына чайкалдырып, артка борылып карамас өчен күзләрен җиргә төбәгән дә Ык елгасы аръягындагы Урыссу совхозы ягына таба атлый. Кайтачак әле ул монда, зур кеше булып кайтачак... Минсәгыйть, Язкар белән очрашачак әле ул... Ә Татарстан моңсу гына елмаеп, үзенең тарихында матур хатирәләр калдырачак улын көтә иде.

***

Барысы да уйлаганга карый күпкә җиңел булып чыкты. Катяны бухгалтер итеп бишкуллап алдылар, атна-ун көн дигәндә, яңа төзелеп беткән, халык телендә «финский» дип йөртелгән йорт бирделәр. Кечкенәләргә ясле дә, балалар бакчасы да булды. Катя баш-аягы белән эшкә чумды. Бу инде 50 хуҗалыклы «Игенче» колхозы түгел. Совхозның акча әйләнеше генә дә йөзәрләгән мең сумнар белән исәпләнә. Шуның өстенә дистәләгән трактор, машина, комбайн... Җиләк-җимеш бакчасы дәүләт эчендәге дәүләт кебек яшәп ята. Кыскасы, күңелсезләнеп утырырга һич вакыт юк.

Халкы да бик чуар, төрле яктан җыелган, төрле язмышлы, төрле характер һәм менталитетка ия кешеләр. Фронтовиклар җиң сызганып, исән калганнарына шөкер итә-итә, җир җимертеп эшләп йөриләр. Тамак ягы бераз рәтләнеп, якты йолдыз булып өмет җемелди башлаган вакытлар.

Урыссуга күчкәч, Ефимның боегуы озакка бармады. Яшь, сәламәт рух болай да озак күңелсезләнеп йөри алмый ул. Ефим исә аралашучан, үзен яраттыра да белә. Уйламыйча сүз сөйләми, олыларны олы, кечеләрне кече итә. Яхшы атланып эш сорап, күзгә кереп йөрмәс, кушканнан баш тартмас һәм һәрвакыт җиренә җиткереп башкарыр.

Эш дигәннән, килгән елның декабрендә Ефим терлек азыгы ташучы булып эшли башлады. Таныш хезмәт, тик хәзер инде, Аллага шөкер, үгез җигүләр юк. Атлар да көр, уйнаклап торалар, иртән абзарга кереп, малкайларның «кетерт-кетерт» башак ашауларын ишетү үзе бер рәхәт. Йөк ишелсә дә куркыныч түгел, беләктә көч, күкрәктә гайрәтнең ташып торган чагы. Хәер, каты кул бастырыклап төягәч, йөге дә ишелми инде аның. Кырдан олаулар тезелешеп кайтканда, егет-кызлар тавышыннан тирә-як яңгырап тора. Ул да булмый, кемдер үзен-үзе дәртләндереп җыр суза:

... Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәлә микән...

Шул җитә кала, әле тегеннән, әле моннан тавышлар килә башлый:
— Ефим...
— Әйдә, беркөн җырлаганны...
— Ефим, әйдә...
Ефим тәртип өчен генә карышып ала:
— Җырлыйлар бит инде.
Шунда ук «Күбәләк»не туктаталар:
— Әй, сандугач, туктап тор әле.
— Кайткач моңаерсың.

Җыр башлаучы инде туктаган, ул хәтта каршы да әйтеп азапланмый. Аңа җырлау кирәкми дә бугай, җыр темасын кузгату җитә. Белә: оста барда кулын, мулла барда телең тый. Ә җыр мәсьәләсендә оста да, мулла да бер — Ефим.

Менә хәзер аңа сүз бирделәр, иксез-чиксез күк астындагы карлы басу уртасында табигать сәхнәсе маэстрога — Ефимга бирелгән. Атлар пошкыруы гына бүлгән тынлыкны егетнең әле чынлап торып ныгып та җитмәгән, әмма әллә кайдан, бәгырь төбеннән чыккан тоныграк тавышы ярып җибәрә:

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә
Зәңгәр күлгә көн дә киләсең.
Йөрәгеңдә нинди утлар яна? –
Уйларыңны килә беләсем.

Кызлар кыеклап та, турылап та җырчы егеткә күз аталар. Һәрберсе кара бөдрәләре дулкынланып бүрек астыннан чыгып торган, искиткеч итагатьле, елмаюы белән тирә-якны яктыртып җибәрүче егетнең җырын үзенә кабул итә:

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә
Яшел болыннардан үтәсең.
Болын чәчәкләрен җыя-җыя,
Кемне болай сагынып көтәсең?

Атларның алдан барганнары инде авылга кереп килә. Ишегалдында йөргән карт-коры тураеп, кулын каш өстенә куеп, йөкчеләр ягына карый:

— Катя малае инде бу...

— Шул инде. Бигрәкләр белеп җырлый...

— Ие, авылда әрәм булып калмасын иде инде мондый тавышы белән.

Мәктәп букчаларын чана итеп шуучы малайлар бермәлгә туктап кала, хәтта алардан калмаска тырышып «ләң-ләң» килеп чабулаучы авыл этләренә кадәр, башларын кыйгайта-кыйгайта нидер аңларга тырышып, кыр ягына борылып багалар. Ә аннан авылга җырның соңгы куплеты килеп керә:

Зәңгәр күлмәгеңнең зәңгәрлеге
Хәтерләтә аяз күкләрне.
Нинди иркә сүзләр ачар икән
Күңелеңнең серле бикләрен?!

Совхоз зур, маллар күп. Сыеры да, сарыгы да көн саен ашарга сорый, алып кайтып кына өлгерт. Мал азыгы ташырга, гадәттә, нинди дә булса һөнәре булмаган яшьләрне куялар. Түләү — тоннадан, ягъни күпме күләмдә ташыйсың — шуңа карап акчасын язалар. Кырдан саламын-печәнен, складлардан онын-көрпәсен китерделәр, барысын да эшләделәр. Ләкин бу эштәгеләр алышынып кына тора. Чөнки яшьләре житүгә, егетләрне армиягә алып китәләр, кызлар — кияүгә чыга да уңайрак, җайлырак эшне кайгырта башлый, кайберсе фермага сыер савучы булып керә, анда акчасы да күбрәк.

Катя бухгалтериядә үз эшен энәсеннән җебенә хәтле белүе, халыкка ягымлы булуы белән тиз арада үз кеше булып китте. Улы үскән саен, киләчәккә ышанычы ныгый. Тормыш әкрен генә көйләнә, ләкин әле максатларга ирешелмәгән. Ефим авылның күз өстендәге кашы кебек егет, бер генә бәйрәм, бер генә мәдәни чара да аннан башка үтми. Сәхнәгә бер чыгып басса, кабат-кабат чакырып җырлаталар. Җәмәгать эшләренә дә өлгерә, бигрәк тә комсомол булып алгач, өмә, күмәк эш оештыруны аңа тапшыра башладылар. Чөнки моны белән генә түгел, төпле сүзе, эш рәтен белүе белән дә башкалардан аерылып тора һәм, иң мөһиме, үз артыннан ияртә белә. Хәзер һөнәр, нинди дә булса һөнәр кирәк.

1956 елның май ае иде. Беркөнне төшке ашка Катерина гадәттәгедән ашыгып кайтып керде. Өстәл янына утырышкач, беркавым сүзсез генә ашадылар.

— Ефим, — дип сүз башлады Катя, — ничек эшләр?

— Әйбәт, әни.

— Эштә хәлләр ничек?

Ефим аптыраган кыяфәттә бер апасы Лиляга, бер Катяга карап куйды.

— Анда ни булсын инде? Сыерлар, сарыклар, шулар арасында — без.

— Сыерлар, сарыклар шул. Җитәр, мөгаен. Тимерче цехына молотобоец булып барасың килмиме?

— Килә, кәнишне...

— Иртәгә үк конторага барып гариза язарсың. Бүген генә сөйләшеп утырдык, урын бар. Эше дә ул хәтле тыгыз түгел, яллары да булыр.

Иртәгәне дә көтмәде Ефим, әнисенә үк ияреп барып, гариза калдырып кайтты... Һәм икенче көнне үк тимерчелеккә эшкә чыкты.

Дөресен генә әйткәндә, мал азыгы ташып ялыккан иде. Бигрәк үзәккә үтә торган, миләрне киптерә торган бертөрлелек туйдырган иде. Көн дә бер юл, көн дә бер үк эш, бер үк хәрәкәтләр. Үзең үк малга әверелерсең, билләһи.

Тимерчелектә исә чын мәгънәсендә иҗатка урын бар. Дөрес, чүкеч бәрүче — кушканны гына үтәүче, ләкин тимер үзенә ихтирамлы мөнәсәбәт таләп итә. Белеп кыздырырга, чамалап сугарга кирәк. Аннары соң, күпме техника монда! Ефим бик кирәкле нәрсәсен тапкандай булды. Сизде: бу дөнья аныкы. Машина-тракторлар — аныкы. Беренче көнне цехка килеп, куәтле тракторлар, «ЗИС» машиналары арасында калгач та, томан белән өртелгән хәтерендә Жмеринкада калган уенчык йок машинасы килде. Ләкин хатирәләргә вакыт юк, олы яшьтәге тимерче абзый нindидер тимер балканың бер башыннан тоткан да, шау-шуны җиңәргә тырышып, ана кычкыра:

— Тот теге башыннан, идрить-тидрить...

Кичләрен клубка чыкканда, кулларын бик озаклап сабын белән юа Ефим, тик күзәнәкләренә үк сеңгән машина мае барыбер бетеп җитми. Бетерергә бик тырышмый да инде, күрсеннәр, пролетариат, эш кешесе. Йөрешләре, үзен тотышларына хәтле үзгәрде егетнең. Әледән-әле ычкынган шаян сүз, янып-җемелдәп торган күзләр, тик торганда да кычкырып җырлап җибәрүләре кәефенең күтәренке икәнлеген күрсәтә.

Катя аңа карап сөенеп бетә алмады. Ефим халык теленә кереп бара, гел уңай яктан үрнәк: әле концертта җырлавын сөйлиләр, әле аның кул астындагы бертөркем яшьләрнең күмәкләп берәр эшне эшләп ташлауларын мактап телгә алалар.

— Каян килеп чыкты бу Мерзон, — дип куйды беркөн партком секретаре, — аннан башка ике кулсыз булыр идем.

Кәгазьләргә күмелеп утырган Катеринаның йөрәгенә сары май булып ятты бу сүзләр, ләкин сиздермәде, ишетмәмешкә салышты. Кайткач, каядыр җыенган Ефимга бик озак карап утырды. Әй сөенер иде Дмитрий хәзер улын күрсә. Шушы сугыш дигән афәт кайларга гына таратмады кешеләрне. Ләкин яшәү көчен җиңә, канда булган, ана сөте белән кергән күркәмлекне бетерә алмады. Алтын кайда да алтын булып кала, тутыкмый ул, асыл сыйфатларын җуймый. Аккан су юлын таба, әнә алар да, бернинди ярдәмсез, үзләре, бары үз көчләре белән, җәмгыятьтә урыннарын таптылар. Тфү-тфү, болай барса, Ефимның да киләчәге зур булырга ошый.

Ефим күрә, сизә иде әнисенең аның белән горурланганын. Өметләрен акларга, ана горурлыгына лаек булырга тырышты. Гаилә таянычы икәнлеген аңлау җаваплылыгы да егетне әхлак кысаларында тотарга мәҗбүр итте. Клубка

чыкса да, бервакытта да клуб артындагы караңгы почмакларда хәмер чөмерүчеләр арасында булмады. Һәрвакыт бина эчендә, мөдир кабинетында йә концертка әзерләнделәр, йә булачак комсомол җыелышының көн тәртибен тикшерделәр. Авызларына аракы эләккәч кызучанраклар да Ефим булганда тынычланып калалар иде. Бердән, егет төптән чыккан, Ходай куәтне кызганмаган, мал азыгы ташыганда, зур-зур капчыкларны уйнатып кына күчерүенә күпләрнең кызыгып карап торганы бар. Икенчедән, ниндидер эчке бер көче дә бар. Тавышын күтәрмәс, үз итеп, шаярып кына эндәшер, ләкин теләсә нинди агрессия, дингез дулкыны кыяга бәрелеп тынычланган кебек, аның белән сөйләшкәндә үзенең башлангыч импульсын югалтыр.

Советлар илендә бер гадәт яши иде. Дөрес, халыкның матур бер традициясе ул — өмә оештыру. Ләкин халыкны гомер буе бушка эшләтергә хыялланган коммунистлар аны бик еш кулландылар. Урып-җыю, печән өсте, бәрәңге алган чорларда совхоз администрациясе дә еш кына күмәк хезмәткә чакырып халыкка мөрәҗәгать итә иде.

Менә бүген дә совхоз халкы печән өмәсенә чыкты. Көннәр, Аллага шөкер, аяз, чак кына җиләс җил исеп тора. Комсомол оешмасы, әлбәттә, мондый чараларның үзәгендә. Өмәгә иң теләп чыкканы һәм сөенгәне, мөгаен, яшьләрдер. Яшьлек — яшьлек инде ул, һәрнәрсәдән кызык таба белә. Бертөркем егетләр-кызлар җыелган җирдә һәрвакыт уен-көлке, җыр, шаян сүз. Өстәвенә, бер-береңә мөнәсәбәт белдерергә, үзеңне күрсәтергә моннан да уңайлырак форсат була аламы соң?

Ефим иртәдән аяк өсте. Аңа берничә егет белән печән җыюны тапшырдылар. Кемдер тырма белән күбәләп тора, болар шуны ат белән тарттырып яки йөккә төяп, эскерт куючылар янына ташырга тиешләр.

— Мин печәнне ташласам да, печән мине гомергә ташламас, ахры. Әйдә, егетләр, утырыгыз, — дип, өстенә изүләре ачык иркен ак күлмәк, дулкынланып, ишелеп торган чәчләре өстенә кыеклатып кепка кигән Ефим, йөк ташу өчен җайлаштырып, тирән итеп ясалган, халык телендә «чытыр арба» дип аталган арбаның алдына утырып, дилбегәгә тотынды. Колхозның эре токымлы, сыртлары елкылдап торган аты алты-җиде ир утырган арбаны «эһ» тә итмичә басу түренә алып чапты. Баштагы мәлдә шау-шу килеп, йөкләрне бик тиз төяделәр. Төйи торалар, Ефим эскерт куючылар янына илтеп, аударып тора. Төшкә таба җегәр кимеде, тавышлар да басыла төште, ләкин көнбатышта каракучкылланып пәйда булган болыт һәм шул яктан ишетелгән тонык кына гөрелдәү кешеләрне ашыктыра башлады.

— Иптәшләр, яңгырга эләкмичә генә бетерәсе иде эшне, — дип, партоешма секретаре дә «Бобиг»ына утырып килеп житте.

Иркен кырга сибелгән печән кибәннәре күзгә күренеп кимесә дә, җитәрлек иде әле. Йөкне аударгач, Ефим атны арбага басып куалый, ат та, үзе дә тиргә баткан.

— Өлгерә алмыйбыз, әйдә безгә төяшергә барыгыз, — дип кычкырды ул бер килүендә. Озын сәнәк белән эскерт өстенә биреп торучы ике ир сәнәкләрен кыскарак саплыга алыштырдылар да арбага сикерделәр. Ефим атның киң сыртына дилбегә кагуы булды, туры бия эре адымнар белән басу түренә ыргылды. Кинәт колакларны ярып чатырдаган тавыш яңгырады, эскерт өстендә торган ике ир, нишләгәннәрен дә аңламастан, аска сикерделәр. Барысы да җиргә чүкте, хатын-кызларның ачыргаланып кычкырганы ишетелде. Башларын күтәреп карасалар, әле генә юыртып барган ат, башын табигый булмаган хәлдә артка ташлап, җирдә ята. Арба янга ауган, камылга тәгәрәгән ирләр, тузанга буялып, сүгенә-сүгенә җирдән күтәрелеп азапланалар.

Беренче булып якындагы хатыннар анга килде.

— Ни булды? — диеште алар, йөгереп килеп ирләргә булыша-булыша.

— Әй, хатыннар, — дип кычкырды берсе, — монда килегез әле тизрәк. Арбаны күтәрегез, Катя малае аста калган.

Ул арада башкалар да килеп житте, «ә» дигәнче арбаны бастырып куйдылар. Аркасы белән яткан Ефимның йөзе ап-ак, иреннәреннән кан качкан. Кепкасы әллә кайда читтә ята, чәчләре табигый булмаганча тузган, киемнәреннән жинелчә генә әллә пар, әллә төтен күтәрелә.

— Әстәгъфирулла, — дип куйды берсе, — әллә яшен сукканмы?

Күпне күргән фронтовик ирләрнең берсе халыкны аралап уртага үтте.

— Шуңа охшый, — диде ул, — көрәк алып килегез, башын гына чыгарып калдырып, жиргә күмәргә кирәк. Тиз бул! — дип кинәт кычкырып жибәрде ул янәшәсендә өнсез булып торган малайга — ... мать! Кеше үләргә ята, ул авызын ачкан...

Шулай эшләделәр дә. Бераздан, төбенә мул итеп печән түшәлгән арбага жигеп, совхозның нәсел айгырын китереп житкерделәр. Ефимны арбага күтәреп салулары булды, егет телгә килде. Халык өнсез калды: Ефим кычкырып «Сарман»ны жырлый иде. Фельдшер үзенә-үзе ышанмыйча иелеп авыруның йөзенә карады: юк, аңсыз, әмма жырлый.

— Да, — дип кепкасын салып, маңгаен сөртте әле генә көрәк сорап кычкырган ир, арба кузгалып киткәч, — да! Безнең белән авылда әрәм булып ята бу егет. Яшен суккач та жырлый алган кешене күргәнем юк иде әле...

***

Яшен шаукымыннан тиз тернәкләнде Ефим.

— Атны бәргән, — диделәр. — Дилбегә буйлап ат тотучыга да эләккән.

Яшь организм, яшәүгә омтылыш, көчле рух аны тиз аякка бастырды. Берничә көннән ул инде иптәшләре арасында иде. Бу вакыйганы көлеп кенә искә ала башладылар. Дөньяны ал төсләрдә генә күрүче, гел биеклеккә, алга омтылучы яшьлек ерак киләчәктә бу күңелсез вакыйганың авыр нәтижәләр китереп чыгарачагын белми һәм уйлап та карамый иде әле.

1958 ел Ефим өчен истәлекле булды. Беренчедән, аны тимерче итеп күчерделәр. Авыл хужалыгы өчен аеруча жаваплы май аенда булды бу хәл. Бу инде ни кушсалар, шуны үтәп йөрүче чүкеч сугучы гына түгел, ә мөстәкыйль эш алып, аның башкарылуы өчен жавап бирүче дигән сүз. Кырларда эшләүче һәр техника — чәчкечме, ургычмы — барысының да төзеклеге, кирәкле детальләр белән тәэмин ителеше тимерчеләр өстендә. Һәр тырманың һәр теше тимерче кулын таләп итә.

Янып, яратып эшләде Ефим. Тимерчелек цехының шау-шуы, мазут, солярка исе, механизаторларның тупас-самими шаярулары — барысы да яшәешнең аерылмас өлешенә әверелде.

Бервакыт, кар инде күренеп алган, ләкин әле ныклап катырырга өлгермәгән ноябрь аенда, авылдагы берничә егетне конторага жыеп алдылар да болай диделәр:

— Илебез зур эшләр башкара. Авыл хужалыгына партиябез аеруча зур игътибар бирә. Техниканы белгән яшьләр кирәк. Кемнәр Бөгелмәгә механизаторлар курсына барырга тели?

Беренче булып Ефим кулын күтәрде. Аңа ышанырга, иярергә күнеккән егетләр, бер-берсенә карашып алдылар да шулай ук ризалык белдерделәр.

Совхоз директоры белән партоешма секретаре бер-берсенә карап куйдылар. Мерзонның лидерлык сыйфатларын күрәләр, беләләр, бүген жибәреләчәк

группага аны кертүләре дә юкка түгел иде. Авылда туып-үскән егетләрнең юк сәбәпне бар итеп курсларга барудан баш тарту мөмкинлеген дә уйладылар да, алдынгы карашлы, кыю, башкаларны үз артыннан ияртергә сәләтле Мерзонны укырга китәргә тиешле группа исемлегенә кертергә карар иттеләр. Ышанычларынаклады егет, димәк, аңа зуррак эшләр дә ышанып тапшырырга була.

Күнелдәге мондый ышанычның материаль гәүдәләнеше 1963 елның соңгы аенда Ефим Мерзонны бүген Азнакай районына караган М.Вахитов исемендәге совхозга ВЛКСМ секретаре итеп билгеләүдә чагылыш тапты.

***

Ефим халык телендә кыскартылып Вахит дип йөртелгән совхозга декабрь аенда, Яңа ел алдыннан килеп төште.

— Шушындадыр инде комсомоллар, — дип, маңгаена «Клуб» дип язылган бинага ымлады «ГАЗ-51» машинасы шоферы, — чак кына тегендәрәк — идарәләре.

— Рәхмәт, абый! — Ефим фанера чемоданын кар өстенә куеп, зәңгәр төтен бөркеп кузгалып киткән агач әрҗәле машинага кулын болгады да тирә-якка карана башлады. Калкулыклар уртасына урнашкан Жину посёлогы кар юрганы ябынган. Ләкин юллар, монда төзелеш барлыгын сиздереп, ком, кирпеч тузаны белән капланган. Көн уртасы булып, халык төшке ашка таралгандыр, ахрысы, урамда йөрүчеләр юк диярлек. Тимер чыңына, машина-трактор гөрелтесенә күнеккән колакларга мондагы тынлык сәер тоела иде. Монсулана башлавын сизгән егет, уйларыннан арынырга теләгәндәй башын чайкап куйды да, чемоданын кулына алып, клубка таба атлады. Эчтә шау-шу, яшьлек авазы... Кергән мәлгә Ефим кемгә мөрәҗәгать итәргә белми аптырап тора иде, янына чуар күлмәк кигән, җилкәсенә шәл салган кыз килеп туктады.

— Сез Ефим Мерзонмы? Мин совхоз үзәк усадьбасының беренчел комсомол оешмасы секретаре Дания булам, Әхмәдиева, — дип танышуны да, таныштыруны да бергә кушып тезеп китте ул. — Сезне күптән көтә идек, әйткәннәр иде. Кызлар, — Дания бинаның түренә, сәхнә ягына борылып кычкырды, — килегез монда, бер егет белән таныштырам.

Рәсмилеккә әзерләнеп килгән һәм мондый өлгерлектән, темптан югалып калган Ефим нәрсәдер әйтергә өлгергәнче, бер төркем егетләр, кызлар арасында калды.

— Нәкъ вакытында...

— Егетләр артмас...

— Чибәр үзе! — Моны әйткән кыз пырхылдап көлеп җибәрде дә иптәшләре артына качты.

Тагы да чаярагы биленә таянды:

— Өйләнгәнме?

Маңгайга бәреп әйтелгән бу сораудан кызлар тагын бер кат чыркылдашып алдылар.

Шул арада ияләшеп өлгергән Ефим бүлмәне яктыртып елмаеп җибәрде:

— Өйләнмәгән. Чыгасыңмы?

Бүрәнә ярыгыннан да көләргә торган кызлар бөтенләй тезгеннән ычкындылар:

— Мине ал, үкенмәссең.

— Юк, юк, җирәбә салабыз, кемгә чыга, шуңа өйләнә...

Яңа ел концертына әзерлекнең бүтән юлга кереп киткәнлеген сизгән Дания ике кулын да югары чөйде:

— Стоп! — Тавышы хәтәр икән, Ефим йөзенә усаллык төсмерләре чыккан

кызга карап алды. — Стоп! Нәрсә монда кияү буләсез?! Нигә җыелганны оныттыгызмыни?

Әкренләп тына башлаган кызлар төркемен ерып, берничә егет килеп исәнләште:

— Рәшит.

— Талибулла...

Дания дилбегәне кулдан ычкындырмаска булды:

— Хәзер, әйдә, мин сине башта фатирга урнаштырыйм.

Житез генә барып плюш бишмәтен киде, шәлен урады.

Ефимны Дусаева Миңнесорур апаларга урнаштырдылар. Эшкә уңганлыгы белән күпмедер дәрәҗәдә Җамал апаны хәтерләткән бу хатынның Сәлимә һәм Марс исемле кызы белән улы бар икән. Сәлимә әле мәктәп баласы, Марс исә армиядә, җәйгә кайтырга тиеш, ди. Миңнесорур апаның аны сөйләмәгән көне юк. Әнисенең сүзләре буенча Ефим аны дөньядагы бар эшне дә булдыра алучы, гаять уңган һәм тәртипле егет итеп күз алдына китерә башлады. Солдат улының фотосын күрсәтә-күрсәтә, бөтен йөзен балкытып сөйләгән Миңнесорур апага карап, кайчакта әнисен исенә төшерә дә йөрәге кысылып куя. Ул да шулай түгел идемени? Әйе, Екатерина Семёновна Ефимның уңышларына сөенгәнлеген тышына чыгармады, ләкин карашында, искиткеч ихтирамлы мөнәсәбәтендә улына ышанганлыгы һәм аның белән чиксез горурланганлыгы ярылып ята иде. Мондый вакытларда Ефим тәрәзәгә карап бераз сүзсез утыра да әкрен генә җырлый башлый:

Сөекле әниемнең
Борчыгандыр җанын
Күңелемнең көйсез һәр чагы.
Еласам — юаткан,
Иркәләп уйнаткан
Әниемнең җылы кочагы.

Тавышланмаска тырышып аяк очына гына басып йөрүче Миңнесорур апа сыгылып төшә.

Уйнаудан туйганда,
Талчыгып калганда,
Ял сорагач керфек очларым,
Җыр көйләп, тирбәтеп,
Йоклаткан изрәтеп
Әниемнең җылы кочагы.

Ефим үзенең кайдалыгын оныткан, кар баскан тауларга караган күзләре берни дә күрми. Сәлимә белән Миңнесорур апа инде яшереп тормыйча кочаклашып үксиләр.

Давыллы көннәрдә,
Ышыклап җилләрдән
Күкрәгенә кыскан кем тагы?
Кадерләп үстергән,
Яшәргә көч биргән
Әниемнең җылы кочагы.

— Үтерә бу бала, — дип сөйли Миңнесорур апа икенче көнне эшкә баргач, — бәгырьләрне өзә. Бигрәкләр юксына инәсен. Ул тавышы, ул моңы...

Килгән унайга Ефим эшкә чумды. Яңа елга концерт әзерләделәр, бөтен оештыру, программасын төзү кебек эшләрне Ефим үз кулына алды. Берәү дә атап тапшырмады моны, ләкин үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, сорау туган саен аңа мөрәҗәгать итә башладылар. Ул тиз арада лидерга әверелде, һәркем белән уртак тел тапты. Мәдәни-агарту эшләре генә түгел, администрация белән элемтәләрне дә җайга салды, комсомол оешмасының документациясен, утырыш протоколларын тел-теш тимәслек дәрәҗәгә җиткереп тәртипкә китерде.

Элегрәк эленке-салынкы уза торган җыелышлар, яңа секретарь белән эшлекле, проблемаларны — рәсмиме, шәхсиме — уртага салып сөйләшә, ситуациядән чыгу юлларын бергәләп, кинәшеп эзли торган күренешкә әйләнделәр. Ефим беркемгә дә боерык яки күрсәтмә бирми иде, башта барысын да тыңлап чыга, һәркемгә фикерен әйтергә мөмкинлек тудыра, аннан соң гына үзенең мөнәсәбәтен белдерә, нәкъ шулай кирәклеген кире каккысыз дәлилләр белән нигезли һәм тавышка куя. Аның тимер логикасы, ышандырып сөйләве теләсә нинди үз киресенә беткәннәрне дә фикереннән кайтырга мәҗбүр итә һәм, гадәттә, карарлар бертавыштан кабул ителә иде. Партоешма да, совхоз администрациясе дә егетнең үткенлеген, эшлекле сыйфатларын тиз күреп алдылар, әледән-әле яшьләрне оештыру, югарыдан төшерелгән күрсәтмәләрне тормышка ашыруны аңа тапшыра торган булдылар. Ефим берсеннән дә баш тартмады. Гадәтенчә ашыкмыйча гына, барысын да төптән уйлап, җиренә җиткереп башкарды.

Аңа өзлексез мөрәҗәгать итәргә шулхәтле ияләшкәннәр ки, бервакыт сәхнәдә «Галиябану» спектаклен уйнаганда, бер егет «Хәлил, нишлисең син?» дип мөрәҗәгать итәсе урында, «Ефим, нишлисең син?» дип ычкындырды һәм бөтен залның көлүенә сәбәпче булды.

Җәйләр җитеп, бөтен дөнья яшеллеккә төренгән матур көннәрнең берсендә фатир хуҗабикәсе Миннесорур апаның улы Марс кайтты. Солдат формасындагы төз гәүдәле егет бөтен урамны балкытып елмайган хәлдә капканы ачуга, ишектән әнисе каударланып килеп чыкты да кулын сузып улына таба атламакчы булды, ләкин аяк астында сөенче бүләге өмет итеп буталган бала-чагага уралып, тукталып калды.

— Һай, рәхмәт төшкерләре, — дип сукранган булды ул, кесәсеннән кемгәдер урман чикләвеге, кемгәдер конфет өләшә-өләшә, — калмас дип куркасызмыни!

Өй тиз арада күрше-күлән, туган-тумача белән тулды. Олы һәм көтелгән кунак төшкәч һәр өйдә була торган ыгы-зыгы башланды. Тиз арада аш салып җибәрделәр, Сәлимә күбәләктәй очып кына кибеткә барып кайтты.

Солдат кайту хәбәрен Ефим идарәдә ишетте. Миннән башка да мәшәкатьләре җитәрлектер, борчымыйм дип, ашыкмады, төшке ашны совхоз ашханәсендә генә ашады да, кичкә таба кырга китешли, өйгә сугылды.

Чыннан да, йортта халык бераз кимегән, иң беренче килгән кунаклар инде таралышкан. Солдат өстен салып, майкадан гына болдырда утыра иде.

— Марс.

— Ефим, — дип егетләр кул кысыштылар.

— Әйдә, бәбкәм, нишләп бик озакладың, — дип каршы алды Миннесорур апа, — утыр әйдә. Сәлимә, Сәлимә дим, аш бүл Ефим абыеңа...

Ул сүзен әйтеп бетергәнче, Сәлимә коштабак белән аш күтәреп чыкты, тозборыч тезде, калын итеп ипи турап куйды.

Марс та өстәл артына утырды. Кашы белән генә ымлап Ефимнан сорап куйды.

— Әйдә берәрне...

— Юк, рәхмәт, әле басуга, фермага барасы бар. Аннан, ул акбашлы малай әллә ни дус итми мине.

— Кирәк тә түгел. — Марс елмаеп куйды. Күренеп тора, ул бүген аракысыз да бәхеттән исерек иде. Почмактагы чаршау артыннан Сәлимәнең абыйсына сөеп-яратып күз сирпеп алганлыгы күренеп кала. Әйтмәсә дә сизелә — горурлана кызый абыйсы белән.

Кич белән Ефим капка төбендә озак кына уйланып утырды. Кайчандыр Хафизда әнисе белән шулай утырганнар иде. Аның әйткәннәре бүгенгедәй исендә, һәрбер сүзен үтәп барырга тырыша Ефим. Апасы Лиля, кечкенәләр Әнис һәм Әнисә белән калды алар хәзер. Барысы өчен дә Ефим җаваплы, аңа карап торалар. Шөкер, ул үзен күрсәтә алды, яхшы аты бар, аңа ышаналар. Һөнәре дә бар. Дөрес, укырга кирәк булачак, ләкин анысы качмас. Гаилә, үз оясын корырга кирәк аңа хәзер. Нәрсә әйтсәң дә, яшь бара, 28 ел гомер үтелгән. Бу хакта инде Миннесорур апа берничә тапкыр читләтеп-читләтеп кенә сүз кузгаткалады, кызлы гаиләләрне сөйләп, уңай сыйфатларын мактап-мактап алгалады.

Ефим үзе дә уйлана ул хакта. Ләкин күңелгә хуш килеп, язмышын бәйләрдәй кеше генә күренми. Юк, бар матурлар да, бар эшчәннәр дә, акыллылар да... Әмма, әмма... Нидер тота, нидер сабыр итәргә куша егеткә. Җамал апа әйтмешли, вакыты җитмәгәндер.

Җәйләр үтеп, көзләр дә җитте, урак өсте башланды. Әле җәяү, әле ат белән комсомол секретаре кырдан кырга чапты. Игеннәр уңган, күзләрне сөендереп дулкынланып утыралар. Төннәр салкынча була башлады, ерак офыкта, комбайн утлары белән ярышып, әледән-әле ажаган уйнаганы күренгәли. Авыл өстендә көнен дә, төнен дә ашлык ташучы машиналарның гөрелтесе, ындыр табагында молотилка шавы янгырап тора. Тузанга баткан, йокыны оныткан кешеләр ябыгып калдылар, гасабилы, ачулы сөйләшә башладылар. Совхоз директорыннан алып быел гына комбайнчы ярдәмчесе булып чыккан яшүсмер малайга кадәр һәркем икмәк язмышы өчен борчылып, көннәр аяз торган вакытта уңышны җыеп калырга ашыктылар.

***

Вәсилә гаиләдә дүртенче бала иде. Апа-абыйлары белән чоры өчен гади генә булган өйдә, башта аяк астында буталып, аннан өлкәннәрнең йомыш-юлына йөгереп, өй эшләренә катнашып үсте.

Әтисе Гайнелгыйлем абзый Габделхаков искиткеч тәртипле, классик татар зыялыларының — Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә тасвирланган татар зыялыларының тормыштагы гәүдәләнеше иде. Беркайчан да сүгенмәс, сүгенү түгел, хәтта беркемгә дә тамак ярып кычкырып ямьсезләнмәс иде. Революциягә кадәр алар нәселе тирә-юньдә мәгърифәтчеләр буларак таныла, Азнакай районының Уразай авылы мәдрәсәсендә хәлфәлек итәләр. Өстәвенә бөтен авылга бер сепараторның да бары тик аларда гына булып, бар халыкның сөт аертырга аларга йөрүе бу гаиләне авылның үзенчәлекле бер үзәгенә әверелдерә.

1917 елгы революция үз артыннан ил өстенә тагын да канлырак зилзилә, тугандашлар сугышы алып килә. Илнең астын-өскә актарып ташлый бу вакыйгалар, язгы ташкын бөтен чүп-чарны өскә күтәргән кебек, җәмгыятьтәге җыен әтрәк-әләм дә калкып чыга, шәһәрдә дә, авылда да житәкче урыннарга үрмәли. Гайнелгыйлем абыйларның да мәдрәсә эшчәнлеге туктатылып, сепараторлары тартып алына.

Төшенчәләр үзгәрә. Аллага ышану — Ленин-Сталин идеясенә ышану

белән, ата-анага хөрмәт партиягә хөрмәт белән алыштырыла. Гомер-гомергә булдыклылык билгесе булган байлык инкарь ителә, ярлылык, хәерчелек мактала, сүздә генә түгел, чынлыкта да чабата түргә менә. Гарәп хәрефләре белән язылган китапларны — диниме ул, дөньявимы, мөһим түгел — өй борынча җыеп алып, яндыра башладылар.

Гайнелгыйлемнәр өеннән дә олавы белән төяп чыгып киттеләр аларны. Әтисе, бичара, гомер буе җыйган рухи байлыкны алып китүче ат артыннан ишегалды уртасына басып карап калды. Чал керә башлаган сакалы дер-дер калтырый, иреннәре тавышсыз гына әллә дога, әллә бәддога укый. Күкрәктә янган ачуы чытырдап кысылган йодрыкларында гына күренә. Гаиләдәгеләрнең берсүзсез буйсынып эшләвенә, авылдашларының һәрвакыт хөрмәт белән карауларына күнеккән әтисен җилкәләре салынган, башы бөгелгән хәлдә күрү кыен иде Гайнелгыйлемгә.

Әтисе кабул итә һәм аңлый алмаса да, Гайнелгыйлем яңа тәртипләрнең озакка икәнен аңлады. Артың белән киртә җимереп булмый, аерым шәхеснең генә каршы булуы бөтен ил буйлап дәүләт дәрәҗәсендә барган процессларны туктата алмый. Дәүләт ул — көч, ул — армия, чиновниклар өере, җәзалау органнары булган көч. Иң яхшысы — килешү, бөтенесе чәршәмбе дип кычкырганда, пәнҗешәмбе булса да, исән калу өчен бөтенесе белән бергә чәршәмбе дип кычкыру. Денем өчен түгел, көнем өчен, ала карга булып йөреп әллә ни кырып булмаячак. Шулай фикер йөртте Гайнелгыйлем һәм эчтән белгәннәрен укый-укый комсомол булды.

Ул көнне атасы каядыр барган жиреннән кайтып кергәндә, кашлары җимерелгән, йөзе караңгы иде. Абзар тирәсендә нидер эшләп йөргән Гайнелгыйлемгә карап та тормыйча, бик җилләнеп өйгә кереп китте. Егет давыл буласын сизеп, куырылып куйды. Балтасын баз өстенә кертеп ташлады да, булачак вакыйгаларны көтеп, бүкәнгә утырган килеш Чатыр тау янындагы тау тезмәләрен күзли башлады.

Чыннан да, озак көттермәделәр. Болдырга чыгып баскан әнисе, кулын каш өстенә куйган килеш, егеткә эндәште:

— Улым, Гайнелгыйлем, кер әле, әтиең чакыра.

Гайнелгыйлем кергәндә әтисе түр сәкедә, күзләрен йомган хәлдә, стенага сөялеп утыра иде. Әллә арып хәлсезләнгән, әллә йокымсырап ук киткән.

Егет эндәшми генә бусага буена чүмәште. Бераздан әти кеше күзләрен ачып, хатынына карап сүз башлады. Тыныч кына сөйләшсә дә, эчтән ярсуы тавышының зыңлап торган киеренкелегенә бәреп чыккан:

— Менә, баланы үстерәсен-үстерәсен дә, ул синең башыңа кәкәй итә икән. Хәзер безнең кирәк юк аңа. — Әти кеше, ниһаять, улы ягына башын борды. — Каян барып чыктың син ул эт өере янына? — Тавышы ачудан кысылып, сүзләре ысылдап чыкты.

— Әти, хәзер заманы шуларныкы. Эт дисеңме син аларны, әллә кем дисеңме, эш башында комсомоллар, коммунистлар, авылны...

— Бәтелдәмә әле, җил тегерманe кебек куалама, — карт үз гомерендә беренче тапкыр улының кызу сөйләшүен кимчелек итеп күрсәтеп, аңа кисәтү ясады. — Кая чабасың, ашыкма. Авылны... Бер көнлек аларның гомере. Мондый имансызлык белән яшәп була димени?

Гайнелгыйлем исә тагы да кызулап, әтисе туктатканчы дигән кебек, ашыгып-кабаланып сүзен дәвам итте:

— Ай-һай, бер көнлек микән? Бик каты тоталар халыкны. Халык бит ул, әти, үзең беләсен, көчне генә аңлый. Бөтен ил буйлап бит ул, бөтен ил буйлап. Әнә, гәжитләрне кара...

«Гәҗит» сүзе әтисен котыртып кына җибәрде:

— Төкердем мин аларның гәҗитләренә, — дип урыныннан сикереп торды соң чиккә җитеп ярсыган карт. — Гәҗит! Гәҗитмени бу?! Менә элек гәҗит иде ул! Дин турында, мөселман дөньясы турында язалар иде. Боларның бар белгәне ярлы-ябагай, революция… Ул көтүче Шәмсиләр, үзенә өй дә салып кәрә алмаган, хатын алып хатын белән дә тора алмаган Гайфиләрне белмиммени мин! Кыскасы, шул, — әтисе Гайнелгыйлемгә таба бала башы чаклы йодрыгын болгап алды, — бүтән күрмим сине ул ат караклары — комсомоллар, коммунистлар янында.

Өлкәннәргә буйсыну, ата-ананы хөрмәт итү кебек гасырлар дәвамында калыплашып килгән халык традицияләрендә тәрбияләнгән егеткә кыен булды ул вакытларда. Ләкин ул заманаларның тиз генә кире кайтмаслык булып үзгәргәнен күрә, сизә иде, шуңа күрә үз дигәнен итте. Әтисе йокыга киткәнче өйгә керә алмый йөргән вакытлары да булды. Мондый вакытларда әнисе өйдән шыпырт кына йә пешкән бәрәңге, йә ипи кыерчыгы алып чыгып, Гайнелгыйлемгә бирер иде дә чыштыр-чыштыр өйгә кереп китәр иде.

Вакытлар үтә, тәртипләр катылана барган саен, Габделхак ага да тынычлана төште. Эчтән килешеп бетмәсә дә, улының хаклы, заман белән бер аяктан атларга кирәклеген аңларга мәҗбүр булды, ахры.

Коллективлаштыру башлангач та, Гайнелгыйлем оештыручылар сафында ук булмаса да, колхозга керүчеләрнең беренчеләреннән иде. Һәрвакыт индивидуалист булган крестьян өчен чит һәм сәер яшәеш иде колхоз тормышы. Ләкин кеше барысына да өйрәнә, барысына да күнегә икән. Тора-бара уртак басу-кырларга, уртак ындырларга да өйрәнделәр. «Минеке» дип канына сеңгән авыл кешесе «колхозныкы» дигән төшенчәгә ияләште, колхозныкын үзенеке дип кабул итте.

Сугыш башланганда, Гайнелгыйлем өйләнгән, балалар атасы булган иде инде. Тормышлар да түгәрәкләнеп килә, хезмәт көненә дә олау-олау икмәк ала башлаганнар иде. Кечерәк кенә булса да, үз өе, бакча башында мунчасы бар. Ихатада каз, кош-корт, бала-чага тавышы, абзарда сыер мөгри, сарыклар бәәлди… Урманай авылы кызы булган хатыны Шәмсия ачык йөзле, ирне ир итеп таный торган, эшкә уңган. Ни кирәк тагын кешегә? Яшә, яшәвенә, балаларның уңышына куанып яшә дә яшә, югыйсә. Юк, адәм баласы күңеле фетнәле, һаман җитми аңа. Шул җитмәгән артыннан куып, булганын да югалта аннары.

1941 елның җәендә Уразай урамнары мәет чыккан йорт кебек тын калды. Урамнар буп-буш, карты-яше, барысы да эштә. Озакламый кара хәбәрләр килергә тотынды, кешеләр хат ташучыны куркып көтә башладылар.

Озакламый бер кулы гарип булу сәбәпле фронтка бармый калган Гайнелгыйлем абзыйга колхоз рәисе вазифаларын йөкләделәр. «Грамотаң бар, — диде райком секретаре бюрода, — авылны, аның кешеләрен яхшы беләсең. Онытма, монда да фронт».

Эшләгән кеше үзе генә белә ул елларда рәис булуның нәрсә икәнен. Районнан эш, күрсәткечләр, уңыш таләп итәләр. Кеше юк. Өйләренә барып керәсең, сәке тутырып бала-чага йоклый. Иң олысына 12-13 яшь. Буыннары да ныгып җитмәгән, тезләрен иягенә кадәр тартып китергән дә, авызын ярым ачып, сабыйлар йокысы белән йоклап ята. Үзе дә аруның соңгы чигенә җиткән, куллары ярылып, күз кабаклары йокысызлыктан шешенгән хуҗа хатын, рәисне күрүгә, бәрәңге пешереп йөргән җиреннән барып, малайны уята башлый. Тегесе тора, күзләре ачылмый, шул хәлдә абына-сөртенә юынырга чыгып китә. Иртәнге аш — ике бәрәңге. Шул хәлдә аңа көне буе урак урасы бар. Боларны күреп торган Гайнелгыйлем абзыйның йөрәге сызды, тамагыннан аш үтмәс булды.

Мангаена җыерчыклар ятты, күз алдында ябыкты, яңак сөякләре калкып чыкты. Хет ашарга булсын иде әзрәк, ашарга! Эштән баш тартмыйлар, ләкин көч, хәл җитми. Их, бирергә иде бераз икмәк, бар югыйсә колхозның запасы, ләкин катгый куелган — бөтенесе хөкүмәтнеке! Сугыш, хәрби чор законнары!

Шулай да беркөн түзмәде Гайнелгыйлем, районга барып, беренче секретарьга керде. «Иптәш секретарь, — диде ул, — аз гына икмәк бирик халыкка. Аларга эшләргә кирәк бит». «Габделхаков, — секретарь нигәдер читкә карап сөйләде, — Габделхаков, син мина кермәден, мин сине күрмәдем».

Әлеге сүзләрнең мәгънәсен Гайнелгыйлем юлда кайтканда гына аңлады. «Теләсәң нишлә, — дигән икән ана секретарь, — ләкин тавышы-сүзе чыкса, үзен җавап бирәсең».

Озак уйлады Гайнелгыйлем. Бер яктан, бөтен колхоз икмәге — хөкүмәтнеке. Икенче яктан — кешеләр дә бит хөкүмәтнеке. Ачка шешенә-шешенә алар кем өчен тырыша соң? Әгәр авыл үлеп бетсә, тфү-тфү, әйттем исә кайттым, яки берничәсе генә китеп барса да, димәк, илгә икмәк җитештерүчеләр кими бит. Максат бит колхозчыларны ачлыктан үтерү түгел, мөмкин кадәр күбрәк икмәк бирү. Ничек ди әле Ленин, «бер адым артка, ике адым алга», диме?

Шулай фикер йөртте колхоз рәисе һәм тәвәккәлләргә булды. Хисапчы белән утырып бар булган байлыкны исәпләделәр дә чәчүгә ярамаган чүпле, ләкин он итеп ипи пешерергә бик тә ярый торган бодайның бер өлешен халыкка таратырга булдылар. Хисапчы нәрсә, ул кушканны гына үтәүче, бөтен җаваплылык рәис өстендә. Гайнелгыйлемнең монда да ата йортында алган дини-әхлакый тәрбиясе үзенекен итте, ул икмәкне һәркемгә тигез итеп түгел, ә иң мохтаҗларга, колхоз кырында иң күп көч куйганнарга мулрак бирдертте. Инде сугыш афәте үткән, ирле гаиләләр дә бар. Ирләренең кайберсе районга йөреп эшли, ир-ат булган йортта күпкә җиңелрәк. Ә итәк тотырып бала белән утырып калган толлар бик авыр гомер кичерәләр — беренче чиратта аларны кайгыртырга тырыштылар. Коммунистларның атеистик тәрбиясе нәтиҗәсендә Алладан, мәчеттән, димәк, изгелек һәм мәрхәмәтлелек тойгысыннан бизгән халык Гайнелгыйлемнең үзен куркыныч астына куеп ярдәм итәргә омтылышын аңламады. Юк, халык түгел, ә үзенә кимрәк өлеш тигән хәллерәк кешеләр кабул итмәде моны. Шул төнне үк кара пәрдә ябылган тәрәзә, бикле ишекләр артында колхоз рәисенең «корткычлыгы», дәүләт байлыгын әрәм-шәрәм итеп, таратып ятуы хакында хат язылды. Мондый хатны кемгә җибәрәсе икәнен, аның нинди нәтиҗәләр китерәчәген белә иде язучы.

Бер көннән соң, төнлә, Габделхаковларның ишеген кактылар. Вәсилә инде йокларга яткан иде, ләкин, нининдер куркыныч килгәнне сизеп, тынсыз калды. Ишектән кергән ике кеше белән әтисе быдыр-быдыр нидер сөйләштеләр дә каядыр җыена башладылар. Әнисе, ашыга-каударлана, нәрсәгә тотынырга белмичә нидер җыештырды, нидер төйнәде. Гайнелгыйлем башын иеп, авыр атлап чыгып киткәч, Шәмсия бик озак үкседе. Кешеләр каршылык күрсәтергә базмасалар да, этләре Карабай хуҗаны каядыр алып китүләре белән килешә алмады. Беркемгә дә явызланмаган, өйнең ялгыз түгеллеген белгертер өчен генә һау-һаулап куючы Карабай, бу ике кешегә өйгә кергән вакытта ук, нишләптер ярсып-ярсып өрергә тотынды. Тегеләр ничек кирәк, алай бусаганы атлауга, тышкы яктан ишекне тырмый-тырмый шыңшый башлады. Кире чыкканда да кырыйларында үрле-кырлы сикереп, хуҗасының кууына, кычкыруына карамастан, аякларыннан, итекләреннән тешләргә тырышып изаланды. Машина кузгалгач, үз-үзен онытып, тәгәрмәч астына керердәй булып, артыннан чапты. Шофёр аты-юлы белән сүгенде, авылны чыгуга, машинадан сикереп төште дә кобурасын ачты. Авыл өстенә җәелгән үле тынлыкны пистолет тавышы икегә

яргандай булды. «Кара козгын» янәдән кузгалып киткәндә, ачык авызыннан кан агып чыккан этнең арткы аяклары тартылып-тартылып куя иде.

Кара еллар, куркыныч чорлар... Ил өстендә ач үлем уйный, кызарып баеган офыклардан ерткыч тиран үзенең чираттагы корбанын эзләп җир өстен күзли сыман... Коръән Кәримнең мәрхәмәтлелек принципларында тәрбияләнгән Гайнелгыйлем исемле бер татар баласы кешелексез режимның чираттагы корбаны булып төрмәгә утыртыла. Хатыны Шәмсия берсеннән-берсе кечкенәрәк дүрт бала белән өйдә кала.

Ләкин, Ходайның рәхмәте, халык гел кара эчле кешеләрдән генә тормый шул. Ни генә әйтмә, яхшы кешеләр күбрәк. Колхоз рәисен кулга алып, ай үтәр-үтмәс, авыл халкы исеменнән Казанга аны яклаган, аклауны сорап мөрәҗәгать иткән хат килеп иреште. Әйтергә кирәк, дәүләт милкенә кул сузучы, халык дошманы булып саналган кешене яклап тавыш бирер өчен, ул вакытта бик зур батырлык кирәк була.

Яхшы көйләнгән машина кебек эшләүче репрессия машинасы да кайчак аксаклап куя икән. Ни хикмәттер, авыл халкы язган үтенеч үзенекен эшләдеме, «җинаять»нең дәлилләре житмәдеме, нәрсә булса да була, бер елдан соң кайтып төште Вәсиләнең әтисе. Әтисе капкадан килеп кергәндә, кызчык өй күләгәсендә чүпрәкләрдән корыштырган курчаклары белән дөньясын онытып уйнап утыра иде. Гайнелгыйлем баскыч төбенә килеп утырды да кыюсыз гына якынлашкан сабыена сау кулын сузды. Әтисенең тир, тузан исе килеп торган, эре шакмаклар төшкән күлмәгенә борынын төртеп озак утырды Вәсилә. Сагыну, юксынуларны аңларлык түгел иде әле, ләкин моның бик тә мөһим вакыйга икәнлеген, тормышларында зур үзгәрешләр булачагын йөрәгенең әллә нинди кыллары белән сизенде.

Ул кичне йокларга яткан әтисе белән әнисе чаршау артында бик озак сөйләшеп яттылар. Рәхәт иде Вәсиләгә аларны тыңлап яту.

Икенче көнне таң белән Гайнелгыйлем районга китте. Беренче секретарь аны ничектер гаепле елмаеп каршылады.

— Утыр, Гайнелгыйлем, — секретарь исеме белән сөйләште, — утыр. Сөйләп җибәр, нинди планнар белән йөрисең?

— Нинди планнар булсын инде арестантның, иптәш секретарь. Архангельскига урман эшенә кеше җыялар икән, язылырга килдем.

— Шулай дисеңме? — Секретарь кулларын кушырып беркавым бик игътибар белән өстәлгә төбәлеп сүзсез утырды. — Китәргә дисең инде, алайса. Ә без монда иптәшләр белән киңәштек тә сине партиядә восстановить итәргә булдык.

Сүзләренең тәэсирен белер өчен, Гайнелгыйлемгә карап алды. Ләкин тегесенең ни йөзендә, ни тотышында эчке кичерешләрен сиздерердәй галәмәтләр күренмәде.

— Рәхмәт, иптәш секретарь, — Гайнелгыйлем нидер әйтергә теләп, тукталып калды, — ышанычыгыз өчен рәхмәт. Ләкин юктыр, мин сезнең генә түгел, ә партиянең ышанычын аклый алмадым бит...

— Юк, юк, мин генә түгел, бюро хәл итте бит синең партия сафларына кайтуыңны.

— Анысы шулайдыр, бюродыр. Ә мине хөкем иткәндә, бюродагы иптәшләр кайда иде соң? — Элекке рәис дулкынланудан торып ук басты. — Ник әнә шул, әнә шул, иң кирәк вакытта яклап чыкмадылар соң алар?

— Да брось, Габделхаков, — беренченең тавышында тимер ноталар яңгырады. — Әйдә, демагогия белән шөгыльләнмә. Булган — үткән, хәзерге белән яшәргә кирәк.

— Кара сакалың үзеңнән калмый, ди. Җай чыгуга теләсә кем судимость

белән күзгә төртәчәк, «үзеннең кем икәненне бел» генә диячәк. Аннары үземне үк пычратучылар белән бер үк авылда ничек яшим мин? Ул оятсызлар ояла белми, алар өчен оялып, аларның кабахәтлеге өчен оялып, күзләренә карый алмыйм, урамда очрасалар, читкә карап үтәм!

— Кара әле, Гайнелгыйлем, — секретарь янәдән дустанә тонга күчте. — Кара әле, сиңа аңлатып торасы юк бит инде, без органнар эшенә катыша алмыйбыз. Үзең дә инде, — беренченең бармаклары өстәл өстендә биешеп алдылар, — тавышсыз гына ерып чыга алмадың. Авылыңда кемнең-кем икәнен белми идеңмени, кирәгенчә бирергә иде, тамаклары тыгылсын иде.

Бераз сүзсез утырдылар. Гайнелгыйлем авыр гына урыныннан торды:

— Рәхмәт барысы өчен дә. Әмма күңелем кайтты шул. Кешеләргә дә, эшкә дә. — Кепкасын рәтләп куйгандай башын селкеп алды да дәвам итте. — Тормышымны янадан, ак кәгазьдән башлап карарга исәп. Рәхмәт.

Авылга ашыкмыйча гына кайтты. Көзнең тымызык, пәрәвез җепләре очудан туктап, әбиләр чуагының тәмамланып килә торган чагы. Көз — үткән елга йомгак ясый торган вакыт. Нәкъ менә көз көне гомернең үткәне, тагын бер елның вакыт чоңгылына китеп югалганы аермачык сизелә. Игеннәр инде җыеп алынган, халык бәрәңге белән мәш килә. Табигать кышкы йокыга хәстәрләнеп итәк-җиңнәрен җыештыра, үткән матурлыкны сагынып, яңгырлар рәвешендә яшь коярга әзерләнә.

Районда катгый сөйләсә дә, тиз генә чыгып китә алмадылар әле. «Кыш үтсен, — диде хатыны Шәмсия, — итәк тулы бала белән кая барып төшәрбез бит. Көтик бераз...»

Хак сөйли, риза булды ир. Дөресен генә әйткәндә, хатынның кузгаласы килмәгәнлеге сизелә, ләкин иргә каршы да килә алмый. Тәрбиясе андый түгел. Аннары соң Гайнелгыйлем дә ике сөйләргә яратмый. Ышансаң, берүзе дә чыгып китәр.

Карлы-буранлы кышны ферма, ындыр табагы тирәсендә төрле эшләрдә чуалып үткәргән Гайнелгыйлемнең язга таба тәмам түземе бетте. Ташулар китеп, бераз юллар төшүгә, районга барып, Архангельскига китәргә язылып, белешмә алып кайтты да юлга кузгалдылар. Бөгелмә тимер юл вокзалына тирә-як районнардан җыелган, якты, матур, бәхетле киләчәк төзергә тиешле совет кешеләрен мал йөртә торган вагоннарга кертеп төяделәр дә, паровоз озын, сагышлы гудок биреп, кузгалып та китте. Кемнәр генә юк иде монда: акчага өметләнүче егет-җилкенчәк, җитәкчеләр белән килешә алмаучы ирләр... Әмма иң күбе колхоз тормышыннан гарык булып, моннан да начаррак булмас әле дип, бәхет эзләп кузгалучылар иде. Урысы, татары — бөтенесе бергә. Гаиләләләр аерымрак почмакка тупланып, барын-югын уртак итеп яшәргә тырыштылар. Ярдәмләшергә, бала-чагага күз-колак булырга да шулай уңайлырак иде. Поезд кыскарак вакытларда тукталып торганда, ирләр станциядән тиз-тиз азык-төлек юнәтергә йөгерә. Шул вакытта кем-нәрсә сатып алып өлгерә, кузгалгач уртага салып, бергә тукланалар.

Бала-чага егылып төшмәсен өчен ачык ишеккә аркылы куелган такта киртәләргә таянып, Гайнелгыйлем уйга калды. Поезд ашыкмыйча гына бара, үзе белән әллә кемнәрне әллә кайларга алып бара. Ни көтә аларны? Ашыкмадымы Гайнелгыйлем? Беткә ачу итеп тунны утка якмадымы? Сорауларның очы-кырые юк. Нишлисең, эшләнәсе эшләнгән, күңелдә әйтерсең ниндидер юеш, кара таш ята. Дөнья шыксыз, чит булып тоела. Болай йөрергә тиеш идемени газиз башлар, әгәр тормышлар болганмаса. Безгә генә төшкән бәла түгел, дип юаныргa гына кала. Ярый лә барган җирдә бу гарип кулы белән эш таба алса.

Барып чыкмаса? Кайларга барып бәрелер. Кайтып егылыр җире дә юк, авылга җиңелеп кайтуны күз алдына да китерә алмый.

Вагонның түр башында гармун тавыш биреп куйды. Бөгелмә егете Вагыйз бу. Типсә тимер өзәрдәй егет кәрәктәй куллары белән төймәләрнең ничек җаен табадыр, әмма аның кулында гармун могҗизалар тудыра инде. Нәрсә куып чыгаргандыр егетне туган оясыннан, берәү дә белми, әмма җырлаганы гел туган ил турында:

Урман эчендә яшел болында
Кырау алмасмы кызыл миләшне?
Үзебез яшьләр, йөрибез сәфәр,
Ятлар сөймәсме безнең кәләшне?

Ул җырлаганда хатын-кыз елый, ирләр, үз уйларына батып, кара коелалар. Хәтта бала-чагага кадәр бермәлгә тынып кала. Менә хәзер дә Вагыйз чираттагы җырын — дөньяга сибелгән татарның ачы, горбәтлектә үткән, шуңа мәҗбүр иткән язмышын каһәрләгән җырын башлады:

Карлыгач кара, муены ала,
Һаваларга очып югала;
Бәхетле бала өйдә кала,
Бәхетсезләр китеп югала.

Моңа кадәр игътибар иткәне булмаган икән Гайнелгыйлемнең, татар җырларының бик күбесе чит җирләрдә йөрүчеләр тарафыннан чыгарылган икән. Бәхет эзләп, мал эзләп ил гизгән егетләр, йөреп-йөреп тә теләкләренә ирешә алмагач, сагыш-моңнарын көйгә салганнар:

Сандугач сайрар җир түгел,
Сайрар иде — туган ил түгел,
Йөгереп кенә кайтыр идем,
Йөгереп кенә кайтыр җир түгел.

Ул көнне Вагыйз кичкә кадәр йөрәкләрне өзгәләде. Йокларга һәркем авыр тойгы белән ятты.

Икенче көнне уянганда, поезд туктаган иде.

— Ярославль, — дип аңлатты проводник, — көндезге икеләргә хәтле торачакбыз.

Бу сүзләрне ишетүгә, Гайнелгыйлем тиз-тиз җыена башлады. Исәбе монда яшәүче сеңлесе Мөзәяннәне барып күрү иде. «Белмәссең дөнья хәлен, — дип уйлады ул, — әллә күрешәбез, әллә юк».

Калганы куркыныч төш кебек булды. Коры ерганак аша үтә торган күпердә Гайнелгыйлем кәгазьдәге адреста күрсәтелгән урамны сорап бер егеткә мөрәҗәгать итте. Тегесе башта аңламый торды, аннары соң чәйнәлеп беткән папиросын төкереп, баздан чыккан тоник тавыш белән: «Пойдём, покажу», дип алдан кузгалды. Күперне чыгып җитүгә, алда тагын ике кеше күренде, Гайнелгыйлем нидер сизенеп күз кырые белән артка күз ташлауга, анда да ике шәүлә чайкалганын күрде. Юл күрсәтергә алынганы да борылды, ияге белән генә ишарәләп күпер төбенә күрсәтте. Тирә-юньдә этле җан да юк. Гайнелгыйлем йөрәгенең еш-еш тибә башлаганын сизде. Күпер төбенә төшүгә, тегеләргә борылып басты.

— Ну, чё, — дип сүз башлады черек теш, — давай всё что есть, некогда нам.

— Мужики, — Гайнелгыйлем, аякларын җайлабрак басып, кепкасын арткарак этеп куйды. — Деньги у меня есть, но я их вам не отдам. С семьёй едем в Архангельск, если деньги оставлю вам, детишки с голоду помрут.

— А нам по... — дип пычрак итеп сүгенде өрәкләрнең берсе. — Россия большая, выкрутишься...

«Пычаклары юк, — дип нәтиҗә ясады Гайнелгыйлем, — булса күрсәтеп куркытырлар иде. Димәк...» Фикерен очлап тормады, һәр мизгел кыйммәт, авылдагы калай әтәчләр белән очрашканда, үзен берничә тапкыр коткарган алымны, искәрмәстәнлекле кулланды — кырыннан үтеп артка чыгарга азапланганына сугып та җибәрде. Тегесе, гәүдәле генә булса да, көпшәк икән, кискән агач кебек җиргә ауды. Калганнарының күзләрендә аптырау галәмәте күренүгә, Гайнелгыйлем инициативаның үз кулында икәнен аңлады. «Или хәзер, или бетерәләр мине». Ышанычлы итеп алга атлады, иң алда торганның күзләренә караган килеш, үзенең өстенлеген тойган хәлдә йодрыгын тегенең нәкъ ике каш арасына утыртты. Беренче очраган черек тешлесе, «убивают» дип акырып, коры елга буйлап йөгерә башлады, калган икесе дә аңа иярделәр. Ләкин Гайнелгыйлем егылганнарны истән чыгарып, мавыгып китте, берсе аңына килеп, аякка басып өлгерде. Арттан башына китереп сугуга, дөнья карангыланып, күз алдында бер көлтә очкыннар чәчрәде дә каядыр убылып төшеп китте.

Ыңгырашып күзен ачып җибәрүгә, аркасына әйләнде дә, төенчек итеп култык астына бәйләгән акчаларын капшады. Костюмы да, төенчек тә юк, күлмәк кендегенә хәтле умырып төшерелгән... Башы үтереп сызлауга карамастан, ашыга-ашыга аягүрә басуы булды, дөньяның күз алдында әйләнүенә, күнеленең болгануына чыдый алмыйча, җиргә чүкте. «Болай булмый, поезд китсә, Шәмсия нишләр берүзе» дигән уй күңелне айкап алуга, торып басты да, иреннәрен чәйни-чәйни, вокзалга таба атлады. Күз төпләре кара янган, бите-башы канга буялган ирен күрүгә Шәмсия өнсез калып, лып итеп вагон идәненә утырды да, кем икәнен дә карап тормыйча, кырыенда йөргән баланың башын күкрәгенә кысты. Гайнелгыйлемне вагонга күтәреп менгерделәр, кемдер калай кружка белән чәй китереп тоттырды, кемдер йөгереп җылы сулы комган, чиләк алып килде. Ыгы-зыгы арасында ирнең телен көчкә әйләндереп әйткән сүзләреннән эшнең нәрсәдә икәнен аңыштылар.

— Ярар, Гайнелгыйлем абый, — дип юатты яшьли тол калып, бала да табарга өлгерә алмаган, туп кебек түгәрәк гәүдәле Галимә, — аптырама. Жан биргәнгә җүн бирермен, дигән. Совет илендә яшибез лә.

Баш сызлавы кими башлаган Гайнелгыйлемгә дөнья гаме кайта башлады:

— Шәмсия, — дип эндәште ул, күеп ярылган иреннәрен ялый-ялый, — Шәмсия, акчаны алганнар бит, нишлибез?

— Да подожди, Гилем, — дип сүзгә кушылды Бөгелмә урысы Егор, — не беспокой жену, что-нибудь придумаем.

Шәмсия ике хис уртасында бәргәләнә, әле һаман аңына килә алмый иде. Бер яктан, иренең исән-сау булуына сөенә, икенче яктан, җиде ят җирдә бер тиенсез калуларына гаҗиз булып, нишләргә, үзен кая куярга белми. Төнлә ирен алып киткән вакытта үз илендә, үз өендә, туганнар арасында иде. «И Ходаем, — дип эченнән ачыргаланды хатын, борчылганын иренә күрсәтмәскә тырышып. — Бу балаларга ни ашатырбыз? И Ходаем...» Саташулы, бастырулы йокы белән төн үтте. Дөньяда гамьнәре булмаган тәгәрмәчләр тыкылдый-тыкылдый һаман алга бардылар, Чатыр тау, Стәрле елгасы, анда үткән гомер торган саен ерагая барды. Ишек ярыгыннан көн яктысы саркылып керә башлауга, Гайнелгыйлем белән Шәмсия урнашкан почмакка Вагыйз килде.

— Кара әле, Гайнелгыйлем абый, — диде ул, аякларын бөкләп вагон идәненә утыра-утыра, — без кичә иптәшләр белән уйлаштык та, — ул кесәсенә тыгылды, — уйлаштык та, монда бик күп түгел инде, ну ачтан үлмәскә житәрлек. Уйлаштык та, — сүзләрендә бутала-бутала, Вагыйз кесәсеннән бер төргәк тартып чыгарып, берни аңламыйча утырган Гайнелгыйлем белән Шәмсиягә сузды, — хәл кадәренчә ярдәм итәргә булдык, бераз акча җыйдык. Хәл кадәренчә инде...

Гайнелгыйлем төенчекне учына кыскан килеш, рәхмәт тә әйтә алмыйча, ишектән артка таба йөгергән урманга карап, озак утырды...

***

Халык юкка гына «Агыйделнең аръягында бер энәгә бер дөя», димәгән икән. Беркайда да пешереп куймаганнар, кайда да бер дөнья. Эше начар түгел, граматолы булуын искә алып, учётчик итеп куйдылар Гайнелгыйлемне, ләкин баракның чаршау-фәлән белән генә бүлеп алынган бүлмәсендә, бердән, гаилә белән яшәү бик авыр иде, икенчедән, чит-ят дөнья, бөтенләй икенче мохит һич кенә дә кабул итәргә теләмәде иркен басу-кырларга, туганнарның һәм дусларның теләктәшлегенә таянып яшәргә күнеккән татар баласын. Монда һәркем үзе өчен, һәркем мин дип яши. Берничә тапкыр кыен хәлдә калган хезмәттәшенә ярдәм иткән Гайнелгыйлемгә сәерсенеп карадылар.

Бигрәк тә хатыны Шәмсия авыр кичерде мондагы тормышны. Сагынуына чыдый алмыйча көн елады, төн елады. Боегып, ябыгып калган хатынына карап ирнең дә эче сызды, ләкин бирешмәскә тырышты. «Үтәр» дип уйлады, «күнегер» дип үзен-үзе юатты.

Тел белмәгәч, аралашыр кеше табу да авыр иде Шәмсиягә. Аннары соң мондагы хатын-кыз ничектер әрсез, бары тик үзенекен генә эшләп өйрәнгән, беркем белән дә исәпләшмиләр. Кычкырышу, әшәке сүз белән кешенең битен ерту аларга берни тормый. Үз гомерендә сүгенү сүзе дә ишетмәгән Шәмсиянең аларның хәтта үзара талашканда әйткән сүзләреннән дә колаклары кызара иде. Әтисе яһүд, әнисе маржа булган Валя түти генә хатынның хәленә керә, киңәшләр биреп аны яклый иде. Гаҗәп, кайдан өйрәнгәндер, әмма Валя азмы-күпме татарча да сукалый һәм шуңа күрә Шәмсиягә туганы кебек якын тоела иде.

— Син алардан не бойся, — дип өйрәтә иде Валя түти Шәмсияне, — сами по себе они хорошие. Тормыш авыр, быт не обустроенный, вот алар шундый наглый булырга научились. Син дә научишься...

Шулай да өйрәнә алмады Шәмсия. Беренче мәлләрдә тешен кысып түзсә дә, янадан «кайтыйк» сүзен ешрак әйтә башлады. Ире эндәшмәде. «Балаларга да кыен, — диде хатыны, беренче класска барган Вәсиләгә ишарәләп, — олылары әле русча аңлашалар, бусы бигрәк бернәрсә аңламый бит».

Икенче юлы сүзне Вахит совхозыннан башлады. «Камилә апа яза, — диде ул җайлап кына, кичке аш вакытында калын итеп туралган ипи телемнәрен ире алдына этәреп. — Вахит совхозы бик күтәрелеп киткән икән. Эш бар, ди. Квартир да бирәләр, ди».

Гайнелгыйлем эндәшмәде, авыр итеп көрсенде генә. Эчендә нинди утлар янганын үзе генә белә, кешегә генә күрсәтми, хатыны тагын шуңа ялкын өсти.

Мондый сөйләшүләр ешайганнан-ешайды. Шәмсия әле Вахит совхозын, әле Урыссуны мактап сөйләде. Азнакай, Әлмәт якларында нефть табуларын, кешеләрнең шунда эшләп акча алуларын да искә алды.

Беркөнне ир түзмәде.

— Тәк, — бала башы чаклы сыңар йодрык өстәлгә ятты, ләкин Шәмсиянең

эченә өмет тулы жылы йөгерде, чөнки «тәк» янап түгел, ә ниндидер карар кабул ителгәнлеген аңлатып, йомшак ноталар белән әйтелгән иде. — Тәк, бу ай бетсен, квартальный премия алабыз да Аллага тапшырып кузгалабыз. Вахитка кайтабыз.

Шатлыгыннан сикергәләп китәсе килсә дә, Шәмсия яулыгын рәтләгән булып, бәреп чыккан шатлык яшьләрен сиздермичә генә сөртеп алды. Әтиләренең һәр сүзен шомраеп тыңлап утыручы олы кызлары Фәния килде дә бер сүз әйтмичә әтисенең биленнән кочып алып, битен аның күкрәгенә яшерде. Кыз тавышсыз гына елый, мөлдер-мөлдер яшь түгә иде, Гайнелгыйлем моны күлмәгенең мизгел эчендә юешләнеп чыгуыннан аңлады.

И-и ул вакыттагы шатлыклар! Әйберләрне җыйнап төйнәгәндә, Шәмсия очып кына йөрде, битләре алсуланды. Иренә шулхәтле яратып карый, әйтерсең лә яңа өйләнешкән парлар. Гайнелгыйлем дә моны сизә, хәләлен кочыплар аласы килә, әмма кырыс кыяфәтен югалтмаска тырыша. Җилкәсеннән тау төшкән кебек сизә, күнеле бердән җиңеләеп, яктырып китте, әледән-әле балалар белән шаярып ала, ул да булмый, Шәмсиягә булышырга тотына. Ир белән хатын ике арада туган җылы аңлашучанлык, икесе генә белгән татлы ләззәтне тойган хәлдә, шул күтәренкелекне сакларга тырышып, бер-берләренә бик игътибарлы булдылар.

Мулланур Вахитов исемендәге совхозда аларны бик җылы кабул иттеләр. Совхоз администрациясе дә, авыл кешеләре дә Гайнелгыйлемне электән үк яхшы белгәнгә, монда үзләшеп калу аңа җиңел булды. Төрле җирдән җыелган халыкны бергә туплап яшәүче, гаять зур җирләргә ия бу хуҗалыкка хөкүмәт бик нык ярдәм итә, шуна күрә фатир да, техника мәсьәләсе дә, нигездә, хәл ителгән. Кил, яшә һәм эшлә генә. Балаларга бакчасы да, мәктәбе дә бар. Әмма Гайнелгыйлем хөкүмәт торагында яшәп, аңа бәйле булырга теләмәде. Урнашып, беркадәр баш-күз алуга, Уразайдагы йортларын сүтеп алып кайтып, яңа ихата торгызып та куйды. Моны алар һич авырсынмыйча, очынып эшләделәр. Гайнелгыйлемне иң гаҗәпләндергәне балалар булды. Читтә боек кына, сүзсез генә йөриләр иде, монда, әйтерсең, чәчәк аттылар. Күзләрендә нур, шау-гөр, ни кушсаң, шуны һич карулашмыйча эшләп куялар. Тәкъсин белән Фәния җәй буе әле кырда, әле терлекчелектә эшләделәр. Әхтәм белән Вәсилә дә кул арасына керә, хуҗалыктагы тавык чүпләп бетермәстәй эшләрне ялт итеп эшләп куялар.

Дөньялар да, Аллага шөкер, унайга китте, халыклар атасы дип саналган мыеклы агай Сталин үлгәч, халык төннән, алып китүләрдән курыкмый башлады. Иң мөһиме — тамак ипигә туйды, иң гаҗәбе — динне һәм дин тотучыларны эзәрлекләми башладылар.

Беркөнне Гайнелгыйлем ничектер, гадәттәгедән кабаланыбрак кайтып керде. Шәмсияне сүзсез генә түр якка чакырып алды да ярымпышылдап нидер сөйләшә башладылар. Хатынның өзек-төтек «И Ходаем, ярар, кайчан» дигән сүзләре ишетелеп торды. Кире чыкканда икесенең дә йөзе бәйрәм алдыннан була торган тантаналы тынычлыкта иде.

— Кызым, — дип эндәште Шәмсия Вәсиләгә, — син тиз генә идәнне юып чыгар әле. Мин тузаннарны сөртә торам.

Ник, нәрсә дип сораштырырга өйрәнмәгән кыз шунда ук эшкә тотынды. Аңа гына түгел, башкаларга да эш тапты әнисе, өйдә кемне дә булса каршы алырга җыенганда була торган ыгы-зыгы купты. Вәсилә юынтык суларны бакча артына түгеп килгәндә, урам капкасында авылның иң өлкән кешесе Салих бабай күренде. Ул туп-туры йортка узуга, тагын өч ир-ат күренде. Болар беразяшьрәк, ләкин сугышларны үткән, инде пенсия яшенә җиткән кешеләр иде.

Вәсилә ишегалдында эшләрен бетереп өйгә кергәндә, 7-8 кеше җыелган иде. Түр якта кем урындыкка, кем идәнгә тезләнеп утырганнар да салмак кына гәпләшәләр. Ниндидер мөһим вакыйга буласын сизеп, гаилә кешеләре аяк очына гына басып йөриләр, пышылдап кына сөйләшәләр. Ул арада Гайнелгыйлем торып басты, башкалар да кузгалышты.

— Ярый, җәмәгать, — әтисе торып, ирләргә йөзе белән борылды. — Без монда изге ният белән, җомга намазына дип җыелдык. Тәртибе буенча мин, җомга намазын укучы имам буларак, башлап сезгә хөтбә укырга тиешмен. — Әтисе башын иеп бераз сүзсез торды. — Әл-хәмдү-лилләһи...

Вәсилә әтисенә шаккатып карады. Нинди генә серләр яшеренми икән кешедә! Кайлардан белә, кайчан, кемнән өйрәнгән ул аларны?

Бераздан Гайнелгыйлем сүзен тәмамлады, утыручыларга арты белән борылып, йөзен кыйбла ягына юнәлтте. Ирләр дә аякка бастылар, ике саф булып тезелделәр. Гайнелгыйлем ике кулын күтәреп колак яфракларына кагылды:

— Аллаһу әкбар...

Моңарчы ишетелмәгән моңлы бу тавыштан Вәсилә каз тәне чыкканын тойды. Ниндидер ят, шул ук вакытта үтә дә таныш, кайчандыр яшәгән, әмма саташулы авыр чир аркасында онытылган дөньяның ишекләре ачылгандай тоелды. Өйгә илаһи тынычлык иңде, һәркем үтә дә серле, кирәкле вакыйга барганлыгын тоеп, үзләре шуңа катнашмасалар да, намаз укучыларга уңайлы шартлар тудырып, хәл кадәренчә өлеш кертергә тырышты.

Мондый җомга намазлары алга таба атна саен кабатлана башлады. Ул көнне Вәсилә, әнисенең әйткәнен дә көтмичә, идәннәрне юып, өйләрне җыештырып куя. Энеләре Хәмит белән Әнәс исә җомганың җаваплы көн икәнен белеп, йә шауламаска тырышалар, йә ирләр килер алдыннан бөтенләй өйдән чыгып китәләр иде.

Вакыт үз җае белән ага торды, еллар бер-бер артлы тезелешеп үттеләр дә үттеләр. Вәсиләнең абыйсы Тәкъсин авыл хуҗалыгы институтына укырга керде, Фәния апасы әтисе белән совхозда эшли. «Уң кулым» дип әйтергә ярата аның турында Гайнелгыйлем. Чыннан да Фәния һәр эшне батырып эшләде, берсеннән дә баш тартмады. Яңа урында, яңа нигездә аның гаиләгә ярдәме бәяләп бетермәслек булды. Ул үзе өчен түгел, туганнары өчен яшәде, укысыннар, диде. «Кеше булгач, мине онытмассыз», — дип шаярта иде.

Укуны тәмамлагач, Вәсилә ике классташ кызы белән Ивановога, тукучылар хәзерли торган училищега укырга керде. Бөтен Союзның төрле почмакларыннан җыелган халык арасында кемнәр генә юк иде. Кызларның аракы эчкәннәрен күреп, Вәсиләнең исе китте. Ирләр мәсьәләсендә дә талымсызлар күп. Ләкин татар авылы әхлагы, өйдә укылган намаз һәм әтисенең вәгазьләреннән ишеткәннәр кызны үз кысаларында нык тотты. Дөресен генә әйткәндә, җирәнә иде ул андый яшәештән, аракы сасысы килеп торган егетләр белән хәтта сөйләшүне дә үзенә түбәнлек санады. Группадашлары арасында Азнакай якларына хас булган кара тутлы, шомырт кара күзле, озын толымлы һәм зифа буйлы кызның чибәрлегеннән көнләшеп, гомер бер генә килә, әрәм итмә, дип, юлдан яздырырга, үзләренә ияртергә теләүчеләр дә булды. Вәсилә көлде генә. Гел укуда булды, өйдән ярдәм юк, шуңа күрә стипендиянең һәр тиенен санап тотты. Шөкер, тамагы да ач булмады, башкалардан калышмастай киенергә дә җитә иде.

Училищены гел «бишле»гә генә тәмамлаучы буларак, аңа теләгән шәһәренә китү мөмкинлеге бирделәр. Кыз Казанны сайлады. Ул килеп төшкәндә, сентябрь ае иде, 1 нче октябрьгә килерсен, диделәр. Вәсилә авылга юл тотты.

— Әйбәт булды, кызым, кайтуың, — дип каршы алды аны әтисе. — Әйбәт булды, бик вакытлы, бәрәңге ала башлыйбыз.

Бу — 1964 елның көзе, совхоз халкы «икмәк» дип янып, үз-үзен онытып яшәгән вакыт иде. Кырлардан, ындыр табагыннан өзлексез комбайн, трактор гөрелтесе ишетелә, кичке серле офыкны ерып, нәрсәләрдер вәгъдә итеп, ажаган уйный. Авыл өстендә кипкән арыш, бәрәңге сабагы исе, өйләрнен утлары ярты төн авышканчы сүнми, клуб алдында яшьлек шавы, гармун моңы...

***

Габделхаковлар өендә күңелле шау-шу. Олы абыйларыннан башка барысы да җыелган. Кичке аштан соң кызлар бизәнергә-төзәтенергә керештеләр. Василә тәмам шәһәр кызы булган, табигый чибәрлеге өстенә, арзан булса да, заманча итеп тегелгән күлмәге аны тагын да күркәмләтеп җибәрә. Кара, озын чәчләре дә бик килешле итеп, кыстырып җыелган, йөзенең төгәл, дөрес чалымнарын ассызыклап, авыл кызларыннан аерып, парикмахер кулы тигәнлеген күрсәтеп торалар.

— Әйдә, абый, — кыз көязләнеп көзге алдында боргаланган җиреннән Әхтәмне култыклап алды, — боларны көтсән...

— Урлап китмәсеннәр, — дип гадәттәгечә басынкы гына кинәш бирде Фәния, Василәдән бушаган көзгегә килә-килә.

Алар килеп җиткәндә, клубның эче дә, тышы да кайнап тора иде. Эш дип күнел ачмыймы, ардым дип ятып йоклыймы инде яшьлек! Җырлап эшли, уйнап яши торган вакытлары бит.

Әхтәм болдырда тәмәке тартып торучы егетләр белән исәнләшеп калды, Василә баш кына какты да эчкә узды. Уртада түгәрәкләнеп торучылар аны шундук үз яннарына алдылар. Ул арада Әхтәм дә кереп басты, абыйлы-сеңелле яңа башланган вальс көенә биеп тә киттеләр.

Василә ишектән кергәч тә туктальп калган, кем беләндер басынкы гына елмаеп, сөйләшеп торучы, кара плащлы, йокысызлыктан күзләре кызарган, битен ике-өч көн кырылмаган сакал каплаган кешегә ымлап, абыйсыннан сорап куйды:

— Кем бу? Бер дә күргән кеше түгел.

— Кайсысы? Теге, кара плащлысымы?

— Әйе.

— Ә, Мерзон ул, безнең комсомол секретаре.

— Мерзон? Урысмыни?

— Әллә тагын. Татарча сөйләшә ул.

Бу юлы инде Василә ишек ягына кызыксынып күз ташлады... һәм кинәт кызара башлаганын тойды, егет бик игътибар белән кызга карап тора иде. Уңайсызлануын яшерер өчен, ул биюле уенга кереп китте, ләкин элекке ваемсызлыгын кайтара, Мерзонның кара күзләрен тоюдан арына алмады. Сәер, рәхәт халәт иде бу, Василә башта абыйсына эндәшергә уйлады, аннан үз-үзенә көлеп куйды: мине егетләр күзли дип әләкләшсенмени инде.

Кайтырга алар үз очларының бертөркем кызлары белән чыктылар. Урам парлап та, төркем-төркем дә таралышкан егетләр-кызлар белән тулган. Көз, үзенә генә хас булган караңгы төненен кара канаты белән авылны төреп алган да аның тынычлыгын саклый. Тик кешеләр генә тынычланырга теләми йөриләр, көлешәләр, җырлыйлар... Аларга ияреп казлар кангылдашып ала, ябалак уһылдап куя. Әкренләп аяк тавышлары тына, парлашып беткән яшьләр дә пышылдап сөйләшүгә күчә. Йокы аралаш борчылып алган төн дә тынычлана, кара юрганына тагын да ныграк төренә.

Үзләренә якынлашкан саен, Василәләр төркеме дә сирәгәя барды. Югары очка алар күрше кызы һәм аларга ияргән тагын бер шәүлә кайтып җиттеләр.

Аның арттан килгәнен белсәләр дә, кызлар сизмәмешкә салыштылар, юк-бар сүздән дә кычкырып көлештеләр.

— Ахирәт, — дип пышылдады Вәсилә, — үземне генә калдырма мине моның белән.

Ниндидер хәйләне сизенеп, атылып килеп җиткән егетнең борын төбендә келә шалтырап ябылды.

— Вәсилә, — дип эндәште егет капка аркылы, — минем исемем Ефим.

— Шулаймыни, — дип сулышын тигезләргә тырышып җаваплады кыз, — ни бар, нишләп йөрисең, Ефим абый?

— Капка аркылы сөйләшәбезмени?

Кинәт кенә Вәсиләгә бу тавыш ошый башлады. Әйтерсең күптәнге танышын очратты, бик күп уртак сүзләрне сөйләшәсе, хатирәләрне уртаклашасы бар аның белән. Бу тавыш шулхәтле тыныч, шулхәтле ышанычлы, аңа бөтен серләреңне сөйләргә мөмкин сыман.

— Ефим абый, — кыз келәне ачарга сузылган кулын көчләп диярлек кире төшерде, әмма сүзләре үзе сизмәстән бераз иркәләнебрәк, назланыбрак чыкты, — бүген соң инде, иртәгә килерсез, яме.

Икенче көнне Вәсилә егетне күзләреннән генә таныды, бүген ул көязлекнең үзе иде: кырынган, өстендә энәдән чыккан костюм-чалбар, аякта бик яхшы, шыгырдап торган ботинкалар. Уен беткәнне дә көтмәделәр, клубтан бергә чыктылар, урамнарны, тыкрыкларны урадылар, сөйләшеп туя алмадылар.

Таң беленә башлаганда, кайтып юрганына төренеп яткан кыз бер нәрсәне аңлады: Казанга бармаячак ул, туку фабрикасы аннан башка гына эшләячәк.

***

Миңнесорур апа Ефимдагы үзгәрешләрне тиз сизде. «Берсенә эләккән безнең егет, — дип уйлады ул. — Юньле кеше баласы гына булсын».

Авылда сүз, хәбәр тиз йөрүчән. Ике-өч көн үтүгә Ефим белән Вәсиләнең очрашулары беркемгә дә сер түгел иде. «Бәрәкалла, бик әйбәт, егетебез чыннан да үткен икән. Нәсел-нәсәбе яхшы, кыз да сүз тидерерлек түгел», — дип сөенде Миңнесорур апа үз баласы кебек якын күргән Ефим өчен.

Ефимның үз гомерендә бу хәтле хисләр һәм уйлар өермәсе эчендә калганы булмагандыр. Әнисенең вафатыннан соң ул апасы, сеңелесе, энесе өчен җаваплылыкның аңа, бары тик аңа гына төшкәнен белә. Өйгә килеп хуҗабикә булган кеше ничек карар аларга? «Өйләнү — түгел сөйләнү», диләр, өйләнү — ул гомерлек. Икенче яктан — күңел җилкенә, йөрәк боерыклар белән яши алмый. Хет нишлә, күз алдында гел Вәсилә, егет әледән-әле эчтән генә кыз белән сөйләшә башлый. Хәтта бәхәсләшеп тә алалар.

Атна-ун көн үтүгә, Ефим тәвәккәлләде, бер сулышта кызга хисләрен дә, киләчәккә планнарын да аңлатып ташлады. Ташлады да, нәрсә әйтер икән дип, сүзсез генә көтә башлады. Әмма гаҗәп, уңай җавап алачагына үзе тамчы да шикләнми иде.

Вәсилә башта көлде, аннан моңсуланып калды... һәм ризалыгын белдерде. Ул көнне алар таңгача киләчәк белән яшәделәр. Уртак тормышларында булачак һәр адымны Ефим һәрьяклап нигезләп аңлатып сөйли иде. Аның хаклы икәнен аңласа да, кыз кайчакта болай, юри генә каршы төшә, тегесе исә елмаеп кына үткәреп җибәрә. Вәсилә аның тормышчан фикер йөртүенә, кешеләрне, дөньяны тирән белүенә һәм төгәл бәяләр бирүенә исе китте. Рәхәт иде Ефим белән, үзен ышанычлы түбә астында, якланган һәм сакланган итеп хис итте.

Калганы тиз булды. Вәсиләләр бәрәңге алып, төшке ашка кереп киләләр иде, урамда алар өенә таба килүче партоешма секретаре Әнвәр абый Булатов

белән Ефим күренделәр. Хатын-кызлар кереп китте, әтиләре авылның рәсми кешеләрен каршыларга капкага юнәлде. Василә, янакларына ут капканын тоеп, әнисенә сиздермәс өчен, мич алдында аш-су белән булаша башлады. Ул арада болдырда аяк тавышлары ишетелде, ирләр өйгә керәләр иде.

— Исәннәрмесез! Мактап йөрибез икән, — дип барысына да берьюлы сәлам бирде Әнвәр абый.

— Исәнме, Әнвәр, — дип җавап бирде Шәмсия мич алдыннан гына, табак-савыт шалтырата-шалтырата.

— Синең, Гайнелгыйлем, өйгә килеп кергән тузан бөртеге дә кая кунарга белми йөридер дә оятыннан чыгып качадыр. Кызларың бик уңганнар бит, — дип сүз дилбегәсен үз кулына алды авыл коммунистларының җитәкчесе.

— Аллага шөкер дисәм, сиңа дөрес булыр микән инде, — дип шаян тонны дәвам итте Гайнелгыйлем абзый, — Аллага шөкер, зарланырлык түгел.

— Кызлы өйгә тузан кермәсә дә, җен ияләшә башлый, ди бит, — дип әңгәмәгә кушылды Ефим.

Ирләрнең гел кызлар турында сөйләшүеннән нидер сизенгән Шәмсия апа Василәгә батырып карап алды. Анысы берни сизмәгән булып аш бүлүен белде.

— Алла да җен генә әле телегездә. — Әнвәр абый алдына аш китереп куйган Фәниягә рәхмәт әйтте дә Гайнелгыйлем абзыйга таба борылып утырды. — Үтә дә дөньяви, үтә дә җитди эш белән килдек әле без.

— Соң, юкка йөрмисездер инде олы башыгызны кече итеп. Йә эш белән, йә йомыш беләндер.

— Менә, егет үзе әйтсен әле. — Секретарь кашыгына тотынды.

— Гайнелгыйлем абый, бу авылныкы булмасам да, мине беләсездер инде. — Ефим дулкынланудан рәсми тонга, «сез»гә күчеп сөйли иде. — Миннесорур апаларда торам, Урыссуда йортым бар, һөнәрем бар. Кыскасы, — Ефим тирән сулыш алды да суга сикергән кеше кискенлеге белән әйтеп куйды, — мин, без, — комсомол секретаре бераз буталып алды, — без Василә белән өйләнешергә булдык һәм мин сезнең ризалыгыгызны сорарга килдем.

— Алай, — дип сузды хуҗа, бармакларын өстәлдә биетә-биетә. Аннан кинәт исенә килеп, кыстарга тотынды. — Житешегез әле, әйдә, житешегез. Суынгач тәме булмый бит аның. Шәмсия, чык әле, — Гайнелгыйлем абзыйның кинәт булган сүздән югалып калганлыгы, шуны күрсәтмәс өчен хатынын чакыруы сизелә иде.

— Менә нинди токмачлар куера бит әле монда, — дип, чаршау артыннан чыккан җәмәгатенә карап сүзен дәвам итте ул. — Мин колхоз йомышы белән килгәннәр дисәм, алар кыз кодалап йөриләр икән.

— Егетне мактап торасы юк. — Әнвәр абый бушаган табагын этеп куйды да, маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларын алдындагы сөлге белән сөртеп алды. — Дөресен генә әйткәндә, аның өйләнүе безнең файдага түгел. Өйләнгәч, хатыны белән квартирада тора алмый бит инде ул, китәчәк үзенә, Урыссуга. Ә ул монда алыштыргысыз кеше. Эчми, тартмый, эш рәтен белә, олыларны олы, кечеләрне кече итә. Үлеп торалар үзе өчен.

— Шулайдыр, әйбәттер егет. Кинәтрәк бит менә...

— Нигә, — Әнвәр абый шикләнеп Ефимга карады, — Василә әйтмәдемени? Тукта әле, вообще-то кыз үзе беләме соң?

— Белә, белә, — дип сүз катыштырырга ашыкты Ефим, көлүен тыярга тырышып.

— Без белмибез, — диде Гайнелгыйлем абый, — шуңа аптырап калдык бит. Кызым, Василә, чык әле монда.

Бөтенесе борылып, кыяр-кыймас чыгып баскан кызга карадылар.

Аш табыны җыелганда мәсьәлә уңай якка хәл ителгән иде инде. Әтисе кунакларны озатып кереп, түр башындагы артсыз урындыкка утырды да сүзсез калды. Аралыкта Шәмсия апаның: «Ну, кызый, безгә әйткән булсаң, ни була иде инде. Әзрәк әзерләнеп торган булыр идек», — дип ишетелер-ишетелмәс Василәне тиргәгәне ишетелә иде.

— Чыгыгыз әле монда. — Хуҗаның тавышы талчыккан булса да, ачулы түгел. — Әгәр кылтаеп урысча сөйләшкән булса, риза булмый идем. Исем-фамилиясе ят булса да, үзебезнең кеше бу, бер күрүдә күнелгә ятты.

***

Туйны Урыссуда үткәрделәр. Туй көнне яңгыр яуды. Ефим «Умырзая» җыры белән кыз ягыннан килгән кунакларның һушын алды. «Да, — диеште тәмәке тартырга чыккан ирләр, — булдыра. Да...»

Ефим һәрвакыттагыча тыныч, бөтен мәшәкатьләрне уйлап, бөтенесен төптән уйлап оештырган иде.

Апасы Лиляның ахирәтләре, күршеләр бик нык ярдәм итте.

Икенче көнне тагын табын корып, яхшы гына кәефләнеп алган кунаклар шау-гөр килеп, Вахит совхозыннан алырга килгән йөк машинасына бик озак төялделәр, ирләр җырларга азапланды, хатын-кыз китәргә ашыкмаган җәмәгатьләрен этә-төртә кузовка менгерде. Саубуллашулар, вәгъдәләр, үзләренә кунакка чакырулар белән капка төбе кайнап торды. Яңгыр изрәткән юл буйлап салулый-салулый киткән машина артыннан кул болгагач, яшь килен өйгә керде. Өйдә җыелмаган өстәл, тау булып өелгән табак-савытка бераз карап торгач, алъяпкыч бәйләде, җиңен сызганды.

Ефим икенче көнне үк эшкә чыкты. Эшчәнлеген, ышанычлы икәнлеген беләләр иде, сөт ташучы машинаны тапшырдылар. Авылда үтә дә җаваплы эш бу, чөнки машина һәрвакыт төзек булырга тиеш. Һәр Ходай биргән көнне ул көнлек савымны район үзәгенә ташып тора, илтә алмый икән — сөт ачый. Ефим иртәнге сәгать дүрттә тора, аның белән Василәдә кузгала. «Кая ашыгасың, сиңа савымга өлгерәсе юк бит», — дип тә әйтеп карый Ефим, ләкин ире чыгып киткәндә йоклап калуны хатын күз алдына да китерә алмый. Бергәләп чәй эчеп алгач, Василәишегалдына чыга, кош-кортка ашарга салып, сыер савып кергәнче, Ефимның сеңлесе Әнисәнең дә мәктәпкә барыр чагы җитә.

Яшүсмер кызларга хас булганча ябык, абыйсы кебек кара күзле, кара чәчле Әнисә Василәне беренче көнне үк үз итте, ачылып сөйләшә, серләрен уртаклаша торган булды. Җиңгәсе дә якын итте, өсте-башы бөтен, тамагы тук, ятимлеген сизмәсен дип тырышты. Ефим исә сеңлесе дигәндә җанын ярып бирергә дә әзер.

«Искитмәле, — дип уйлап куя кайчак Василә, — бу хәтле яратуга олы җанлы кешеләр генә сәләтледер. И Ходаем, бәхетемне күпсенмә!»

Әнис инде студент. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумында укый. Әледән-әле, сәбәп белән дә, сәбәпсез дә, кайткалап тора. Ул кайтуга, Василә бар булганны табынга чыгара, берәр нәрсә пешерер өчен тагын да иртәрәк тора. Атна-ун көн эчендә егеткә ит куна, тазарып китә.

— Корсак тулгач, тире тартыла да, күз йомыла, йокы килә башлый, — дип шаярта ул, өстәл буеннан кузгалгач, — ятсам, кичкә хәтле тора алмыйм, кая, берәр эш юкмы?

Бу гаиләдә бер-берсенә кечкенәдән үк искиткеч ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләнгән. Лиля иң өлкәне булса да, тормыш дилбегәсенең Ефимда

икәнлеген барысы да берсүзсез таныйлар, шулай кабул ителгән. Ул, матур сүзләр язарга ярата торган каләм әһелләре әйтмешли, чын мәгънәсендәге «алтын багана» иде. Ефим үзе дә моны аңлый, аңлый гына түгел, бөтен кыл бөртекләре белән тоя иде. Ул үзенең бурычын гаиләдәгеләрне матди яктан тәэмин итү дип кенә карамый, ул аларга әти дә, әни дә булырга тырыша, әхлакый тәрбия, дөньяга дөрес караш формалаштыруны үз мисалында тормышка ашырырга омтылып яши. Аның омтылышын Вәсилә дә күрә, бөтен йөрәге белән аңлый һәм ире күрсәткән үрнәккә лаек булыр өчен, кулыннан килгәннең барысын да эшли иде.

Сөтне озак ташырга язмаган икән, бераздан Ефимны автомеханик итеп күчерделәр. Вәсилә дә балалар бакчасында эшли башлады.

Ефимны яна эшендә дә яраттылар, чөнки, бердән, эш рәтен белә. Теләсә нинди техниканың көен таба, иренми, трактор кабынып эшли башлаганчы механизаторлар белән бергә була. Һәрвакыт запаслы, көймә комга килеп терәлгәндә мөрәҗәгать итсәң, кирәкле запчастьны табып бирер. Дөрес, моңа нинди юллар белән ирешкәнен Ефим үзе генә белә. Техника күп, авыллар гөрләп тора, һәркайсына запчасть кирәк. Склад, база мөдирләре янына якын килә торган түгел. Алар үз дәрәҗәләрен белеп, теләсә кем белән исәнләшмиләр дә хәтта. «Бирергә» дип директор кул куеп җибәргән кәгазьне дә борып җибәрергә мөмкиннәр — юк, бетте-китте. Ефимның кешене таный, аралаша белү сәләте бик ярдәм итте. Үзе хәмерне сөймәсә дә, бик күңелле мәҗлесле кеше, теләсә нинди компаниядә үз кеше булып китә. Акчадан бигрәк дуслык бәяләнгән заманда ул бик күпләрнең күңеленә ачкыч тапты.

— Иркенрәк тун киеп кил иртәгә, — дип күпмәгънәле ишарә ясады Бөгелмәдәге тимер юл буенда урнашкан складларның мөдире, бер өстәл буенда сыйланып утырганда, — автопаркка барырбыз.

Сорашып, төпченеп тормады Ефим, ләкин икенче көнне автопаркта әлеге киңәшнең бик тә урынлы икәнен аңлады.

— Бу минем дус, — дип таныштырды склад мөдире Ефимны автопаркның тәэминат бүлеге начальнигы ярдәмчесе белән. — Әйбәт кеше, үзе мондамы?

— Юк, бүген шәһәрдә совещание, шунда китте.

— Кыяфәтең юк, әллә башың авыртамы?

— Бар инде әзрәк. — Ярдәмче кәефсез һәм сөйләшәсе килмәгәнлеге күренеп тора иде.

— Кая, әйдәле, аяк өсте тормыйк, — склад мөдиренең монда үз кеше икәнлеге күренә, — керик әле синең почмакка.

Паркның аулак бер почмагында, күзгә ташланмаслык итеп урнаштырган вагончыкка үттеләр. Склад мөдире, шкафта хуҗаларча актарынды, стаканнар, ипи кисәкләре чыгарып куйды. Хуҗа да күзгә күренеп җанланды, Ефим үзеннән ни теләгәннәрен аңлап, «На всякий случай!» дип җиң эченә кыстырып кергән акбашны өстәлгә чыгарып утыртты.

— Бала табу берни түгел, похмельне бирмәсен Ходай, дигән ди бер хатын, — дип шаярта-шаярта, бөкесен бәреп чыгарды да шешәне склад мөдиренә сузды. Тегесе ике стаканга аракы койды.

— Нигә, Ефим, үзең эчмисеңмени?

— Юк, эчми ул, — дип кыска тотты сүзне склад мөдире.

— Әйдә, Хәбип абзый, исәнлеккә.

Ирләр стаканнарны куйгач, беркавым сүзсез тордылар, ах-ух килеп ипи кисәге чәйнәделәр, битләренә алсулык йөгерде.

Рәхәт чикте ул көнне Ефим. Парк бай, базаларда, складларда ниләр генә юк.

— Моны сина бирә алмыйбыз инде, — диде Хәбип абзый, Ефим барып тотынган бер запчастька ымлап, — шул, кыстырып чыксаң гына инде.

Капкадан тәэминат начальнигы урынбасары озатуында чыкканда, тун арасына кыстырган шестерналар, ременьнәр авырлыгыннан Ефим көчкә йөри иде. Әмма күңеле күтәренке, иртәгә атналар буе тик торган тракторларга җан керәчәк чөнки.

Яз — авыл өчен бөтен тереклекне уятучы көч кенә түгел, яз — авыл халкы өчен яңа тормыш, хезмәт дигән сүз. Көннән-көн ныграк җылыткан кояшка сыртларын куеп, укра чүпләгән кошларның чыр-чуына рәхәтләнеп торган сыерлардан башлап райком секретарена кадәр яңа дәрт, ашкыну белән яши башлаган вакыт бу. Яз борчулар, мәшәкатьләр дә алып килә. Җырларда җырланган игенченең даны хәзер атларның көрлегенә түгел, техниканың төзеклегенә бәйле. Көзге уңышның язмышы ремонт мастерскойларында, машина-трактор паркларында, гаражларда хәл ителә. Тракторлар гөрләп эшләп утыра икән — җирең сөрелгән, тырмаланган, чәчелгән булыр. Машиналар йөгерек хәлдә икән — ашламасы вакытында кайткан, уңышың яңгырга эләкмичә амбарга кереп утырган булыр.

Шундый киеренке язгы көннәрнең берсендә, совхоз администрациясендәге гадәти иртәнге җыелыш тәмамланганда, партоешма секретаре директорга эндәште:

— Трофим Сидорович, хәл итәсе бер мәсьәлә калды бит әле...

— Нәрсә тагын? — Урыннан кузгала башлаган директор кире урындыгына чүмәште.

— Завгар билгеләнмәгән бит әле. Кеше юк.

— Ничек юк? Әнә, әзер кадр бар — Мерзон. — Мәсьәләне хәл ителгәнгә санап, директор аякка басты. — Монда уйлап та торасы юк. Приказ әзерләгез.

Ефим, шулай итеп, икенче көнне гараж мөдире булып уянды. Дөресен генә әйткәндә, болай да мөдирлек вазифаларын башкара иде инде ул. Ләкин рәсми рәвештә хезмәт хакы ала, документларга кул куя башлавы әлеге иртәнге җыелыштан соң булды.

Ефим эшли башлагач, гараж, мастерской күзгә күренеп үзгәрде. Элек гаражның түбәсеннән су үтә, теләсә кайда тимер-томыр, кулланылган май тутырылган чиләкләр ауный иде. Иң беренче эш итеп өмә оештырдылар — бина ялт итеп калды. Көн чабып, төн чабып, яңа мөдир материал кайтартты, янгыр яуганда елап утыра торган түбәдән су үтми башлады. Кешеләр дә үзгәрде. Сынып чыккан, эшкә ярамый торган запчастьне кая туры килсә, шунда ыргыта торган механизаторлар үз эш урыннарын пөхтә тота, кайтып киткәндә җыештыра, хәтта себереп куя торган булдылар. Әмма иң мөһиме — Ефимда алар хуҗа белән бергә яклаучы да күрделәр. Механизаторларның хөкүмәт эшеннән тыш шәхси тормышы да барлыгын яхшы белә иде ул. Беркайчан да, беркемгә дә ярдәм итүдән баш тартмады. Моны бик тиз аңлаган халык аңа хәтта гаилә проблемалары белән дә мөрәҗәгать итә башлады. Эчеп кайткан ир өендә дулый, хатыны Ефимга йөгерә. Яшь киленнең төн уртасында тулгагы башланса, хуҗа Мерзоннар ишегенә шакый. Ефим тора, радиаторы катып ярылмасын өчен суы агызып куелган машинасына кайнар су тутырып кабыза да район үзәгенә, больницага алып китә. Аннан турыдан гына эшкә киткән чаклары да булды. Моны ул һич авырсынмыйча эшләде.

Урамнарда челтер-челтер гөрләвекләр агып, тау битләре ала-кола төскә кергән вакытлар иде. Вәсилә иртән күңеле болганып уянды. Урыныннан да үзен мәҗбүр итеп кенә кузгалды, Ефимны эшкә озаткач та, нәрсәгә барып

тотынырга белмичә йөрде дә урынга барып ятты. Төшке ашка кайткан ире хатынның суырылып калган йөзен, әледән-әле укшып куйганын күрде дә, айваена карамыйча, район үзәгенә алып китте. Олы яшьтәге табибә Василәне игътибар белән карап чыкты да елмайды:

— Нәрсә дим, котлыйм.

— Ни белән? — Василәнең башында уйлары чуалды.

— Сез йөкле, ханым.

Коридорга чыккач, Василәирененң күзләренә тутырып карады. Дүрт ел көттеләр алар бу сүзне. Дүрт ел икесе дә эчтән көеп, шуны тышка чыгармаска тырышып яшәделәр...

Кешечә, гади генә итеп шатлана һәм эшли белми иде шул Ефим, барысын да соң чиккә житкерә: сөенсә, үзе генә түгел, хәтта ай белән кояш та бии башлый, эшләсә, түп-түгәрәк итеп, тел-теш тидермәслек итеп куя. Ә, юк, хезмәт белән куанычын дөньяга чыгарса да, кайгысын-көенечен берәү дә күрмәде, үзе генә белә иде. Йомыла, эндәшми йә бөтенләй чыгып китә, күзгә-башка күренми.

Ул көнне исә Ефим бөтен саклап тоткан запчастьларын механизаторларга өләште. Кич, таралышыр вакыт житәрәк, ирләрне мастерской почмагында такта белән бүлеп алынган будкага жыйды да, кесәләреннән ике акбаш чыгарып, өстәлгә утыртты. Ирләр бер-берсенә караштылар, Ефим исә өзлексез шаяртты, үзе, гадәттәгечә, стаканга кагылмады.

Ефим белән Василәнең беренче кызлары туган көн авыл хезмәтчәннәренең һөнәри бәйрәм көненә туры килде. Игеннәр жыеп алынган, һаман усаллана барган жил кызыл, сары төсләргә төренгән агачларны йолкый, кырлар буйлап яфрак куып уйный иде. Гомерендә беренче тапкыр Ефим район үзәгендә бу көндә үткәрелә торган тантанада катнашмады. Ул көнне әти кеше бала тудыру йортына бер капчык алма, шампан шәрабе, чәчәк букеты тотып килде. Шатлыгы белән бергә көенечле күз яшьләрен дә күп күргән шәфкать туташларының болай канатланган һәм юмарт кеше белән беренче кат очрашулары иде.

Светланадан соң ике ел үтәр-үтмәс икенче кызлары — Елена дөньяга аваз салды. Аннан өченче бала — Ирина туды. Ире үзе сыңар аваз чыгармаса да, Василәнең Ефимга ир бала бүләк итәсе килә иде. Өченчесе дә кыз булгач, хатын үртәлеп елады. «Ирең килгән» дип хәбәр биргәч, тәрәзәдән карады, анда Ефим басып тора, ике ягында ике кызлары — Светлана белән Лена. Үзләре дә курчак кебек итеп киендерелгән, күз явын алырлык кызлар кулларына курчак тотканнар. «Бүләк итеп әтиләре алып биргән», дип уйлады Василә. Икенче кат тәрәзәсенә Ефимның тавышы ишетелде:

— Василә, хәлләрең ничек?

— Әйбәт, тагын бер кызыбыз бар.

— Молодец! Күрсәт әле.

Василә кулындагы төенчекне тәрәзәгә якын китерде. Светлана белән Лена шыбырдаша, ике яклап әтиләрен тарткалый башлады. Ул чүгәләп балаларга нәрсәдер әйтте дә яңадан тәрәзәгә борылды:

— Тере курчак алып кайтабыз дигән идем кызларга, «шулмы, исеме ничек?» дип сорыйлар. Кара әле, менә монда Амалия: «Василәа Гыйлемовна кыз булганга бик борчыла, елый», — диде. Син ул эшеңне туктат. Ник борчыласын? Кыз ни, малай ни — барысы да үзебезнеке. Ә монысы гел Лиля апага охшаган бит...

— Ярар, Ефим, ярар. — Кинәт жинеләеп, тынычланып калган Василә саубуллашып кул болгады да бәләкәчен имезергә утырды.

— И-и-и, бәхетледер син, Василә, — дип куйды Бәйрәкә Тамак хатыны, — безнекеләр килми, килсә дә исерек була.

— Әйтмә дә, — дип жөпләде икенчесе. — Без монда чагында нишләпләр

яталар икән, сыер савылды микән дип йөрәкләр яна. Синеке әнә, ичмасам, наять булып йөри.

Вәсилә үзалдына елмаеп, инде яшьләре кипкән күзләрен сөртеп алды. Анысы шулай, Ходайга мең шөкер. Хатын мыс-мыс итеп яткан бәбиен күкрәгенә кысып, артыннан сөеп куйды.

***

Еллар үтте, тәгәрәшеп балалар үсте, Мерзоннар гаиләсе Урыссу совхозының аерылмас бер өлешенә әверелде. Ләкин беркайчан да, беркайда да дөнья үзгәрешсез тормый. Кемдер килә, кемдер китә дигәндәй, совхоз директоры Трофим Сидорович та олыгайды, Ефим исә торган саен халык арасында абруй яулады. Күпләр инде аны директор урынында күрәләр иде.

Ләкин, шагыйрь әйтмешли, «аһ, дәрига», без һәм халык теләгәнчә генә булса икән! Нәкъ шул вакытта зур гына түрәнең малаена урын кирәк була. Яңа директор килә. Ләкин инде Ефим Мерзонның да эшлекле, әзерлекле һәм оператив киңлеккә чыгарга әзер кадр икәнлеген райкомда күреп алган булалар. «Менә, — диләр аңа, район үзәгенә чакырып, — сиңа Урыссу АТПсы. Оешманың хәле мактанырлык түгел, син — коммунист, партия сиңа предприятиене алдынгы сафларга чыгаруны бурыч итеп куя».

Ләкин Ефимның эшлекле сыйфатларын райкомда гына түгел, Казанда да яхшы беләләр иде, җиләк-җимеш һәм яшелчә совхозы башкалага буйсынганлыктан, аны тиз генә җибәрергә теләмәделәр. Күпмедер вакыт ул әле тегендә, әле монда эшләп йөрде.

Хезмәт сөючән кеше буларак, аңа партия һәм халык исеменнән пафослы сүзләр кирәкми иде. Ул болай да ни-нәрсә, кайда нәрсә җитмәгәнлеген, үзенең бурычын яхшы белә. Аңа бары бер нәрсә кирәк — комачауламасыннар. АТПда үткәргән беренче киңәшмәдә үк әйтеп куйды: «Иптәшләр, һәр нәрсәдә тәртип кирәк. Үзебездән башлыйк — бүгеннән бер-беребезгә исем-отчество белән эндәшә башлыйбыз. Без — җитәкчеләр нинди, халык та шундый булачак. Үзебезне үзебез һәм бер-беребезне хөрмәт итәбез икән, эшчеләр дә безне хөрмәт итәчәк». Үзе үк беренче үрнәкне дә күрсәтте. Киңәшмә беткәнне аңлатып, урыныннан кузгалды да эксплуатация начальнигына эндәште:

— Әнәс Хәмидуллович, территорияне карап чыгыйк әле.

1969 елдан бирле шушы хуҗалыкта эшләүче Әнәс Хәмидулла улы яна начальникны территория буенча алып китте. Дөрес, мактанырлык түгел. Коймалар агач, өстән чәнечкеле тимерчыбык тарттырылган. Ләкин керергә-чыгарга теләгән кешегә һич комачаулый торган түгел, чөнки җепсәләре черегән тактага бер тибү җитә — куба да чыга, рәхим ит, теләсә нәрсәне алып китеп була. Машиналар иске, ике көн йөрсә, бер көн ремонт кирәк. Диспетчер йорты — Ютазыдан сүтеп алып килеп салынган, мунча хәтле генә йорт.

Озак йөрделәр. Әнәс Хәмидуллович яңа хуҗаның — Ефим Дмитриевичның — күзләрендә гамь һәм борчу күрде. Эксплуатация начальнигы булып озак еллар эшләү дәверендә аңа күп җитәкчеләр белән эшләргә туры килде, ләкин моның кебек практикны, һәрнәрсәне төшенергә тырышучыны очратканы юк иде. Барысын да күрергә тырышты, һәр почмакны тикшерә, йөргән саен кашлары җыерыла, вакыт-вакыт онытылып, борын эченнән көйли башлавы нәрсәдер исәпләве, тирән уйларга чумуы хакында сөйли. Кинәт кенә сорап куйды:

— Торак, фатир мәсьәләләре ничек?

Югалып калган Әнәс Хәмидуллович бераздан:

— Сезгә райком белән сөйләшергәдер инде бу хакта. Сезнең бит гаилә, — дип башлаган иде, Ефим Дмитриевич аны бүлдерде.

— Юк, сез мине аңламадыгыз. Мина димим, эшчеләрнең дим.

Әнәс Хәмидуллович тагын да аптырый төште. Ничек инде, әле бит монда запчастьларны таптырасы, гаражлар, машиналар, әле бит, әле бит...

— Әнәс Хәмидуллович, — Мерзон көне буена беренче тапкыр саран гына елмаеп куйды, — әгәр кешеләрнең эшкә теләге булса, барысы да була. Без алардан таләп итәргә генә түгел, ә бирергә дә тиеш.

АТПда күптән төзелә торган, инде «сакаллы» төзелешкә әйләнгән йорт бар иде. Шунда киттеләр. Икенче көнне йорт тирәсендә ыгы-зыгы башланды. Төзүчеләр бригадасы да табылды, өмәгә чыккан халыкның, кеше артык күп булганлыктан, кайберләрен кире кайтарып җибәрергә дә туры килде.

Мерзон килгәч, «сакаллы» төзелеш кенә түгел, бөтен автотранспорт предприятиесе таяк тыккан кырмыска оясына охшап калды. Ике-өч ел эчендә агач койманы таш дивар алыштырды, территориягә асфальт җәелде. Подвалы белән үзәк склад, бер ягында машина юа, икенче ягында техник күзәтү үткәрә торган җайланмалар куелган бина сафка басты. Гаҗәп, коллективта үзара мөнәсәбәтләр дә танымаслык булып үзгәрде. Кеше эшкә теләп килә, ябышып ята торган булды. Үгетләп, сүгеп йөрүнең кирәге калмады.

Барысы да әйбәт, предприятие гөрләп тора. Республиканың Күчмә Кызыл байрагы Ефим Дмитриевичның кабинетын бизи. Татарстанның транспорт министры Александр Павлович Обыденнов киңәшмәләрдә шәхсән үзе Мерзонның кулын кысып, башкаларга үрнәк итеп куя. Ләкин Ефим эчтә ниндидер канәгатьсезлек сизә иде. Эштә вакытта бу хакта уйланырга җай юк, өйгә кайткач, өч яктан өч бәләкәч әйләндереп ала да, бөтенесе каядыр китеп югала. Шулай да эчтә нидер утыра, нидер бимазалый.

Җәйнең көзгә кереп бара торган бер көнендә ничектер иртәрәк кайтырга туры килде. Урыссу совхозыннан посёлокка йөреп эшли торган ун чакрым араны ул үз уйларына батып үтә. Бүген дә, үткән көнгә анализ ясап, кырларга гамьсез генә күз йөгертә иде. «Нишләп һаман кукурузны җыеп алырга куллары җитми?» дип уйлады... һәм кинәт эчтә утырган канәгатьсезлекнең сәбәбен аңлап алды: авыл тарта икән аны! Дөресрәге, авыл хуҗалыгы — менә нәрсә якын икән күңелгә! Бу хис аны шулхәтле биләп алды ки, хәтта кайтып керүгә чыр-чу килеп урап ала торган кызлар да, әтиләренең борчулы икәнлеген сизеп, тынып калдылар.

Ир белән хатын озак сөйләштеләр ул кичне.

— Ялгышасың, Ефим, — диде Вәсилә, иренең кире авылга кайту теләгенә җавап биреп. — Ялгышасың. Бер асфальтка чыккан кеше янадан басу юлына төшми инде ул...

Ләкин уйлаганын тормышка ашыра торган кеше шул Ефим. Берәр атнадан беренче секретарьга керде. Исәбе — Урыссу совхозын (ул вакытта аны Подгорный дип тә йөртәләр иде) автотранспорт предприятиесенең ярдәмче хуҗалыгы итеп алу. Бик тә, бик тә файдалы хезмәттәшлек булачак иде бу. Ефим китергән, икътисади яктан нигезләнгән дәлилләргә «ә» димәде, «җә» димәде, игътибарсыз гына тыңлады да уйларга вәгъдә итте Беренче. Сизде Ефим: тәкъдиме райкомга ошамады, ләкин бер башлагач, ахыргача барырга карар кылды. «Совхозга да, предприятиегә дә файда булачак, — дип уйлады ул. — Документлар тәртиптә, мин үз кесәмне кайгыртмыйм, дәүләт мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәм».

Ләкин эш күрсәтү урынына купшы сүзләр сөйләп, җайлы һәм авырлыкларсыз гына яшәргә өйрәнгән партия әһелләренә халык та, хөкүмәт тә кирәк түгел шул. Аларны үз кәнәфиләре, җылы кабинетлары ныграк кызыксындыра. Беркем түгел, әнә шул тормышның реаль таләпләреннән уттан курыккан кебек курыккан бушбугазлар җимерде инде Советлар илен. Ефимны да гафу

итә алмады тынычлыгы бозылудан курыккан партократия. Җиң сызганып эш башлаган Ефимны, ярты ел үтәр-үтмәс, районга чакырып алдылар. «Бик авылга ашкынасың икән, — диделәр аңа бюрода эшлекле кыяфәттә утыручылар, — әйдә, Бәйрәкә Тамакка колхоз рәисе булып бар».

Ефим башлаган эшен ярты юлда калдырасы килмәвен, гаиләсе барлыгын, кызларның рус мәктәбендә укуын, Бәйрәкә Тамакта исә мондый мөмкинлек булмавын аңлатырга тырышып карады. Ләкин җитәкчеләре төртеп күрсәткән һәр корбанга өерләре белән ташланырга өйрәтелгән бюро әгъзалары тыңларга да теләмәделәр, берсен-берсе уздыра-уздыра Ефимны формализмда, партия карарларын үтәмәүдә гаепләргә тотындылар. Күрсәткән хезмәтләре дә, иң артта сөйрәлгән АТПның республика күләмендә алгы сафка чыгуы да, коллективның җитәкчесе өчен җан атып торуы да, перспективадагы планнарның масштаблы булуы да — берсе дә исәпкә алынмады. Әллә нинди гөнаһларда гаепләп, бюро Ефим Мерзонны эшеннән азат итү турында карар кабул итте.

Ирнеңниләр кичергәнен хәтта Васильә дә аңлап бетермәде бугай, чөнки Ефим үзенә йомылды, беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәде.

Аны сакал-мыек басты, һәрвакыт гаять пөхтә киенүче кеше булса да, кулына ни туры килсә, шуны элеп йөри башлады. Башында беренче ак чәчләр күренде, хәтта гәүдәсе дә бөкрәя төшкән кебек иде. Әйтерсең, ул гаделсезлекне күңеленнән генә түгел, ә чын физик авырлык буларак күтәрә. Васильә аны еш кына бакча башында күрә, күзләре каядыр еракка караган, әмма аларда бушлык, ул берни дә күрми, ахры. Сораштырып, сөйләштерергә тырышып та карады хатын, Ефим эндәшмәде. Бары бер тапкыр, кечкенә кызлары Ирина әтисе турында бөтен класс алдында нахак сүз әйткән малай белән сугышып, елап кайтып кергәч, аны алдына утыртып, болай диде:

— Кызым, минем хакта нәрсә әйтсәләр дә ышанма.

Шул көнне Васильәнең эченә җылы йөгерде — дөньядан өметен өзгән кеше тавышы түгел иде бу. Гадәттәгечә тыныч яңгырый, димәк, ул нидер уйлый, уйлый гына түгел, ниндидер планнар кора.

Алай уйлады, болай уйлады да Васильә, үзе райкомга барып карарга булды. Белә бит Ефимны: авызы тулы кан булса да төкермәячәк, беркайчан да баш имәячәк. «Кызулык белән кирәкмәгәнен дә әйткәндер, — дип уйлады хатын юлда, — анда да кешеләр утыра бит, аларның да бәлки ачулары килгәндер. Ләкин бит ачуланып кына яшәп булмый дөньяда. Аңлатып карыйм әле Ефимның да бик авыр кичергәнен, минем китапханәче булып эшләгән акчага гына өч балалы гаиләне яшәтеп булмаганын...»

Бик ышаныч белән барса да, райком бинасына якынлашкач, адымнары әкренәйде Васильәнең, күңеленә шик үрли башлады. Коридорда әзрәк басып торгач, күз күргән кеше дип, агитация-пропаганда эшләре буенча китапханәчеләр белән даими элемтәдә торучы өченче секретарьга керергә булды.

— Исәнмесез, Ансил Мирзиевич, — дигән тавышка кәгазьләргә күмелеп утыручы ир башын гына күтәреп карады да тагын өстәлгә иелде. Бераздан күзләрен Васильәгә төбәде, ишарә белән утырырга кушты.

— Сөйләшергә дип килгән идем, Ансил Мирзиевич. Ефим бит яхшы белгеч, неужели бер эш тә юк инде?

— Соң, ул бит без тәкъдим иткән эшкә барырга теләмәде. Бәйрәкә Тамак нәрсәсе белән ошамый аңа?

— Ошау-ошамаудан түгел. Бердән, өч кызыбыз да рус мәктәбендә укый, олысы инде тәмамлау алдында...

— Васильә Гыйлемовна, беренче чиратта, Мерзон — коммунист. Партия кая куша, шунда барырга тиеш.

— Ләкин партия кешенең шәхси тормышын сызып ташлый алмый бит...

— Икенчедән, — өченче секретарь хатынны тыңламый инде, ул артында гранит стена булып торган партия бюрократиясенең ышанычлы терәген сизгән хәлдә сүзен дәвам итте, — икенчедән, без ана Урыссуда да эш тәкъдим итәбез, фермаларга көтүчеләр житми әнә.

«Көтүче? — дип уйлады хатын эченнән. — Менә син инде ул көтүче, бүтән эшкә ярамыйсың. Кәгазь тутырудан башканы белмисең».

— Туктагыз әле, — секретарь кинәт нидер исенә төшкәндәй алга авышты. — Сезне ирегез жибәрдеме минем янга? Үзе куркамыни?

Васильә ирексездән елмаеп жибәрде.

— Әнә телефон, шалтыратыгыз. Ефим өйдә, берүзе. Трубканы үзе алачак. Сорарсыз, ул жибәрдеме, әллә мин сезнең кешелеклелегегезгә ышанып ялгыштыммы. Шалтыратыгыз!

Хатынның елмаюы секретарьның ышанычын бермә-бер киметте, урындык аркасына ята төшеп, күзләрен өстәлгә төбәде. Васильә чыгу ягына юнәлде, ишектә тагын борылды:

— Егылганны кыйнарга, бер ялгызга өер белән ташланырга оста сез. Ләкин Ефим бик яхшы белгеч, эш кешеләре, халык аны югары бәяли. Югалмаячак ул, алтын жирдә ятмый.

Өйгә кайткач, иренә райкомга баруы, сөйләшүе турында бер сүз дә әйтмәде. Белә: Ефим горур, үз бәясен үзе белә, хатынының болай йөрүен өнәмәячәк. Ул беркайчан да, беркемгә дә ялынмады, тәлинкә тотмады. Һәрнәрсәгә үз көче, үзе белеме, булдыклылыгы белән иреште. Партиягә ышана иде ул, шуңа күрә үзенә карата булган гаделсезлекне аеруча авыр кичерде. Шушы берничә атна эчендә аның дөньяга мөнәсәбәтендә, инануларында кискен үзгәрешләр барлыкка килде. Партиягә бик күп чит, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар кереп оялаганын аңлау килде аңа.

Партия — идеология, ләкин гомер-гомергә тормышны хужалыкчылар алып барды, бара һәм барачак. Бертөркем бюрократлар Ефимны өнәп бетермәсә дә, аны югары бәяләүчеләр дә юк түгел иде. Беркөн Мерзоннар өендә телефон шалтырады, трубканы алган Ефим республиканың транспорт министры Александр Павловичның тавышын ишетеп, ирексездән елмаеп жибәрде. Сөйләшкән саен йөзе яктыра, кашлары языла барды. Ул көнне Васильәне бөтенләй икенче — үтүкләнгән күлмәк, чалбар кигән, елмаеп торучы, юк сүздән дә кызык табып шаяртучы Ефим каршы алды. Министр Мерзонны Минзәлә автотранспорт предприятиесе житәкчесе итеп билгеләве хакында хәбәр итте.

***

Ефим бер атнадан служебный «Волга»да кайтып төште. Һәрвакыттагыча пөхтә киенгән, күзләрдә гамь. Кызларның шатлыгына чик-чама юк иде, әтиләре дә тулысынча алар иркендә булды. Кичке якта гына, мул әзерләнгән табын янында Васильә белән икәүдән-икәү генә калдылар.

— Андагы эш, — диде Ефим, — аңлатып бетерә торган түгел. Ну, беренче секретарь, Хәмәдиев яхшы кабул итте. Беренче тапкыр кергәч тә әйтте: «Синең учётный карточкага язганнар белән сине эшкә якын да китерә торган түгел. Но министр сине бик югары бәяли, ә мин аны бик хөрмәт итәм, ул юкны сөйләмәс. Димәк, йә кәгазьдә язылганнар ялган, йә синең бик көчле дошманнарың бар».

— Нәрсә диден?

— Аңлатып тормадым. Хәмәдиевка бит сүз кирәкми, эш кирәк.

— Тырыш инде, Ефим, балалар үсеп килә бит...

— Беләм, — балаларны искә төшергәч, Ефим елмаеп куйды, — эшләмәгән эш түгел. Ярар, ятыйк булмаса, үзеңне бер алып барып күрсәтермен әле андагы хәлләрне. Анда тездән саз, койма юк, территориядә кәҗәләр йөри...

Баш-аяк белән эшкә чумгач, Ефим сирәгрәк кайта башлады. Гыйнварның чатнап торган бер көнендә, чираттагы кайтуында Василәгә:

— Минзәләдә, беләсеңме, кемне очраттым? — диде.

— Кемне? — дип кызыксынды хатын.

— Фәрит белән Миңнегөлне хәтерлисеңме? Сарманда, теге, бик матур җырлаучылар.

— Хәтерләмичә, хәтерлим. — Василәгаз плитәсе буеннан ире каршына килеп утырды. — Алар да Минзәләдәме?

— Фәрит Минзәләдә. Райкомда эшли.

Фәрит белән Миңнегөл группадашлар иде. Алабуга пединститутының филология факультеты, рус-татар бүлеге студентлары. Көләч йөзле, гармунчы егет белән нәрсәгә тотынса, шуны булдыра торган, җор телле мишәр кызы шулхәтле пар килгәннәр иде, иптәшләре аларның киләчәген бары бергә юрап кына карады һәм шулай булды да. Шаулап-гөрләп торган студент тормышыннан олы дөньяга алар инде ир белән хатын булып, кулга-кул тотынышып атладылар.

Сарман районы Рангазар авылында яшь пар Мифтаховларны күтәреп ук диярлек алдылар. Ләкин алар монда озак тоткарланмадылар. Белемле, сүзгә оста Фәритне тиз арада район комсомол оешмасының оештыру бүлегенә эшкә чакырдылар. Бүлекне моңа кадәр җитәкләгән Әхтәм Габделхаковны профессиональ техник училищега директор итеп күчерделәр дә Фәрит белән алар арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнашып калды. Икесе дә яшь, бер үк район үзәгендә яшиләр, яңа тормыш башлаган, гаиләле кешеләр. Аралашып, кунакка йөрешеп гомер итәләр.

1981 елның яз башы. Әхтәмнең туган көненә, Фәрит белән Миңнегөл, гадәттәгечә, баян күтәреп килделәр һәм шунда ук мәҗлеснең игътибар үзәгенә әйләнделәр. Мәзәк сөйләп көлдерү, сүз әйткәндә төртелеп калган кунакка шаян сүз кыстырып, кыен хәлдән чыгару дисеңме — Мифтаховлар барысын да үзләренә каратты. Бераздан баян телгә килде, Миңнегөл яңгыравык тавыш белән җыр башлады. Шулвакыт түрдәге өстәл буеннан берәү гаять тә аһәнле, күкрәктән чыккан моң белән аңа кушылды. Бу шулхәтле көтелмәгән һәм матур чыкты ки, бер мизгелгә Фәрит гармун төймәләрен бутап алды хәтта. «Ефим... Ефим Дмитриевич... Урыссудан» дип пышылдашып алды өстәл буе. «Әхтәмнең бертуганы Василәнең ире. Бик зур кеше, зур начальник», — дип аңлатма бирде тирә-яктагыларга барысын да белүче бер ханым.

Фәрит белән Миңнегөл тыныбрак калганнар иде, Ефим Дмитриевич үзе Фәриткә эндәште:

— Моны уйный аласыңмы?

Ул вакытта бик популяр булган «Аерылдык урман юлында» күңелләрне әллә кайларга алып китте. Һәркем үзен яңа тормыш юлы, яңа сукмак башында торган кебек хис итте.

Мәҗлестән эчке бер җылылык хисе белән таралыштылар. Ирләр хатыннарына бик игътибарлы булды, йөрәкләрдә тормыш мәшәкате белән күмелеп калган мәхәббәт уты баш калкытты. Бер-берсенә дустанә мөнәсәбәт күрсәтеп кул бирештеләр, беркем дә тамак ярып, исерек тавыш белән җырларга маташмады. Итагатьле, затлы Ефим Дмитриевич янында һәркем үзен тыйнак, тәртипле тотарга тырышты.

Инде менә Минзәлә җирендә очраштылар. Монысында инде мәҗлестәшләр булып кына түгел, хезмәттәшләр булып. Һәм бу очрашу тора-бара чын ирләр дуслыгына, гаиләләр дуслыгына әверелде.

«Эшләгәнгә — эш, ашаганга — аш», диләрме әле? Ефимның эштән бәхете булды инде. Үзеннән соң ул һәрвакыт матур эзләр, күркәм эшләр калдырды. Урыссу совхозы мастерскойларының тәрәзә төпләрендә ул эшләгәндә гөлләр үсеп утыра иде. Урыссу поселогының автотранспорт предприятиесе дә ул эшләгәндә заманча җиһазландырылган оешмага әверелде. Ташландык хәлгә килгән, көчкә-көчкә сөйрәлеп барган Минзәлә АТПсы да Ефим Дмитриевич житәкли башлагач, күзгә күренеп үзгәрде. Территорияне таш коймa белән әйләндереп алу һәм асфальт җәю, ашханә төзү, яна машиналар кайтару белән генә билгеләнми иде яна житәкченең уңышы. Баштагы мәлләрдә Ефим Дмитриевичның башлангычларын, яңалыкларын күпләр бик сак кабул иттеләр, хәтта эштән китү белән куркытырга омтылучылар да булды. Ләкин тиз арада шоферлар бу үзгәрешләрнең файдалы икәнлеген аңлап алдылар, коллективтагы атмосфера күзгә күренеп үзгәрде, кешеләрнең үзара мөнәсәбәте яхшырды.

«Әгәр Минзәлә АТПсын рәткә кертсәң, Чаллыга күчерәбез сине», — дигән иде министр. Сүзендә торды, Чаллы автотранспорт житәкчесе лаеклы ялга китүгә, Ефим Дмитриевичны билгеләделәр. Ай-һай кыен булды баштагы мәлләрдә! Бердән, бөтен өйрәнелгән яшәеш җимерелгән, хуҗалыкның, сәяси-иҗтимагый тормышның рәте-чираты югалган туксанынчы еллар башы иде бу. Акча юк, эш юк, запчастьлар юк — кыскасы, юктан башка нәрсә юк. Булмаганны булдырырга, шәхси танышлыклар аркылы элемтәләрне жайга салырга, кайда үгетләп, кайда ялынып, ә кайда исә хәтта янап та йөк ташу өчен заказлар табарга туры килде. Ләкин ничек кенә булмасын, шәһәрнең генә түгел, бөтен илнең икътисады параличланган вакытларда да Ефим Дмитриевич кул астында эшләүчеләр хезмәт хакын вакытында диярлек алып бардылар.

Икенчедән, шәһәрнең ул вакыттагы хуҗасы Алтынбаев белән мөнәсәбәтләр, йомшак кына итеп әйткәндә, шактый киеренке иде. Хуҗаның бу урынга үзе теләгән кешене утыртасы килгәнен аңлады Ефим Дмитриевич, ләкин предприятие Транспорт министрлыгы карамагында булганлыктан, Александр Обыденнов бу урынга нәкъ менә Ефим Мерзонны тәгаенләгән иде. Дөрес, Алтынбаев тиз күрде Мерзонның эшлекле сыйфатларын, мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртте.

Чаллы предприятиесен гомеренең соңгы көненә хәтле житәкләде Ефим Дмитриевич. Вафат буласы көнне дә шифаханәгә китерелгән кәгазьләргә, эшчеләргә өч айлык премия бирү турындагы карарга кул куйды. Әҗәл агай якынлашканын, аның салкын сулышын сизеп, кырыенда утыручы кече кызы Иринаны күрше палатага кереп киткән Василәне чакырырга җибәрде. Йөгереп килеп житкән Василәгә нидер әйтмәкче иде, әйтә алмады, кулын күтәреп сөеклесенең битеннән генә сыйпады да күзләрен йомды. 2001елның 27 августы, Ефимның яраткан ел фасылы, җәйнең көз белән күрешергә әзерләнгән, республика кырларында комбайннар гөрләгән, кичләрен ажаган арыш камчылаган вакыт иде...



Фирүзә
Җамалетдинова

# ҺӘМ ҮЗЕБЕЗ — ТАРИХ КӨЗГЕСЕ...

## И Казан!

Иңнәреңә унмы (?) гасыр баскан,
Төпкә төшәргә соң кем базган?
Чиркәү чыңы аша азан тавышы
Сискәндереп куя, и Казан!

Гыйбадәттә түгел, урамда да
Безнең һаман башлар иелгән.
Затлы яулыкларны, түбәтәйне
Ничә салып, ничә киелгән.

Авырлыгы һаман башка төшә,
Челләләрдә кайный миләр дә.
Тик эссегә, суыкка да күндек,
Күндек лә без әллә ниләргә.

Сөембикә манарасы кебек
Басып торуыбыз кыйшаеп,
Үзебезне сискәндерә, Казан,
Ә шулай да монда ни гаеп?

Ә шулай да һаман яшибез бит,
Ничә торган, ничә егылган...
Чал тарихың карап тора сыман
Һәр кызыңнан, һәрбер угылдан.

...Манараны төз итәсе килә,
Китәр идек сыман зураеп.
Һәм барасы килә киләчәккә,
Сөембикә кебек тураеп.

Эндәшәсе килә, шәһәрләрдән
Казан, диеп, иң-иң изгесе!
Тик нишлисе... Манарабыз авыш...
Һәм үзебез — тарих көзгесе...

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА — *шагыйрә, прозаик; «Толымлы ай», «Догалы корт», «Еллар кәрваны» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Үз җырым бар

Чикерткә дә үз телендә жырлый,
Югыйсә, ул яши безнең өйдә.
Тыңлагыз, дип жырлый. Йә, ни әйтик,
Мич артыннан ишетелгән көйгә?

Чикерткә дә үз телендә жырлый,
Ни әйтсәк тә, безне ишетми ул.
Безнең өйдә гел үзенчә яши,
Жырыбызны хәтта иш итми ул.

Кушылмый ул бер дә минем көйгә,
Ә мин тыңлыйм, тыңлыйм чикерткәне!
Бик беләсем килә кайчагында
Өебезгә аны кем керткәнне.

...Минем дә бит асыл сүз-моным бар,
Зурлап яшим бөек туган телем.
Зат инде ул! Төшенерсең бер көн,
Минем дә бит үз жырым бар, илем!..

## Мин бер көндә ничә гомер яшим...

Мин бер көндә ничә гомер яшим,
Беләм үзем генә.
Үзем генә белгән бу гомердә
Житсен түзем генә.

Бар жиһанга якты кирәк миннән,
Кешеләргә — сүзем.
Күрсен өчен алар бәхет дигән
Ераклыкның күзен...

Изгелекләр, намус, ышаныч һәм
Ярдәм кирәк, кирәк!
Житми көчем, жилгә каршы торып,
Һаман тибә йөрәк...

Мин бер көндә ничә гомер яшим,
Чыдап барысына.
Жанкаемны кисә жилләр...
Сабыр
Канатларым сына.

Челпәрәмә килгән мизгелләрнең
Ватыкларын жыям.
Нидер тапмак булган бу мәлемдә
Әллә ниләр жуям...

Жуелганын, табылганын, аннан
Бер жаныма түгеп,
Мин бер көндә ничә гомер яшим!
...Үзем өчен түгел...

## МУЗАЛАР ТЫН ТОРМАСЫН ДИСƏК...

**Туплар атканда, музалар тын торыр, дигəн гыйбарə бар. Ə дөнья тарихы үзе асылда сугышлар тарихыннан гыйбарəт, дилəр. Кешелек тарихыннан без орыш-сугышларның бер атна дəвам иткəнен дə, йөз елга сузылганын да белəбез. Лəкин бер акыллысы əйткəн, сугышның беренче корбаны дөреслек була, дигəн. Бездə ватандашлар һəм Ватан сугышлары турында гына да меңлəгəн əдəби, музыкаль əсəрлəр, гыйльми хезмəтлəр язылган, нəфис һəм документаль фильмнар төшерелгəн, картиналар иҗат ителгəн. Əмма алар арасында тарихи хакыйкатькə, сугышның чын асылын ачып бирүгə дəгъва кылганнары күпме генə икəн? Сугышларны һəрдаим фетишлаштыру, аларның рəсмилəштерелгəн каһарманнарыннан бертуктаусыз пот ясау — ул империячел бəхетсезлек кəсəфəте генə түгелме? Əгəр озын-озак гасырлар дəвамында алып барылган сугышлар илнең тарихи хəтеренə гелəн гадел сурəттə генə уелып калган икəн, димəк, ул, ахыр чиктə, юк итү кораллары уйлап табуда гына зур җиңүлəргə ирешеп, безнең əби-əнкəйлəрнең төшенə дə кермəгəн кер юу машинасын да аңа сугышта җиңелгəн халыклар ясап бирергə тиеш буламы?**

**Кызганыч ки, эшлəр хəзергə шулайрак бара. Сугышларны гел гаделлəштереп, илəтне берөзлексез патриот булырга өндəп, хəзер дə «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» буенча гына эш йөртүче ура-патриотлар илне беркайчан да алгарышка илтə, аңа бəрəкəт индерə алмастыр.**

**Безнең дəвердə урысның үзем укып белгəн иң намуслы язучысы, сугыш ветераны Виктор Астафьев сугышның кырыс хакыйкате турында сүз əйткəч, Красноярск крае парламенты аны ниндидер ташламалардан мəхрүм итү турында карар чыгарган иде. Гомере буе солдат батырлыгы һəм сугыш фаҗигасе хакында язган бөек белорус əдибе, сугыш ветераны Василь Быков, үз иле җитəкчелəре кырын карый башлагач, Алманиядə сəяси сыену урыны тапты. Кыскасы, хəзергечə əйтсəк, икесе дə менə дигəн «бишенче колонна» вəкиле була иде.**

**Минем ике бабам да сугышта һəлак булган. Берсе — Ленинград чолганышында, икенчесе — Көнбатыш Аурупа туфрагында. Əмма аларның тол хатыннарына да, шул əбекəйлəрем итəгендə өелеп калган берсеннəн-берсе яшьрəк нарасыйларга да хөкүмəт беркайчан да якты чырай күрсəтмəгəн, киресенчə, салым, заемнар белəн изə-изə, аларның соңгы телем икмəген дə тартып алган... Их, шуларны уятып, бер генə булса да китап укытасы иде үзлəренə. Мəсəлəн, «Ледокол»ны. Гəрчə ул бездə хупланмаса да. Лəкин сизеп торам: мин хаталанам, көфер сүз сөйлим бугай. Сугыш кырында шəһит киткəн бабамнарның да, гомер буе михнəт чигə-чигə гүр иясе булган əбекəйлəремнең дə, гадел хезмəттəн башканы белмичə бакыйлыкка күчкəн сугыш ятимнəре эткəм-энкəемнең дə рухларын берүк шат кылсын. Аларга инде фани дөреслек кирəкмидер. Алар фəкать илаһи сүз — догага мохтаҗ. Ə фани дөреслек безгə, исəннəргə кирəк...**

**Җиһанда күптəн инде Өченче дөнья сугышы бара. Аның да үз Сталины, үз Гитлеры бар. Һəм алар, элеккечə үк, бер үк максатка хезмəт итə. XXI гасыр башында глобаль дошман да тəгаен ачыкланды кебек. Шуңадыр, күрəсең, «хохмачлар» хəзер Мөхəммəд пəйгамбəр карикатурасын ясап кинəнə.**

**Сүз уңаеннан əйтик, Сталин «Священная война» җырын 1941 елның февралендə үк язарга күрсəтмə биргəн, дилəр.**

**Газинур МОРАТ**

## Җир өсләрендә йөримен

Жир өсләрендә йөримен,
Йөримен кебек бушка...
Һавалар кошка кадерле,
Күкләр газиздер кошка!

Жир өсләрендә йөримен,
Нибары кеше булып.
Һәм кеше булуым белән
Филдән дә көчле булып.

Жир өсләрендә йөримен,
Чебендәй күрә байлар.
Икмәклек хак түли-түли
Көлә түрә агайлар...

Аларга елмаеп үтәм
Мин дә тыелып кына.
...Жир өсләрендә имәннәр
Ава кыелып кына...

Кала сүзләр, кала эзләр,
Кешеләрнен төсләре...
Жир өсләрендә йөримен,
Кадерле жир өсләре!

## Йөзек һәм шәл

Мамык шәлләр сата шәмдәй ханым,
Ак мамыкка ап-ак гөлме сипкән?!
Һәрбер караш энә күзе юкса,
— Йөзек аша, — диләр, — чыгар микән?

Чын бәһасе шәлнең шунда, имеш,
Матурлыктан, белмим, кемнәр бизәр?
...Шәлдәй жылы сүзләр эзләп йөрим,
Күңел аша үтеп чыгар сүзләр.

Бизәк итеп шәлләренә салган
Жаны түзмәс, тулып түгелер ул.
— Йөзек аша чыгар микән? — диләр,
Беләм, йөзек — халык күңеле ул!

Яман сүзне халык әйтмәс аны,
Кеше әйтер әйтсә, анысы хак.
Яшәешкә гөлләр сибеп биргәч,
Бардыр заманадан аласы хак.

Гөлләр сибәм мин дә сүзләр итеп,
Үз чорымнан сөеп жыйдым менә.
Шәлләр сата шәмдәй зифа ханым...
Мин үземне уйлап куйдым менә...

***

Кышлар озын, көннәр кыска була иде,
Таулар биек була иде балачакта.
Бар табигать сыендырган иде безне,
Көндез кояш, кичен ае торды сакта.

Кичләр тула, көннәребез тула иде,
Шат авазлар, ихлас көлешүләр барда.
Бу дөньяны тау шуу дип белдек микән,
Егылсак та төшәр идек килеп карга.

...Аһ, чанам юк, килдем юкса балачактан,
Кар тауларым язлар булып эреп аккан.
Сукмагым да чыккан инде бозлавыкка,
Егылсам да әрнүләрем сызлавыктай.

Шат авазлар җуелганнар ал таңымнан,
Бу тормышны уен диеп алданылган.
Таулары да бер калкулык кебек кенә,
Үтәм барыбер күз нурымны сибеп менә.

Туктап калам... Бала чагым бит каршымда,
Гүя торам биек-биек тау башында!

## Болдырларым

Туган нигез... Такта болдырларын
Алып менә Айның үренә.
Шуннан миңа Җир шары да хәтта
Туп шикелле генә күренә.

Туган йортның сары болдырлары...
Мин җилпенеп кенә төшкәнмен.
Йөгерә-оча ерак киткәнмен мин,
Ялкыннарга юлыгып пешкәнмен.

Өшегәнмен кышкы салкыннарда,
Адашканмын буран эчендә.
Сары болдырларның һәр тактасын
Сагынганмын елак кичемдә.

Әткәй, әнкәй! Артка борылып карыйм,
Гомер кадәр озын юл үткәч.
Шул болдырга басып, тулган Айга
Карап торгансыздыр мин киткәч.

Ә мин хәйран юллар үткәнмен шул,
Мин җир буйлап ерак киткәнмен.
Чит яклардан бәхет эзләгәнмен,
Һаман могҗизалар көткәнмен.

Шул юллардан йөгерә-йөгерә кайтам,
Көч бир, Ходам, егылып калмаслык.
Гомер кадәр ара киткәнмен мин,
Кайтып кына җитә алмаслык.

Борчуларым Җир шарыдай олы,
Болдырларга бассам — үтәчәк.
Туган нигез, сары баскычларым
Мине тагын кеше итәчәк.

Айга кадәр күтәрәчәк мине,
Айның да иң биек үренә.
Борчу түгел, аннан Җир шары да
Нокта кебек кенә күренә...



Хәмидә
Гарипова

# ТОЗАК

БӘЯН

«Мансур хатынын атып үтергән...» дигән яман хәбәр, яшен тизлеге белән Җимешле авылына гына түгел, бөтен районга таралды. Чыбыксыз телефонның шәплеге «Сантел», «Телесет»ларны көнләштерерлек шул. Аппаратлары искерми, җил-давыл чыгып, элемтә чыбыклары өзелми, техник хезмәткәрләргә эш хакы түлисе юк.

Авыл таяк тыгып болгаткан кырмыска оясын хәтерләтте. Көтелмәгән коточкыч хәл турында ишеткән Җимешле халкының аптыраштан тәмам башы буталды. Мансурлар тыкрыгына җыелган төркем гөж килде. Һәркем әлеге вакыйгага карата үз фикерен белдерергә ашыкты. Яше-карты, ире-хатыны тел чарлады, гүя, учакка утын өстәлә барды. Бераздан сүз буасы тәмам ерылды:

— Бая гынак Мансурларга кергәнием, ахирәткәем, йокы бүлмәләренең түшәмендә убыр авызы шае ырҗайган тишек күреп, котым очты! Теге тилемсә Шәйхиләре елап шешенеп беткән. Җиң очы белән күзләрен уып, дуңгыз урынына акыра ие, мескен. Үзе, түшәмгә төртеп күрсәтеп, нидер аңлатмакчы була. Пәме кызганыч инде, бичара... Малайны үзебезгә алып чыгып, көчкә йоклатып җибәрдем.

— Зөлхәбирәнең ни үлесен, ни тересен тапмаганнар...

— Әллә мәетен идән астына күмдеме икән, мөртәт? Үз башына котырынгандыр әле, имансыз...

— Булыр, булыр... Ирләргә ышанма, Иделгә таянма! Гомер иткән хатынын дөмектереп, яшь бичә алмакчыдыр.

— Персидәтел дигәч тә, әллә кем булган! Кеше үтерә, имеш. Газраилдән узып, җан кыярга аңа кем рөхсәт биргән? Аллаладан фәрман килгән, диярсең. Тьфү-тьфү! Әйттем исә кайттым. Каян телемә шундый көфер сүзләр килеп керде инде, җә? Тәүбә әстәгъфирулла, мондый хурлыкны, үземә генә түгел, нәсел-нәсәбемә язма-күрсәтмә!

— Демократия, имеш... Илдә тәртип бетте. Сәвит заманын сүгәләр сүгүен дә, тик яхшы яклары турында онытып җибәрәләр. Әнә, гөрләп торган компартиябез җан тәслим кылганнан бирле, җитәкчеләргә илле дә хут китте. Ялтыр битле, кибән корсаклыларны, элеккегечә «келәм»гә бастырып, кеше алдында ут өертеп, «мунча кертүче» калмады шул. «Коммунист исемен пычратырга не позволю! Хәзер үк партбилетыңны өстәлгә чыгарып сал!» — дип, өстәл сугып дер селкетүче юк, — диде элеккеге партоешма сәркатибе, хәзерге мөәзин Әкрам карт. — Халыкны көпә-көндез кычкыртып таласалар да, ачкүзләнеп, казна

малын капчыклап умырсалар да, җан кыйсалар да, бай-түрәләргә нипачум: ут та юк, суд та юк! Халык хисабына типтереп яшиләр, житмәсә, атлаган саен Мәскәүдә җыелышып ятып, бары тик үзләрен генә яклый торган закуннар чыгаралар. Хәер, суды да сатлык ич анын, кем акчалы, шул өстен чыга!

— Сәясәтегезне бер якка куеп торыгыз әле, абзыкайлар. Күпме чәйнәсәгез дә, авызыгызга май таммас. Лыгырдаудан бер файда юк! — дип сүз кыстырды сыер савучы Галия. — Бер дә аптырыйсы түгел. Кем урлый, шул юллый. Үзебезнең хәл мөшкел әле монда. Бичара Зөлхәбирә апанын бер көтү баласы ятим калды бит. Лутчы шуларны кайгыртыйк. Каладагылары үз көнен үзе күрер, анысы. Төпчеге кызганыч. Житмәсә, саусыз бит әле ул. Анасы булмагач, ташландык урам көчеге кебек, ят кешеләр күзенә карап, ачка тилмереп, каңгырап йөрсенме инде, мескен? Аны кая урнаштырабыз?

— Күрерсез дә торырсыз, менәтерәк, каладан берәр чәчбине ияртеп кайтачак әле Мансур. Өйгә яшь хатын килүгә, анысы төпчек малайны ике дә уйламый җүләрләр йортына олактырачак. Анаң үги булса, атаң җизни булыр, дип белми әйтмәгәннәр...

— Тумаган тайның билен сындырып утырма әле, Санияттәй! Кем өйләнә? Нинди яшь хатын? Йорт хуҗасы Мансур үзе дә каядыр юкка чыккан. Әйтерсең, җыенысын җир йоткан...

— Әй, юкка кайгырмасана! Шайтан булсынмыни персидәтелгә. Исендә дә юктыр әле оятсызның. Гомер иткән хатынын дөмектергәнгә куанып, кәнтәйләре белән җыелышып, берәр жирдә авыз күтәреп җырлашып эчеп утыралардыр.

— Җәмәгать, тел — сөяксез инде ул. Кем сөйләсә, шуныкы дөрес тоела. Сез теләсә ни дип уйлагыз, түлке минем Мансур Минһажевичның хатынын үтерүенә бер дә ышанасым килми. Күршедә генә яшибез ич, ничек сулаганнарына чаклы ишетелә. Монарчы пар күгәрченнәр кебек бик тату гомер сөрәләр иде, — диде аксакал Хатыйп абзый.

— Халык азынды хәзер. Артыгын уйлап, нәчәлстуага дәгъва белдермәсеннәр, аны-моны таләп итмәсеннәр, башлары миңгерәсен дип, юри аздыралар бугай гавамны, — дип сүзгә кушылды Тычкан Мәйсәрәсе. — Телевизордан җыен имансызны күрсәтәләр. Элеккегечә, балалар-оныклар белән тезелешеп утырып, рәхәтләнеп кино карар хәл юк: үтереш тә суеш; житмәсә, көпә-көндез анадан тума ятакта әүмәкләшәләр... Оятыннан җир тишегенә керерсең, билләһи. Боларга да шунын шаукымы тигән булса кирәк. Арага хыянәт керсә, чебен дә фил булып күренә ул, нәнәм-җаныем!..

— Нинди хыянәт? Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, — диде кибетче Зөһрә. — Булмаганны! Мансур энекәш үзе дә ипле ир, киленебез дә әр-хур түгел. Егерме елдан артык күз алдыбызда чөкердәшеп яшәделәр. Монарчы араларыннан кара мәче узганы сизелмәде, тавыш-тыннары чыкмады.

Персидәтел өе янында умарта күче кебек җыелып торган халыкны күреп алгач, сөт ташучы Мәснәви машинасын ыжгыртып шулар янына килеп туктады. Көнҗәләдәй сары чәчләрен җилпетеп, кабактай зур башын кабина тәрәзәсеннән чыгарды. Бераз карлыкканрак калын тавыш белән:

— Ник җыелыштыгыз? Нәрсә шаулашасыз? Ул-бу юктыр ич? — дип сорады.

— Булмаган кая! Беләсең килсә, Зөлхәбирәне ире атып үтергән...

— Җыен ахмак сүзне уйлап чыгарырга сиңа куш инде, Жамалый абзый. Үтерми генә торсыннар әле безнең балаларның яраткан Чәчәк апасын! Бүген иртәнге биштә стансыга тиклем үзем алып бардым . Билет алып, Ульян поездына утыртып җибәрдем. Бишенче вагонга.

Җыелып торучыларның күзләре маңгаена менде. Алай да яхшы хәбәр күңелләренә хуш килде. Тагын бер мәртәбә гөжләшеп алдылар:

— Менәтерә вәйт! Ә безне сон, җыен исәр, димәсән...

— Кайгыбыздан тәмам аңгырайдык ич...

— Калага барасы булгач, саусыз баласын ник үзе белән алмаган? Ул бичараны нишләп берүзен елатып калдырган?

— Маллары яман акырышканга аптырап, бая абзарларына кергәнием. Карасам, бурадай сыерлары савылмаган, имчәкләреннән сөте тамып тора. Бозауларына печән салучы булмаган. Зөлхәбирә үзе өлгермәсә, мина әйтеп калдырса, ни була инде, җә? Аннан гына кулым төшеп калмый ич. Гөнаһсыз малларны тилмертеп яткырып булмас. Савасын савып, ашатасын ашатып чыгыйм әле булмаса, — дип, Тәскирә түти, җилфердәп, персидәтелнең биек капкасыннан кереп югалды.

— Зөлхәбирә апаның кеше алдына җыйнаксыз чыгуына үзем дә аптыраганыем, — дип сүзгә кушылды Мәснәви. — Чәче тузган, йөзе шешенгән. Плащ та кимәгәние ичмасам, чәчәкле халат өстенә арка җылыткыч гына элгәние ул. Аягында... кызыл эчле галушлар. Калага кем шулай киенеп бара инде, җә? Гелән ыспай йөргән ханым димәссең. Өеннән пуледәй атылып чыкты бит ул. Чут кенә машина көпчәге астына эләкмәде. Ярый әле тормозлар яхшы минем, басып өлгердем. Кул изәгәч, утырттым инде. Стансага җиткәнче, бер авыз сүз катмады. Ни булганын сораштырырга телем кычытса да, яхшысынмадым. Төсе качканые персидәтел хатынының. Әллә бик нык куркынган инде шунда. Юл буе як-ягына карангалап, көрсенеп барды. Акылына зәгыйфьлек килмәсә ярый инде... Юллык акчаны миннән әҗәткә сорап алды. Бер дә юкка түгелдер бу! Мансур Минһаҗевич үзе кайда икән соң?

— Кем белсен аны! Таң алдыннан «УАЗ»игын үкертеп урман дамбасына таба киткәнен тәрәзәдән күреп калганыем,— диде каршы як күршеләре Мәсфия абыстай. — Иртәнге намазга тәһарәт алып йөри идем. Ату тавышын мин дә ишеттем. Эт аулаучылар килгәндер, шулар гөрселдәтәдер дип уйладым.

***

...Балалар бакчасында мөдир булып эшләүче, сабыр холыклы, итагатьле, чибәр Зөлхәбирә ханымны Җиләкледә яшәүчеләрнең барысы диярлек үз итә иде. Кара тутлы йөзендә өлгергән зәйтүн җимешедәй чем-кара күзләре магнит кебек үзенә тартып, җылы нур сибеп тора. Энҗе тешләрен җемелдәтеп елмаюга, әңгәмәдәшен авызына карата да куя. Килешле иреннәре алсу бантик сыман аның. Яшьрәк чагында, авыл клубы сәхнәсендә табан астыннан ут чыгарып, чегән, һинд кызы биюләрен башкарганда, зал аягүрә басып алкышлый иде аны. Бакчага йөргән һәр сабыйны туган телендә матур, дөрес итеп сөйләшергә, өстәл янында, урамда үз-үзен әдәпле тотарга, җырларга, биергә, әкиятләр сөйләргә, рәсем ясарга, балчыктан төрле сыннар әвәләргә, төсле җепләрдән уенчыклар бәйләргә шул унган ханым өйрәтте. Мөдирнең балалар белән мөгамәләсе бик җылы, шуңа күрә әти-әниләрнең күңеле һәрчак тыныч булды. Зыялы, тәрбияле хатын һәркемнең күңеленә ачкыч табарга сәләтле иде. Каенанасы белән дә сүзгә килмәде, ире белән тәмсезләнешеп, өйдәге чүпне урамга чыгарып чәчмәде. Авылда иң затлы туннарны, яңа модалы костюм, күлмәкләрне беренчеләрдән булып ул киде. Бит очларын алсуландырып, җиләк иреннәре белән ягымлы елмаеп, киң кырлы затлы эшләпәсен күперенке куе чәчләренә кырын салып, тирә-юньгә кыйммәтле француз исләмае исе таратып, кәз-кәз атлап, билләрен сыгылдырып узып киткәндә, тәнендә җаны булган һәр ир заты ымсынып карап калырлык иде шул Зөлхәбирә. Белмәссең, әллә күз тидерделәр, әллә берәрсе, көнчелегенә чыдаша алмыйча, бозым зәхмәте салдымы?

***

Мансуры бер күрүдә гашыйк булган иде чибәркәйгә. Педучилище тәмамлар алдыннан авылга практикага җибәрелгән кызга агроном егет сулыш алырга да ирек бирмәде, сагыз кебек чатнап ябышты. Алар танышканда, Мансур үзе дә кызлар күзе төшмәслек егет түгел иде: куе кара кашлар, шомырттай күзләр, лачыннныкыдай үткен караш, ачык йөз, киң маңгай, горур кыяфәт! Уртачадан аз гына калкурак буй, яшьли эшләп чыныккан, уйнаклап торган йомры мускуллар, корычтай нык бәдән. Сабантуй мәйданнарында сынатмады, алыптай көндәшләрен чирәмгә сырты белән сылады Мансур. Ә көрәштә бил генә сыналмый, әүвәле холык-фигыль сынала. Кемнең рухы нык, шул — җиңүче. Сүз дә юк, максатыңа ирешү өчен, җан-фәрманга тырышырга, үзеңне аямаска, җитмеш җиде кат тир түгәргә туры килә. Менә шул чакта чын ир-атка хас күркәм сыйфатлар тәрбияләнә дә инде. Сабантуй батыры исеменә лаек булып, центнерлы тәкәне көчле иңнәренә салып, мәйдан тирәли әйләнеп чыгу бәхете һәркемгә тәтеми шул! Кичке уеннарда гармун уйнап, яшьләрне җырлата-биетә күңел ачтыруы үзе ни тора! Туйлар, бәйрәмнәр ансыз узмый. Телгә оста, сүз сорап күршегә керми. Кирәксә, сандугач булып сайрый. Тырыш, үҗәт, кешелекле булганы өчен хөрмәт итәләр аны авылда. Студент чагында ук, әнкәсе җилкәсен кимереп ятмады, шабашкага йөреп, әүвәле өс-башын карады. Соңгы курста читтән торып уку бүлегенә күчте. Мари урманында агач кисәргә ялланып, йорт-җирлек бүрәнә кайтартты. Бер җәйдә буратып, күтәртеп үк куйды. Авыл агайлары «аһ» итте: «Буласының б... нан билгеле! Вәйт ичмасам, малатчина! Мөслимәттәйгә рәхмәттән гайре сүз юк. Улын сыңар канат белән үстерсә дә, чын кеше тәрбияли алган! Гаярь Минһаҗ каны уйный малаенда, мәрхүм атасы ил тоткасы иде», — диештеләр...

Зөлхәбирә елларда Казанга, әти-әнисе янына кайтып йөргәнгә күрә, Мансур аны һәр дүшәмбедә иртәнге поезддан каршылый, ә шимбә көнне кичкесенә озатып куя. Билет алып, үзе утыртып җибәрә, хушлашканда, кызның бит очыннан үбеп кала торган иде. Арысландай егетнең беленнән кочып, аның калкандай киң аркасына ышыкланып, тузанлы авыл юлыннан җилләр белән узышып матайда җилдерүләр башкала кызының күңелен җилкендерми калмады булса кирәк. Егетне күрүгә, йөрәгенең әллә кай төше дертләп кабына, туташның сулышы кысыла, битләре алмадай алсулана, күз карашы балкып китә, иреннәре елмаерга гына тора. Мондый чакларда ул тагын да сөйкемлерәк булып күренә. Җитеш тормышлы хәрби очучы гаиләсендә бердәнбер иркә бала булып үскән кызның авылда яшәргә теләге дә, әзерлеге дә юк инде югын. Әмма тиле яшьлек андый гына киртәләрне җимерми каламы соң? Җаннар җанга тартылганда, ярсу йөрәкләрдән кайнар хисләр ташып түгелгәндә, яшь күңелләр ашкынганда, тормышның мондый вак-төягенә игътибар итәләр ди мени?

— Зөлхәбирә, сеңлем, сиңа бер серне чишим әле. Мансурның авылда берничә ел озатып йөргән кызы бар бит. Сыер сава ул Сәвилә исемле, ут чәчле чая кыз. Кушаматлары Елан аларның. Йөрүе бик мәзәк, әллә ничек, тавышсыз гына килеп керә, нәкъ елан кебек шуыша инде, менәтерәк, — дип сөйләде фатир хуҗабикәсе Фәүзия апа. — Егеткә тиң буласы килеп, калага барып, читтән торып хисапчылыкка укырга кереп кайткан, диләр аны. Ә Мансурыбыз, шәһәр кызын күргәч, тәмам башын югалтты, бугай. Сәвиләне читкә тибәрде, ахрысы...

Хуҗабикәнең беркадәр шелтәле карашын сизеп алган Зөлхәбирә җавапсыз калмады:

— Агрономыгызны яныма чакырып китермәдем. Сәвиләгә карата хисләре шулчаклы гына булгандыр. Чын мәхәббәт арага җил кертми ул!

— Ярарсана, әйттем исә кайттым, үпкәли күрмә тагын! Еланныкыларның

камыры үзгәрәк аларның, ничаклы кыдрачлансалар да, затлылык житеп бетми. Сәвиләләре дә әлләкем түгел. Бер түгел, өч диплом апкайтса да, Мансурдай егет солтанына тиң булалмас.

Зөлхәбирәнең санаулы практика көннәре ахырына якынлашкан мәлдә, Мансур, тәвәккәлләп, кызның кулын сорарга Казанга китте. Башкала үзегендәге мәһабәт йортта, Горький паркы каршында яши икән аның сөйгәне. Булачак кәләше фатирына рөхсәт сорап килеп керүгә, егет ягымлы елмаеп исәнләште, кызның әнисе Зәмзәмия ханымга хуш исле кыр чәчәкләре бәйләме сузды. Биштәрен чишеп, өстәлгә каклаган каз түшкәсе, өч литрлы банкага тутырылган юкә балы, биш йолдызлы коньяк чыгарып утыртты. Ә сөйгәненә бүләккә кыз яратып сибенә торган затлы француз ислемае — «Шанель №5» не хәстәрләгән иде. Олыларга сиздермичә генә, мутланып, кызга күз кысып алды. Ә анысы, сөеклесен хуплап, бер ягымлы караш ташлады да, оялчан елмаеп, чем-кара күзләрен озын, куе бәрхет керфекләре эченә яшерде.

«Биш йолдызлы»ның муенын бора-бора, булачак каенатага сүз башлады:

— Һе, баш бар икән үзендә, игенче дус! Кем тәрәзәсен ничек шакырга икәнлеген дөрес чамалагансың, — дип, дустанә елмайды полковник. — Яшермим, бер күрүдә күнелемә хуш килдең! Көн итә ала торган егеткә охшап торасың. Болай зурлап килгән кешене кире бору килешмәс. Үзара яратышсагыз, хәер-фатыйха бирми булмас, шулай бит, әнисе? Тик кара аны, кызымның аккош канатыдай ак кулларын тирескә тыктырасы булма! Жир актарып, билчән йолкыр өчен үстермәдек без аны! Ул озын нәфис бармаклар пианино клавишаларында бик шәп биешә. Кызыбыз, училищесын тәмамлагач, укуын институтта дәвам итәр, чын педагог булып чыгар. Фатирыбыз иркен, бүлмәләр житәрлек, өйләнешкәч, теләсәгез, бездә торырсыз. Сиңа калада төшемлерәк эш белешермен.

Сөенеченнән кош тоткандай балкыган Мансур, эшне бозып ташламас өчен, карышып, телен озайтмады:

— Киләчәк күрсәтер, Зәки Зиннурович! Барысы да әйбәт булыр! — дип кенә куйды.

Яз иртә килгән иде ул елда. Чәчүне Май бәйрәмнәренә чаклы башкарып чыктылар. Тимерне кызуында сугып, хәтта Зөлхәбирәнең диплом яклавын да көтмичә, гөрләтеп туй ясадылар. Урыс халкында, майда никахлашма, гомер буе чиләнерсең, дигән әйтем бар. Безнеңчәсе, төн йокысы күрмәссең, языын эш бик күп, кәжә маең чыгар, була торгандыр, мөгаен. Булмагае, урыс белән маржа түгел ич алар. Һәр милләтнең үз көе дә үз чөе, үз гореф-гадәте. Һәркайсына хөрмәт белән карау тиеш, әмма үзеңнекен тоту хәерле. Май — хушбуйлы, тәмле исле, чәчәкле ай, табигатьтәге гүзәллектән башлар әйләнгән, күзләр камашкан, хисләр тулып ташыган мәл. Сөешеп кавышкан яшьләрнең түбәләре күккә тигән, дөньялары — түгәрәк, күнелләре — күбәләк. Яңа өйдә матур гына яшәп киттеләр. Калада үскән иркә кыз, килен булып төшкәч, әкренләп авыл тормышы жаена күнегә башлады. Аның һич кенә дә кеше алдында сынатасы, үзенә бәхет төннәре вәгъдә итүче жан сөйгәненең йөзенә кызыллык китерәсе килми иде. Улының бәхетле булуына ихластан сөенгән Мөслимә карчык, жайлап, көйләп, мактап, үсендереп, иплә кенә киленен сыер саварга, тавык-чебеш карарга, чүп утарга, яшелчә үстерергә, телеңне йотарлык камыр ризыклары пешерергә өйрәтте. Әүвәлге мәлдә төрле мәзәк хәлләр килеп чыккалады анысы. Яшь килен канәчкеч кигәвен һөҗүменнән изаланган сыерны сауганда, койрыгы селкенмәсен өчен, шунын очына гер тагып көлкегә калды. Ярый әле сөтлебикә сабыр булып чыккан, герле койрыгы белән Зөлхәбирәнең маңгаена кундырмаган! Чүп үләне белән бутап, яңа гына тишелеп чыккан кишер үсентеләрен йолкып бетерүче дә ул. Суган чемчеген, тамырланасы ягын өскә каратып, баштүбән утыртуы тагын... Әмма каенана мәрхәмәтле булды, зәһәрләнеп тавыш куптармады,

нәрсәдер тиешенчә килеп чыкмаганда, каты бәрелмәде, тәфсилләп аңлатып бирде. Килененең саксызлык белән кое чиләген төшереп батырганына, бәкедә кер чайкаганда, яраткан кәшемир яулыгын агызып җибәргәненә эчтән генә сызса да, ачуын тышка чыгармады. Дөнья малы — дуңгыз каны, баш исән булса, мал табыла ул, диюдән узмады. Яшь килен дә тәмле телле булды: «Әле ярый син бар, әнкәй! Исән-сау гына була күр! Әнкәй, акыллы киңәшләрең өчен рәхмәт яусын үзенә! Икенче юлы син өйрәткәнчә эшләрмен!» — дип өзелеп торды. Калага барган саен, каенанасына бүләк, күчтәнәч ташыды. Казан кодагый да юмарт кыланды, каян гына табып бетергәндер, Мөслимә кортканы ул яратып эчә торган, кабына фил рәсеме төшерелгән һинд чәеннән өзмәде. Һәр яңалыкны үзләштерергә омтылды яшь хатын. Иренчәкләнеп, төшкә чаклы йокы симертмәде, эт булып арыдым дип, иренә зарланмады. Авылда яшәгәненең икенче елында, Казанга баргач, юл уңаеннан «Үзем хуҗа» кибетенә сугылып, күп итеп чәчәк орлыклары, үсентеләр, бүлбеләр алып кайтып утыртты. Уңган килен ул җәйдә кычыткәнлы албакчаны гөлбакчага әйләндерде. Аллы-гөлле, көяз, купшы розалар, ак лилияләр, шәмәхә ирислар, алсу, кызгылтсу, куе кызыл төстәге, куш йодрыктай зур чәчәкле чалмабашлар, сары керфекле эре ромашкалар тирә-юньгә хуш ис таратып, узып баручыларны туктап җәннәт бакчасына күз салырга, сокланып тел шартлатырга мәҗбүр итә иде. Көләч йөзле кашкарыйлар, дәлияләр, хризантемалар, сентябриналар кара көзгәчә албакчаны бизәп, нурландырып торды. Юмарт яшь хатын, шуннан соңгы язда, кышын ире ясап биргән җыйнак тартмачыкларны тәрәзә төпләренә тезеп куеп, бихисап күп чәчәк үрентеләре үстерде, аларның үзеннән артканын күршеләргә, туганнарга, балаларын ул эшләгән бакчага йөртүче аналарга өләште. Шул рәвешчә, Зөлхәбирәнең җиңел кулыннан берничә ел эчендә Җиләкле авылы тулаем гөлбакчага әверелде. Авыл балалары, тәрбиячене үз итеп, Чәчәк апа дип йөртә башлады. Яңа ачылган роза гөленә охшаган, йөзендә Кармен чалымнары сиземләнгән, янып торган чибәр хатынын Мансур йөрәк назын биреп, чын күңеленнән ярата иде шул. Ә хатын-ызны иркәләп, сөеп торсаң гына, мендәр кебек йомшак була, ә рәнҗетеп, каһәрләп яшәсәң, су сибелмәгән гөл кебек кибә, шөкәтсез чүл кактусына охшап кала, усаллана, тәмам аждаһага әверелә, дигән шул борынгылар. Шөкер, иреннән унды Зөлхәбирә. Мансуры аны ихластан хөрмәт итә, какмый-сукмый, авыр сүзләр әйтеп рәнҗетми, күңел җылысын кызганмый. Пар килгән гаиләдә әти-әниләрен сөендереп, бер-бер артлы өч олан дөньяга аваз салды. Еллар үткәч, Зөлхәбирә басынкылана төште, сылу гәүдәсе әкренләп килешле генә түгәрәкләнә башлады, әмма ханымның сөйкемлелеге тагын да арта баргандай тоелды.

***

...Төпчек улын шактый олыгаеп, бик авырлык белән тапты Зөлхәбирә. Тәүлеккә якын тулгак ачысыннан газапланды ул, әмма нарасый дөньяга аваз салырга ашыкмады. Сабыйның кендек бавы муенына уралганлыктан, инде карын суы киткәч тә, авырыннан арына алмый тилмергән ананың үз хәле хәл иде. Дүрт килолы нарасый мең азап белән дөньяга килгән мәлдә күм-күмгәк иде. Тууга, башка бәбиләр кебек, кычкырып елап аваз салмады, карында кичергән «кислород ачлыгы» үзенекен эшләгән, күрәсең. Акушерка Фәрдүнә апаның бай тәҗрибәсе, җитезлеге аркасында гына сабыйга кабаттан җан керде. Абыйларына караганда көйсезрәк булды төпчек малай. Җитмәсә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, алты айлык чагында нарасыйның бүсере чыгып теңкәгә тиде. Табибларга күрсәткәч: «Операциясез булмас. Эчәк кысылса, зур бәла килеп чыгуы мөмкин», — диделәр. Район хастаханәсендә пычак астына кертелгән бала, наркоздан бик авыр айныды. Улы өчен җанын ярып бирергә әзер торган әнисенең үзенә иңәлеп карауларын күрми, өзелеп эндәшүләрен ишетми кебек тоелды. Нарасый

чем-кара күзләрен сәер пыялаландырып ятты. Тешсез авызын җәеп, элеккечә матур итеп елмаймады. Үзенчә «быты- быты» килүен дә оныткан, ахрысы, ник бер ым чыксын! Зөлхәбирәнең сизгер йөрәге әлеге хәлгә парә-парә телгәләнде, йокысы качты. Табибларга ялварып, ярдәм итүләрен сорады. Сәрхушлектән башы чыкмаган җан көеге — анестезиолог Әнәс кенә, наркоз аппаратының күптән искергәнен, шунлыктан йоклаткыч даруның дозасын төгәл билгеләп булмавын башкаларга сиздермәскә тырышты. Үзенең бу саксыз гамәле белән тупырчык кебек сабыйның киләчәк язмышына ничаклы зыян салуы, аның ата-анасына күпме борчу, хәсрәт китерүе хакында уйлап та бирмәде.

Баланы баш табибка күрсәттеләр. «Наркоздан соң күзәтелә торган гадәти хәл, үтәр, барысы да әйбәт булыр!» — дип, ананы тынычландырырга маташты ул. Эш бүлмәсенә таба атлаганда, күңелен борчулы уйлар өермәсе биләп алды: «Шул имгәк анестезиологны әллә кайчан эштән куарга вакыт икәнен беләм дә бит! Тик алмашка кемне куясың? Әллә яшь белгечләр каладан кайтырга ашкынып торамы? Җәһәннәм читендәге район хастаханәсенә, күке төкерәге чаклы эш хакына, тәүлек әйләнәсе җаваплы, тынгысыз авыр хезмәткә каян, кемне чакырып китерәсең? Җитмәсә, артта сөйрәлгән районда торагы да төзелми бит аның!» — дип, чын йөрәктән борчылды хуҗа.

Үтмәде шул бәла. Шәйхи саңгырау гына түгел, аңкый-сүңкый булып калды. Яшьтәшләре мәктәпкә китте, ә ул бичара, әнисенә ияреп, бакчага төшә, сабыйлар белән идәндә мүкәләп уйный, комда казына. Тик торганнан шыңшып еларга тотынса, тынычландырыр хәл юк. Көтмәгәндә килгән бәхетсезлек, ананың сизгер йөрәгенә сары сагыш булып үрмәләде, аны бөҗрадай кысып, һәрдаим сызлатып, гасабилап торды. Ханымның күз тирәләрендә, авыз читләрендә сизелер-сизелмәс сырлар пәйда булды. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, беркөнне каенанасы, карт карга сыман тавышын каркылдатып:

— Килен, дим, турысын әйтүемә ачуланма! Алма кебек оланыбызны син генә харап иттең! Әйттем мин сиңа: багучыга алып барыйк, имчегә сылатыйк, абыстайга өшкертик, дидем. Тыңламадың. Олы кешенең сүзен аяк астына салып таптадың. Менә изалан инде хәзер гомер буе! Үзең сорап алган чир, — дип, аның болай да әрнегән ярасына учлап тоз салды.

Каенананың яхшысыннан козгын тавышы килә, дигәннәр. Мөслимә кортка килененең йөрәк маен яман итеп чукып алды. Зөлхәбирәнең тамагына төер тыгылды, күзләренә яшь бөялде. Әмма акыллы хатын, сүзне тирәнгә җибәрмәде, күкрәген тутырып, тирән итеп бер сулады да, бәгырен авырттырып төшкән ачы дулкынны «Уф-ф-ф!» — иттереп тышка чыгарды. Тиз генә үз-үзен кулга алып:

— Ялгышканмындыр, берүк гафу итә күр инде, әнкәй! Син хаклы булгансыңдыр. Нихәл итик соң? Үзең дә: «Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, дип әйтәсең ич», — дип, мизгел эчендә ике араны җайлап куйды.

***

Мансур, хуҗалык рәисе итеп сайланганнан бирле, таң атәчләре белән бергә уянып, иртүк эшенә чыгып югала, өйгә ярты төн җиткәндә генә арып кайтып ава. Зур йорттагы тавык чүпләп бетермәслек бөтен эш Зөлхәбирә җилкәсенә өелеп кала. Каенанасы картайды, акылы көйсез сабый баланыкыннан ким түгел, җаена тормасаң, эш харап. Терлек-туарсыз да яшәп булмый бит авылда. Әле ярый, оланнар исәйде, әкренләп кул арасына керә башлады. Мансурның холкы беркадәр корырак булса да, гадел ул, монарчы хатынын юкка рәнҗеткәне булмады. Ходайга шөкер, тормыш арбасын ул җигелеп тарта, шул яктан Зөлхәбирәнең күңеле тыныч. Үзе дә сынатмый: эшенә өлгерә, кирәк чагында иренә таянычка инең куя белә, иркәли-назлый тынычландыра, төпле

киңәшләрен бирә. Еллар үтү белән, Зөлхәбирәнең холкында үзгәрешләр булмый калмады, билгеле. Ул күз яшьләрен эчкә йотарга, елыйсы урынга көләргә, авыр сүзләрне йөрәгенә җыймыйча, колак артыннан уздырып җибәрергә өйрәнде. Авыл халкы тик тормый бит, персидәтелгә чыккан ачуын бичәсеннән алмакчы булып, хатынына төрле гайбәт сүзләр ишеттерергә атлыгучы озын телләр бар. Әмма зирәк хатын иренә авырлык китермәскә, аның кәефен төшермәскә, эчендә ут кайнаганда, парын тышка чыгармаска тырыша. Каенанасының сулышы өзелгәнче, бәхиллеген алып калырга өлгерде, сиксәнне тутырган кортканы соңгы юлга бөтен шартын китереп, зурлап озаттылар.

***

...Районга Казаннан табиблар килүен ишеткәч, Зөлхәбирә, кырык жирдә таралып яткан кырык эшен ташлап, төпчеген алып, шунда элдертте. Карадылар, тикшерделәр, төрле киңәшләр бирделәр. Күзлекле неврологның сүзләре ананың күңеленә сары май булып ягылды:

— Медицина чакрымлы адымнар белән алга бара, ханым. Неврология өлкәсендә зур ачышлар ясалды, үтә заманча, «акыллы» диагностика аппаратлары барлыкка килде. Сезгә киңәшем шул: шифаханәгә алып барыгыз әле улыгызны, ышандырып әйтәм, файдасы тими калмас. Анда балагызның хәлен хастаханәдәгедән үзгәрәк ысуллар кулланып җиңеләйтәчәкләр. Шифаханәләрдә Көнчыгыш медицинасы алымнарын отышлы файдаланалар, фитотерапия — үләннәр белән дәвалау киң таралган, кирәксә, гирудотерапия алымы кулланалар — сөлек салалар. Соңгы елларда массажның нинди генә төрләрен ясамыйлар! Әйтик, мануаль терапия ярдәмендә сукырларның күзе ачыла, чукракларның ишетү сәләте кайта, хәтта таякка калганнар терелеп аякка баса. Рефлексотерапия ысулы белән — энәләр кадап, аеруча апитерапия — бал кортлары, ипотерапия — атлар ярдәмендә дәваланып, нерв чирләреннән арынучылар бихисап. Ханым, савыгуга өметне беркайчан өзәргә ярамый, — дип төгәлләде ул сүзен.

Зөлхәбирә эшне тиз тотты, табиблар юлламасының да файдасы тигәндер, түрәчек ханымнар каршына үзе дә буш кул белән бармады. Ничек итсә итте, чагыштырмача тиз арада, данлыклы «Әбелхәят чишмәсе» шифаханәсенә, «Ана белән бала» сменасына юллама алуга иреште. Инвалид бала анасына социаль иминият фондыннан путёвканы бушлай бирделәр. Әлеге яңалыкка Мансур да куанды, якыннарын затлы машинасына утыртып, шифаханәгә үзе илтеп урнаштырып кайтты.

***

«Әбелхәят чишмәсе» шифаханәсе җирнең җәннәт почмагына урнашкан. Чал Чулманның уң як ярына, әйтерсең лә сигез палубалы ифрат зур ак пароход килеп туктаган. Гүя аның күпсанлы пассажирлары, бередәге гүзәллеккә сихерләнеп, йөзьяшәр ак каеннар, киң ябалдашлы көяз юкәләр, гаскәриләр кебек тезелешкән купшы яшел чыршылар белән уратылып алынган, аллы-гөлле чәчәкле, хуш исле печәнле, шифалы чишмәле, җиләкле, гөмбәле тугайларга таралышкан. Ак пароходның бередәге гүзәллектән тәмам башын югалткан чал чәчле капитаны, якорьне шушында гына салырга, башка беркая кузгалмаска карар кылган, диярсең. Ә бер айлы төндә сихри көчләр аның биниһая зур корабын күз ачып йомганчы текә яр өстендәге киң мәйданчыкка менгереп куйган сыман! Күпсанлы «каюта»ларның зәңгәр пәрдәләрен ачып куйгач, Чулман өстен ямьләндереп кояш чыккан чагында, йөзләгән «иллюминатор» пыялаларында сихри нурлар биешә, әлеге манзарадан күзләр чагыла. Бирегә елның кайсы фасылында килеп төшсән

дә, хозурлыктан баш әйләнерлек. Язның үз яме, жылы җәй белән алтын көз турында әйтеп торасы да юк, хәтта салкын кышның үз бизәге, дигәндәй...

Үз гомерендә беренче мәртәбә шифаханәгә килеп эләккән Зөлхәбирәгә ул чын оҗмахтай булып тоелды. Әйтерсең, хатын бөтенләй башка галәмгә килеп эләккән иде. Биредә ашыга-кабалана таң төбеннән эшкә чыгып чабасы; көненә йөз төрле проблема хәл итәсе; кич җитеп, теленне салындырып, өйгә кайтып кергәч, мал карыйсы; ризык әзерлисе, тау чаклы табак-савыт, олаулап кер юасы юк. Шифаханә эчендәге рәхәтлекне сөйләп, аңлатып кына бетерерлекмени?! Монда һәрнәрсә алдан уйланып, ял итүчеләр мәнфәгатен кайгыртып эшләнгән. Дәвалаучы табиблар, шәфкать туташлары тарафыннан һәрдаим җылы мөнәсәбәт күрсәтелүе үзе ни тора! Арыган йөзле, таракан эзе сыман почерк белән адәм танымаслык итеп кәгазь сырлаудан башы чыкмаганга, күзләрен күтәреп авыруга багарга вакыт тапмый торган район больнисе табиблары түгел шул инде болар. Врачка керергә зар-интизар булып, су буе чиратларда үзара әрепләшеп, тилмерешеп утыручы усал чырайлы карчыклар, чирләшкә, елак балаларын тынычландырырга азапланучы, талчыккан кыяфәтле яшь аналар юк монда. Һәркайда ягымлы елмаю, җылы мөгамәлә, беркем беркая ашыкмый, кабаланмый, кычкырып сөйләшми.

Түшәменнән зәңгәрсу-фирәзә сталактитлар салынып торган әкияти «тау куышы»нда ялтыр мәрмәр ташлар арасыннан бәреп чыккан кәүсәр чишмәләре челтерәп ага. Биредә ял итүче күркәм затлар, кыр казлары кебек тезелешеп, көнгә өч мәртәбә шунда шифалы су эчәргә төшә. Мең төрле чирдән арындыра торган сихәтле җылы суны нечкә билле, озын борынлы затлы нәни савытларыннан ашыкмыйча, тешләренә тидермәскә тырышып, җайлап кына суыралар, вак йотымнар белән яратып эчәләр. Сауналарда тирләп, бассейннарда йөзеп; дәвалы җылы ләмнәргә уралып, су асты массажларында тәннең һәр күзәнәген уятып, минераль сулы ванналарда изрәп, тоз гротларында тынычлап йоклаганда; иркен кәнәфигә чумып, сандугачлар сайрап, талгын музыка уйнап торган бүлмәләрдә челтерәгән нәни фонтан җырын тыңлаганда табыла икән ул сихәт дигәннәре! Кичке аштан соң, теләсәң, йокы симерт, кырын ятып китап укы, йә булмаса, бакчага чыгып һава сулап кер, серле урман сукмакларында йөреп, җанына рәхәтлек ал, рухыңны савыктыр, илһам чишмәләре челтерәтерлек мая тупла.

Моңарчы шифаханәгә ирен ялгызын гына чыгарып җибәргәненә үкенеп тә куйды ул. Мансуры чакырса да, бергәләп ял итәргә баруга аяк терәп каршы торды ич Зөлхәбирә. Исәр димәсәң, нинди рәхәтлектән баш тарткан икән бит! Теләк булганда, өч атнага йорт-җиргә, балаларга, исән чагында, каенанам күз-колак булмас идемени? Көчтәнәчен муллан бирсәң, сыерны күрше хатыны да савып тора.

Шифалы ванналарда, мең төрле дәвалау үзлегенә ия ләмнәрдә, массаж кабинетларында сихәтләнеп, тәмам арыган Шәйхи кичтән үк изрәп йоклап китте. Форсат туудан файдаланып, Зөлхәбирә азрак йөреп керергә ниятләп, бүлмәсеннән чыкты. Түбәнге каттан дәртле музыка авазлары ишетелә иде. Күрше бүлмәдә яшәүче купшы ханымнар, бизәнеп-төзәнеп, затлы күлмәкләрен, биек үкчәле туфлиләрен киеп, гөрләшеп бию кичәсенә төшеп бара иде. Ай-вәена карамыйча, Зөлхәбирәне үзләренә иярттеләр. Зур зал тирәли куелган йомшак утыргычларга тезелешкән ял итүчеләрне танырлык түгел! Көнозын спорт киемнәреннән, трико, футболкалардан, гади кроссовкалардан, «чәпәли»ләрдән йөргән кешеләр пөхтәләнгән, чибәрләнгән, хәтта беркадәр яшәреп киткән кебек.

Дәртле заманча музыка аккордлары залдагыларның күбесен мизгел дигәндә үз эченә бөтереп алды. Кем ничек булдыра ала, шулай селкенергә, ирекле хәрәкәтләр ясарга кереште. Зөлхәбирәнең йөрәге җилкенеп куйды. Яшь чагында иллә оста бии иде бит ул! Егерме яше тулар-тулмас авылга кайтып төпләнеп, баштанаяк эшкә, катлаулы гаилә тормышына чумгач, табан астыннан ут чыгарулар онытыла

язды, билгеле. Балалар туганчы, авыл клубында оештырылган кичәләрдә катнашкалады әле ул. Ә соңрак, үзләре кунак җыйгач, яисә берәрсенә мәҗлескә баргач, башкалар күңелен күрергә теләп, азрак селкенгәләп алуны исәпләмәгәндә, аның биергә мөмкинлеге булмады, теләге дә сүрелде бугай. Куш учка сыярлык нечкә билле, җитез хәрәкәтле, ут борчасыдай тере Зөлхәбирә түгел шул инде ул. Гәүдәсе беркадәр түгәрәкләнде, ни дисәң дә, яше кырыкка якынлаша, җыйнак сынлы хатынга өч ир бала табу эзсез узгандыр, дисезме?

Ниһаять, «пәри туе» тәмамланды. Музыка алышынды. Диварга сыенып, биючеләрне читтән генә күзәтеп, елмаеп басып торган мөлаем йөзле ханым янына ыспай гәүдәле, илле яшьләр тирәсендәге ир якынлашты. Ягымлы гына эндәшеп, аны биергә чакырды. Бермәл икеләнеп торган ханым, йөрәкләрне җилкендергеч «Вена вальсы» көен ишеткәч, мизгел эчендә яшьлегенә кайткандай булды. Озын буйлы, ябыграк гәүдәле ирнең иңнәренә кулын салып, зал буйлап йөзеп китүен сизми дә калды! Үтә дә назлы авазлар җыелмасыннан тукылган дәртле матур көй, җаннарга бәлзәм булып тамды, биючеләрне тәмам әсир итте, үзенең серле дулкыннарында тибрәтте.

— Балерина түгелсездер бит, ханым? Музыканы искиткеч шәп тоемлыйсыз. Бию тактына дөрес басасыз. Гәүдәгез бик сыгылмалы, төз аякларыгыз нәкъ биючеләр өчен яратылган, — диде купшы мыеклы ир заты. — Үзегез дә бик сөйкемле, янып торган роза чәчәгенә охшагансыз! Мин Сезне монда килгән көнне үк күреп алган идем. Танышырга теләгем зур булса да, ничектер җае чыкмады. Равис Әһлиевич булам мин. Равис дип кенә эндәшсәгез, тагын да әйбәтрәк. Бүгенге көндә күктәге ай кебек ялгызмын, янымда балкып торучы үз йолдызым юк, — дип, үзе белән таныштырып үтәргә өлгерде ул.

Зөлхәбирәнең битенә ут капты, уңайсызланып, өлгергән зәйтүн җимеше төсле күзләрен читкә борды. Бераздан йөрәге түзмәде, әле генә үзенә мактау сүзләре яудырган ир затына сынаулы караш ташлап, аны баштанаяк күздән кичерде, эчке канәгатьлек хисе белән яңа танышына «зыялы адәм» дигән бәя бирեп өлгерде. Төс-кыяфәте тел-теш тидерерлек түгел Рависның. Грек профильле борыны очына эленгән алтын кысалы күзлегенә тиклем килешеп тора. Коңгыртсу күзләренең карашы тыныч, ягымлы. Какча яңаклары чиста итеп кырылган. Куе чәчләре кыска калдырып алынган. Тәрбия күргән йомшак куллары ак, тырнаклары маникюрлы. Уң кулының атсыз бармагында кыйммәтле «печатка». Өстендә затлы материалдан тегелгән соргылт костюм. Шуңа ярашлы галстугы зәвык белән сайланган. Ир кич буе чибәр ханымны күз уңыннан ычкындырмады, биюгә чакырды. Яңа танышлар аралашып китүне сизми дә калдылар.

— Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшлим мин. Командировкалардан кайтып кергәнем юк диярлек. Бер караганда, бу минем өчен әйбәт тә әле. Ялгызлык газабын оныттырып тора. Хатыным вафат булды бит минем, — диде ул, уфтанып. — Ике кызым да гаиләле. Сирәк кайталар. Үпкәләп булмый, һәркемнең үз тормышы. Берсе — Мәскәүдә, икенчесе Германиядә көн күрә. Шалтыратышып, хәл белешеп торабыз.

Зөлхәбирәнең авылда яшәвен, саулыкка туймаган баласы белән бергә дәва эзләп килгәнлеген белгәч, ир заты көрсенеп куйды:

— Заманасы әллә нинди бит аның, ханым. Чирле бала бер сездә генә түгел. Статистика мәгълүматларына күз салсак, вазгыять — чәчләр үрә торырлык. Яңа туган сабыйларның яртысы гына сәламәт дип язалар. Ә мәктәпне тәмамлап чыкканда, үсмерләрнең җитмеш-сиксән проценты хроник чирлегә әверелә икән. Элек армиягә өрлек кебек егетләр китә иде. Ә хәзер хәрби комиссариаттагылар аптыраштан баш кашырга мәҗбүр. Призывниклар нинди генә чирләрдән интекми: дистрофия, язва, холецистит, гастрит, аю табаны... Кайсы — наркоман,

кайсы — эчүче, кайберсендә СПИД, ә психик авырулылары ничаклы? Соңгы елларда онкология чире котырына, йөрәк авырулары елдан-ел яшәрә бара.

— Шулай булмый ни! Туганнан бирле психик тетрәнүдән башлары чыкмый бит балаларның, — дип сүзгә кушылды Зөлхәбирә. — Зарарлы һава сулап, пычрак су эчкән, химикатлы ипи, колорадо корты агуы сибелгән бәрәңге ашап үскән буыннан ни көтәсең? Алар бит урамга чыгып, тау да шумый, компьютерга терәлеп катканнар. Кигән киемебез — синтетика, өстән салганда, очкыннар чәчри. Кая карама, сыйфатсыз, ялган тауарга тап булабыз.

— Кая барабыз, диген, ә? Илебез кем кулына калачак? Милли генофонд күз алдыбызда яраксызга чыгып бара, — дип, Равис Әһлиевич үзенең ихластан борчылуын сиздерде. — Илкүләм проблема бит бу! Аны хәл итүне гаиләгә генә кайтарып калдыру дөрес эш түгел. Дәүләт дәрәҗәсендә чаң кагарга, ашыгыч чаралар күрергә вакыт. Саллы программалар кабул итәргә, шуларны ил белән күтәрелеп гамәлгә ашырырга кирәк! Бергәләп көрәшсәк, бәлки әле соң түгелдер. Хастаханәләрне заманча җиһазламый, табиблар белән тулысынча тәэмин итми торып, сәламәтлек саклау өлкәсендә әллә ни алга китеш булмас, мөгаен.

— Табиблар вазифасына авыруларны китереп чыгаручы сәбәпләрне ачыклау, юкка чыгару керми бит. Хастаханә чирләр дәвалый — әлеге вазгыять китереп чыгарган нәтиҗәләр белән генә көрәшә, — дип әңгәмәне дәвам итте Зөлхәбирә. — Ә табиб хаталары күпме? Алар өчен кем җавап бирә? Минем дә йөзендә нур уйнап торган тупырчык кебек нарасыем табиб ялгышы аркасында бер сәгать эчендә телсез чукракка, ипсез гарипкә әверелде...

Зөлхәбирәнең йөзендә күңелсезләнү билгеләре чагылуын сизеп алган ир юату сүзләре тезде:

— Алай да, күңелегезне төшермәгез әле, ханым. Өметсез — шайтан гына, диләр. Бирегә килеп дөрес эшләгәнсез! Мондагы табиблар бик шәп! Улыгызның хәле яхшырыр! Дөнья булгач, төрле могҗизалар туып тора. Узган килүемдә хәтта бер ягы параличланып, тораташтай катып калган егетнең интенсив мануаль терапия курсыннан соң, терелеп аякка басканын күрергә насыйп булды.

Бирсдә тормыш үз җаена агыла. Гадәттә, процедуралар тәмамланганнан соң, кичке ашка кадәр берничә сәгать буш вакыт кала. Кемдер караоке бүлмәсендә сәләтен күрсәтә. Күңелләренә сандугач кергән сөйкемле ханымнарның, ыспай ир затларының бер төркеме баянчыны сырып алган. Көйне көйгә җинел генә ялгап торучы баянчы Николай Фёдоровичка кушылып, халык җырларын сиптерәләр генә.

***

«Шифаханәгә Мәскәүдән танылган сәясәтче Сафиулла Гобәйдуллин килә. Дискуссия өчен сорауларыгызны әзерли торыгыз», дигән белдерү ял итүчеләрне җанландырып җибәрде. Китапханәнең уку залындагы гәҗитләр кулдан-кулга йөреп, таушалып бетте. «Время», «Хәбәрләр» тапшыруларын караучылар күбәйде. Ир затлары бергә җыелганда, һәркайсы үз каланчасыннан чыгып, халыкара хәлләр, базар бәяләре, дәүләт сәясәте хакында сүз кыстырды, хәтта үзара бәхәсләшеп алырга читенсенеп тормады.

Абруйлы кунак белән очрашу кичәсендә залда алма төшәр урын юк иде. Кершәндәй ак кәчтүм-чалбарлы, чал чәчле, юка кылыч борынына затлы күзлек элгән, карсак буйлы, какча гәүдәле мөхтәрәм галим шифаханәнең баш табибы Алмаз Садыйков озатуында сәхнә түренә күтәрелде, башын җинелчә ия төшеп, залны сәламләде. Дөньяны аркылыга-буйга гизгән, сәяси, икътисадый вазгыятьне биш бармагы кебек белгән галим тиз арада залны үз авызына каратып куйды. Ул әүвәле халыкара мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләре, четерекле

яклары, дөнья базарындагы бағланышлар, илебезнең анда тоткан роле, бүгенге икътисадый вазгыять турында тәмләп сөйләде. Сорауларга чират житкәч, моңарчы сабыр гына тынлап утырган кешеләр шыбырдаша башлады. Яшьләр өлгеррәк булып чыкты, бер-бер артлы сораулар яудырды:

— Дөньяга нинди афәтләр яный?

— Террорчылыкны авызлыклап булырмы?

— Бүгенге геосәясәт кайсы ягы белән үзенчәлекле?

Тәҗрибәле лектор, рәсми тел кысаларыннан бигүк читләшә алмаса да, гади халыкка аңлаешлырак сүзләр сайларга тырышып, тәфсилле җавап бирде.

— Эбола чире Африка илләрен тетрәндерде, меңләгән кешенең гомерен өзүен дәвам итә. Гарәп илләрен колачлаган «Ислам террорчылыгы» хәрәкәте, локаль күренеш булудан туктап, көннән-көн киңрәк тамыр җәя. Болардан тыш, наркомания котырына, күп халыкларның милли генофонды тамырына балта чаба. Әфганстан, Таҗикстан аша безнең чикләргә таба үрмәли. Әлеге афәтләрнең һәркайсына аяусызлык хас. Аларның яңа территорияләргә үтеп керүенә юл куймау зарури. Шул җәһәттән уяулыкны арттыру, дәүләтләргә саклык чараларын бергәләп күрү, ил чикләрен үзара килешеп ныгыту мөһим. Ә геосәяси куркыныч исә эбола белән терроризмнан да куркынычрак бәла-каза китереп чыгарырга сәләтле, чөнки ул бөтен дөнья халкының иминлегенә берьюлы яный. Кызганыч, бүген җиһанда тынычлык гаранты саналган БМО Уставын санга сукмаучылар пәйда булды. Астыртын рәвештә кылынучы явызлыкның асылы — үз мәнфәгатеңне, берьяклы карашыңны башкаларга көчләп тагу, теләктәшләрне артык үсендерү, риза булмаучыларны дошман күрү, аларга карата төрле мәҗбүр итү чаралары куллануда гыйбарәт. Башбаштаклыкка күз йомсак, ахыры хәерле тәмамланмаска мөмкин. Халыкара сәясәттә тотрыклылыкны какшатучы астыртын агымнар шактый, — диде.

Авыл мәктәбенең тарих укытучысы Гали Саматович урыныннан күтәрелде, тамак кырып куйды:

— Лектор иптәш, теләсә кайсы дәүләт, беренче чиратта, үз халкы мәнфәгатен кайгыртырга тиеш дип беләм. Финанс хәлебезнең кинәт түбән тәгәрәвенә тиешсез җирләргә тыгылуыбыз, Украинага бәйле гамәлләребез, әҗәтле илләрнең миллиардлаган бурычын кичерүебез сәбәпче түгелме? — дип сорады.

— Украина — тугандаш ил, кендек җепләребез нык береккән. Тарихи бергәлек ул. Кырымны яңадан үз канат астыбызга алдык. Якын туганы авыр хәлгә калганда, намусын җуймаган кеше, ничек битараф була алсын? Бәлагә тарыган күршебезгә саллы финанс ярдәме күрсәттек. Украинаның көнчыгыш өлкәләренә гуманитар ярдәм йөзеннән, азык-төлек, медикаментлар, кием-салым, төзелеш материаллары озатыла. Сугыш афәтеннән җәфа чиккән, йорт-җирсез калган миллионнан артык качакны үзебезгә сыендырдык.

Сүз дә юк, әлеге гамәлләр океан артындагы кайбер даирәләрнең кытыгын китерде. Көнбатыштан канунсыз чикләүләр кертелүнең икътисадка зыяны сизелерлек. Әмма артка чигенешнең сәбәбе ул гына түгел. Сәүдә өлкәсендә, сәнәгать җитештерүе буенча илләр арасында тыгыз интеграция шартларында дөньякүләм икътисадый кризис шаукымыннан Россия генә читтә кала алмый, — дип җавап бирде.

Үгезнекедәй таза муенына калын алтын чылбыр таккан, пеләш башлы, юан корсаклы АЗС директоры, урыныннан тормыйча гына, гөбедән чыккандай калын тавыш белән:

— Нәрсә анда, Мәскәүдә күмәкләп артка чигенүне битараф кына күзәтеп, кул кушырып утырырга җыенмыйлардыр бит? — дип кычкырды.

Сафиулла Габдуллович:

— Юк, әлбәттә. Хөкүмәт илнен финанс-икътисад системасын савыктыру юлларын эзли. Финанс тармагын тотрыкландыру максатыннан, банкның төп ставкасын күтәрделәр, — дип сөйли башлаган иде, көтмәгәндә арткы рәттән яңгыраган кырыс тавыш лекторга фикерен очларга ирек бирмәде.

— Иште банкирларыгыз ишәк чумарын... Шуның аркасында коммерцияле банкларда кредит ставкасы икеләтә күтәрелде. Эшкуарлар муенына салынган элмәк бит бу! Күрәләтә банкротлыкка этәрү! Үз житештерүченне кычкыртып талап, кризистан чыгып буламыни? — дигән сүзләр күпләрне сискәндереп җибәрде.

Залда киеренке тынлык урнашты, әмма озакка сузылмады. Ниһаять, бәхет капкасы ачылып, ял йортына үтә чыккан көнчелеге аркасында, иренең һәр адымын тикшереп, колак итен ашап тинтерәтүче хатыны Гыйльменисаны ияртми генә килеп урнашуы хөрмәтенә бүлмәдәше Бәчили белән янарак кына бер яртыны бөкләп кергән Котбетдин, йомшак урындыгында йокымсырап китеп, чебен таеп егылырлык ялтыр башын күршесендә утырган Аннушканың мул күкрәгенә төртүен сизми дә калган иде. Марҗа тутинең көтмәгәндә терсәге белән каты итеп кабыргасына калап алуына түзә алмыйча, аю чаклы салмыш ир урыныннан сикереп торды. Үзенең кайда икәнлеген, монда нишләп утыруын аңышмаган хәлдә:

— Ата-а-с! На-а-ших бьют! По-мо-гите кто-нибудь! — дип кычкырып җибәрде. Бер тын алгач, үзенең калкандай күкрәгенә бала башы чаклы йодрыгы белән төя-төя: — Абзагыз — не хала-бала! Әфганда душманның котын алган десантник Эюпов мин! Үземне кырерсытырга никому не позволю! — дип өстәде.

Сәясәтчегә дорфа рәвештә бирелгән четрекле сораулар аркасында янарак кына киеренкелек хисе кичергән зал, әлеге мәзәк хәлнең килеп чыгуын көтеп кенә торган сыман, шунда ук «шартлап ярылды», бар кеше шаркылдап көләргә керешге. Равис Әһлиевич янәшәсендә утырган Зөлхәбирә, тавыш килгән якка борылып карагач, кышын иренең фермасында тирес чыгаручы, җәен сыерлар көтүче күрше авыл агаен танып алды. Беркемгә дан китермәгән ул мәгънәсез сугышта «интернациональ бурычын» үтәгәндә, сыңар күзен югалткан, контузия алуы аркасында башы сызлаудан интеккән, инде олыгаеп килүче, нервылары таушалган якташының, әллә нигә бер эчкән хәмерне буена сеңдерә алмыйча, адәм көлкесенә калуыннан кыенсынып, башын түбән иде.

Халыкны тынычландыру өчен, унбиш минутлык тәнәфес игълан ителде. Ирләр урамга чыгып тәмәке көйрәтте, хатын-кыз холлдагы зур көзге каршында бөтерелде: чәчләрен төзәткәләде, кием-салымын сыпыргалады. Очрашуны оештыручы ханым лектордан түбәнчелек белән гафу үтенде. Кунакны җимешле кайнар чәй, теленне йотарлык тәмле юкә балы ягылган белен белән сыйладылар. Уймак чаклы бәллүр чәркәгә коелган затлы француз коньягын йотып куйгач, затлы кунак беркадәр тынычлана төште.

Бераздан дискуссия дәвам итте. Лектор, әллә халыкка ярарга тырышып, әллә саклык йөзеннән, илдәге икътисадый хәлнең алай ук өметсез түгеллеге, хөкүмәтнең берәүне дә ярдәменнән ташламаячагы турында кирәгеннән артык күпертелгән төче сүзләр сибә башлагач, иненә мамык шәл япкан, кечкенә буйлы, җыерчыклы йөзле Һиндия карчык сагаеп калды. Күпне күргән әбекәйнең башыннан: «Әттәгенәсе, күрәләтә күзгә төтен җибәреп маташа, хәерсез. Мәскәүдән киллем дигәч тә, безне чеп-чи томанага саный түгелме соң бу?» — дигән уйлар йөгереп узды. Үзалдына кыбырсынып, гаҗизләнеп, як-ягына каранды, түземе төкәнгәч, йөрәксенеп торып басты. Пенсиягә чыкканчы профком рәисе булып эшләп шомарган, чая телле, туры сүзле картканың соңгы араларда күңелен бимазалаган борчулы фикерләре, ташкын булып тышка бәреп чыкты...

Лектор аграр сәясәтне шәрехләүгә керешкәч, авылдан килүчеләргә җан керде. Сарык йоныннан бәйләнгән калын свитер кигән комбайнчы агай:

— Көнбатыш акылына килмәсә, туксанынчы еллардагы кебек, Рәсәй халкы ачка тилмермәсме? — дип сорады.

— Сезнең кебек унган игенчеләр басу тотырып ашлык үстергәндә, сөт елгаларыбыз агып торганда, ач калмаячакбыз, билгеле, әмма каешларны бераз кысыбрак буарга туры килмәгәе. Һәр начарның яхшы ягы була. Азык-төлекне читтән кертү күләме азайгач, икмәк, ит, сөт, бәрәңге, яшелчә житештерүче авыл кешесенә эчке базарда көндәшлек кими. Үстергән малыгызны кыйммәтрәк бәягә сату мөмкинлеге туа,— дигән җавап сорау бирүченең күңеленә сары май булып ягылды.

— Басуларыбызны куәтле чит ил техникасы эшкәртә. Соңгы елларда заманча комплексларны, чәчүлек орлыгын, ашламаны Европадан ташыдык. Импортны кысрыклыйбыз дип, югары технологияле «Маккормик», «Ропа», «Нью-Һолланд», «Лексус»лардан ваз кичеп, совет заманыннан калган иске-москыга күчеп утырыйкмы инде? — дип чәпчеде агрохолдингта эшләүче, кызу канлы инженер егет.

— Ә нигә ваз кичәргә? Заманча технологияләрсез алгарышка юл ябык. Үзебездә модернизацияләнгән яңа житештерү мәйданчыклары сафка басканчы, кыйммәт бәягә булса да техниканы читтән кертергә туры киләчәк.

Яшь агроном Айрат та форсаттан файдаланып калырга уйлады, кыю гына:

— Фермерлыкка керешергә иде исәп. Кризис аркасында безгә дәүләт ярдәме тукталмасмы?— дип сорады.

— Юлыгыздан тайпылмагыз! Илнең азык-төлек иминлеген тәэмин итү өчен, хөкүмәтнең авыл хуҗалыгына саллы инвестицияләр кертми чарасы юк. Дәүләт ярдәме гаилә фермаларына, эш башлаучы фермерларга грантлар, лизинглар, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ташламалы кредитлар, авыл җиренә эшкә кайткан яшь белгечләргә өстәмә түләүләр, яшь гаиләләргә торак төзү өчен субсидияләр рәвешендә күрсәтелә. Бу форсаттан тулысынча файдаланып калырга киңәш итәм. Сезнең кебек асыл егетләр барында, авыл хуҗалыгынын ныклап аякка басуына шигем юк! — диде.

Җанлы әңгәмәдән ике як та канәгать калды, зал Мәскәү кунагын алкышлар белән озатты.

***

Санаулы көннәр тиз узды. Равис Әһлиевичнын ял вакыты ахырына якынлашты. Беркөнне ул Зөлхәбирәнең ашханәдән чыкканын көтеп алып, кичен бергәләп чәйләп алырга чакырды.

— Кичерегез, ялгызым ирләр бүлмәсенә керүне әдәпсезлеккә саныйм, — диде Зөлхәбирә.

— Тапкансыз борчылыр нәрсә! Укагызны коймам, үзегезне кабып йотмам. Хәтта бармак очым белән дә кагылмам. Күңелле итеп гәпләшеп кенә утырырбыз. Өемдә шыр ялгызлык көтә бит мине, Зөлхәбирә ханым. Сагыштан үләрлек тынлык. Хәер, Сезгә андый халәт таныш түгелдер шул...

Зөлхәбирә икеләнә калды. Ул Рависны ихластан кызганып куйды. Бу зыялы адәм белән аралашу хатынның үзенә дә ошый башлады түгелме соң? Министрлыкта эшләүче зур түрә димәссең, кече күңелле. Үзе нечкә юмор хисенә ия, ә ул сыйфат акыллы кешеләргә генә хас. Үзе — тәрбияле, фикере — анык, сүзе — мәгънәле. Белмәгән нәрсәсе юк бугай аның, киң карашлы зат. Житмәсә, нечкә тоемлы психолог та әле. Кайсы темага сүз башласа да, әңгәмәдәшен уңайсыз хәлдә калдырмый. Теләсә кайсы ситуациядән чыгу юлын бик тиз таба.

— Ярый хуш, Сезнеңчә булсын! Минем бүлмәгә ялгыз гына керәсегез килмәсә, җайлыйбыз аны, матурым. Зинһар, ризалашыгыз инде, яме! Хәзер бер парны чакырып киләм. Бүген иртән элеккеге группадашым Әлфисне очраттым. Ялга хатыны белән парлап килгән. Люкска урнашканнар, — дип, ягымлы ир заты җил-җил атлап китеп барды.

Кичке тугызынчы яртыда бала йокыга талды. Улынын алсулык йөгергән битеннән үбеп алгач, ана бермәл ана елмаеп карап торды, юрганын рәтләп япты.

Зөлхәбирә ашыкмыйча гына кием шкафы янына килде. Затлы велюр күлмәген, кадак үкчәле «көймә» туфлиләрен киде. Купшы чәчләрен кабартып өйде. Чамасын белеп кенә иннек, кершән сөртенде, яраткан ислемаен сибенде. Тәвәккәлләп Равислар бүлмәсенә килеп кергәч, көтелмәгән хәлдән артына утыра язды. Угрылык өстендә тотылган карак кебек, куырылып килде. Түр башында, берсе кочагына икенчесе сыенып, үзләренең район советы рәисе Әлфис Кәримович белән... ире Мансурның хисапчысы — яше кырыктан узган сазаган кыз Сәвилә елмаешып утыралар иде. Зөлхәбирәне күргәч, кунаклар йөлт кенә бер-берсенә карашып алса да, сер бирмәде. Бәйрәм өстәле муллан иде, чәй янына мәе куелды. Бәллүр чәркәләргә кыйммәтле шәрабләр коелды. Табындашлар шактый кызгач, Әлфис Кәримович затлы костюмының куен кесәсеннән планшетын чыгарды. «Истәлеккә бер гүзәл мизгел, чейз!» — дигән булып, бергәләшеп фотога төштеләр. Керсез күңелле Зөлхәбирә бу минутта киләчәктә аның көйле тормышын челпәрәмә китерерлек нинди мәкерле тозак корылганлыгын сизми калды. Аның саф күңелендә һичнинди азгынлык, усал ният юк иде шул...

***

Зөлхәбирә шифаханәдән кайткач, Дәүләт Советына сайлаулар булып узды. Мөгаен, күрәчәккә каршыдыр, Мансур депутатлыкка кандидат итеп Әлфис Кәримович белән бер округтан күрсәтелгән иде. Халык ышанычын районның зур түрәсенә түгел, ә гади хуҗалык җитәкчесенә күрсәтте. Сайлау кампаниясен оештыруда куштаннарын ат урынына җигеп, күпме көч куйган, ничаклы чыгым тоткан район советы рәисе әлеге җинелүне бик авыр кичерде. Әлфис Кәримовичның йөрәгендә укмашкан кара кан, үч тойгысы, сыйфатлы Буа чүпрәсеннән куелган ачы камыр сыман кабарып, ташып түгелде. Ачуыннан кая барып бәрелергә белми йөргән көннәрнең берсендә, кабинетында юкны бушка аударып, планшетын актарып утырган мәлдә, күзенә шифаханәдә үзе төшергән фотолар чалынды. Аның зиһене ачылып китте. Сөмсере коелган йөзенә кинаяле елмаю кунды. «Карарбыз әле, кем-кемне фәлән итәр...» — дип үзалдына сөйләнде ул. Зөлхәбирә белән Равис Әһлиевичны янәшә куеп, компьютер ярдәмендә фотомонтаж ясауның әллә ни авырлыгы булмады. Ул фотоларны тиз генә төсле принтердан чыгартып алды. Мансурның йөрәгенә хәнҗәр кадалырлык итеп хат кисәге әмәлләргә үзенең хәленнән килмәс иде, мөгаен. Сәвилә ярдәм итте: кайнар мәхәббәткә багышланган бер француз романыннан бик шәп өзек табып бирде. Шуны күчереп яздылар. Әлфис Кәримович, Казанга эш белән баргач, әлеге пасквильне каланың бер почта әрҗәсенә төшереп җибәрде дә, мыек астыннан елмаеп, шыпырт кына шул «бомба»ның шартлавын көтеп йөри башлады. Әлеге калын конверт, ниһаять, хуҗалык идарәсенә килеп ирешә. Көндәлек почтаны ачып, хатларны журналга теркәп утырган сәркатип кыз Ләлә, аны-моны уйламыйча, бу конвертны да ачты. Фотоларга күз салуга, көтелмәгән хәлдән зур итеп ачылган уймак авызын ябарга онытты. Ә хатның эчтәлегенә күз йөртеп чыккач, аның чигәләре кызыша башлады: менә ичмасам мәхәббәт! Армиядәге яраткан егете Мөнирдән шундый хат килеп төшсә, шатлыгыннан күккә сикерер иде ул, мөгаен. Конвертны кулында әйләндергәләп, нишләтергә белмичә аптырап торган мәлдә, алгы бүлмәгә Сәвилә ажгырып килеп керде. Яшен ташы җитезлеге белән хатны тартып алды да бүлмәдән чыгып югалды. Биш-ун минут эчендә бөтен бухгалтерия хатыннары «ах-вах» килде, чышын-пышын гайбәт чәйнәргә керешә. Эш сәгате бетүен көчкә көтеп җиткереп, бу чаклы «мөһим» яңалыкны танышларына тәмләп сөйләргә дип, төрле якка чыгып чапты.

Баш хисапчы янәдән әйләнеп керде, мәҗмуганы сәркатипкә сузды. Ләлә, башын башка куеп, чибәр ир янәшәсендә елмаеп утырган Зөлхәбирә апасының фотосына тагын бер мәртәбә күз төшереп алды да телен шартлатып куйды. Хатны фото янына салып, конвертны келәйләп ябыштырды. Сәвилә исә:

— Яши белә ичмасам кешеләр, мин сиңа әйтим! Тыштан әүлия булып кыланалар! Мансур Минһаҗевичның күркәнекедәй кабарынган куыгы шартлый болай булгач! Хи-хи-хи! Шул кирәк аңа! Мөгезле шайтан! Казан кызына өйләнә, имеш! Берни түгел, теге вакытта мине санга сукмаганы өчен, Ходай тоткан аны! Әгәр миңа өйләнгән булса, гомердә болай адәм мәсхәрәсенә калмас иде! Беләсең килсә, шәһәрнекеләрнең барысы да бер чыбыктан сөрелгән... җыенысы сөйрәлчек, — дип, бүлмәне сасытты.

Кемгә-кемгә, нәкъ менә аңа, авылга кайткач серләрен чишмәгәне өчен, Зөлхәбирәгә рәхмәт укып йөрисе кана! Юк шул, Елан Сәвиләсе булсын да, зәһәрен чәчми калсын, имеш. Юкса, үз агуына үзе тончыгып үләчәк бит ул!

***

Кичке алтылар тирәсендә хуҗалык рәисе контора каршына кайтып туктады. Кабинетына узып, гадәтенчә, яңа килгән корреспонденцияне күздән кичерә башлады, гәҗит-журналларны карап чыкты. Хатларга күз йөртеп алды: салым инспекциясеннән, экологлардан, банктан... Ә бусы кемнән тагын? Чират калын конвертка җитте. Аны ачып укый башлагач, Мансур үз күзләренә үзе ышанмады. Хаттагы сүзләр, әйтерсең, аның бармакларын гына түгел, бәгырен пешерә башлады. Дулкынланудан ирнең уч төпләре, маңгае тирләп чыкты.

*Зөлхәбирәм!*

*Кайнар иреннәреңнең җиләк тәмен әле дә тоям кебек. Тәшләремә кереп иләсләндерәсең! Синең белән үткән ләззәтле төннәребезне үлеп сагынам. Бергә үткәргән һәр сәгатебезнең минуты елга тиң. Бер генә дә исемнән чыкмыйсың, гүзәлкәем! Мин сине шашып сөям! Миңа карата булган хисләреңнең ихласлыгына өмет итәм! Ташла шул мокытны! Ятма авылда чиләнеп! Кавышыйк, бәгырькәем! Истәлеккә бергә төшкән фотобызны җибәрәм.*

*Үбеп, Рависың!*

— дигән юлларны укыгач, Мансур бер мәл өнсез торды. Әйтерсең, өрлектәй ирнең маңгаена күсәк белән ордылар. Фотоны кат-кат әйләндереп карагач, ваклап ертып, җирәнеп чүп чиләгенә ташлады. Хатны йомарлап кесәсенә тыкты да:

— Кавышырсыз... теге дөньяда, — дип, әллә нинди ят, ямьсез тавыш белән, котырынган үгездәй үкереп җибәрде.

Сейфтан коньяк шешәсе тартып чыгарды. «Кандала даруы»н кабымлыксыз гына авызына койды. Ачуы басылмады. Ул нишләргә белмәде: кабинет буенча арлы-бирле йөренде, кәнәфиенә бер утырды, бер торды. Йөрәк әрнешенә чыдаша алмыйча, бала башы чаклы йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. Астына кирәкле кәгазьләр тезелгән калын пыяла кисәге чатнап урталай ярылды. Моңарчы бохар песиедәй яшәгән хатыны ике йөзле Янус икән бит. Ни гомер куенымда кара елан җылытып ятканмын... Бала савыктыра, имеш... Ха-ха-ха! Хатынымны сөяркәсе янына үзем илтеп куйганмын икән. Җирбитләр! Хәмер сөреме Мансурның башына менеп җитте булса кирәк. Ул бермәл чайкалып торды да кәнәфиенә ауды. Таң алдыннан уянып китте, аптырап, як-ягына каранды. Нишләп конторда йоклап калган соң әле ул? Шофёры ник өйгә кайтарып куймаган? Көч-хәл күзләрен угалап, ир торып басты. Нindидер мөһим нәрсәне исенә төшерергә азаплангандай, кин маңгаен җыерды. Аның үтереп эчәсе килә, теле аңкавына келәйләнеп ябышкан иде. Кичтән катырак салынган, күрәсең. Кабинетка авыр ис таралган. Сәгать ничә

соң әле? Өйгә кайтып, нәрәткә чаклы бераз черем итеп алмый булмас. Борын яулыгын эзләп, кулын кесәсенә тыккач, нindидер кәгазь кисәге кыштырдап куйды һәм... барысы да исенә төште. Яман уй ирнен миен көйдереп алды.

Калганы күз алдыннан детектив кино кадрлары шикелле бик тиз йөгереп узды. Менә ул өенә кайтып туктады. Алпан-тилпән атлап, болдырга күтәрелде. Ишек эчтән бикле түгел иде. Аяк киемен салып тормыйча, түр якка узды. Дивардагы кыйммәтле Иран келәме өстенә элеп куелган ике көпшәле ау мылтыгын алды. Калтыранган куллары белән ана ике патрон этеп кертте. Поши хәтле пошины атып еккан Мансур әле ул, бу юлы гына хыянәтче «киек»нең йөрәгенә тидерми калмас. Ирнең кан баскан күзләренә бу минутта ак-кара күренми иде. Ул йокы бүлмәсе ишеген шыгырдатып ачты. Таралып йоклап яткан хатынына бер мәл нәфрәт белән карап торды да чертләтеп өстенә төкерде. Йокы күлмәгеннән умырып тотып, хатынын кисәк кенә өстерәп торгызды. Житмәсә, Шәйхие әнисе кочагына сенеп киткән булган икән, кирәкмәгән вакытта ул да күзләрен ачты. «Ник мине болай вакытсыз уяттыгыз?» — дигән сыман, еламсырап, әнисенә сарылды. Аптыраулы карашын әле берсенә, әле икенчесенә күчерде. Аннан соң әтисе кулындагы мылтыкка карап катты. Атасы борын астыннан гына нәрсәгәдер усал мыгырданып куйды, кесәсеннән нindидер йомарланган кәгазь кисәге чыгарып, хатынының йөзенә томырды.

Яланаяк идәнгә төшеп басканда, үзенә ни-нәрсә янаганын аңламаган хатын, тиз генә йомшак чүәкләрен элде, өстенә чәчәкле халатын, кәжә йоныннан үзе бәйләгән йомшак жилетын киде. Гомердә булмаганны, иренең салган баштан болай дорфа кылануына хәтере калса да, ачуын тышка чыгармаслык көч тапты:

— Әтисе дим, таң төбеннән нишләп өй буйлап мылтык күтәреп йөрисең? Ауга барырга жыенмагансыңдыр ич? Бик арыгансың бугай. Бераз ятып хәл жыеп алсаң, әйбәтрәк булыр. Әйдә, чишенергә үзем булышам, — дип эндәште.

Шул мәлдә парлы көпшәләр аның калку күкрәгенә юнәлде. Аптыраудан хатынның күзләре маңгаена менде. Куркуыннан кымшана да алмыйча, рәхимсез карашлы ире каршында тораташтай катып калды. Нәни йөрәге әнисенә коточкыч хәвеф янаганын сизеп алган бала, уктай атылып, әтисенең терсәгенә барып асылынды. Мансурның мылтыклы кулы чалшаеп китте, көпшә кисәк кенә өскә күтәрелде. Мизгел эчендә ату тавышлары яңгырады. Бер-бер артлы очып чыккан пуляларның берсе бәллүр люстраны челпәрәмә китерде, икенчесе, түшәмне чәрдәкләп, каядыр кереп юк булды. Йөрәген тотып, киселгән үләндәй идәнгә ауган хатыны өстеннән атлап чыккан Мансур, әле генә нәрсә майтарганын аңламас хәлдә, абына-сөртенә урамга чыгып йөгерде. Капка төбендә торган машинасына утырып, жан-фәрманга куалап китеп барды...

***

...Зөлхәбирәне Ульяновскидагы туганнарыннан олы улы Марсель эзләп тапты. Аның телефон трубкасыннан ишетелгән өзек-төтек тавышы ананың болай да борчулы жанын айкап ташлады:

— Әни-жаным, зинһар өчен, бүген үк кайта күр! Әтине инсульт бәрде... Ул реанимациядә... система астында... ризык капмый... беркемне танымый... Шәйхи сине бик сагына... туктаусыз елый... тынычландырып булмый...

Йөрәгендә янартау уты кайнаса да, хатын тиз генә жыенып, юлга чыкты. Гомер итү — кыр аша үтү генә түгел шул. Язмыш дигәнең, адәм баласының сабыр канатларын каната-каната, сындыра-сындыра сыный...



Луиза
Янсуар

## ДӨНЬЯНЫКЫ ҮТӘР — БЕЗДӘН ДӘ...

### Кешеләр

**1**

Кешеләрдән жылы эзләр булсаң,
Кешеләрдән ерак кит икән.
Йөрәк — йөрәк бит ул, тыпырчыныр,
Учларыңа кыс та көт икән.
Унга, сулга чәчмә сагышыңны,
Чүбек итмәсеннәр зарыңны.
Урла да кит Каф тау артларына
Тик үзеңә насыйп ярыңны.
Дала күкрәгендә учак тергез,
Тирмә үзәгенә бишек эл.
Сиңа насыйп язмыш — тик синеке —
Ымыңны да хәтта ишетер.

**2**

Ә кешеләр үз үлемен ашыктыра.
Син дә — шулар исәбендә.
Мин дә — шулар.
Жирдә безнең күләгәләр кисешсә дә,
анда барыбер олагырбыз —
сыңар, сыңар.

Шуңа сине эзлим жирдә.
Шуңа — көтәм.
Шуңа син дә ут йотасың
төннәр буе.
Тик кешеләр жиңә алмый мин-минлеген.
Кешеләрнең күләгәдән
озын буе.

---

Луиза ЯНСУАР — *шагыйрә; «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» һ.б. китаплар авторы. «Татнефть» һәм Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге һәм Россия-Италиянең Халыкара «Белла» әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

***

Сөйләшәсем килә. Сүзсез генә.
Күзләреңнән күзем алалмый.
Җимерәсем килә диварларын
Сине камап алган каланың —
Берлин стенасын җимергәндәй.
Һәм өясем кирпеч — кабаттан.
Син иде бит — мине ерак кышта
Карлар белән ышкып агарткан.
Син иде бит — барыр юл өзелгәч,
Канатларын салып калдырган.
Син иде бит — күкләремнән минем
Мәңгелеккә кинәт атылган.
Утырасың менә. Агызасың
Чынаякка куе төнәтмә.
Син бар бүген. Уйдырма да түгел,
Саташу да, хәтта өрәк тә.
Сөйләшәсем килә. Сүз табалмыйм.
Табылмыйлар сүзләр — кирәктә.
Нәкъ кешеләр кебек — бер җуйгачтын,
Кайтарамын димә инрәп тә.
Җимерәсең кирпеч диварларын
Торгынлыкка күчкән дөньямның.
Елмаясың үзең. Сүзсез генә.
Мин дә елмаюым тыялмыйм.
Без ерак та кебек. Бик якын да —
Яңа кагыйдәләр чигендә...
Булсын, әйдә, кагыйдәләр, сеңсен
Әрем тәме чәйдән иреңгә.
Син бар, исән — каннан вә тиредән
Югалтканым түгел, тапканым.
Берлин диварыннан калынрак
Булса-булсын яңа калканың...
Шул үзең бу. Бер гөнаһсыз карлар
Кайтардылар сине яңадан.
Утырасың. Ә мин, ахры, мәңге
Күзләреңнән күзем алалмам.

## Читен

Айга табынгандай йә кояшка,
Табындылар сиңа — уннар, йөзләр.
Бусагаңа килеп тезелделәр —
Соры иде алар...
Бертөслеләр...
Карашлары аша мәңгелеккә
Бәреп чыгам, диеп, тыпырчындың...
Потлар белән дыңгычланган илнең
Булып калдың вак бер кыйпылчыгы.
Мин дәшмәдем.
Алар сафындагы
Урынымны бушаттым да...
Киттем.
Син урасы җаннар әле күптер.
...Мина никтер
Ак карлардан читен...

## Кичү

Җылыга, җылыга күнекмә,
Күнекмә ышыкка, бушлыкка.
Йөрәкне йөрәккә ялгыйлар,
Кайчакта ялгызлык кушып та.

Киектәй эзеңнән йөгерәм,
Киектәй багасың үзең дә.
Бу дөнья, мәңгелек сораудай,
Төбәлгән син булып күземә.

Мин аңа җаваплар табалмыйм.
Җаваплар, мөгаен, кирәкми.
Ирекккә җибәрәм — үземне
Һәм синең талчыккан йөрәкне.

Бер — дөнья.
Ә юллар — бихисап.
Кинәнеп сулыймын март җилен...
Артыгын даулама дөньяда,
Артыгын яулама. Һәм — кимен.

Корбаны да булма кемнеңдер,
Һәм булма җанына бишек тә.
Йөрәкне йөрәккә ялгыйлар,
Кайчакта сөюне кичеп тә.

## Җәйләү

*Бабам истәлегенә*

Без сабыйлар идек —
Син дә, мин дә.
Көтүдәге һәрбер бәтине
Тиңли идек
Бөдрә болытларга...
Җәйләү буйлап —
Икәү тәпили...

Инебездә — биштәр.
Башта — кепка.
Икебез дә шундый
Хәтәрләр...
Син сызгырсаң,
Сыйрак дерелдәтеп,
Шым калалар иде
Бәрәннәр.

Әкият белән
Тулы иде дөнья:
Тигәнәкләр —
Чыңгыз урдасы...

Синең куллар юнган
Хәнҗәр кулда —
Яуга чыгам —
Шундый йоласы...
— Җиңелсәң дә,
Кулга бирелмә,
Һәм —
Хыянәтче булма! —
Шул хәтәр...
Нинди олы булган
Синең йөрәк —
Каршыбызда яткан
Юл кадәр.

Мин шул юлдан
Тәпилимен хәзер.
Тигәнәкләр —
Җанга сарыша...
Ә кулымда —
Шул ук агач хәнҗәр.
Чыкмыйм инде яуга,
Алышка.

Җан кыярга
Өйрәтмәдең мине:
– Кисмә, — дидең, —
Кеше сукмагын.
Кыныда тот
Хәнҗәреңне!
Атма!
Уңга-сулга
Атма укларың...

Без сабыйлар идек —
Син дә, мин дә.
Бөдрә иде таллар...
Болытлар...
Син шул сабый килеш
Китеп бардың
Язның бер кичендә —
Офыкка...

Анда сине
Көткәннәрдер, ахры,
Алгысыдын никтер...
Ашыктың...
– Мин бит озак
Бардым инде, — дидең. —
Үпкәләмә...
Бераз талчыктым...

Мин хәзер дә
Шул җәйләүдә...
Кайчак
Сәфәрдәшләр очрый —
Юл сабар...
Тик берсе дә,
Тик берсе дә мина
Сөйләмәде
Синдәй кыйссалар...

## Көз шул...

*Резедага*

Көз бит, дисең, шуңа гына шулай.
Таш йортларга суык үрмәли...
Әллә нинди авыр уйлар йөри
Тибәр-типмәс йөрәк тирәли.

Көз шул, димен, ә калганы үтәр,
Бу әрнүләр үтәр — бездән дә.
Без күнектек инде җан туңганда
Елышырга бары... сүзләргә...

Үткәннәргә борылып карамаска,
Сорауларга җавап тапмаска.
Һәм карусыз гына елмаерга —
Ызаныңны ятлар таптаса...

Сагынмаска... Хәтта танымаска
Кадерсезгә калган ярларны...
Көз бит, дисең...
Шуңа гына булмый
Хакыйкатьтән аерып ялганны...

Көз шул, димен, ә калганы үтәр,
Дөньяныкы үтәр — бездән дә.
Без күнектек инде җан туңганда
Елышырга бары... сүзләргә.



Замандашлар. Үткән гасырның 50нче еллары истәлеге.
Сулдан уңга: Әнвәр Давыдов, Габдрахман Әпсәләмов, Зәки Нури,
Гайнан Әмири (Уфа), Гази Кашшаф.



Халик Садри (1890-1955) — гражданнар һәм Ватан сугышында катнашкан язучы. Самара. 1918 ел.



Үткән гасырда Татарстан язучылар берлегендә әдәбиятны пропагандалау бүлеге эшли иде.
Һәр елны даими рәвештә төрле залларда «Казан язы» дип аталган
әдәби-музыкаль кичәләр уздырылды. Шул кичәләрнең берсендә төшерелгән рәсем.
Уңнан сулга: Рәдиф Гаташ, Рашат Низами, Нәби Дәүли, Рәфкать Кәрами,
Гариф Ахунов, Госман Садә, Илгизәр Фазлуллин. 1985 ел.



*Төрле елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә эшләгән шагыйрьләр. Уңнан сулга: Рәшат Низами, Нури Арсланов, Мөдәррис Вәлиев. 1982 ел.*



*Ватан сугышында һәлак булган Хәлимов Нәҗметдиннең улы — күренекле әдип Айдар Хәлим Волгоградтагы Мамай курганында. 2010 ел.*



*«Казан утлары» журналының 70 еллык юбилей бәйрәме Г.Камал исемендәге театрда зур тантана белән үтте. Залдагы урыннарга сыймаган тамашачылар йөрү рәтендәге баскычларга кадәр сырылып утырдылар. 1992 ел.*

*Шамил Закировның тууына 70 ел*

# ДИРЕКТОР

*Кайсы болыннарның исен*
*Китердең, җил, бу кичне?*
*Ул сине ишетмәс инде –*
*Ут сүнде, пәрдә төште.*



Шамил Закировның җәсәден театрдан алып чыкканда, яшь артистлар юлга кызыл гөлләр сибеп барды. Талгын музыка урамга саркып чыкты. Әллә соң ул минем колакка гына ишетелдеме? Мәрәсимгә килгән йөзләрчә кеше тулуга карамастан, театр буш иде. Мәет чыккан йорттай шыксыз иде ул. Бу чагыштыру түгел — чыннан да театр өч дистә елга якын мәрхүмнең төп йорты булды бит. Өенә ул кунарга гына кайта иде булса кирәк.

Мин аның белән беренче тапкыр 1983 елның кара көзендә Чаллыда күрештем. Туфан Миннуллин җитәкләгән язучылар десантына — ул елларда әдәбиятта хәрби терминнар бик модада иде — мине дә ияртteләр нигәдер. Автогигантның бер цехында, аннары китапханәдә узган берничә очрашуны хәтерлим. Ул заманда китап укучылар шактый иде әле, тирә-яктан шәһәргә килгән татарлар тамырдан бөтенләй аерылып бетмәгән — аерым әсәрләр хакында сорау бирүчеләр дә булды. Мин Чаллыда беренче мәртәбә — бөтен илгә даны шаулаган каланы кызыксынып карап йөрим, тик карашым бетон диварларга бәрелеп сынып китә, кая карама — соры бертөслелек. Шагыйрьләр монда ничек яши? Коточкыч күнелсез шәһәр. Тамырсыз. Гомум сорылыкны яшерергә теләпме, адым саен димәсән, йорт сыртларына кызыл хәрефләр белән лозунг-шигарьләр язып элгәннәр. Әлбәттә, алар барысы да урысча. Коммунизмга тагын нинди телдә чакырасың?! Татар теле монда яраксыз. Матбугат йорты янәшәсендәге партия архивы урнашкан йортның кашагасына «СССР халыкларына дан!» дип язып элгәннәр иде әнә... Даны еракка китте. Татар ул шигарьне укып рәхәтләнде инде: СССР халыклары надан! Монда, Чаллыда, ике лозунгның берсе «Ты должен...» дип башлана иде. Бармагын төртеп фронтка чакырамыни! «Я никому не должен!» — диде Равил Фәйзуллин. Язучыларның партоешма башлыгы Туфан Миңнуллин шаркылдап көлде. Ошатты.

Юкка көлгәндер ул. Без анадан ук дәүләткә бурычлы, тиеш булып тудык. Ата-бабалар ул бурычны ач-ялангач интегеп бушка эшләсә дә, совет империясе өчен сугышларда һәлак булса да, нахак бәла белән төрмәләрдә интексә дә, түләп бетерә алмаган, безгә дә калган. Тик хәзер беркем дә бернинди «бурыч» түләргә теләми иде инде. Системаның шөрепләре кыршылган иде. Ләкин хокуклар турында сүз юк әле. Һельсинки килешүләре безнең өчен әкияткә тиң. Нинди хокук?! «Кеше хокуклары» дигән төшенчә үзе үк крамола. Аннан инде диссидентлыкка да ерак калмый. «Милләт хокуклары» дигәне аның бүген дә колакка ят яңгырый. Нинди милләт бит! Чөнки «милли хокуклар» дигәч үк, «үзбилгеләнү хокукы» искә төшә. Ә андый хокукны беркем дә беркемгә бирергә җыенмый. Аны яулап кына алып була.

Татар язучылары арасында ул елларда диссидентлар юк иде, тик үзен совет дәүләте хакына нидер тиеш дип санаучылар да күп булмагандыр. Тиеш дип санамый, әмма кушканны хәлдән килгәнчә үти.

Шагыйрь үзен беркемгә берни тиеш түгел дип саный икән... ул шулай саный, димәк. Холыкка, тәрбиягә бәйле. Бәлки кеше рухынын тәмам азат булуы шуннан башланадыр. Яшен кебек ялгыз, галәм сыман салкын, ажаган күк кысыр? Белмим. Расистлар тарафыннан үтерелгән Мартин Лютер Кингнын кабере ташына: «Азат, ниһаять, азат», — дип язып куйганнар, имеш. Теге дөньяда гына беркемгә дә тиеш булмыйсын.

Шамил Закиров исә үзен һәркемгә бурычлы, һәркемгә нидер тиеш дип саный иде. Анын яшәү мәгънәсе шул, ул шунын белән бәхетле. Күнелендә китаби коммунизм догмалары белән ислам фәлсәфәсе бергә укмашкан, күкрәгендә шул тибә. Гореф-гадәт белән канына сенгән сонгысын ул үзе дә сизмәгәндер әле, анысы сонрак бәреп чыгачак, ул елларда исә Шамил Закиров идеаль коммунист иде.

Менә шул... Чаллыга килеп төшүгә, безне уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, саргылт йөзле, житди чырайлы бер ир-егет каршы алды. Аягында резин итек, инендә... кожанка дип әйтәсе килә хәзер, портрет хатирәләргә тәнгәл булсын өчен... юк, ул замандагы гаять модный болони плащ иде кебек өстендә. Чаллы башкарма комитетынын культура бүлеге мөдире, диделәр. Чиновник. Мин, билгеле, аларнын иерархиясен бик белеп бетермим. Тик Туфан абый кочаклап алгач, әлеге кешенен юк-бар бәндә түгел икәнен тиз анладым.

Чиновникнын резин итек киюе дә тиздән анлашылды, Чаллы әле ул елларда асфальт белән тәмам томаланып житмәгән иде.

Вокзалдан тиз генә чыгып китә алмадык. Безне каршы алучы түрәнен (бигрәкләр дә без күз алдына китергән, без күнеккән түрәгә охшамаган инде!) танышлары хәйран күп булып чыкты. Бер-ике адым атлауга, әле берсе, әле икенчесе килеп күрешә:

— Шамил Зиннурович!

— Шамил Зиннурович...

— Шамил әзи?

Ниһаять, пычрак ерып, көч-хәл белән кызыл трамвайга таба киттек. Кызыл булуына карамастан, трамвай шәһәргә бердәнбер ямь бирүче нәмәрсәкәй иде, һәм безне күндәм генә шәһәр идарәсенә илтеп куйды.

Шамил Закиров, мәдәният әһеленнән бигрәк, төзелеш прорабы сыман кыяфәте белән күз алдында калган.

Хәзер, үзе үлгәннән сон берара вакыт үткәч, анын гомер юлын күз алдына китерсән, кылган гамәлләрен барласан, инанасын — ул чыннан да прораб булган икән! А.Вознесенскийнын «прорабы духа» дигән тәгъбире бар: «Художнический характер, проявившись не профессионально, а в деятельности ради искусства, часто создает своё в искусстве через других. Не будь помощи таких людей — не появился бы шедевр. Это подвижники, двигатели культуры, поршни духовного процесса, строители надстройки, общественники культуры — я бы назвал их «прорабами духа».

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенен Гаяз Исхакый исемендәге мәртәбәле премиясенә 2008 елда Шамил Закиров та лаек булды. Галәттә, бу бүләкне ижаты ижтимагый тормышка сизелерлек тәэсир иткән каләм әһелләренә бирәләр. Дәгъвачылар күп. Аеруча әдәбият тирәсендә булашучылар һәр премия тирәсендә әвәрә килүчән. Нәкъ менә шул премияләр биргәндә, алар гаделсезлекнен ин югары ноктасын күрәләр. Әмма язучы булмаган Шамил Закировка — мәшһүр Исхакый исемендәге! — премияне тапшыру бераүдә дә ризасызлык уятмады, киресенчә, әлеге тантананы мәгънәлерәк, бүләкне исә тагын да эчтәлеклерәк итте. Ул ана чын-чынлап лаек иде. Исхакый әсәрләрен театр сәхнәсенә күтәрү өчен күп көч куйган житәкче буларак та, әдипнен туган авылында уза торган «Исхакый укулары»н оештыручы буларак та... «Кызыл Байрак»ка — Сәйдәштанга барып, сәнгать бәйрәме үткәрү, төрки театрларнын «Нәүрүз» фестивален гамәлгә кую — барысында да Шамил Закиров башлап йөрде, төпкә жигелеп тартты. Хәбәрдарлар белә: Татар жәмәгатьчелеге өчен Шамил әфәнде, затлы театрыбызнын директоры булу өстенә, зур хәрефләр белән язарлык Милләтпәрвәр иде. Халкыбызнын барлык



*Камал театры коллективы ял вакытында*

гамен йөрәге аша үткәреп, олылыгын да, кимлеген дә күңеленнән кичереп яшәде ул. Юк, аның янгыравыклы авазы меңләгән халык өстендә трибуналардан канат какмады, ул көр тавыш белән беркемне дә азатлыкка чакырмады, хәленнән килгәнчә, һәм хәтта килмәгәндә дә, милләт йомышының зурысына, кечесенә карамыйча, үҗәтләнеп, ул хәрәкәт итте, эш башкарды, ярдәмгә мохтаҗ һәр милләт баласына булышырга тырышты. Милләтне ярату — тыймаганда! — җиңел, аерым кешене якын итү кыенрак. Ул азатлыкка чакырмады, чөнки иң әүвәл һәркем Аны үз күңелендә табарга тиешлекне белә иде. Күпчелеккә милли азатлык түгел, тук тормыш зарур, нишлисең, аяусыз дөреслек шул...

Әлбәттә, Шамил Закиров кебек «рух прорабы» булыр өчен, татар моңын, татар гамен тумыштан ук ана сөте белән канга сеңдерү кирәктер. Туган авылы Нарат-Елгада ук инде ул үзешчән сәнгать түгәрәгенә оештыра. Клубта «күңелле кичәләр» үткәрә. Менә шул елларда чыккан район гәҗитеннән хәбәр: «Концертта чыгыш ясаучы мәзәк һәм нәфис сүзле, биюче һәм җырчы Шамил Закировны колхозчылар көчле кул чабулар белән алкышлады».

Мәктәпне «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлагач, сәнгатькә гашыйк яшүсмер Казан химия-технология институтына укырга керә (аякта нык басып торырлык һөнәр кирәк, дигән әтисе!). Һәм... институт Казандагы аз санлы татар сәнгате учакларының берсенә әверелә. «Татарстан яшьләре» гәҗитенең 1968 ел, 18 апрель саны, Роберт Батуллин яза: «Программада язылмаса да, концертның режиссёры IV курс студенты Шамил Закиров икәнен белдем. Ул — бөтен концертны җанландыручы, оештыручы, номерны номерга тоташтыручы, үзе язган репризаларны оста башкаручы! Шамил, кирәк булса, җырлап та, биеп тә ала. Драмалардан өзекләр уйнап та шыгрым тулы залның иң яраткан артистына әверелә».

Ул гына да түгел, институтның «Кировец» дигән, урыс телендә чыга торган гәҗитендә аның татарча шигырьләре дөнья күрә. Минем өчен бу бик соң килеп ирешкән яналык булды — Шамил Закиров шигырьләр язган!

*Җыр гомере — кош гомере, диләр...*
*Дөрес, кошлар оча югары, —*
*Ләкин алар җиргә егылып төшә.*
*Җырның егылганы юк әле.*

*Ялкыны юк утның күмерсез,*
*Җырдан башка яшәү күңелсез.*
*Халык җыры гүя — төпсез диңгез,*
*Җырлый белгән халык — үлемсез.*

Шамил Закиров сыман татар сәнгате өчен жанын бирергә әзер (һәм бирде дә!) мәдәният әһеле, фидакяр житәкче безнең бу фәкать акчага корылган прагматик җәмгыятьтә кабат булырмы икән? Кистереп әйтүе кыен. Ләкин ул бар иде бит... Аның булуы, безнең арада яшәп китүе татар мәдәниятенең киләчәгенә өмет уята.

Ул аягүрә килеш китеп барды. Әллә ул да, шагыйрь сыман, ин ихлас теләгән кайчандыр ачык күк капусына күндергән иде микән:

*Дөнья бездән генә калмаган ул,*
*Берчак килер үлем — ятсынмас.*
*Аусам иде шулчак, бәйгеләрдә*
*Йөрәге ярылып үлгән ат сыман.*

Мостай Кәрим.

Бервакыт мин аны яшь рәссамнарның күргәзмәсендә очраттым. Ул бер картинаны сатып алырга җыена иде. «Әлләни түгел бит», — дип шигемне белдергәч, ул күзен кысып елмайды: «Зарар юк, — диде. — Рәссамының матди хәле бик мөшкел. Ярдәм итәргә кирәк. Күңеле дә күтәрелер».

Ул ниндидер ярдәм өмет итеп, нидер сорап килгән кешеләргә юк дип җавап бирә белми иде, ахрысы. Татар авазын авыздан чыгара алган һәр кешегә ул үзен тиешле дип санады. Кан кардәш буларак, телдәш буларак. Әлбәттә, андый чакта хәсетле кешеләр дә табыла, алданганын сизсә, ул аларга чын күңелдән, сабыйларча рәнжи иде.

Шулай да аның ярдәменә чын-чынлап мохтаҗ кешеләр — күпчелек, үтенечне ишеткәч, ул калын дәфтәрен актара башлый. Анда нинди генә телефон номерлары юк! Шәймиевтән алып авылдагы умартачы Шәяхмәткә кадәр...

Кешеләргә ярдәм итә алуына ул сөенә, шуңа кинәнеп яши иде. Бу яктан ул бәхетле булды.

Дошманнары булдымы икән аның? Булгандыр. Дөньяда атлап йөрүеңне дә тиктомалдан дошман күрүчеләр азмыни җир йөзендә?! Ләкин аларга Шамил Закировның мөнәсәбәте Мөдәррис Әгъләмчәрәк иде: «Тукай гүре туфрагында дошманнарым юк минем!»

Илле яшем тулган көндә, Камал театрындагы әдәби-музыкаль кичәдән соң, мин аны аш мәҗлесенә чакырдым. «Кәефем китеп тора, бара алмамдыр», — диде ул. «Кешеләр дөрес аңламас, — дидем мин, шаяртыбрак. — Дус бар, дошман бар, унбиш минутка гына булса да кереп чыгыгыз». Ул килде, Батулла агай белән янәшә утырды. Тамада (үзе әйтмешли, тәгам агасы, ул минем туйда да бу җаваплы вазифаны үтәгән иде) Батулла аңа беренчеләрдән булып сүз бирде. Юбилеенда, җеназасында кешене (яки инде мәрхүмне) мактыйлар, табигый. Минем бит юбилей — рәхәтләнеп тыңладым.

Шушы бәйрәмдә соңгы күрешүебез булган икән, мина аның турындагы җылы сүзне җеназасында әйтергә туры килде. Ишеттеме икән? Ишеткәндер, шуңа бик тә ышанасы килә.

Җеназада театр халык белән шыплап тулган иде. Халык Шамил Закиров белән бәхилләшергә килгән. Менә гаҗәпләнгән бер олы гына түрә: «Юкса директор гына иде бит», — дип әйтеп куйды. Хәер, олы булдымы икән ул? Чиновниклар иерархиясен минем хәзер дә төгәл генә аныклап бетергәнем юк. Шуны гына әйтә алам: Шамил Закиров директор иде! Татар театры директоры аның сыман шундый рух прорабы булырга тиеш тә.

Иң гыйбрәтлесе — халык ул көнне җеназадан кемне югалтуын аңлап китте. Яңа бистә зиратында җанга якын тагын бер калкулык калды.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# ФӘРИТ ЯРУЛЛИН ҺӘМ АНЫҢ ДАИРӘСЕ



Искиткеч талантлы композитор Фәрит Яруллинга багышлап язылган әдәбият шактый. Әмма әлегәчә аның шәхесенә бәйле сорауларга җавап юк диярлек. Әтисе, талантлы музыкант һәм композитор Заһидулла Яруллинның тормышы турында да мәгълүмат бик аз. Ата-анасы ничек тәрбияләгән, кемнәр дус, кемнәр көндәш — берсе дә ачык түгел. Бу мәкаләдә шушы сорауларга тукталасым килә.

Ярулла улы Заһидулла Яруллин 1888 елның 12 октябрендә Мамадыш районының Кече Сөн авылында крестьян гаиләсендә туа. Заһидуллага бары биш кенә яшь булганда әтисе дә, әнисе дә вафат булалар. Балачагы һәм яшьлеге авырлыкта, мохтаҗлыкта уза. Әти-әнисенең үлеменнән соң Заһидулла беркадәр вакыт туганнары тәрбиясендә яши, аннан соң бер Чистай баена савыт-саба юарга керә. Тик бу гаиләдә озак яшәргә туры килми. Көннәрдән бер көнне Заһидулла хуҗаның яраткан этенең аягын имгәтә. Ачуы чыккан хуҗа малайны урамга куып чыгара. Аны уен кораллары көйләүче немец И.Шнейдер үзенә сыендыра. И.Шнейдер малайның музыкага сәләтле булуына игътибар итә. Заһидулла инде авылда чагында ук курайда уйный торган була. Шнейдер аны фортепианога, шулай ук музыка коралларын көйләргә өйрәтә. Заһидулла нотага өйрәнә, аз-азлап төрле уен коралларында музыка күнекмәләрен үзләштерә. Тик бу бәхетле көннәр озакка сузылмый. И.Шнейдер кисәк кенә үлеп китә һәм Заһидулла янә сыеныр урынсыз кала. Эш хакы эзләп мохтаҗлыкта бер урыннан икенче урынга күчеп йөрү чоры башлана. Ул йә аш таратучы хезмәтче, йә ресторанда музыка уйнаучы булып эшли. Аны Түбән Чаллыда да, Минзәләдә дә, Түбән Новгородның Мәкәрҗә ярминкәсендә дә күрергә мөмкин була. Инкыйлабны ул 1905 елны Уфа шәһәрендә каршы ала. Ә 1907 елда Казанга килә. Аның тормышында яна һәм якты чор башлана. Заһидулла Яруллин турында «Курайчы малай» дигән китапчыгында М.Латыйфуллин менә ниләр яза: «Иске Казанның кеше ин күп йөри торган Печән базарына эләккән Заһидулла шәһәрдәге эш урыннары турында ишетә. Рестораннарның берсенә пианист булып урнаша. Әмма анда озак эшләми. Көннәрнең берендә музыкантның эшләгән акчасын хуҗаның үзләштерүе сәбәпле, Заһидулла белән хуҗа арасында тавыш чыга. Сөйкемле, яшь кенә бер кеше пианистны якларга тырыша. Ул «Сәйяр» труппасы актёры һәм режиссёры Габдулла Кариев булып чыга. Заһидулланың кунарга урыны булмавын ишеткән Кариев аны «Болгар» кунакханәсенең бер номерында яшәп яткан дустына алып килә. Ул Г.Кариевның дусты атаклы Габдулла Тукай була. Гасыр башындагы әдәбият һәм сәнгатьнең ике атаклы вәкиле — Г.Тукай һәм Г.Кариев белән узган кич З.Яруллинның тормышында иң якты көннәрнең берсе булып хәтерендә кала. Төн авышканчыга кадәр сөйләшеп чыга алар. Заһидулланың курайда уйнавын тыңлыйлар. Ә икенче көнне дуслары аны пианист-иллюстратор сыйфатында «Свет» кинотеатры хуҗасына тәкъдим итәләр»[1]. Китапта булган вакыйгалар әдәби уйдырмалар белән үрелеп бара. Әмма китапта, дөрестән дә, музыкантның алдынгы татар зыялылары белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы сурәтләнә. Г.Тукай З.Яруллинны яхшы белә, еш кына аның уйнаганын тыңлый, музыкант буларак аны югары

[1] Латыйфуллин М. Курайчы малай. — Казан, 1966. — 26-27 б.

бәяли. Алар икесе дә «Шәрык» клубы оештырган әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашалар. Аралашу өчен, үзара якын бәйләнешкә кереп берләшкән кешеләрнең уртак даирәләре була. Заһидулла Яруллин инкыйлабка кадәрге Казанда милли сәнгать культурасының күренекле вәкилләренең берсенә әйләнә. «1915 елның 10 апрелендә, — дип язылган шул чордан сакланып калынган афишаларның берсендә, — «Ашказар», «Гөлчәчәк», «Зиләйлүк», «Урам көе», «Эскадрон», «Баламишкин», «Сакмар», «Русча марш», «Тукай көе» һәм башка җырларны Г.Козлов скрипкада, З.Яруллин пианинода башкаруында кичә уздырыла. Ахырдан, укучылар көче белән, Кавказ биюләре башкарыла. Кичә ярлылар файдасына уздырыла».

1912 елда Заһидулла өйләнә. Хатыны Нәгыймә (тулы гәүдәле, алсу янаклы, уртага аерылган озын кара чәчле) Лаеш районының Хәерби авылында туган. Ул иртә ятим калган, белеме юк, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә, яхшы җырлый. Көннәрдән бер көнне, 1914 елда, гаиләдә Фәрит атлы малай барлыкка килә. (Композиторның гаиләсе белән якыннанрак танышу теләге белән бу мәкаләнең авторы берничә мәртәбә анасы Нәгыймәнең Лаеш районындагы Хәерби авылына барып кайта.) Туганнан туган абыйсы Гарифулла Ярмиев менә ниләр сөйли: «Заһидулла Һади Такташ урамындагы зур гына йортның бер бүлмәсендә яши. Ул буддыклы, аз сүзле кеше иде. Кечкенә бүлмәсендә гармун йә думбра, йә нәрсә дә булса төзәтеп утыра. Техникага яхшы төшенеп, казынып утырырга ярата. Хатыны хуҗалык эшләрен алып бара. Өйдә өр-яңа рояль тора. Укучылары өйгә дә килә, Заһидулла аларны фортепианода уйнарга өйрәтә. Кайчак артист дуслары керә, уен коралларын сынап карыйлар. Ә кайчакны Заһидулла нинди дә булса көйне онытып җибәргән булса, исенә төшерергә хатынын ярдәмгә чакыра. Хатыны киң күңелле, тулы гәүдәле, сөйкемле иде. Гаиләнең матди хәле шактый җитешле, әмма Заһидулла балалары булмауга уфтана. Хатыны эндәшми, әмма ул да бала булуын бик тели. Шулай бервакыт ул мунчага бара һәм шунда бер хатын белән сөйләшеп китә. Бу хатын мунчага юынырга улы белән килгән була. Беләк буе малай шундый тулы, йомры, карап туйгысыз бала була. Бу хатын үзенең күптән түгел бала табуын, ялгыз яшәвен, тормышының бик авыр булуын, нишләргә дә белмәвен сөйли. Балалар яраткан Нәгыймә баланы тотып торырга сорый, юындырырга булыша, соңыннан исә баланы үзенә алырга ризалашалар. Гаиләдә ир бала булу шатлыгының иге-чиге булмый. Ана белән ата бала өчен җаннарын да җәлләми. Малай матур һәм нык, сәламәт булып үсә. Килгән бар кеше аның матурлыгына, акыллы күзләренә соклана. Әмма бәхетле көннәр озакка сузылмый. Гаиләдә торган саен тавыш-талаш чыга. Шундый көннәрнең берсендә Заһидулла Фәритне алып Уфага китә»[2].

1923 елда Уфага килгәч, Фәрит Яруллинның музыка белән махсус шөгыльләнү чоры башлана. Атасы улының музыкага мәхәббәтен, искиткеч сәләтен күреп, аны нота грамотасына өйрәтә башлый. Әмма ана игътибарын һәм күп вакытын бағларга мөмкинлеге булмый. Фәрит атасы өйрәтүе буенча күбрәк үзлегеннән шөгыльләнә. «Миңа аның белән күп шөгыльләнергә туры килмәде, — дип искә ала соңыннан Заһидулла. — Күп вакыт эш белән мәшгуль идем, кинода, ресторанда эшләдем. Фәрит мәктәптә укыды. Аның ишетү сәләте искиткеч иде. Ул һәрвакыт тирә-юньдәге һәртөрле авазларны ишетә, музыка тәэсирен тотып ала белә, импровизация ясарга сәләтле иде»[3]. Малай музыка мохитендә үсә, халык җырларын балачактан үзенә сеңдерә. Шул рәвешле ишетү сәләте, музыкага тартылыш көче үсә. Гаилә Никольская урамында (хәзер М.Гафури урамы) фатирда тора. Ерак түгел генә Фәрит укыган менә дигән беренче татар-башкорт мәктәбе. Фәритнең шул еллардагы тормышын күзалларга безгә замандашларының хатирәләре ярдәм итә. Сабакташы Шәүкәт Мәсәгутов истәлеге: «Ул таза гәүдәле, аксыл, маңгай өстендә калдырылган чәчле, үзенең классташларыннан яшь ярымга өлкән малай иде. Тыныч һәм аз сүзле, башкалар кебек коридорда чабып йөрми. Классташларының ручкалары, карандашлары, дәреслекләре һәм дәфтәрләре портфельгә салынган булса, Фәрит исә кесәсеннән карандаш кисәге чыгарып, аерым кәгазь кисәгенә генә яза. Дәрес хәзерләүгә аз игътибар итә, әмма сәләтле булуы белән өлгереп бара, артка

---

[2] 1974 елның җәендә Гарифулла Ярмиев белән сөйләшүдән.
[3] Атасының хаты сәнгать фәннәре кандидаты Ч.Бәхтиярова архивында саклана.

калучылардан саналмый. Мәктәптә укучылар көче белән татар спектакльләре куела. Залда пианино тора, балалар еш кына төркемнәре белән залга йөгерешеп керәләр, ә Фәрит импровизация ясый, халык көйләрен уйный. Безнен күбебезгә бу беренче тапкыр музыка тәэсирен тою иде»[4].

Шуны да әйтеп үтү кирәк: шактый мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре бу мәктәптән чыкканнар. Алар арасында иң әүвәл композитор Ф.Яруллин, балетмейстер Ф.Гаскәров, язучы Ә.Фәйзи һәм Р.Саттар, артистка З.Бикбулатова, рәссам Р.Гомәр исемнәрен атап була. Мәктәптә язучы Н.Исәнбәт укыта. «Безгә дәрес хәзерләргә килгәч, — дип искә ала классташы Х.Гобәйдуллин, — Фәрит дәресен ахырга кадәр хәзерләми иде. Гадәттә фортепиано артына утыра һәм уйный башлый. Ә шәһәргә Сагайдачный оперетта труппасы килгәч, Фәрит аның спектакльләренең берсен дә калдырмыйча карап бара, икенче көнне ишеткән көйләрен уйный башлый. Бу аның зур талантка ия булуын күрсәтә»[5]. Шулай ук 1926 елда Фәритнең фортепианода яхшы уйнавын атасы да искә ала. Аны музыка торган саен ныграк үзенә җәлеп итә бара һәм аның белән житди шөгыльләнү теләге туа. 1930 елда Фәрит атасы белән янадан Казанга кайта, Казан музыка техникумына укырга керә. Фәрит Яруллин тормышында яңа чор — профессиональ белем үзләштерү чоры башлана. Заһидулла Мамадышка, ә аннан соң туган авылы Кече Сөнгә кайтып китә һәм шунда икенче мәртәбә өйләнә. Яна гаиләдә уллары, җырлар, романслар, скрипка өчен концерт, балалар өчен сюита, 7 өлештән торган татарча беренче «Кеше» ораториясе авторы һәм башка күп әсәрләр язучы, танылган музыкант, педагог һәм композитор Мирсәет туа. Бу 1938 елда Фәритнең авылга атасын күрергә кайткан соңгы елы була. Шунсы кызык: туганнар янадан беркайчан да күрешмиләр.

Фәрит Яруллин Р.Л.Поляковның виолончель классына укырга керә. Ел буена тырышып уйнарга өйрәнә һәм тиздән оркестрда уйный башлый. Әмма яраткан уен коралы — фортепиано һаман үзенә тартып тора. М.А.Пятницкая фортепианода уйнавына, талантлы импровизацияләренә игътибар итә һәм аны үз классына чакыра. Шул рәвешле, тиздән Ф.Яруллин ике бүлектә дә укый башлый. Моңа кадәр күрелмәгән дөньяны ачкан классик музыканы өйрәнү Фәритнең алга таба үсешендә әһәмиятле урын тота. Яшь музыкант күп һәм тырышып укый, һәр яңалыкны тиз тотып ала, музыкага караган вакыйгалар эчендә кайный. Замандашлары булачак композиторның сәләтлелеген, кызыксынучанлыгын, эчке тәрбиясен, бәясен яхшы белүен искә төшерәләр. Үзенең хатирәләрендә М.А.Пятницкая аңа тулы бәяләмәне болай бирә: «Искиткеч музыкаль, техникумда уку еллары аңа фортепианода уйнау осталыгы биргән, ижатка омтылышы көчле. Менә дигән эчке дөньясы бар, вазифаларына житди карый, үзен горур тота, шул ук вакытта кешеләр белән мөнәсәбәтендә ихласлык күренеп тора. Зур ышаныч-өметләр уята. Музыкаль булуы гына түгел, ә тәрбиясе белән дә аерылып тора. Һәрвакыт инсафлы, кызыксынучан»[6].

Фәрит үз көнен үзе бик иртә күрә башлый. Табигате белән нечкә күңелле егет гаиләдәге чуалчыкны авыр кичерә. Анарда үз эченә бикләнү, балаларга хас булмаган житдилек иртә уяна. Тирән уйланулар тормышны үзләштерергә зирәклек бирә, төпле фикер йөртергә ярдәм итә. «Аз сүзле, күзәтүчән, уйчан, үз эченә бикләнгән» — замандашы З.Хәйруллина аны шундый итеп хәтерендә калдырган. «Фәритне бик тыйнак һәм аз сүзле итеп беләм, — дип белдерә икенче замандашы Г.Х.Таһиров та. — Күбрәк башкаларны тыңлый, ә инде әңгәмәгә кушылырга туры килгәндә, аз сүз белән акыллы итеп, үз сүзен әйтә»[7]. Таныш булмаган кешеләр янында аралашмый торган булып күренсә, якын дуслары янында исә ул шат, ярдәмчел, үзен иркен тота. «Мөлаем, киң күңелле, риясыз, табигатьтән аңа тәнкыйтьчел акыл, юмор хисе бирелгән», — гобойчы М.Батталов аны әнә шундый итеп искә ала. Ата-аналары килеп киткән чакларда да Фәрит беркайчан бернәрсә сорамый. «Ашау-эчүгә, киемгә битараф иде, — дип искә төшерә З.Хәйруллина. — Әмма көндәлек тормыш кирәк-ярагына игътибарсыз булса да, музыка дөньясында исә үзгәреп, бөтенләй яктыра.

[4] Башкорт радиосының музыка редакторы Ш.Мәсәгутов белән сөйләшүдән.
[5] Сәнгать фәннәре кандидаты, театр белгече Х.Гобәйдуллин белән сөйләшүдән.
[6] Ч.Бәхтиярованың шәхси архивыннан.
[7] «Казан утлары», 1984, №1, 173-177 б.



*Фәрит Яруллин (уңнан беренче) сугышчан дуслары белән. 1941 ел.*

Карап торырга басынкы, салмак кебек күренгән кеше чынлыкта дәртле, кайнар йөрәкле, максатчан омтылышлы»[8].

Фәрит Школьный тыкрыгындагы музыка техникумының тулай торагында яши. Н.Жиһанов, З.Хәбибуллин, Х.Гобәйдуллин, Х.Батыршин, М.Батталов һәм башкалар да шунда. Композитор З.Хәбибуллин ул вакытларны шулай исенә төшерә: «Авыр вакытлар. Аена 4 сум бирелгән стипендия акчасына гына яшибез. Еш кына үзебездән ерак түгел ломбардка әйберләребезне закладка салабыз. Утын житми, кышкы суыктан савытындагы кара өши. Бүлмә жылытылмый диярлек. Тик егетләр күнелләрен төшермиләр. Сәгать алтыда А.А.Литвинов тулай торакка кереп, барыбызны да уятып, дәрескә жибәрә. Төп һөнәри белем бирү дәресеннән тыш яраткан дәресебез — оркестр классы. Ул атнага ике мәртәбә үткәрелә һәм без аны түземсезлек белән көтеп алабыз. Күбебез биредә беренче мәртәбә Гайдн, Моцарт, Бетховен, Римский-Корсаков әсәрләрен ишеттек. Чайковскийның дүртенче симфониясе аеруча көчле тәэсир итте. Классик гүзәл әсәрләрне үзен башкарып карау әйтеп бетергесез өйрәнү мәктәбе булды. Еллар узды, әмма безгә музыка тәэсиренең көчен төшендергән остазны, оркестр классы буенча педагог А.Литвиновны, күп укучылары хәзерге көнгә кадәр рәхмәт хисләре белән искә алалар»[9].

Иртәдән техникумда дәресләр, төштән соң егетләр еш кына радиокомитетта булалар, жырчыларга уйнарга концертларда катнашалар. Аккомпанементны Фәрит үзе чыгара. Ул вакытта ноталар булмый. Мондый импровизацияләрне атасыннан күп ишеткән Яруллин гармунлаштырылган көйне фортепианога салганда үзенчәлекле итәргә тырыша, аңа ижади килә.

Бу турыда композитор Ю.В.Виноградов болай дип сөйли: «Бервакыт мин мөлаем, бер яшь егетнең жырчыга уйнаганын ишеттем. Шунда ук гадәти булмаган аһәнлелек куллануына игътибар иттем. Аның уены үзенчәләштерелгән булуы һәм импрессион аһәнлелеге белән аерылып тора иде»[10].

Замандашлары Яруллинның завод каршындагы эшче яшьләр театрында (ТРАМ) инструменталь триода виолончель партиясен башкаруын хәтерлиләр. ТРАМ спектакльләрендә сатирик эчтәлекле темалар күтәрелә. Триода Н.Жиһанов (фортепиано), Х.Батыршин (флейта), Ф.Яруллин (виолончель) уйный. Х.Батыршин көй материалы бирә, ә Жиһанов белән Яруллин аны уйнарга яраклаштыралар. Бу ижади тәжрибәләрне алар бик мавыгып үткәрәләр.

Ф.Яруллин техникумда укыганда, музыкаль белем бирүгә бәйле үзгәрешләр килеп чыга. Музыка техникумы, театр һәм сәнгать училищесы белән берләшеп, бер уку йортына әйләнә. Төп максат — профессиональ музыкантлар үстерү түгел, ә уеннар оештыручы — инструкторлар әзерләүгә кайтып кала. Хорда жырлауга, клуб эшен, халык уен коралларын өйрәнүгә игътибар ителә. Махсус класслар кыскартыла. Мондый үзгәртүләр үзенең нәтижәсен озак көттерми. Укучыларның саны кими, кайбер тәжрибәле укытучылар техникумнан эштән китә. Талантлы яшьләр — булачак композиторлар А.Ключарёв, М.Мозаффаров, Н.Жиһанов Мәскәүгә күчә. Алар артыннан 1933-1934 елларда Ф.Яруллин, З.Хәбибуллин да. Икесе дә Мәскәү консерваториясе каршындагы рабфакка, ә рабфак ябылганнан соң, Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясенә укырга керәләр.

[8] Музыкантлар белән сөйләшүдән.
[9] Композитор З.Хәбибуллин белән шәхси сөйләшүдән.
[10] Ю.В.Виноградов белән шәхси сөйләшүдән.



*Фәрит Яруллинның хатыны Галина Сачек-Яруллина «Русалка» операсында. 1937 ел.*

Утызынчы елларның икенче яртысы — күпмилләтле совет культурасы тарихында әһәмиятле этап. Мәскәү консерваториясе каршында биш милли студия ачыла (татар, башкорт, төрекмән, казакъ һәм үзбәк). Максат — милли музыкаль театрларга профессиональ кадрлар әзерләү. Нигездә, җырчылар һәм инструментларда уйнаучылар күздә тотыла. Соңрак бу опера студияләре композиторлар да әзерли башлый. Студияне тәмамлаган җырчылар төркеме — С.Садыйкова, С.Айдаров, М.Рахманкулова, А.Измайлова, Г.Кайбицкая, М.Булатова, Ф.Насретдинов һәм башкалар. Алар Татар дәүләт опера театрының үзәге булдылар. Репертуар эшенә композиторлар С.Сәйдәшев, З.Хәбибуллин, Ф.Яруллин, Ж.Фәйзи, ә либретто язарга шагыйрь һәм язучылар М.Җәлил, Ә.Ерикәй, Ә.Фәйзи, М.Максуд һәм башкалар җәлеп ителә. М.Максуд «Кара йөзләр», М.Җәлил «Алтынчәч», Ә.Фәйзи «Шүрәле» либреттосын язарга керешәләр. Советлар Союзының Зур театры каршындагы әлеге студия балет труппасы һәм хореография училищесы артистлары турында кайгыртуны да үз өстенә ала. Аларны тәмамлаучылар — З.Гайфуллина, Л.Ласточкина, Г.Таһиров, Ш.Байдәүләтов укуларын тәмамлап, Татар опера театрына эшкә кайталар. ТАССР халык комиссарлары советы, студия эшләп торсын өчен, ул вакытта күрелмәгән 1 млн. сум акча бүлеп бирә. Шул рәвешле бөтен көч республиканың профессиональ башкаручыларын һәм иҗади кадрларын булдыруга салына. Шуның нәтиҗәсендә опера театрын һәм филармонияне, ә бераз соңрак консерваторияне булдыру мөмкинлеге туа.

Ф.Яруллинга Мәскәүдәге тормышының беренче еллары җиңел булмый. Ул Димитровкадагы тулай торакта мохтаҗлыкта көн күрә. Татар клубына җыелучы язучы һәм музыкантлар төркеме белән якынаю бераз җиңеллек китерә. Ул елларда Мәскәүдә яшәүче татарларның үзләренең эшче клубы була. Татар язучылары һәм музыкантлары көче белән клубта музыкаль кичәләр үткәрелә һәм секцияләр оештырыла, спектакльләр куела. Клубның үз режиссёры һәм музыка җитәкчесе булган драма труппасы эшли (төрле елларда аны М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Н.Җиһанов җитәкли). Бирегә композиторлар С.Сәйдәшев, Ф.Яруллин, Ж.Фәйзи җырларын китерәләр. Шагыйрьләрдән М.Җәлил, Ә.Ерикәй актив иҗат итә.

Б.С.Шехтер классында укыганда, Ф.Яруллин күп кенә җыр, берничә инструменталь пьеса, фортепиано өчен соната яза. Санап кителгән әсәрләрнең укытучысы стиле тәэсирендә язылганы күренеп тора. Егерменче елларда җырлар язучы композитор, «1905 ел» операсы авторы, танылган Б.С.Шехтер революция һәм оборона темасына үз иҗатында аеруча әһәмият бирә. «Яшь гвардия» һәм «Ударниклар бригадасы маршы» авторының әсәрләренә хас сугышчан рух, марш адымнары, агитация-плакат стиле аның укучыларына да күчә. Ләкин Ф.Яруллин үз иҗатыннан канәгать булмый. Шиккә бирелүчән һәм канәгатьсезлек хисе кичергән, әле һөнәри яктан ныгымаган музыкант белән, кызганычка каршы, укучы һәм укытучы арасында була торган үзара аңлашу, тыгыз бәйләнеш урнаша алмый. Шехтер аның белән атналар буе очрашмый. Дөрес, татар студиясендә дәресләргә йөрү ирекле була. Яшь композитор өчен шушындый авыр чорда аңа Мәскәү консерваториясенең композиция кафедрасы мөдире Г.И.Литинский ярдәмгә килә. Беркадәр вакыт Фәрит Яруллинны күзәтеп йөргән Литинский аны үз классына күчерә. Бу турыда профессор үзе болай дип искә ала: «Уртача укый, башкалар кебек үк яза, ә язарга икенче төрле кирәк. Ф.Яруллин күзгатылмыйча тирәнгә яшерелеп яткан бик бай фантазияле, талантлы кеше. Киләчәк белән тартып чыгарырга кирәк.

Әгәр шулай итә алсаң, сокланып туймаслык, бөтенләй таң калырдай нәрсәдер барлыкка килә»[11]. Виолончель сонатасы язылганнан соң, 1936 елда ул Г.И.Литинский классына күчерелә.

Г.И.Литинский классында Ф.Яруллин үзенә карата бөтенләй бүтән төрле мөнәсәбәт тоя. Класста син кем булуыңа карамастан — рабфак, студия яки консерватория студентымы — барсына да бертөрле таләп һәм тәртип. Дәресләр һәрвакыт атнага ике мәртәбә үткәрелә, эшләнгән эшләр каты тикшерелә. Милли музыка культурасының үсеш проблемалары белән тирән кызыксынуы, аңларга тырышу сәләте һәм яхшылыгы белән педагог укучыларын үзенә җәлеп итә. Ул бер җирлеккә генә караган аерымлыкны хупламый, татар музыкасы рус, бөтен Европа илләре өчен гомум музыка культурасының яңа казанышларына нигезләнергә тиеш, дип фикер йөртә. Профессиональ белемнең һәм башкару техникасының югары кимәлдә булуын таләп итә. Шул ук вакытта ул укучысының милли һәм үзенә генә хас үзенчәлеген сакларга омтыла. «Милли музыка үзенчәлегенә карата сак фикер йөртеп, — ди соңрак Генрих Ильич, — мин аның алга таба үсешенә, коры пентатоника чигеннән читтә ята торган якын, ә аннан соң ераграк өлкәләренә үтеп керергә тырышам». Татар музыкасына һәм талантлы укучыларына (Литинскийда ул елларда С.Сәйдәшев, Н.Жиһанов, З.Хәбибуллин укый) шундый җылы мөнәсәбәте аны композиторларның озак елларга сузылган якын дусты итә. «Литинскийны башкалардан аерып торган сыйфат, — дип яза укучыларының берсе Э.Мирзоян, — укучысының сәләтле, алдагы көндә өметле булуына нык ышану. Һәм шунда инде икеләнүләр тарала, үзеңең хаклы икәнлегеңә инану килә»[12].

Фәрит аны таләпчән, кырыс укытучысы итеп кенә түгел, ә укучысының иҗат эшенең барышы, тормыш мәсьәләләре, көнкүреше белән кызыксынучы сизгер дус итеп тә кабул итә. Мондый мөнәсәбәт Литинский белән Яруллин арасында шундый дуслыкка әйләнә, Генрих Ильич үзенең укучысын «Мәңге онытылмас» дип атый. Ә фронттан хатынына язган хатларның берсендә Яруллин: «Коточкыч өметсезлеккә төшкән чакта мине аякка бастырган бердәнбер кеше — ул Литинский. Гомерем буе мин аңа бурычлы»[13], — ди.

Г.И.Литинский классында укыганда, Ф.Яруллин «Җырлама син, иркәм», А.С.Пушкин шигыренә «Чегәннәр» романсын, виолончель өчен соната яза, симфония һәм квартет иҗат итә. Әмма чын мәгънәсендәге иҗат дәрте аңа балет белән мавыгу чорында килә. Н.Жиһанов әйтүенчә, «Литинскийда композиторларга жанрлар сайлый белү сәләте бар»[14]. «Шүрәле»гә кадәр Яруллин Ә.Фәйзи либреттосына язылган «Зөлхәбирә» операсы өстендә эшли. Әмма балет язу уе туугач, аның өчен бу теләк югала. Композитор архивында әлеге операдан берничә өзек саклаган. Либретто язарга Ә.Фәйзи чакырыла. Балет либреттосы 1938-1940 еллар эчендә языла. 1938 елда студия артистлары киткәч тә Яруллин эшен дәвам итеп Мәскәүдә кала. Әзер өзекләр Казанда музыка җәмәгатьчелегенә фикер алышу өчен тәкъдим ителә, радиодан яңгырый. Фикерләр уңай була. 1941 елның көзендә Мәскәүдә уздырылачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына балетны әзерләргә дип, Яруллин Казанга кайта. «Бу — Татарстанның бөтен музыка җәмәгатьчелегенә һәм сәнгать эшлеклеләренә киеренке вакыт иде, — дип искә ала декаданың иҗат бүлеге консультанты итеп билгеләнгән Г.И.Литинский. — Композиторлар һәм артистлар «Совет» кунакханәсенең икенче катына урнашалар. Һәр иртә сәгать 11дә мин бөтен бинаны карап, бүлмәләрне йөреп чыгам. Берәүләрен мактыйм, икенчеләрен ачуланам, кирәк була калса, төзәтәм. Бөтен җирдә иҗат сулышы. Н.Жиһанов «Алтынчәч», М.Мозаффаров «Галиябану» операларын, Ф.Яруллин «Шүрәле» балетын яза. Бик шәп тантана, театр артистларының зур концерты көтелә». Декаданың комиссары итеп Ю.П.Ральф, баш балетмейстерга П.А.Гусев билгеләнелә. Мәскәүдән яшь, талантлы балетмейстер Л.Якобсон балетны сәхнәләштерергә чакырыла. Сценарий белән танышкач, ул аны әле җиренә җиткерелмәгән дип таба һәм баштагысыннан шактый үзгә яңа вариант тәкъдим итә. Шуннан соң материал үзгәртеп төзелә.

[11] Г.И.Литинский белән шәхси сөйләшүдән.
[12] Советская литература. — 1971, №3, 63 б.
[13] Композиторның хатлары Г.Г.Сачек һәм Н.Яруллинаның шәхси архивында саклана.
[14] Композитор белән шәхси сөйләшүдән.



*М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Шүрәле» балетыннан күренеш.*

яңа номерлар һәм музыкаль күренешләр кертелә (башлыча II акт музыкасында һәм «Янгын» күренеше). Композитор белән балетмейстер еш бәхәсләшәләр, әмма тегесе дә, монсы да күп һәм киеренке эшлиләр, нәтиҗәдә уйланылган төп идеягә иң яраклы юлны табалар. Бер үк вакытта биючеләр белән репетиция дә ясыйлар. Балетны кую (декада белән бәйле) бик кыска срокта һәм искиткеч киеренкелектә башкарыла.

Замандашлары Л.Якобсонны үз эшен югары дәрәҗәдә белүен һәм башкаручыларга бик таләпчән булуын искә алалар. Бу турыда биючеләрнең берсе (Кош-кыз партиясе) А.Ф.Гацуллина менә нәрсәләр сөйли: «Якобсон искиткеч балетмейстер, талантлы, уйлап табуга һәвәс. Һәр күренештә ул образлардан чыгып эш итә, хыяллана, уйлый. Аның репетицияләреннән без хәлдән таеп китәбез, чөнки авыр, катлаулы яңача хәрәкәтләр. Шулай да соныннан зур канәгатьлек хисе кичерәсең»[15]. Хореография чишелешенең яңалыгын, ачыклыгын үзенең истәлекләрендә П.А.Гусев күрсәтеп китә. «Бу — үтә дә заманча», — ди ул. Кем генә килсә дә, барсы да соклана һәм балетны декаданың үзәк вакыйгасы булыр дип саный. Заманчалыгын һәм уйлап табуга һәвәслеген шул хәл дәлилли: Якобсон Ленинград һәм Мәскәү постановкаларын куйганда, 1941 ел хореографиясенең өстенлеген саклый. 1941 ел постановкасы репетицияләрендә Н.Балтачиева (Сөембикә), Г.Кумысников (Былтыр), Б.Әхтәмовлар (Шүрәле) бии. И.В.Әүхәдиев дирижёрлык итә. Композитор өчен бу иң бәхетле көннәр була.

1940 елның июнендә Фәрит үзенең булачак хатыны Г.Г.Сачек белән таныша. Балет артисткасы Галина зур кара күзле, матур, зифа буйлы кыз. Ул Киевта туа. Әтисе чех милләтеннән, Гражданнар сугышында һәлак була. Кыз әнисе белән яши. Алар танышканда, Галинага 25 яшь була. Ул Харьков хореография училищесын тәмамлый. Днепропетровски музыкаль драма театрында бии, ә Казанга килгәч, Татар опера театрының балет труппасына эшкә керә. Бер-берсен бик яраталар. Композитор сөйгәнен «Гөлчәчәк» дип йөртә. Галина Георгиевна сөйләве буенча, «Фәрит гадәти булмаган тыйнак һәм намуслы, эчке дөньясы искиткеч бай. Аз сүзле, әмма музыкасы кебек үк югары фикер йөртә торган һәм иң чиста, изге ниятле кеше иде»[16]. Ул үзенең балеты турында күп сөйли, эчтәлеге белән таныштыра, төп темаларын көйләп күрсәтә. Театрны нык ярата. Татар драма театрына еш йөриләр. Ана аеруча төп рольдә Х.Әбҗәлилов уйнаган «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт) спектакле ошый. Галина Георгиевна Фәритнең беркайчан ата-анасы турында сөйләмәвен исенә төшерә. Әмма бервакыт кунакханәгә анасы килә. Аның күп еллар әнисен күргәне булмый, хәтта кайда булуын да белми. Очрашу икесен дә дулкынландыра, сөйләшеп сүзләре бетми, искә төшерешәләр, бер-берсенең хәлләрен сорашалар. Шул вакыттан соң ул еш кына аның янына бара, ярдәм итә. Ара-тирә атасы да килеп китә.

Бу чорда композитор бик күп эшли. Кайда гына булмасын, нота кәгазьләрен, карандаш һәм бетергечне үзеннән калдырмый. «Музыканы тиз һәм җиңел яза, — дип искә ала Г.Г.Сачек. — Соныннан аңладым, шушы тоелган җиңеллек артында искитмәле, бертуктаусыз эчке уй, эш яткан икән. Музыка аның бөтен барлыгын били, уйларын үзенә ала, кешеләр белән якынлыгын чикли. Еш кына мин аның

[15] 1976 елның 16 мартында артистка А.Ф.Гацуллина белән шәхси сөйләшүдән.
[16] Г.Г.Сачек белән шәхси сөйләшүдән.

төшенкелеккә бирелгәнен күрә идем. Ярты юлда өзелгән сүз, кисәк йомылу, хисләрен белдергәндә басынкылык, еш кына таркаулык, уйчанлык — болар барсы да аның иҗат белән даими мавыкканын күрсәтә»[17].

Композиторга үз балетын сәхнәдә күрергә насыйп булмый. Бөек Ватан сугышы башлана. Артистлар, музыкантлар фронтка китәләр. Акрынлап театрда эш тәгәлләнә бара. 26 июльдә Ф.Яруллинга да чакыру кәгазе килә. 27 июльдә дуслары, якыннары белән саубуллашып, ул җыелу урынына китә. Аны Ульяновскидагы пехота училищесына курсант итеп җибәрәләр.

Хезмәт итү җинел булмый. Җайлашмаган, елгыр булмаган, үзе әйтмешли, «ирекле профессия кешесе» Яруллин хәрби тәртипне, күп чакрымлы аралар үтүне авыр кичерә. Әмма бик тиз үзгәрә, җыйнаклана, хәрби ыспайлыкны, хатынына язганча, «элеккеге зифалыгын» кайтара. Училищеда ул үзешчән сәнгатьтә катнаша. Ульяновскиның Офицерлар йортында концерт бригадасы составында чыгыш ясый. Иҗатын дәвам итә, башлыча хәрби темага җырлар яза.

Өч айдан соң укуын тәмамлаган Ф.Яруллинны иптәшләре белән фронтка җибәрәләр. Беренче бәрелештә үк Ф.Яруллин җилкәсе яраланып госпитальгә эләгә. Биредә ул тиф белән авырый һәм дүрт ай буе яшәү белән үлем арасында була. Шушы вакытта, 1942 елның 29 февралендә, Казанда Ф.Яруллинның кызы туа, Наилә дип исем кушалар.

1942 елның яз-җәй айларында Ф.Яруллинга Уфа, Куйбышев, Саратов, Пермь шәһәрләрендә булырга туры килә. Куйбышевта ул Киров исемендәге Ленинград академия театры сәхнәләштергән «Пиковая дама», «Аккош күле» спектакльләрен карый. Д.Шостакович, П.Гусев, Саратовка эвакуацияләнгән Г.И.Литинский белән очраша. Г.И.Литинский яраткан укучысы белән соңгы очрашуын сагынып еш искә ала.

Аның студентлар белән дәрес алып барган чагы. Шулвакыт җилкәсенә биштәр аскан, хәрби киемдә, ябык, сакал-мыек баскан бер яшь кеше ишекне ачып карый. Бары тик аңа гына хас ачык, мөлаем елмаюыннан, янып торган күзләреннән генә укытучы Фәрит Яруллинны танып ала. Алар үз күзләренә ышанмыйча, шулкадәр шатлыктан, сүзсез басып торалар. Ә аннан, Литинский фатирына кайткач, дуслары һәм якыннары, Ф.Яруллинның зур иҗат планнары, яна әсәрләре турында бик озак сөйләшәләр. Фәрит шактый күп җырларын, концерт, кантаталарын, язылачак симфониясенең фрагментларын күрсәтә. Дирижёрлар факультетында укырга теләвен әйтә. Нәкъ шул чакта Г.И.Литинский Яруллинны Мәскәү консерваториясенең хәрби факультетына кайтару кирәклеген хәл итәргә тели. Бу мәсьәләне хәл итүгә бөтен көчен куя. Ләкин рөхсәт алынганда Фәрит якты дөньяда булмый инде.

Вакыйга болай була. 19нчы танк корпусының пехота подразделениесендәге Ф.Яруллин хәрби вакыйгаларның нәкъ уртасына эләгә. 1942 елда — Сталинградта, ә 1943 елда Курск дугасындагы сугышларда катнаша.

Ватан, хатыны, кызы һәм музыка. Фронттан килгән хатларның эчтәлегендә уйлар гел алар турында... «Мин бер генә нәрсә — котырган фашизмга каршы көрәштә Ватаныма кирәк булырга теләр идем. Испан хатыны Долорес Ибаррури дөрес әйткән: «Тезләнеп яшәүгә караганда басып үлүең яхшырак». Шундый уйлар белән фронтка китәм», — дип яза ул әтисенә. «Шикләнмә, без җиңәчәкбез», — монысы хатынына язган хатларда. Әлеге хатларның һәр юлыннан наз, ярату хисе бөркелеп тора. Кызын коча, ярата, күрә алмавына җаны әрни. «Тормышының шатлыгы, өмете»н саклауны сорый. Шулар белән бергә аның башында музыка турында уйлар кайный. «Шүрәле» музыкасындагы шактый нәрсәләр яңадан тикшерелә, үзгәртелә, уйланыла. Икенче актның музыкасын йомшаграк санап, аны өр-яңадан эшләргә хыяллана. Якобсон хезмәтен югары бәяли. «Минем музыка, — дип яза ул, — аның постановкасы белән чагыштырганда чүп кенә. Ул үзенең энергиясе һәм үз дигәнендә нык торучанлыгы белән мине яхшы уйларга этәрде». Туктаусыз хафалануының сәбәбе — спектакльнең язмышы. Композитор фронтка киткәндә репетицияләр әле дәвам итә һәм ул премьераның булырына ышана. «Сәхнәдә баруын күземнең бер кырые белән генә күрер идем. Минем аны шундый күрәсем килә». Яңа иҗади

[17] Вечерняя Казань, 1984, 27 февраль.




*Белоруссия. Рыленки туганнар каберлеге. Татарстан делегациясе вәкилләре Ф.Яруллин каберенә чәчәк салалар.*

уйлар тынгылык бирми. «Шүрәле»мне нык сагынам. Сөембикәнең лейтмотивы янача яктылыкта яңгырар. Ул минем киләчәк симфониямнең урта өлеше булыр. Тик, ни кызганыч, әле хыялымны тормышка ашыра алмыйм. Нәҗипкә көнләшеп тә, шатланып та карыйм, чөнки каләмен нык тотып, үзенең элеккеге уңышларын арттыра бара». Хатларының тагы бер үзенчәлеге — иҗатын дәвам иттерергә мөмкинлеге булмауга әрнү. Шул ук вакытта, Ватанны яклау бурычының әһәмятен дә аңлый. Сугышның «кайнар» нокталарына якынайган саен, патриотик рух тагы да көчәя. Хатларының шундый юлларыннан бетмәс рух көче күренә.

«Беренче чиратта, эшләргә тиешлек белән чагыштырганда, боларның барсы да юк нәрсәләр. Ватан өстендә туган куркыныч минутта бу — аның алдында изге бурыч. Кечкенә генә мөмкинлегең булса, — дип яза ул хатынына, — Бөек эшләр хакына Ватаныңа, халкыңа хезмәт ит. Бу дәһшәтле көннәрдә кайда да файда китерә алырдай урын эзләп тап».

1943 елда, гыйнвар ахырыннан 6 июль арасында, 19нчы танк корпусы гаскәрләре Курск янында хәлиткеч сугышка әзерләнәләр. Ә 12 июльдә Курск дугасында канкойгыч сугыштан корпусның бар булган составыннан бары 250 тирәсе кеше генә чыга. Фәрит Яруллин да исән кала. Корпус ставка резервына күчерелә. Яруллинны 31нче армиянең 82 нче дивизиясе 250нче полкына җибәрәләр. Тиздән бу полк Көнбатыш фронтка күчерелә. Гаскәр Белоруссия юнәлешендә Мәскәү-Минск шоссесе буенча хәрәкәт итә. Шушында, Смоленск янындагы сугышларның берсендә, 1943 елның 17 октябрендә, взвод командиры лейтенант Фәрит Яруллин һәлак була. Аның гәүдәсе Орша шәһәре янындагы Яна Тухиня авылы зиратында туганнар каберлегендә. Хәзер бу урында «Рыленки» мемориаль комплексы төзелгән. (Витебск өлкәсе Дубровинский районының Тухиня авылы)[18]. Исемлек СССР оборона Министрлыгы Үзәк архивы документында теркәлгән.

Кем шушындый талантлы, өметле композиторны фронтка җибәрә? Ни өчен күбесе бронь ала, ә ул юк? Аның фронтка китүе шулай бик мөһим буламы? Төрле язмаларда бу мәсьәлә буенча өзлексез фикер алышалар. Без инде хәзер беркайчан да дөресен белә алмабыз, әмма юрамалар бар. Бу юлларны язучы белән бер сөйләшүдә Г.И.Литинский шуларның берсен искәртә: «Сугыш башлана, күп музыкантлар фронтка китәләр. Н.Җиһанов, И.Әүхәдиев һәм кайберәүләр кала. Яруллин белән Әүхәдиев арасында ачыктан-ачык конфликт чыга. Шунда Фәрит:

[18] 1233 фонд, ей. 2. 29 эш., б. 10 һәм 20 эш., б. 169.

«Син барыбер балетка дирижёрлык итмәячәксен», — ди. Чыннан да, Әүхәдиев дирижёр буларак йомшак, күренеп торган сәләте юк, шуңа ул композиторны канәгатьләндерми. Ана, Яруллинга, әлбәттә, күбрәк тойгы, хис, музыкага ижади якын килү кирәк. Һәм Әүхәдиев аңа каршы җавабын озакка сузмый, ул аңа бронь бирми. Композиторларның барсы диярлек бронь ала, ә Яруллин — юк»[19]. Бу уңайдан шуны да әйтеп үтәсе килә: әлбәттә инде талантлы кешеләрнең һәрвакыт дошманнары була. Яруллинның үзенең дә иҗатта уртача сәләтлелекне, битарафлыкны җене сөйми. Шуңа күрә кемнеңдер кулы уйнавы бик мөмкин. Ләкин документлар белән расланмаган юрамалардан, шикләнүләрдән чыгып кына композитор янәшәсендәге кешеләрне гаепләү гадел булмас.

Искиткеч музыкант һәм композитор Фәрит Яруллин гомере менә шулай фаҗигале төстә өзелә. Аның капельмейстерлар факультетында уку, сугышның авыр вакыйгалары турында симфония язу нияте була. Күптөрле уйлары, ниятләре дә юкка чыга. Язылган әсәрләре музыкага гадәти булмаган сәләтен күрсәтә. Үлеме бөтен совет сәнгатенә әйтеп бетергесез югалту була. Гаиләсе өчен фаҗига. Сугыш вакыты авырлыклары, иренең үлеме Галина Георгиевнаның сәламәтлеген нык какшата. Тормышның бар михнәтен аның белән бергә кызы — Наилә Фәрит кызы Яруллина да күтәрә. Иң авыр вакытларында алар аны үзләренең яннарында кебек тоялар. Бөтен гомерләре буена тугрылык һәм мәхәббәт саклыйлар. «Минем язмышымда ул җыр булып кала» дип атала Г.Сачек-Яруллинаның бер мәкаләсе. Анда күңелне дулкынландыра торган шундый юллар бар: «Каршымдагы диварда аның рәсеме, төрле телләрдә театр афишалары, тартмада күпьеллык тугрылыклы әңгәмәдәшләрем — саргайган хатлар бәйләме һәм йокы бирми торган хатирәләр»[20].

Хатынының, кызының бөтен тормышы искиткеч композитор, батыр сугышчы, ир һәм ата ядкарен мәңгеләштерүгә багышлана. Алар — аның турында иң кадерле истәлекләрне саклаучылар, композиторның иҗатын һәм тормышын өйрәнүчеләр, полкташлары, дуслары янына, сугышчан юлын, иҗатының әлегә билгесез сәхифәләрен ача торган яңа документларны эзләүдә катнашучылар. Ил буенча аны фронтта күргән кешеләргә мөрәҗәгать итеп хәбәр салына. Эзләүдә Д.С.Самойлов, Х.Габдрахманов, С.Д.Сурмилло һәм башка шактый күп кеше катнаша. Бу эшне 19нчы танк корпусының ветераннар советы рәисе, отставкадагы подполковник М.Н.Тихненко җитәкли. Ветераннар советына караган Мәскәүнең 646нчы мәктәп укучылары да эзләнүләрдә катнаша. Күп тырышлык сорый торган җентекле эш нәтиҗәсендә, бары 1985 елда гына, композиторның сугышчан юлы тәмамланган һәм җирләнгән урыны табыла.

Ф.Яруллинның исеме һәм иҗаты язучыларның, музыка белгечләренең һәрвакыт күз уңында. Бу еллар эчендә аның турында шактый газета, журнал мәкаләләре, Ч.Бәхтиярованың «Фәрит Яруллин» дигән монографик очеркы, А.Алмазованың «Фәрит Яруллин һәм татар балеты» монографиясе, Р.Низаминең ике китабы (аларның берсе — «Фәрит Яруллин» — ЖЗЛ сериясендә, икенчесе — «Ут һәм җыр») басыла. Фәрит Яруллин исеме урамга, уку йортларына бирелә, музейлар ачыла. Боларның барсы да аның якты талантына ихлас соклану, батыр сугышчы истәлегенә ихтирам билгесен күрсәтә. Ә «Шүрәле» балетының бәһаләп бетергесез музыкасы Рәсәй театрларында гына түгел, бөтен ил сәхнәләрендә яңгырый.

**Аида АЛМАЗОВА,**
*сәнгать фәннәре кандидаты*

[19] 1975 елның 18 һәм 26 декабрендә профессор белән шәхси сөйләшүдән.
[20] Вечерняя Казань, 1984, 27 февраль.

# «КАРА ПУЛАТ» СЕРЛӘРЕ

«Казан утлары» журналы өчен музыкаль әсәрләрнең язылу тарихын өйрәнә башлагач, күп кенә музей-архивларга мөрәҗәгать ителде. Дөресен әйтергә кирәк, әлеге мирасханәләрдә сакланган материалларга үтеп керү бик җиңел түгел. Бу дөньяга эләккәч тә, сина кирәкле мәгълүмат кулга керәм дип тормый. Кайбер җыр, опералар турында әйтелеп кенә үтелергә мөмкин, кайсылары телгә дә алынмый. Шунда: «Эх, ни өчен ул вакытта теге яки бу әсәрнең язылу тарихын теркәп бармаганнар икән?» — дигән үкенечле сорау туа. Ә бүгенге көн әсәрләренә игътибарлымы соң без? Язучы, композиторларның иҗат лабораториясе белән кызыксынабызмы? Әлеге сораулар 2015 елның мәдәни вакыйгасына әйләнгән «Кара Пулат» опера-риваятенең язылу тарихын өйрәнергә этәрде дә.

«Кара Пулат» — «Зөһрә», «Алтынчәч», «Шүрәле» кебек эпос, риваятькә корылган татар музыкасы ядкарьләренең варисы, соңгы елларда тарихның төрле чорларын яктырткан «Ак бүре», «Алтын Урда», «Алтын Казан» музыкаль әсәрләр циклының дәвамы кебек. «Кара Пулат»та традицион әкиятләргә хас ак һәм кара көчләр көрәше сурәтләнә. Шагыйрь Ренат Харис аны «Янмый торган кыз» риваятенә нигезләнеп иҗат итә. Риваятьнең эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: «Туктамыш артыннан килгән Аксак Тимер (риваятьтә Тамерлан дип бирелгән) Болгар шәһәрен утка тота, дәрәҗәгә дә, картлыкка яки яшьлеккә карамыйча, кешеләрне юк итү башлана, хатын-кызлар һәм балалар әсирлеккә алына. Болгарда ул вакытта патшалык иткән Габдулла хан, шәһәрне саклап кала алмавын аңлагач, гаиләсе һәм якыннары белән иң нык таш пулатларның берсенә — Хөкем палатасына кереп бикләнә. Аксак Тимер гаскәре пулатны яндыра һәм тикшерү барышында хан кызының Хисаметдин исемле мулланың (Болгарда изге кеше була) ак киеме итәгендә янмыйча утырып калганлыгы ачыклана. Үлгән ханның әлеге кызын аның кече энесе белән Тамерлан үзенең пайтәхете Сәмаркандка алып китә...» Пулат янгыннан соң Кара Пулат дип йөртелә башлый.

Ренат Харис әлеге риваятьне нигез итеп алып, аны үстерә, баета. Автор бу турыда үзе менә нәрсәләр сөйли: «Соңгы елларда Болгар тыюлыгы тернәкләнеп китте, «Яңарыш» фонды җитди эшләр кузгатып җибәрде. Әлеге вазгыятьтә халыкның кызыксынуын тагын да көчәйтергә кирәк иде, ягъни экскурсовод җиткергән коры фактларны ниндидер сәнгать соусына төрергә. Әнә шунда мин уйлана калдым. Болгар шәһәрендәге һәрбер таш легендага әверелгән. Җәмигъ мәчете, Зур манара, Көнчыгыш, Хан төрбәләре — барысы да игътибарга лаек. Алар арасында Кара Пулат мәгърурлыгы белән аерылып тора. Шуңа да мин нәкъ аның белән бәйле риваять эзли башладым. Китапларда берничә версия бар иде, «Янмый торган кыз» риваятенә тукталдым, аңа өр-яңа эчтәлек өстәп, либретто иттем».

«Кара Пулат» башта синопсис[1] буларак барлыкка килә. Шагыйрьнең шәхси архивында саклана торган бу документта «Двенадцать девушек» («Чёрная палата») музыкально-драматическая легенда дип тәкъдим ителә. Сюжетның Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан яндырылган 12 кыз легендасына нигезләнүе ассызыклана. Синопсис рус телендә, анда әсәрнең нигезе тасвирлана. Сәмәрканд әмире Аксак Тимер гаскәрләре Болгар шәһәре каласын басып алганда, 12 кызны да кулга төшерәләр, араларында Хан кызы булуы да билгеле. Аксак Тимер боерыгы буенча, аны кәнизәк итмәкчеләр, ләкин 12 кыз арасында кайсы Хан кызы икәне билгеле түгел. Хан кызын тану максатында сугышчылар аларны төрле сынауларга дучар итсәләр дә, тугры дус кызлары аны сатмыйлар. Кемдер Хан кызының утта янмаганы

[1] Әсәрнең гомуми эчтәлеге

турында хәбәр житкерә. Сәмәрканд әмиренең нөкәре кызларны Хөкем сараена алып кереп яндырырга боерык бирә (...) Янгын сүрелгәч, пулат ишеге ачылып, аннан ап-ак киемдә хан кызы пәйда була. Болгар ханының гаскәрләре (араларында Хан кызының сөйгән яры да була) аны коткарып калалар.

«Мин әүвәл синопсис язам. Синопсиста әсәрнең башы белән ахыры логик йомгакка әверелергә, бәйләнеш хасил булырга тиеш. Ләкин эш дәвамында бер сүз, бер жөмлә сюжетны бөтенләй башка якка борып жибәрергә мөмкин», — дип либретто ижат итүнең серләре белән бүлешә автор. Бүгенге көндә әлеге үзгәрешләрне барлау катлаулы, чөнки компьютер заманында жөмләләрне юкка чыгару өчен бер төймәгә басу житә! Шул рәвешле, Ренат Харис либреттосының тулаем үзгәрешләрен күзәтергә мөмкинлек юк. Шулай да либретто авторы һәм композиторда сакланган төп нөсхәләр аша әсәрнең эволюциясен күзалларга була.

Либреттоның беренче варианты 2012 елның 1 сентябрендә язылып беткән. Титул битендә «Кара Пулат» рәсеме (Ренат Харис авторлыгында), либретто үзе дә «Кара Пулат» дип тәкъдим ителә. Синопсистагы персонажлар да «исем алганнар». Хан кызы — Нәргизә. «Нар» гарәп телендә — «ут, ялкын», фарсыда — «гранат агачы жимеше», образлы әйткәндә, «бәхетле» мәгънәсендә; «гиз» сүзе исә гарәп теленнән — «газәл», ягъни «мәгърурлык, бөеклек», шулай ук «ихтирам, мактау, дан, шөһрәт», фарсыда исә күпмәгънәле «гыйззәт» сүзеннән — «көч, куәт, дәрәжә» мәгънәләрендә. Димәк, Нәргиз — ир исеме, «ялкынлы көч» мәгънәсендә, яисә «ут кебек куәт, бөеклек». Хатын-кыз исеме буларак, ана [ә] кушымчасы ялгана һәм ул кайбер чыганкаларда — «ут аша узучы», ә фарсыда — «иң бәхетле» мәгънәсендә. Ренат Харис Нәргизәсенә дә әсәр дәвамында, төрле сынаулар үтеп, чын мәгънәсендә ут аша узарга туры килә, либреттоның икенче вариантында аның бәхетле вакыты да сурәтләнәчәк әле. Ягъни исем төрле яклап герой язмышын ачып бирә. Карабатыр — «кара көчләрне гәүдәләндерүче мәгънәсендә» булса, Мәмәт — «ярдәмче», бу очракта — Карабатырның уң кулы. Әлеге персонажлардан тыш, катнашучылар исемлегендә — чичән, сугышчылар һәм унбер кыз. Вакыйгалар Хөкем сарае янына Аксак Тимер яугирләреннән ап-актан киенгән 12 кызны алып килүе белән башлана. Ягъни либреттоның беренче вариантында спектакльдә тәкъдим ителгән Турыбатыр белән Нәргизәнең мәхәббәт линиясе бөтенләй юк.

Икенче вариантта (ул 2012 елның ноябренә карый) әсәргә яна персонаж — Турыбатыр — Нәргизәнең сөйгәне килеп керә. Бу вариантта мәхәббәт темасы алгы планга чыга дисәң дә ялгыш булмас. Әсәр туйга әзерлек күренешеннән башлана. Финалда 11 кыз янып бетә, Нәргизә белән Турыбатыр, бөтен сынауларны узып, бергә калалар. «Мәхәббәт темасы — мәңгелек темаларның берсе, әгәр дә ул юк икән, гадәттә, спектакль озак яшәми, тамашачы күңеленә үтеп керә алмый. Әнә шуны күздә тотып, Нәргизә һәм Турыбатыр тарихын булдырдым да», — дип бәян итә Ренат Харис.

Өченче вариант исә эш барышында туа. Режиссёр да, композитор да әсәргә үз өстәмәләрен алып килә. «Кара Пулат» — композитор Эльмир Низамовның татар сәнгате үсешендә зур жанрларны үзләштерү буенча икенче тәжрибәсе. «Кара Пулат» либреттосының да, «Алтын Казан» мюзиклы кебек үк, халык ижатына нигезләнүе композиторда бөтенләй башка музыкаль чишелеш тудыру теләген уята һәм шул максаттан ул опера жанрына мөрәжәгать итәргә була: «XIX гасыр итальян һәм рус операларының романтик теле, XX йөзнең эксперименталь европа опералары миңа һәрвакыт якын иде. Соңгыларында мелодик аһәң драматургия һәм эксперимент хакына корбан ителә. Ә татар музыкасы — минем өчен, беренче чиратта, вокаль музыка. Шуңа да «Кара Пулат» музыкасын башыннан ахырына кадәр жырлана торган итәсе килде. Шул максаттан, традицион романтик опера һәм XX гасырның катлаулы опера теленә мөрәжәгать иттем», — ди композитор. Музыка белгечләре фикеренчә, Эльмир Низамов нәкъ әлеге урталыкны тапкан да. Опера арияләренең жырлап торуы исә аларның татар мелизмнары белән баетылуына бәйле. Әкияти сюжетта яшь көйязарның романтик сәнгати фикерләве тагын да ачыграк сизелгән кебек. Композитор әңгәмәләрендә, операда мажор ноталар юк дәрәжәсендә, дип ассызыкласа да, нәкъ менә музыка ярдәмендә әсәр тулысы белән яктылык, чисталык

гәүдәләнеше буларак кабул ителә. Гәрчә «Кара Пулат» драматик вакыйгаларга нигезләнсә дә. Әсәрнең музыкаль жанрын билгеләүдә галимнәр әлегә уртак фикергә килә алмады. Шуңа да бу мәкалә кысаларында жанр авторлар версиясе — опера буларак тәкъдим ителә. Чөнки безнең максат — «Кара Пулат»ка әдәби-музыкаль анализ ясау түгел, аның язылу тарихын барлау.

Композитор «Кара Пулат» әсәре буенча эшен либретто кулына килеп кергән көнне үк — 2012 елның гыйнварында башлаган. «Либреттоны укып чыккач та, Нәргизәнең ахыргы ариясе күзгә ташланды һәм шунда ук бу өлешен язып куйдым. Минем «Кара Пулат» шуннан башлана», — Эльмир Низамов «Кара Пулат» турында сөйләгәндә, «минем» сүзен еш куллана. Бу очраклы түгел. Музыкаль әсәрләр — берничә авторның иҗат җимеше һәм, табигый ки, аларның һәрберсенең үз әсәре. «Кара Пулат» та һәрбер иҗатчы «кулы»нда үзенчә формалаша һәм шуңа аның тууы, сәхнәгә менүе алар хәтерендә үзгә сакланган.

«Либреттоны кулга алгач, берничә тапкыр укып чыгам, аңларга тырышам, аннан материалны берничә зур бүлеккә бүләм, зур бүлекләрне — тагын да кечерәккә. Әсәрнең гомум музыкаль канвасын барлыйм. Аннан соң гына һәр бүлек буенча аерым эшләргә тотынам. Әгәр дә көй өчен сүзләр җитмәсә, Ренат Харистан өстәмә текст язуын үтенәм яисә, киресенчә, кыскарта башлыйм. «Кеше исеме янмый» дигән теманы (хор өчен) озак эзләдем. Ул реквием кебек яңгырарга тиеш иде, шул ук вакытта татар мөнәҗәте кебек гади, ләкин бик үтемле булырга да. Әнә шул халәтне бик озак эзләдем», — ди Э.Низамов, әсәрнең язылу тарихын искә алып.

*Ташлар яна, корыч яна,*
*суларны ялкын ялмый...*
*Дөнья яна, гомер яна —*
*кеше исеме янмый!*

«Кеше исеме янмый» музыкаль темасы «Кара Пулат» спектаклендә лейтмотив кебек яңгырый. Композитор аны башында һәм ахырында гына кулланырга ниятләсә, режиссёр Георгий Ковтун бу музыканы, вокализ буларак, өченче өлештә — Нәргизәдән, дүртенче өлештә чәчәннән думбрада башкарттыра.

Музыка язу бер нәрсә, аны оркестровкага салу — бөтенләй икенче. Кайбер композиторлар бу эшне башка кешегә тапшырырга да мөмкин. Ләкин Эльмир Низамов өчен әсәренең нинди тембр, буяулардан «киенүе» бик мөһим һәм ул әлеге эшкә музыка язу кебек үк җитди карый. «Оркестровканы мин «Новая музыка» камера оркестры өчен яздым. Ул зур оркестр түгел, шуңа партитурада аңа өстәмә бәрмә һәм тынлы уен кораллары керттем. Оркестрны көчәйтүче шушы уен коралларыннан башка мин теләгән музыкаль яңгырашка ирешү кыен булыр иде», — дип аңлата композитор. Шуны билгеләү мөһим: әгәр дә «Кара Пулат» өчен симфоник оркестр тәкъдим ителгән булса, табигый инде, партитура башка булыр иде. Ләкин композиторларга нинди шартлар тәкъдим ителә, алар шуларга яраштырга мәҗбүр. Бигрәк тә опера кебек зур әсәрне сәхнәгә чыгару мөмкинлеге булганда! Чөнки музыкаль-театраль жанрларның ак кәгазьдән иҗат ителүе һәм сәхнәгә менүе, драма әсәрләре белән чагыштырганда, сирәк күренеш. Бу исә иҗат процессының катлаулы булуына бәйле. Бүгенге көндә либретто авторы да, композитор да зур жанрларны фәкать заказ буенча гына башкара ала, чөнки аларны «өстәл»гә язу вакыт, энергия, көчне суга салуга тиң. Ничек кенә булмасын, «Новая музыка» камера оркестры (җитәкчесе — А.Гулишамбарова) премьера көннәрендә Эльмир Низамов музыкасының төрле төсмерләрдән торган буяуларын нечкә зәвык белән тамашачыга җиткерә алды.

Композитор сүзләренә караганда, «Кара Пулат»ны иҗат итү өч елга сузыла. Операның төп тема һәм арияләре беренче елда язылса да, әсәрне кую-куймау мәсьәләсе килеп баскач, эш тукталып тора. 2014 елның маенда сәхнәләштерү турында төгәл карар чыккач кына, ул эшне яңартып җибәрә һәм быелның гыйнварында режиссёр Георгий Ковтун белән берлектә аны төгәлли. Чөнки профессиональ режиссёр һәрвакыт әсәрне үз күзаллавынча дөньяга чыгара. «Кара Пулат»ны куючы



*Операдан күренеш*

Санкт-Петербург режиссёры Георгий Ковтун Татарстан тамашачысына 80нче еллар ахырыннан таныш. Муса Җәлил исемендәге Казан татар дәүләт опера һәм балет театрында соңгы елларда аның куелышындагы «Кыйссаи Йосыф», «Пер Гюнт», «Спартак», «Алтын Урда» балетлары, шулай ук «Кармен» операсы — һәрберсе аерым игътибарга лаек. «Кара Пулат»та режиссёр Ренат Харис белән өченче тапкыр очраша һәм әлеге очрашу нәтиҗәсендә драматургик материал да шактый үзгәрә. Мәсәлән, Георгий Ковтун Турыбатырны сөеклесе күз алдында Аксак Тимер сугышчылары тарафыннан җәзалап «үтертә». Һәм, иң мөһиме, финалда Нәргизә башка кызлар белән беррәттән һәлак була. Режиссёр тарафыннан әсәрнең финалы үзгәртелүенең төп сәбәбе — ханнарның да гади кешеләр белән бер дәрәҗәдә булуын ассызыклау. Ренат Харис баштарак бу үзгәреш белән килешмәсә дә (чөнки риваятькә каршы бару), соңрак аны тормышчан финал буларак бәяли: «Нәргизә үзе өчен корбан булган кызларның үлеменнән соң ничек яшәр иде бу җирдә, киләчәктә аны нәрсә күтәр иде? Мин беркайчан да куючы режиссёр белән бәхәскә керергә тырышмыйм. Музыкаль әсәрләрне өч автор «бар кыла», әгәр аларның һәрберсе үзен бер автор итеп тоймый икән, спектакль таркала. Кайвакыт концептуаль үзгәрешләр булса, каршы чыгарга мөмкинмен, ләкин анда да әсәрнең идеясе дөрес борылыш алмавын күрсәм генә. Техник сәбәпләргә бәйле үзгәрешләр дә бар бит әле. Мәсәлән, «Кара Пулат»та кызлар хоры биегәннән соң, аларны шул минутта ук җырга күчермәс өчен (ул очракта вокал ягы аксаячак!), режиссёр 4-5 минутлык тыналыш кирәклеген әйтте. Нәтиҗәдә, Турыбатыр һәм Нәргизә дуэты туды». Әйе, концептуаль үзгәрешләрдән тыш, «Кара Пулат»ның өченче вариантында Турыбатыр белән Нәргизә һәм Турыбатыр белән Карабатыр дуэтлары өстәлә. Композитор бу ике яңа дуэт язылуы турында менә ничек искә ала: «Ул вакытта премьера чыгарга бер ай гына калган иде, шуңа мин ашыгыч рәвештә Ренат Хариска шалтыраттым, һәм ул ике көннән өстәмә сүзләр җибәрде. Нәргизә белән Турыбатыр ариясен күз ачып йомганчы иҗат итсәм, Карабатыр белән Турыбатыр дуэты авыррак бирелде».

Кыскасы, Георгий Ковтун эш барышында әсәргә шактый үзгәрешләр кертә. Либреттодагы концептуаль үзгәрешләр әсәрне бөтенләй башка яссылыкка күчерә һәм, безнең фикеребезчә, опера монардан ота гына. Ак көчләрнең җиңүе белән тәмамланасы финал трагедия төсмерен ала. Ил язмышы өчен көрәшкән Турыбатыр үз үлеме белән трагик герой дәрәҗәсенә күтәрелсә, кызлар үлеме тугрылык темасын алга чыгара. Унай геройлар котылгысыз һәлакәткә дучар булсалар да, опера рухи җиңүне раслый. Шул ук вакытта алдарак әйтелгән техник сәбәпләргә

бәйле үзгәрешләр (өстәмә ария, биюләр кертү) драматургик яктан эзлеклелекне какшата. Нәтиҗәдә спектакль кайбер урыннарда аерым сюжетлардан торган җыелма тамашаны хәтерләтә. Бу исә, үз чиратында, сюжетка схематиклык өсти.

Операның Тинчурин театрында куелуының символик мәгънәсе бар кебек. Узган гасырның 30-40 нчы елларында нәкъ менә әлеге бинада опера һәм драма труппасы чиратлашып уйный. Ул вакытта бу күренеш бина юклыктан килеп туган мәсьәлә булган. Хәер, «Кара Пулат»ның драма һәм комедия театрына өйдәш булып керүе дә нәкъ шуңа бәйле. Телибезме-теләмибезме, массив декорация, костюмнар өчен Тинчурин сәхнәсенең кысан булуын танырга мәҗбүрбез. Пространство тарлыгы куелышның дәрәҗәсен төшергән кебек тәэсир калдырды. Бу уңайдан иҗат төркеме дә шактый авырлыкларга юлыккан. Мәсәлән, Тинчурин театрында оркестр чокырының кечкенә булуы музыкантларны тамашачы залына күчерергә мәҗбүр итә. Ә бит музыкаль театр кануннары буенча оркестрның тамашачы янында урнашуы акустик яктан дөрес түгел, шул ук вакытта эстетик як та бар бит әле. Сәхнәнең кысан булуы «Кара Пулат»та катнашучылар санын да кыскартырга мәҗбүр итә. Либреттода 12 кыз булса, сәхнәгә алар җидәү булып менә. Кызлар саны кыскаргач, табигый, сугышчылар саны да азая. Ягъни киң масштабка дәгъва иткән әсәр камерный буларак дөньяга чыга. Әлбәттә, «Кара Пулат»ның драма театрында куелуы — бер чирканчык кына. Ул «Яңарыш» фонды заказы белән Болгар тыюлыгында туристларга күрсәтү максатында махсус иҗат ителә, һәм быелгы җәй аны тере декорацияләр — Кара Пулат хөкем сарае янында уйнау планлаштырыла. Шулай да әлеге операның нәкъ менә Тинчурин театрында старт алуы Казанда музыкаль театр кирәклегенә тагын бер кат инандырды. Егерме еллар элек күтәрелә башлаган мәсьәлә бу уңайдан тагын да актуальләшә төште. Операда катнашкан Гөлнара һәм Рүзил Гатиннар, Артур Исламов, Денис Ханбаба кебек солистларга гына түгел, консерваториядә белем алган һәм аны тәмамлаган башка яшь җырчы, композиторларга иҗат итәргә мәйдан булдыру зарур. Чөнки, ихтыяҗ булмау сәбәпле, күпләр Мәскәү, Санкт-Петербург, чит илләргә китәргә яисә шоу-бизнес белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Татар музыка сәнгатендә сыйфат яңарышы, ягъни ренессанс булсын өчен дә кирәк безгә музыкаль театр. Дөнья музыка мирасы белән чагыштырганда, бу өлкәдә безнең җиңүләребез зур түгел. Моның сәбәбе татар профессиональ музыкасының, аерып алганда, академик музыканың бик яшь булуы. Шуңа бу мирасны баетырга, тулыландырырга, төп игътибарны аңа юнәлтергә кирәк. Музыкаль театр ачылу исә Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһанов әсәрләрен барлау, аларга яңа караш ташлаудан тыш, яңа опера-балет, мюзикл, оперетта, рок-оперsucceeded тууга этәргеч булыр иде.

Кыскасы, «Кара Пулат»ның куелуы бик вакытлы һәм кирәкле булып чыкты. Татар дөньясында ул чыннан да зур вакыйгага әйләнде. Киләчәктә «Кара Пулат»ны музыкаль, әдәби яктан тирән анализлаган фәнни эшләр дөнья күрер, сәнгати кыйммәтенең ни дәрәҗәдә икәне ачыкланыр. Әлегә исә «Алтын битлек» театраль премиясенең экспертлар советы, музыка белгече Елена Черемных аны «оперетта, мюзикл» номинациясендә «Алтын битлек»кә тәкъдим итү идеясе белән чыкты. Бу үзе үк «Кара Пулат» дәрәҗәсенең югары булуына ишарә.

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ЮКСЫНУ



Соңгы дәвернең илле-алтмыш елы эчендә татар дөньясының иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни хәрәкәтендә азмы-күпме катнашкан һәркем өчен Мансур Хәсәнов исеме яхшы таныш. Ярты гасырдан артык республикада мәйдан тоткан күренекле шәхесләрнең берсе ул. Шуңа күрә дә хәзер инде өлкән буын саналган язучы-галимнәрнең, рәссамнарның, композиторларның яки театр әһелләренең бу зат турында үз фикерләре, үз хатирәләре күптер. Шул исәптән минем дә бар кайбер хатирәләр. Күркәм һәм күренекле бу кешене беркадәр белә идем шикелле. Заманында аның чыгыш-нотыкларын күп ишеттек, күп тыңладык, гыйльми хезмәтләрен укыдык, өйрәндек. Үзе белән дә очрашып, әңгәмәләшкән чаклар да булмады түгел. Шуларның берничәсен, хәтер коесыннан чыгарып, укучыларга бәян итеп китмәкчемен. Баштук шунсын да әйтергә кирәк: бүгенгедән чыгып караганда, ул күпләр өчен шактый «ябык» (закрытый) кеше иде. Шул заман җитәкче даирәләрнең этикасы, рәсми статусы, үсмер чакта ук «лаеш шулпасын» күп татып формалашкан холкы, һәм, ниһаять, таләпчәнлек һәм җаваплылык хисе, теләсә-теләмәсә дә, үзен билгеле бер калыпта тотарга мәҗбүр иткәндер. Хәер, монысы инде безнең хөкем эше түгел.

Мансур аганы беренче күрү 1960 елның көзендә булды. Ул Казан университетының тарих-филология факультетында декан урынбасары булып эшли иде. Мин — әле яңа гына урта мәктәпне тәмамлап, студент булуга ирешкән унҗиде яшьлек үсмер егет. «Ленин укыган университетта укыйм бит мин!» — дип очынып йөргән көннәр. Безнең бүлеккә укырга кергәннәрнең күбесе бездән өлкәнрәк яшьтә: берәүләре армиядә булган, берәүләре кайлардадыр эшләп килгән, кыскасы, өлгергән, күпмедер дәрәҗәдә акыл утырткан, җитлеккән егет-кызлар. Ә без — мәктәпне генә тәмамлаган үсмерләр — «школьниклар» (безне шулай дип йөртәләр иде) авырлыклар белән, зур конкурслар үтеп, укырга кердек керүен, әмма... әлеге өлкәнрәкләр кебек тулы хокуклы студент исемен йөртергә безгә иртәрәк булып чыкты! Хикмәт шунда: без рәсми төстә көндезге бүлеккә укырга кергән исәпләнсәк тә, иң әүвәл бер ел хезмәт практикасы узарга, ягъни производствода эшләргә тиеш, һәм шул ук вакытта... өлкәнрәк яшьтәге курсташларыбыз белән бергә, тулы программа буенча имтиханнар да тапшырырга тиеш икән! Яшьләр укуны гына түгел, хезмәтнең нәрсә икәнен дә белеп, тоеп үссеннәр өчен Хрущёв шундый тәртип керткән, имеш... Теоретик яктан бу гамәл дөрес булса да, чынлыкта безнең хәл мөшкел һәм мантыйкка сыя торган түгел иде. Үзебез — студент, ә лекцияләргә йөрү юк, студентлык билеты бар, стипендия юк... Өстәвенә, яшәү җиребез дә юк, тулай торакта урын бирелми... Без, шәһәр тәртипләрен җүнләп белмәгән яшь-яшь авыл малайлары, көне-төне дигәндәй, эш эзлибез, тегендә барабыз, монда сугылабыз, ә эшкә алмыйлар. Документларны карыйлар да: «Сез бит көндезге бүлектә укучы студентлар, бер үк вакытта укып та, эшләп тә булмый бит ул! Өстәвенә берегезнең дә үзләштергән һөнәре юк...» — диләр. Шулай көннәр буе төрле ишекләргә кагылып йөрибез-йөрибез дә, аптырагач,



*«Казан утлары» журналының 70 еллык юбилее тантанасында президиумнан күренеш. Сулдан уңга: Зилә Вәлиева, Мансур Хәсәнов, Равил Фәйзуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Мостафа Өнәр, Ренат Харис, Әхмәт Галиев. 1992 ел. Казан.*

деканатка, Мансур Хәсәнович янына киләбез. Башка таяныр жиребез юк. Ул безнең сөйләгәннәрне тыңлый, күзлеген төзәткәләп, беркавым сүзсез тора да, телефон алып, шылтырата башлый, кемнәргәдер нәрсәдер аңлата, сорый, аннан безгә борылып: «Бу юлы фәлән оешмага кагылып карагыз әле!» — ди. Әйткән жиргә барабыз, әмма нәтиҗә юк, шул ук бер сүз: «Сез бит студентлар, сез бит фәлән...» Деканатка көн саен диярлек кереп, Мансур аганы (ул вакытта аның үзенә дә 30 яшь кенә булган әле) туйдырып та бетергәнбездер инде. Бер кергәндә, ул безгә болай диде: «Егетләр, хәлегез жиңелдән түгел. Шулай да күңелегезне төшермәгез, һәр авырлыктан үзенең бер чыгу юлы була... Шуны онытмагыз: бүгенге көндә сезнең өчен иң мөһиме — уку. Сез шуның өчен Казанга килгәнсез дә. Берәр жиңелрәк эш табып, тиешле белешмә алып килү җаен карагыз. Әзрәк хәйләкәр дә була белегез. Сездән эш нәтиҗәләрегез турында деканатта сораучы булмас (ул бу сүзләрне серле генә елмая төшеп әйтте), аңладыгызмы?» Аңлаган кешегә аңлашырлык иде бу сүзләр. Берара төрлебез төрле жирләргә таралып, кара эшче булып төзелешләрдә эшләп йөрдек. Соңрак һәр кеше эш мәсьәләсен үзенчә хәл итте. Кайда булсак та, эштән бигрәк, башта-уйда уку гаме иде, төп вакытыбызны уку программасына бирергә тырыштык, нәтиҗәдә тиешле имтиханнарны тапшырып чыга алдык, икенче курска тулы хокуклы, стипендия (22 сум) алышлы студент булдык. Без дигәнең кемнәр иде алар, диярсез. Берсе — Әнвәр Шәрипов, хәзерге көндә әдәбиятчы-галим, филология фәннәре докторы, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы; икенчесе — Рәфикъ Юныс — күренекле публицист, шагыйрь, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; өченчесе — үзем — Равил Фәйзуллин; дүртенчебез — Чистай районының Каргалы авылы егете Шәүкәт Сафиуллин, ни кызганыч, шул елларда фажигале рәвештә вафат булды... Шулай итеп, Мансур ага Хәсәнов белән беренче очрашулардан соң да ярты гасыр гомер үткән. Әгәр үз вакытында Мансур ага безгә төпле киңәшләрен бирмәгән булса, язмышларыбыз ни юлдан китәр иде, әйтү кыен. Алдан күрүчән тәрбияче-остаз булган шул Мансур агабыз.

Тагын бер истәлек-хатирә. Монысы үткән гасырның житмешенче еллар ахырына карый. Мансур Хәсәнов озак еллар (1971-1991) Татарстан Министрлар Советы (хәзерге Министрлар Кабинеты) председателенең урынбасары булып эшләде. Бер үк вакытта, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Республика (соңрак — Дәүләт) премияләре комитеты рәисе дә иде. 1978 елны Язучылар коллективы мине дә бу премиягә тәкъдим итте. Итүен иттеләр, ә мәсьәлә ничек хәл ителер, жиңеп булырмы? Чөнки көндәш-кандидатлар ишле һәм көчлеләр. Язучылар гына да дүртәү. Әле

кемнәр диген! Минннән тыш Туфан Миннуллин, Сажидә Сөләйманова, Эдуард Касыймов... Сәнгатьнең бүтән өлкәләреннән тагын унлап кеше. Ходай рәхмәте белән диикме, ул елны язучылар арасыннан лауреат исеме мина насыйп булды. Ул вакытта мина 34 яшь иде. Бу дәрәҗәле исемне 30 яшькә кадәр язган шигырьләрем тупланган «Шигырьләр һәм поэмалар» китабым өчен бирделәр. Әлбәттә, комитет утырышында кандидатлар турында житди бәхәсләр булган. Соңрак ишеттем: мине Нәжип Жиһанов, Нияз Даутов, Гариф Ахунов, Айрат Арсланов, Харис Якупов һәм башкалар яклап чыкканнар. Әгәр Комитет рәисе Мансур Хәсәновның фикере бүтәнчәрәк булса, мин лауреат була алыр идем микән? (Соңрак бу комитет әгъзасы булып үзем дә байтак еллар тордым һәм андагы хәл-атмосфераны, рәис кешенең ролен яхшы беләм!) Мансур Хәсәновичның шул елның 26 апрелендә кулны кысып әйткән сүзләре һаман колак төбемдә: «Котлыйм! Сина бу премия яхшы шигырьләрең өчен, һәм дә... әдәбиятның киләчәген уйлап бирелде. Сынатма!» — диде. Бу олпат кеше әтием кебек якын тоелды мина ул минутта.

Сүз Тукай премиясе турында чыккач, күнелдә йөргән бер фикерне дә әйтеп үтим. Соңгы елларда бу югары исемгә бик үк лаек булмаган, үзешчәннәр дәрәҗәсендәге кайбер сәнгатькярләр дә лауреат булып куйдылар. Турысын әйтик, Мансур Хәсәнов комитет рәисе булган чорда андый хәлләр күзәтелмәде. Идеологик басым астында кайбер әсәрләргә, темасына карап, өстенлекләр бирелгән очракларны табарга да мөмкиндер, әмма югары профессиональлек һәрчак төп критерий булды ул елларда. Тукай премиясе тирәсендә татар жәмәгатьчелегенең эмоциональ накалы һәрчак бик югары. Объектив булып, алтын урталыкны тотып, гадел эш алып бару жинел булмагандыр Мансур Хәсәновка. Гомумән, Тукай мирасын саклауда, ижатын ил һәм дөньякүләм танытуда М.Хәсәновның хезмәте зур. Кырлайдагы Тукай музеен өр-яңадан төзү эше белән турыдан-туры ул идарә итте. Бу хакта замандашлары күп мәртәбәләр язып та чыктылар. 1986 елны, Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган зур тантаналарның бер үзәк өлеше Кырлайдагы нәкъ ул төзеткән мемориаль музей комплексында үтте дә. Зур горурлык белән искә алам, СССРның төрле почмакларыннан, шулай ук чит илләрдән килгән күпсанлы кунаклар һәм үз ватандашларыбыз катнашкан зур митингны ачу һәм алып бару мина йөкләнгән иде. Бу мактаулы һәм жаваплы вазифаны мина тапшыру да Мансур Хәсәновичның фатихасы белән булгандыр дип уйлыйм. Чөнки бөтен бу эшләрнең башында ул тора иде, ул жаваплы иде.

Ярый, бигайбә, Мансур ага Хәсәновның мина һәм ижатыма мөнәсәбәте турында күпкәрәк китте шикелле. Хәер, бу нәрсә табигый да, чөнки һәр кеше теге яки бу шәхесне үз язмышы, үз күнеле аша күрә, шуннан чыгып аны үзенчә бәяли. Хәзер, шәхсилектән читкәрәк китеп, бүтән-башкалар берлегендә, гомумкүзлектән аңа карашыбызны белдереп карыйк. Үз заманының жәмгыять яшәешендә кем иде соң ул Мансур Хәсәнов? Зур галим һәм дәүләт эшлеклесе. Беркемдә дә бәхәс уятмаслык кыска һәм дөрес бәяләмә. Әйе, галим. Әмма аның дәрәҗәсендәге галимнәр бар бездә. Әйе, дәүләт эшлеклесе. Әмма аның кимәлендәге эшлеклеләр дә юк түгел... Ә менә шул ике югары биеклекне, дөресрәге ике зур сыйфатны үзендә табигый рәвештә берләштергән шәхесләрне табу кыен. Алар юк дәрәҗәсендә. Мансур Хәсәновның уникальлеге әнә шунда, минемчә. Әйтеп үтелгәнчә, ул 20 еллап Татарстан Республикасы Министрлар Советы председателенең урынбасары (соңрак — беренче урынбасары) булып эшләде. Республиканы Фикрәт Табиев житәкләгән чорлар бу. Әгәр ул вакытта М.Хәсәнов урынында башка чиновник эшләгән булса? Әлбәттә, эшләр теләлеп тормас, барыр иде үз жаена. Ә ни рәвешле, нинди нәтижә белән барыр иде? Ф.Табиев ул вакытта яшь, гайрәтле, киң колачлы житәкче-лидер, әмма туган тел, гореф-гадәт, тарихи белем ягыннан милли тәрбиясе сай житәкче. Дуамаллыгы да юк түгел. Әгәр янәшәсендә замандашы һәм вуздашы Мансур Хәсәнов булмаса, рухи-мәдәни дөньябызда «утыннар күбрәк ватылган» булыр иде дип уйлыйм. Мансур ага — чын мәгънәсендә үз халкының асыл улы. Авыл мәктәбен тәмамлап, университетта татар әдәбияты һәм теле бүлегендә укыган, халкыбызның тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белгән милли жанлы зыялы кеше иде. Бөек әдип Галимжан Ибраһимов ижаты буенча беренче белгеч. Әдәбият фәненең үсеш

юлларын билгели алучы теоретикларның берсе. Сүземне дәлилләр өчен, аның хезмәтләренең берсеннән цитата китереп үтәм: «Иң зур проблемаларның берсе: әдәбият белеменең, гомумән, татар әдәбияты белеменең хосусан үз методологиясен булдыру зарур. Аның төп принцибы — фәлсәфи категорияләрне турыдан-туры, механик рәвештә әдәбиятка күчерүдә түгел, ә әдәбиятның, сәнгатьнең, кеше рухы эшчәнлегенең мөстәкыйль өлкәсе икәнлеген тануга нигезләнгән, корылган булырга тиеш. Әдәбият сәясәткә, идеологик күренешләргә өстәмә, иллюстрация рәвешендә түгел, дөньяны һәм кешене образлы танып белү объекты буларак өйрәнелергә тиеш».

Кызганыч, хәзерге көндә республиканың идарә структураларында белеме, интеллекты һәм оештыру сәләте ягыннан Мансур Хәсәнов дәрәҗәсендәге шәхес әлегә күренми.

Һәр зур шәхеснең кылган яхшы гамәлләре күп була. Шулай булырга тиеш тә. Әмма шул гамәлләр арасында иң төбе, иң мөһиме — тарих сәхифәләрендә калырдайлары була. Мансур Хәсәнов мисалында ул — Татарстан Фәннәр академиясе. Үз академиябезнең барлыкка килүе турыдан-туры Мансур Хәсәнов исеме белән бәйле. Ул — әлеге башлангычның төп инициаторы. Республика фән үзәгенә, ягъни Татарстан Фәннәр академиясенә нигез салучы һәм аның беренче президенты. Беләбез, СССР вакытында автономия статусындагы республикаларга үзләренең Фәннәр академиясен булдыру (дөрес, кайберләренең тиешле базалары да булмагандыр) мөмкинлеге бирелмәде. Яна шартларда да төрле кыенлыклар бихисап иде. Сәяси яктан да, озак еллар дәвамында формалашкан стереотип барьерлар ягыннан да... Ниһаять, максатка ирешелде: 1992 елда рәсми рәвештә Татарстан Фәннәр академиясе ачылды. Татарстандагы фәнни оешмалар эшендә яңа этап башланды: ФА канаты астына күп кенә институтлар берләште, яңалары барлыкка килде. Шуларның берсе — Татар энциклопедиясе институты. Бу институтның оештыручысы һәм җитәкчесе дә әлеге дә баягы Мансур Хәсәнов булды. 20гә якын ел эчендә һәрберсе 70-80 табаклар чамасындагы калын-калын томлыклар чыкты. Фән һәм мәдәниятебез тарихында бу бөек ыргылыш булды. (Үз энциклопедиясе булмаган халыкны зыялы милләт дип әйтү кыен. Энциклопедиясезлекнең, икенчерәк әйткәндә, бай тарихың була торып та, мәгълүматсызлыкка дучарлыкның никадәр авыр һәм кимсенүле хәл икәнен иҗат процесында нык татыган буын вәкиле буларак әйтәм моны. Белгән, тойган, кичергән, әмма бөтен нечкәлекләре белән хәтердә калмаган теге яки бу факт турында тәфсилләбрәк белү өчен тупланма-энциклопедияне генә ачып карыйсы урында, күпме вакыт һәм җегәр сарыф итеп, тау-тау китаплар, белешмә-сүзлекләр актарырга туры килә иде! Хәзер исә, рәхим ит, бөтен теләгәнеңне үк табып булмаса да, бик күп нәрсәне энциклопедия томнарын карап аныкларга була). Бу эш М.Хәсәнов вафатыннан соң да уңышлы дәвам иттерелә, хәзерге вакытта планлаштырылган барлык томнар да (рус һәм татар телләрендә алар алтышар) басылып бетү стадиясендә. Татарстан Фәннәр академиясе, Татар энциклопедиясе дигәч, иң әүвәл Мансур Хәсәнов исеме хәтергә килә.

Элегрәк тарихта шәхеснең ролен киметебрәк күрсәтергә тырышу тенденциясе бар иде. Һәрхәлдә без үскән, социализм хөкем сөргән чорда шулай булды. Әлбәттә, шәхестән культ ясарга (анысын да күрдек!) ярамый, әмма шәхеснең ролен, тарихтагы урынын бәяләп җиткермәү дә дөрес булмас. Мансур Хәсәнов зур шәхес иде. Зур хезмәтләре белән милли тарихыбызда якты эз калдырды. Сагындырасың, Мансур абый! Күреп белгәннәр юксына Сине!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

# ИҢДӘ — ҖИҺАН...

Җәүдәт Шәүкәт улы Сөләйманов — Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе академигы, КФУның программалаштыру технологияләре кафедрасы профессоры, техник фәннәр докторы, ТР Фәннәр академиясе вице-президенты, ТР Фәннәр академиясе «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты директоры, КФУның мәгълүмати системалар кафедрасы мөдире, математик лингвистика өлкәсендә Россиядә әйдәп баручы белгечләрдән исәпләнгән галим, «Сәләт» яшьләр оешмасы житәкчесе һ.б.

Бу кадәрле мәртәбәле гыйльми һәм вазифаи юнәлешләр янәшәсенә ШАГЫЙРЬ дип өстәп куюю бераз ятрак һәм хәтта сәеррәк тә тоела сыман. Ә бит аны беренче шигырьләреннән үк күреп алган Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев: «Шигърияттебезгә Сөләйман кебек чын талантның килүе бик сөендерде. Гыйльми фикерне чын татарча әйтә. Бу — минем өчен зур ачыш», — дигән иде.

Шагыйрь иҗатының гаҗәеп бер үзенчәлеге бар: традицион шигърияткә күнеккән күзгә ул бераз үзгәрәк һәм катлаулырак күренә сыман. Чөнки алар үтә күренмәле шигырьләр түгел, аңа, беренче чиратта, күз белән дә, күңел белән ияләшергә кирәк. Әлбәттә, бу аерымлык, Сөләйманның бүгенге заманның эзләнүчән шагыйрьләреннән булуы хакында сөйлидер.

Дөресен әйтим: редактор буларак, мин бик аз китапларга шулай авырлыклар аша якынаям. Шунысы кызык: андый китапларда, гадәттә, зур иҗат яшеренгән була.

Сөләйманның «Сүтелә йомгак...» (2011) китабын эшләү вазифасы миңа йөкләнгәч тә, башта каушап калдым. Кинкырлы бу иҗаттагы тирәнлекне тоемлап бетерә алырмынмы, дип курыктым. Хәер, шигъриятне һәркем үзенчә аңлый ласа! Тукаебыз тикмәгә генә: «Фикерегезне язгыз, тик якты булсын фикерегез; Фикерегездер — фикеребез һәм фикеребездер — фикерегез», — димәгәндер. Шагыйрь фикере — кыйммәтле фикер, һәм ул берничек тә үзе өчен генә була алмый шул. Мин дә Сөләйман дөньясын үземчә ачтым. Китапның: */ Һәр җанлының үз әмәле, / Үзенә хас үсү мәле... / Бамбук үсә өскә, өскә, / Умырткасын тота көчкә, / Сөямләп үлчи тәүлек, /* — дигән шигырь белән башланып китүе дә тикмәгә генә булмагандыр. */ Биеклекне бамбук даулый, / Гасырларда имән шаулый, /* — дип тәмамлана ул шигырь. Әлбәттә, кульязманы укып, танышып чыккач та, мин шагыйрьне меңьяшәр имән итеп күз алдына китергәнмендер. Шагыйрьнең Кояш астындагы олуг миссиясен ул үзе дә ассызыклап куя бит, «Милләт эзе җирдә — шигырьләр», — ди. Ә аларда, әлбәттә, халкыбыз язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында кайгырту-уйланулар... */ Олаулап татар сагышы, / Бәгыре челтәр-челтәр... /*

Аның һәр шигыре бары тик Сөләйманга хас; сурәтләү алымнары да оригинальлеге белән башкалардан аерылып тора һәм һәр шигырьнең үзегендә тормышчан матурлык яши. Чөнки шагыйрь соклана белә, үзе артыннан укучысын да дөньяга сокланып карарга мәҗбүр итә. */ Арыш мыегын кытыклап / Тибрәнә көмеш рәшә, / Рәшә белән тияр-тимәс / Арыш нидер серләшә. / Кояш нуры чак-чак сыйпый, / Чү! Болыт, каплый күрмә, / Әнә, җил дә исми хәтта, — / Югалды Зирекледә. / Бу бит тылсым, могҗиза, дип, / Тын тора йөрәк — сизгер, / ...Тургай җыры кагылса да / Югалыр күк бу мизгел. /* Йә, сокландырмыймы бу шигырь? Туган якка мәхәббәтне арттырмыймы? Гүя шагыйрь уйлап-язып азапланмаган, әйтерсең аны табигать бер могҗиза итеп илаһи күкләрдән иңдергән. Шагыйрь үзе соклана белмәсә, башкаларны да сокландыра алмыйдыр шул, минемчә. Шигырь һәркемне туган ягын уйларга мәҗбүр итсә дә, без үз хисләребезне тоя төшеп, җанга якын бу галәмияткә бер мизгелгә Сөләйман күзләре аша карыйбыз. Һәм күңелдә офыкларның киңәеп

китүен, матурлыкның тантана итүен тоябыз. Болай гына да түгел, бер яктан табигать белән шагыйрьнең аерылгысыз бербөтен икәнлеген, аның сулышы, кичерешләренең төрле бизәк-сурәтләр аша бирелүен күрсәк, икенче яктан, ул чагылдырган табигать аша шагыйрьнең күңел тирәнлеген, рухи киңлекләрен дә тоемлыйбыз.

Әлбәттә, сокланып һәм сокландырып язган шигырьләр генә түгел, авыл язмышы өчен борчылып язган шигырьләр дә аз түгел шагыйрь иҗатында. / *Язмыш йомгагының җан-җепләрен / Таушалдырган иде җил-давыл. / Өзгәләнгән меңләп гасаб җебе — / Ничек түздең шуңа, и авыл?!.* /

Борчылу, әрнү, гамь — шигъриятнең бизәкләре. Алардан башка чын шигърият була алмыйдыр. Сөләйманда ул әрнүләр күп очракта халык җаны белән тоташа. Ә халык шигъриятгән һәрчак күңелен яклардай дөреслек эзли. Кемдер, укып: «Мин уйлаганны ничекләр оста итеп әйткән бит!» — ди икән, бу — шагыйрь өчен зур җиңү инде. Чын дөреслекне әхлакый югарылыкта яза алган шагыйрьләрен генә тарих гасырлардан-гасырларга алып чыга, һич югалтмый саклап килә.

Шагыйрь эзләнә, үзе күргәнне башкаларга күрсәтергә тырыша, сүздән сурәт ясый. / *Оныткан да ник искәнен, / Игеннәрне ишә-ишә, / Нидер эзләп азаплана / Тынгы җуйган яңгыр җиле. / ...Ә башаклар һаман яңгыр көтә...*

Шагыйрьнең туган якка, туган авылына бәйле шигырьләре бүгенге вазгыятьне ап-ачык күз алдына китерә. Хәер, чишмә, хәтта елгаларның кибүе, авылларның җир өстеннән җуела баруы, шуңа бәйле рәвештә, халкыбызның рух, моң чишмәләренең дә кибүе кемне генә борчымый икән соң? / *...Олы елган моңсу-боек, / Читләшкән сыман елгаң, / Күңелле түгел миңа да — / Ах, каенлык югалган...* / — ди шагыйрь.

Әйе, яхшы шигырьнең һәрберсе үзенчә тәэсир итә. Хәер, сүз сәнгатенең чын асылы шундадыр да. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк: / *Яшәешнең тәме бетә, хис яшькә әйләнмәсә, / Күңелләрнең тибрәнүе бәгырьгә бәйләнмәсә.* /

Сөләйманда хисле укучы өчен дә, гамьле укучы өчен дә шигъриятнең колачы җитәрлек.

Аның күп кенә шигырьләрдә строфалар, шигъри үлчәмнәр бөтенлеген сакламаганы сизелми дә кала, чөнки укучыны фәлсәфи фикер үзенә бөтереп ала. Ул сүзләр белән гаҗәеп ирекле идарә итә, һәр очракта да аларны җиңел буйсындыра һәм беркайчан да сәнгати бөтенлекне җуймый. Шагыйрь сүзнең олы сәнгать икәнен яхшы белеп эш итә. Фәлсәфәсе дә яшәү, тормыш, халык язмышы турында уйланулардан гыйбарәт. Әйе, мәңгелек уйланулар, бер чорда да актуальлеген югалтмый торган темалар...

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы да фәлсәфәгә уралган, аларның да үзенә тарту көче аз түгел: горур, шул ук вакытта тугрылыклы, самими, садә. Сөләйман шигъриятендә мәхәббәт — яшәешнең асылы ул. Сөләймангача мәхәббәт шигырьләре никадәр күп язылса да, бер әсәре дә, болай әйтүчеләр булды лабаса, дип уйларга урын калдырмый. Ул аны үзенчә күрә, үзенчә олылый. / *Җылы сүз дип, / синнән өметләнмим, / Кояш нурларында туңсам да. / Тик нигә соң гел тоясым килә / Күләгәнне генә булса да...* /

*Яки:* / *Иңдә — җиһан, / Билдә — офык, / Аяклар очак иде... / Абынып / очтым упкынга... / ...ул синең кочак иде.* /

Чын мәхәббәткә мәңгелек итеп карау, сөю балкышында гомернең төрле төсмерләрен чагылдыру — монысы да шагыйрьнең табышыдыр. Хәер, ике йөрәкне бәйләүче нәфис хисләрдән торган мәхәббәткә караганда, туган җиргә, туган якка, сөйгән халкына булган мәхәббәт күпкә алкынрак, куәтлерәк сыман Сөләйманда. Сөйгәне өлешенә тигән сөюне ул, яман күзләрдән саклагандай, бик яшеренеп кенә, сагыш пәрдәсе аша гына күрсәткәндәй итә. Ә сөюе ихлас аның. Мәхәббәтнең илаһи бөеклеге, чын мәгънәсе — тугрылыкта, гомер көзләренә якынлашканда да, «җанкисәгем» дия алудадыр... / *Җирдә әле матурлык аз түгел, / Матурлыкка бишек безнең күңел, / Мәхәббәтне таный безнең күзләр, / Көмеш чыңлы булсын безнең сүзләр дә,* / — ди ул «Җанкисәгем Венерага» дигән шигырендә. Шагыйрь әйткән сүзен яратып һәм ышанырлык итеп әйтә шул.

Тирәннән, күңел төпкеленнән килгән аһән безне шагыйрь дөньясыннан аермый тота, еш кына үзебез яшәгән заман турында уйларга мәҗбүр итә. / *Бу заман язгы елга кук,* / *Юк әле тынар чагы,* / — дип яза шагыйрь. Ә бит, баксаң, һәр заман язгы елгага тиң булган. Бу хәлне без Сөләйманның шигырь-поэмаларында аеруча ачык күрәбез. Әмма алтын казык — татар бер чорда да үзен-үзе югалтмаган! / *Төрки тамыр — алтын казык,* / *Шул тамырдан татар,* / — дию дә тикмәгә түгелдер аның.

«Җиде казык тота минем бар дөньямны», — ди шагыйрь икенче бер шигырендә. Җиде казык — җиде бабагача сузылган нәсел шәҗәрәсе. Җиде буыннан соң нәселне бәйли торган җепләр тулаем өзелеп бетә, ди галимнәр. *«Мин үзем дә казык»*, — ди ул шул ук шигырендә. Ягъни Шакир мулла, Сөннәтулла муллалар нәселенең дәвамчысы. Җәүдәт Сөләйманның туган җире Чувашстан Республикасының Батыр районы Кызыл Чишмә авылы булса да (бабасы Сөләйман исә Буа районының Үти авылы мөәзине), әбисе ягыннан нәсел җепләре Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылына тоташа. Бусы — минем дә туган авылым, һәм безне бер үк нәсел җепләре бәйли. Моның белән мин аеруча горурланам! Җәүдәт абый — гаҗәеп туган җанлы зат, шуңа да туган-тумача, якыннарыбыз турында һәрчак кызыксынып-сорашып тора. Җиде буынгача муллалардан торган нәсел тарихын барлый, өйрәнә, шәҗәрәсен төзи. Хәер, монысы сүз уңаенда гына. / *Нинди серләр саклыйсың син, туган җирем?* / *Күргәнсеңдер манарадан Болгар илен.* / *Сизмәдем дә, кай арада истең соң син,* / *Тарап үттең тамырлардан, Вакыт җиле?* /

Шагыйрь үзенең тамырларына, халкыбызның тирән тарих катламнарына аеруча сак мөнәсәбәт, җан җылысы аша кагыла. Ул аның «Таш язмалар», «Тамырлар», «Иске Казан» кебек поэмаларында тагын да ныграк сизелә. / *Җил уйнады тулпар ялларында,* / *Җил көйләде кучеп кылдан кылга,* / *Хатирәләр буйлап алып кайтты безне* / *Бөек Биләр кыйбла булган чорга...* /

Поэманы укыганда, йөгерек аргамакларның тояк тавышлары ишетелгәндәй була, галиҗәнап Алмас хан гүя каршыга үзе килеп баса: / *Җир-ана, аңлыйм ла мин,* / *Утлы дәва бу.* / *Йөгән сыман* / *Мәгърур Болгар баласына.* / *Әмма бүген* / *Дин дә түгел,* / *Ден дә түгел,* / *Сайлау бара* / *Үлем белән яшәү арасыннан».* / *(«Тамырлар»)*

Шагыйрь туган авылында бәрәңге алганда да, күңеле белән Бөек Биләрдә — Алмас хан янәшәсендә яши. Халкыбыз җуйган биеклекләр өчен әрнеп, янә якты кыйбласына алып чыгар юлны тарихыбызның тирәнлегендә һәм әлегәчә яшәү көчен югалтмаган тамырларда күрә. Ә халкыбызның үткәннәре гыйбрәтле, легендалар, риваятьләр аша күпләргә таныш та. Биләр — X-XIII гасырларда гөрләп торган болгар шәһәре. Шагыйрь әйтүенчә, зурлыгы һәм халык саны буенча Биләр урта гасырның Киев, Париж, Рим, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләренә тиң булган. Һәм Биләрдәге Кызлар тавы да тарихи риваятьләрне вакыт җилләреннән әлегәчә саклап килә. Риваятьләргә караганда, Биләр кызлары (40 кыз) шул тауда кирмән төзеп, шәһәрне монгол явыннан — дошманнардан саклаганнар. Әмма дошман көчле булып чыккан: кызлар һәлак булганнар. Икенче бер риваятьтә бәян ителгәнчә, дошманнар, кызларның үзләреннән туфрак ташытып, тау өйдерткәннәр дә уникe кызны шул тау итәгенә күмеп калдырганнар...

Кызлар тавы атамасы менә шуннан калган ди...

Сөләйманның «Тамырлар» поэмасын укыганда, Биләр кызларының ил-җиргә тугрылыгы аларның күңел халәте аша ачыла. / *Дошман сунсен көл белән,* / *Очсын җилгә көл булып.* / *Әфсен-төфсен, таң килсен,* / *Дошман явыз җан бирсен!* / — диләр алар. Тик кызларның теләгән җил алып китә. Ә мәгърур Кызлар тавы әле дә шул үлемсезлекне саклап тора кебек. Шуңадырмы, бүгенге ватанпәрвәрлек житенкерәмәгән бер заманда шагыйрьнең поэмалары аеруча тансык тоела. / *Уникe сын булганчы,* / *Уникe йолдыз булыйк.* / *Дошманга кол булганчы,* / *Ай-кояшка кыз булыйк...*

Сөләйман үзенең поэмаларында борынгыдан килгән миф-риваятьләрне, халык әлегәчә саклаган мон-аһәңнәрен һич югалтмыйча, тагын да тирәнәйтә төшеп тасвирлый, фантазиягә юл куеп, аларны үзләре яшәгән чынбарлык кысаларыннан этеп чыгармый. Хәтер һәм тарих аның иҗатында иң изге төшенчәләр булып кала бирә. / *Тере хәбәр булып шыттым* / *Мин — Атилла оныгы,* / — ди ул бер шигырендә.

Кыскасы, Сөләйман үткәннәрне бүгенгегә сәнгати осталык аша тоташтыра, гүя шулай халкыбыз өчен киләчәккә барыр юлны җуймаслык җирлек әзерли.

Шуңадыр ул татарның талантлы балаларын үз янына туплый, аларга ярдәм булып киләчәккә барыр юлны күрсәтә. 2012 елда «Сәләт» аланында ясаган чыгышында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Җәүдәт Сөләйманның Татарстанда фән үсеше һәм мәгарифкә кагылышлы хезмәтләрен, «Сәләт» фондын үстерүдәге уңышларын югары бәяли. «Ватаным Татарстан»газетасы редакторы Миңназыйм Сәфәров сүзләре белән әйтсәк: «Татарның булдыклы балаларыннан милләт горурлыгына әверелерлек зыялылар тәрбияләү белән шөгыльләнүче милләтпәрвәр ул!»

*/ Былбыл телле былбыл сайрап яши, / Татар теле яши татарда. / Татар телен йотмый дөнья комы, / Татар телен йота татарлар. / Бу әрнүле сүзләр агу түгел, / Әче дару, татар, җанына. / Бар теләгем — яшәү уты салу / Чыңгызлардан килгән канына... /* — дип юкка гына әрнемидер шагыйрь җаны.

Әлбәттә, бу өметсезлек түгел әле, бары тик Тукайча халыкны уятырга тырышу өчен, мишәрчәләп әйтсәк, «янбызына берне төртеп алу гына». Өмет тулы шигырьләре исә аның тулпар сыман чорлар аша чорларга ыргыла. */ Күлтәгин ташына бәйләнсә күңелдә / Канатлы тулпарлар, әй, чит-ят кавемнәр! / Без исән! /* — ди ул.

Сөләйманны берәүләр элитар шагыйрь, берәүләр исә трагик шагыйрь, дип ассызыклый, мин исә гади укучы буларак, үз күзәтүләремнән чыгып, милли шагыйрь дип тә өстәр идем.

Аннан, Сөләйман иҗатын игътибардан читтә калганнардан санамыйм. Ана халык шагыйрьләре Ренат Харис, Равил Фәйзуллиннар, галимнәр Тәлгат Галиуллин, Рифә Рахман һ.б. игътибар иткән. Һәрберсе тарафыннан саллы-саллы фикерләр әйтелгән, иҗатка тулаем анализ ясалган. Минем алардан соң кулга каләм алуым, әлбәттә, нииндидер яңалык әйтәм, дип түгел, «Сүтелә йомгак...» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабының редакторы буларак, үземнең күңел кылларына кагылган серле шигъриятне укучылар белән уртаклашасы килүдән генә. Бу шигъриятнең чып-чын мишәрчә яңгырашы да әллә ничек күңелемә якын шул!

Галимнәребез дә, язучыларыбыз да моны сизми калмаганнар.

Әйе, укучыга барып ирешү юлында иҗатның зурлыгын үлчәмнәргә салучылар булганда, шигърияткә карата кызыксыну да кимемәс кебек. Шунысын да әйтеп үтик: Сөләйман иҗаты 2014 елда Татарстан Язучылар берлеге һәм ТР Мәдәният министрлыгының Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премиясенә лаек булды. Бу — иҗатка зур бәһа инде.

Ә Җәүдәт Сөләйман үзе: «Мин күңелемдәгене генә язам», — дияргә ярата. Шигърият — кеше күңеленең яп-якты бер чагылышы ул. Шуңа чиксез тирән ул, кешелекле һәм ихлас ул, садә ул...

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА**

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез Җәүдәт Сөләйманга 60 яшь тула. Юбилее белән котлап, саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез!*

# САФЛЫККА МАНЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Сизәсезме, жирдән сафлык китеп бара... Һава тоныклана, чишмәләр болгана, жир агулана, күнелләр карала... Тәнгә дә, жанга да саф ризык табу көннән-көн, елдан-ел авырлаша...

Хәер, ялгышам, хәлләр бөтенләй үк өметсез түгел, бар ул яктылык, күләгәдә калырга хакы булмаган матурлык, сафлык бар әле! Иң мөһиме — аны эзләүчеләр булсын!

Минем сезне гажәеп талантлы, бары сафлыкка гына хезмәт итүче каләм иясе белән таныштырасым килә. Бу сүзләр сәер яңгырый, әлбәттә. Аның исеме инде күптән бар укучыга таныш булып, телдән төшмәскә, ә китаплары исә кулдан-кулга йөрергә тиеш. Әйләнгән саен йөзе экранда балкымагач, шау-шулы бәйрәм-кичәләрдән читтәрәк йөргәч, аны танучылар сирәктер. Артык тыйнак кеше ул Фирүзә. Үзен күрсәтеп йөрергә әрсезлеге дә, вакыты да юк, муеннан эшкә чумган: көннәре генә түгел, төннәре дә кеше әсәрләрен укып-тикшереп үтә. Дәүләт эше язучы өчен бик кадерле, кирәкле булган вакытны гына түгел, кайчакта саулыкны да урлый, күнелдә бөреләнгән күпме әсәр чәчәк атмый кала... Кулымнан килсә, бу талантлы каләм иясенә, иҗат итү өчен бөтен мөмкинлекне тудырып, уч тутырып акча бирер идем дә:

— Син яз гына, үз әсәрләренне яз! Син милләткә бик кирәкле, бик кадерле зат! — дияр идем...

Әмма үзем дә шул ук хәлдә, казна эше аяк-кулны бәйли. Ходай биргән сәләтне, санаулы елларны, вак-төяккә сарыф итмичә, бары иҗатка гына багышлый алган бәхетле язучылар безнең заманда бик сирәктер шул...

Хәер, сүзем бит каләмдәшем Фирүзә Жамалетдинова турында иде. Матбугатта басылган беренче шигырь-хикәяләре белән танышкач та:

— Бу кадәр киң колач, күнел сизгерлеге, акыл-зирәклек кайдан килә? Тамырларың бик затлыдыр синең, — дип сокланган идем.

Чынлап та, укымышлы муллалар нәселеннән икән. Шөкер, үзләрен юк итәргә теләсәләр дә, орлыклары сибелеп калган. Саф, таза, уңдырышлы орлыклар. Алар нинди жиргә килеп төшсә дә, яшәргә көч таба, кояшка үрелә, уңыш бирә.

Фирүзәнең «Еллар кәрваны»н укып та, биниһая карт, иске бу дөньяда шулкадәр яналык таба алуына гажәпләнгән идем. Һәр шигырь — үзе бер галәм, һәркайсында — камиллек, нәфислек, фикер тирәнлеге, офыклар кинлеге, эчеп туймаслык сафлык, акыл-хис... Әлеге китабы өчен шагыйрә зур бәя алды, ана Һади Такташ исемендәге әдәби бүләк бирелде.

Фатих Хөсни исемендәге премиягә дә күптән лаек ул. Чөнки Фирүзә Жамалетдинова талантлы шагыйрә генә түгел, гади генә вакыйганы да притча дәрәҗәсенә күтәрә алган оста хикәяче дә. 2013 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән соңгы китабына аның илле дүрт хикәясе тупланган. Китап шулай дип атала да: «Хикәяләр». Кыска, жыйнак әсәрләр алар, әмма бәрәкәтле: уч кадәрле жирдән дә зур уңыш жыеп аласың. Әсәренең беренче юллары белән үк укучыны үз артыннан ияртергә сәләтле Фирүзә. «Ни булган, бу кыйсса ничек тәмамланыр?» дигән сорауларга жавап табарга теләп ияр ана укучы. Һәм таба да! Чөнки язучы беркайчан да юлдашының өметен алдамый, ярты юлда ташлап калдырмый. Һәр хикәядә сер бар, аларның тарту көче дә шунда бугай. Укучы шул серне белми торып әсәрдән аерылмый, хәтта соңгы ноктасына житкәч тә, аның тәэсиреннән айный алмый, тормышка автор күзлеге аша карап, үзе өчен ниндидер яналык ача, сабак ала, уйлана, бәяли, акыл жыя...

Һәр язучы әдәбиятка үз сүзе, үз дөньясы белән килә, телиме ул моны, теләмиме, әмма әсәрләре аша аның шәхесе ачыла. Фирүзәнең зирәклегенә, күнел сизгерлегенә, үз геройларына булган хөрмәт-мәхәббәтенә сокланырлык. Кешеләрне, тормышны белмәгән-яратмаган иҗатчы әйбәт әйбер тудыра алмый. Мина калса, һәр әсәрне биеклеккә күтәрүче, күнелләргә сендерүче көч — мәхәббәт ул. Кешене мәхәббәт яшәтә, ди Фирүзәнең бер герое. Үзе дә иҗаты белән шуны раслап килә. Укучы шул ихлас мәхәббәтне тоя, язучыга ышана, аның белән янәшә атлый, уй-фикерләрен жанына сендерә, аннары теләмичә генә

саубуллаша. Бу әсәрләрдә гүя ки син дә яшисен. Җан рәхәтлеге белән укыла ул хикәяләр, турыдан-туры күңелгә юл яра. Кайсы шатлык, кайсы моңсулык белән кагыла. Әйе, чынлап та шулай, һәр әсәр үз эченә бөтереп алып кереп китә дә, сине җылы кочагыннан җибәрми тора. Күңелне әсир итү дигәнең шул буладыр, күрәмсең.

Фирүзә Җамалетдинова табигать күренешләрен зур осталык белән сурәтли. Әсәрләренә туган теленең бар моңын, бар тәмен сеңдереп яза: «Кояш көне буена кырмыскадай кайнашкан мәшәкатьле галәмгә текәлеп, һәммә тереклекне ихлас сөеп, көлеп тора. Әкрен искән җилдә мәңгелек белән өр-яңадан очрашкан җете нәни яфраклар лепердәшә. Кояш җылысын тоеп, җир куеныннан калкып чыккан ямь-яшел үлән кыяклары өстеннән назлы җил тәгәри. Көтүченең әле тамчы да очы китмәгән өр-яңа чыбыркысының саңгырау тавышы ишетелә...» Шул күренешләр аша язучы туган җиргә булган самими, җылы хисләрен, олы мәхәббәтен генә түгел, тирән сагышын, ил язмышы өчен борчылуын да сиздереп куя кебек: «Урамда буран, тәрәзәләргә ябышып, эт өргән тавышлар чыгара. Морҗа тишегеннән кереп улый. Җиле дә булышчы, өйнең җылысын суыра...»

Кеше күңеленең төпсез коеларын айкый Фирүзә. Укучы игътибарын шаккатмалы сюжетлар белән түгел, барчабызга да таныш булган гадәти күренешләр белән җәлеп итә. Әдибә сизгер һәм күзәтүчән, әйтерсең, тормышны уч төбенә салып, үзенә кирәкле энҗе бөртекләрен сайлап ала. Хикәяләрне укыганда, заман сулышын тоясың, күңелләр аша чорыбызның җылы да, салкын да җилләре уза сыман.

Фирүзә үз халкының яшәешен, йөрәк тибешен аңлап-тоеп яза. Турыдан-туры кычкырмыйча, гыйбрәтле язмышлар, сискәнерлек күренешләр аша милләт яраларын күрсәтеп, җан әрнүен сиздереп куя, акыл сатмый, нәсыйхәт укымый, әмма киләчәк турында уйланырга мәҗбүр итә. «Васыять», «Тамырлар», «Язмыш җиле», «Җину», «Себердә», «Кеше күңеле — кара урман», «Хата», «Хыянәт» кебек хикәяләрдә халкыбызның сокланырлык сыйфатлары, күркәм гадәтләре белән бергә бүгенге фаҗигасе, үкенечле югалтулары да чагыла.

Геройларын ал төсләргә манмыйча, тормыштагыча табигый итеп күз алдына китереп бастыра Фирүзә. Портретлар тасвирлап мавыкмый ул, күз-каш сурәтләми, чөнки аның өчен кешенең төс-кыяфәте түгел, җаны-күңеле беренче урында. Фирүзә Җамалетдинова хикәяләрендә образлар вакыйга, күренешләр аша түгел, ә киресенчә, вакыйганың асылы геройның кичерешләре, уй-фикерләрләре, сүзләре аша ачыла. Моң-сагышлары, сөю-нәфрәтләре, әрнү-шатлыклары белән күңелгә кереп кала алар. Оныгы өчен шәһәрдә татар мәктәбе ачтырырга теләп, әмма шәһәр башлыгына эләгә алмыйча, ахыр чиге, очратып сүз кату өмете белән, аның артыннан теннис, хоккей, футбол уеннарына йөрүче фидакарь карт та, тупас, әдәпсез «Кыш Бабай»ны күреп, балачакның матур әкиятен бер мизгелдә югалткан сабыйлар да, авыл болыннарына, шул болыннарда чыбыркы шартлатып йөрүче көтүчегә гашыйк хыялый хатын да, яраткан улы белән аралашудан мәхрүм калган чарасыз ата да, каладагы бер тукталышка исеме бирелгән Комаровның кем икәнен ачыклап-төпченеп йөрүче тынгысыз агай да, шигырьләр яза-яза ил буйлап югалган улын эзләп йөрүче сагышлы ир дә, яңа туган оныгы муенында тәре күреп сискәнгән, нәселенең киләчәген югалткан татар хатыны да, хәтта ирек белән хуҗаларын бер үк дәрәҗәдә сөйгән тугры эт тә — барысы-барысы укучы күңелендә якты эз калдыручы образлар.

Ә бит кайсыбер геройларның хәтта исеме дә юк, «ир, хатын, карт, оныкмалай, карчык» кына алар. Бу мөһим дә түгел кебек. Аларның әрнү-борчулары, нәни куанычлары, тыйнак бәхетләре аша заман пәрдәләре ачыла, барча төсләре белән балкып, тормыш үзе күзгә карый.

«Язмыш җиле» хикәясен генә алыйк. Ул шундый юллар белән башланып китә: «Бала табу йортының җилфер ишеге котны алып чыелдап ябылды». Шул сүзләре белән үк язучы укучыны ниндидер фаҗигагә әзерли. Әнә бит болыттай ак халатлы шәфкать туташы да уйга батып барган хатынга дәшә: «Әллә үле туган бала сезнекеме?» Димәк, нидер булган. Әмма хатын бала турында түгел, никтер әнисен уйлап бара икән. Бары җилгә генә дәшә: «Оныгымны югалттым... Юк, ул исән үзе...» Алайса, ник шулкадәр борчулы соң бу хатын? Сер хикәя ахырында гына ачыла.

— Ник елыйсың? — дип сорады киленем һәм гаҗәпләнеп күземә бакты.

— Нигә тәре тактың балага? — дидем мин.

Үзенә менә дигән егет үстереп биргән татар анасына урыс килене берни булмагандай тыныч кына җавап бирде.

— Аны мин тудырдым, әнкәй. Исемен Андрей куштырам.

Дөньяга яңа аваз салган нарасыйның үзенә дә, нәселенә дә ят булуын тоя хатын. Бу фаҗига түгелмени?! Чит кавем кешесе белән кушылырга ниятләгән егет-кызларыбыз укысын иде әлеге хикәяне, мондый ялгыш-югалтулардан саклансыннар иде.

Сафлык бөркеп торучы затлы, югары сыйфатлы хикәяләр генә тупланган бу китапка. Җирдәге һәр җан иясенә рәхим-шәфкатьле булып, күңелдә мәхәббәт утын сүндермичә, бары игелек кылып яшәргә өндәгән уйлы-гамьле бу әсәрләргә әдибәнең акыл һәм күңел сафлыгы сеңгән. Яшь буынны кешелекле, иманлы итеп тәрбияләр өчен менә дигән кулланма алар.

**Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА**

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез Фирүзә Җамалетдинова үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

## *Безнең календарь*

### Абдулла Әхмәтнең тууына 110 ел



Абдулла Әхмәт (1905-1976) 1905 елның 25 мартында хәзерге Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериный дигән татар авылында туа. Утызынчы елларда хикәяче буларак таныла, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр булып та эшли.

Абдулла Әхмәт сугышның беренче көннәрендә үк фронтка китә, алгы сызыкта гади солдат була, яралана, госпитальдән соң — янадан алгы сызыкта. 1943 елдан башлап сугыш беткәнчегә кадәр ул «Алга, дошман өстенә!» исемле татарча фронт газетасында хәрби мөхбир булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Абдулла Әхмәт проза һәм драматургия жанрларының һәр икесендә дә нәтиҗәле эшли.

### Әдхәт Синугылның тууына 80 ел



Әдхәт Синугыл (1935-2004) 1935 елның 15 мартында Башкортстанның Эстәрлебаш районы Куганак-Баш авылында туа. Армиядән кайткач, авыл мәктәпләрендә укытучы, мөдир, китапханәче, Миякә район газетасында тәрҗемәче булып эшли. 1959-1964 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем алгач, тарих, татар теле һәм әдәбияты укыта башлый. Бераздан Казанга күчеп килеп, «Ильич юлы» (хәзерге «Биектау хәбәрләре») газетасында тәрҗемәче, соңрак район радиоузелендә радиотапшырулар мөхәррире булып эшли. 1967-1970 елларда Татарстан китап нәшриятында — мөхәррир, ә 1971-1977 елларда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә әдәбият бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

Ә.Синугыл балалар өчен бик күп шигырь-поэмалар яза, тәрҗемәләр белән дә әдәбиятка үзеннән зур өлеш кертә.

# ЗАМАН ПРОЗАСЫНДА — ЧОР СУЛЫШЫ

*Яңа гасырга аяк басканга да унбиш ел булган. Әдәбият тарихы өчен бу бик азмы, әллә XXI гасырның инде үз сүз сәнгате формалашырга вакытмы? 2014 елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан эпик әсәрләргә багышланган «түгәрәк өстәл»дә әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр шул хакта фикер алышты, түбәндәге сорауларга җавап эзләде:*

***– Бүгенге көн татар прозасының торышы, үсеш тенденцияләре, эволюциясе нинди? Кайсы темалар өстенлек итә?***

***– XXI гасыр прозасы — капма-каршы ике яр арасында: заман укучысының әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып язу, аның ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм классик чорлардан килгән әдәби закончалыкларны, традициональлекне саклау. Бүгенге прозада уңышка ирешү өчен, иҗат кешесенә кайсы юлны сайларга кирәк? Алтын урталыкны ничек табарга?***

***– Татар прозасын тугандаш халыкларга һәм дөнья аренасында таныту — тәрҗемә эше милли ихтыяҗларны канәгатьләндерәме? Иҗат конкурслары бүгенге прозаны үстерүдә нинди вазифа башкара? Алар әдәби кыйммәткә ия зәвыклы әсәрләр тууга этәргеч бирәме, әллә шөһрәт артыннан куу гынамы?***

***– Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр тел вазгыятенә дә шактый кискен «бәрелде». Бу XXI гасыр прозасы телендә чагылыш таптымы? Хәзерге язучы сүз тәмен ни дәрәҗәдә тоя?***

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА, филология фәннәре докторы:**



«Казан утлары» журналын чын мәгънәсендә татар әдәбиятының хәл-халәте күрсәткече дип атарга мөмкин. Күләмле әсәрләрне тиз арада, «табадан төшүгә» укучыга ирештерә торган башка әдәби журналыбыз юк. Димәк, иҗади тәҗрибәләр ясау мәйданчыгы да, милли әдәбиятыбызда барган тенденцияләрнең көзгесе дә ул.

2014 елны журналда проза әсәрләренең саны да, сыйфаты да үсү күзгә ташлана. Моның сәбәбе нәрсәдә: берникадәр торгынлыктан соң прозада гомуми күтәрелеш башландымы, әллә инде бу факт редакциянең сәясәте үзгәрү белән бәйлеме — әлеге сорауга җавап бирү авыр. Әмма шунысы хак: «Казан утлары»ның 2014 елгы һәр санында диярлек милли әдәбият өчен ачыш, табыш булырлык әсәрләр тәкъдим ителде.

Сүзне гомуми тенденцияләрдән башлыйсы килә. Әлбәттә, татар әдәбиятындагы тема ягыннан чикләнгәнлек, «хәзерге» тормышны сурәтләүгә дәгъва иткән авторларның нигездә үткәнне искә төшереп хикәяләве, сюжетта авыл тормышының яки авылда үскәннәрнең шәһәргә китүе үзәккә куелу — гомумбилгеле сыйфатлар. «Җепшеклек» елларында һәм ике гасыр чигендә шәһәр, зыялылар тормышын сурәтләп матур-матур романтик әсәрләр биргән, интеллектуаль проза үрнәкләре, шартлы-фәлсәфи текстлар тудырган әдәбиятыбыз бу юнәлешләрдә бик авырлык белән хәрәкәт итә. «Үткән» — бүгенге әдәбиятыбызның төп сурәтләү объекты булып кала. Матур тел белән, кеше психологиясен һәм тормышны, милли үзенчәлекләрне белеп язылган әсәрләрдә (әйтик, Ә.Моталлаповның «Гамь» романы кебек) дә шушы традиционлыкны билгеләп үтмәү мөмкин түгел.

Шулай да аерым бер яңалыклар: темалар яки алымнарда янарыш, форма өлкәсендә тәҗрибәләр ясау омтылышы үзен сиздерә. Ләкин текстларның күп өлеше татар әдәбиятында күзәтелә торган төп кимчелектән, вакыйгаларны күрсәтеп-сурәтләп түгел,

сөйләп бирүдән азат түгел. Прозада публицистик хикәяләү матур әдәбият әсәрләренең эстетик кыйммәтен төшерә торган сыйфат буларак саклана. Минем фикеремчә, XXI гасыр өчен актуаль темаларга кагылу форма яңалыкларына да юл ачар иде. Яңа форма — эчтәлекне, яңа эчтәлек форманы үзгәртүгә сүз сәнгатендә табигый.

2014 елны журналда басылып килгән проза әсәрләрен күзәтү менә шундыйрак гомуми нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Нindirәк яңалыклар бар соң? Шиксез, хикәя прозадагы үзгәрешләргә сизгер, янарыш һәм үсеш кичерүче жанр булып кала. Заман хикәясендә татар әдәбияты өчен традицион алымнарның — психологизм, фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килү, эмоциональлек, символлар теле белән эшләүнең — яңа мөмкинлекләре барлана. Болар матур нәтиҗәләргә китерә. Журналның беренче санында тәкъдим ителгән Айгөл Әхмәтгалиева хикәяләре шундый, ел әдәбиятының уңышы саналырга лаек әсәрләр. «Кайтаваз» исемле беренче хикәя ана белән бала арасындагы яратуны, бу мөнәсәбәтнең үлем куркынычы да, картлык та, табигать стихиясе дә җиңә алмый торган олы көч булуын раслап язылган. Вакыйга гади генә — аяклары авырткан ананы тозлы күлгә алып барырга юлга чыккан кызы белән кияве тау елгасы буенда ялга туктыйлар. Шушы елга кыз күңелендә балачак хатирәләрен уята. Тирән психологизм белән сугарылган хикәядә автор татар прозасында, бигрәк тә аның кече жанрында еш очрамый торган алым куллана: ана психологиясен — аның үз уйларында, кыз фикер-кичерешләрен шулай ук үз исеменнән тергезә. Мондый күптавышлылык, күпэмоциялелек хикәянең тәэсир көчен арттыра. Хикәянең исеменә салынган «кайтаваз» атамасын да уйната язучы. Кайтаваз — хәтер, кайтаваз — өлкән буын өчен кадерле кыйммәтләрнең яшь буында кабатлануы да, хикәяне тәгәлләп куйган абзацта кайтаваз яхшылыкның, мәрхәмәтлелекнең, яратуның кешегә әйләнеп кайтуы дип тә аңлашыла. Ана белән кыз мөнәсәбәтләренә метафора булып килгән сарык һәм аның бәрәне вакыйгасы, хикәянең үзәк вакыйгасына әверелеп, җыйнак кына текстта ассоциацияләр дә, укучының үз күңелендә яшәгән фикерләрне дә уятырга сәләтле булып чыга.

Икенче хикәя — «Коткаручы»да да шул ук алымнар үзәккә куела. Болар Айгөл Әхмәтгалиеваның традицион татар хикәясен үстерүдә үз сукмагын табуы, бу сукмакның XX йөз башы әдәбиятыннан ук үзгәрә килгән матур юлга килеп кушылуы турында сөйли.

Шундый ук ел ачышы булырлык хикәяләрне 12 нче санда Рөстәм Галиуллин тәкъдим итә. «Җиһан» дип аталган беренче текст кешегә килгән кайгыны фаҗига дәрәҗәсенә җиткереп, укучыны да шушы фаҗигане кичерергә мәҗбүр итә. Әле генә кыз баланы югалткан әти кеше Солтан белән бабасы Җәлил хәсрәтен автор, аларның һәрберсенә карата психологизм алымын кулланып, кабер казу вакыйгасында тергезә. Сүзне Җәмилә белән Саниягә күчереп, автор алар уен, алар кичерешен җиткерә. Шуның белән янәшә, Җәлилнең искә төшерүләрендә, ике ирнең һәм ике хатынның «Нишләп?» дигән сорауларында тормыш фәлсәфәсе калка. Җиһан, тормыш — байлык артыннан куумы, әллә бәхет башкадамы дигән сорауга җавапны хикәя үзе бирә. Балада, тормышның дәвам итүендә бәхет дигән фикерне аңларга юл күрсәтелә. Ялгышлардан тәүбәгә килү, иманга басу юлы хакында соңгы бишун елда шактый күп әсәрләр язылса да, әлеге фикернең ярдәмче рольдә, чишелеш булып килүе хикәяне үгет-нәсыйхәт ясcылыгына төшүдән саклап кала алган.

Журналның 2014 елда махсус конкурс игълан итүе повесть жанрына уңай тәэсир ясавын да күрсәтеп үтми булмас. З.Хәкимнең бүгенге дөньяның саркастик моделен тудырган, постмодернизм үрнәге булган повесте тәкъдим ителү — елның казанышы дияр идем. Конкурска килгән повестьлар арасында башка кызыклы әсәрләр дә булды. Дөрес, бәйге йомгакланмаганга, повестьлар хакында фикер әйтү иртәрәк: болар хакында әле конкурска йомгак ясалгач сүз булыр.

Роман жанры XXI гасыр дөнья әдәбиятында иң зур үзгәрешләр кичергән жанрлардан булды. Чөнки яңа, постмодернистик роман заман сурәтен тергезү һәм бәяләү өчен мона кадәр сүз сәнгатендә билгеле булмаган мөмкинлекләр ача. Шул ук вакытта, милли әдәбиятыбызда бу жанрның традицион кимәлне үз итүен дә әйтмичә булмыйдыр. Тарихи романнар, сугыш яки совет чоры вакыйгаларын тергезеп язылган романнар янында «заман» романнары берничә елга берәү генә иҗат ителә.

Шуна да Зиннур Хөсниярның «Гарасат» романын мин аеруча кызыксынып укыдым. 2014 елны басылып чыккан 5 роман арасында ул — «яңа татар романы» дип исемләнерлек бердәнбер әсәр. Дөрес, романның 2013 елда конкурста җиңгәнлеге искәртелә — димәк, иртәрәк язып төгәлләнгән булган. Ләкин киң катлам укучыларга ул журнал вариантында барып иреште, 2014 ел романы буларак бәяләнә ала. Шунысын да әйтергә кирәк: романда ул язылып төгәлләнгәннән соң, үзебезнең җирлектә кайнаган хәлләр белән аваздашлык көчле. Болар, беренче эпиграф белән янәшәлектә, әдәбиятның, язучының булачак хәлләрне алдан күрә алуына, аларга прогноз бирүенә һәм бирергә тиешлегенә, шуларны шәрехләү һәм бәяләү вазифасының мөһимлегенә ишарә ясый.

XXI гасыр татар әдәбиятында «яңа» роман-повестьлар булмады түгел: Зөлфәт Хәким, Марат Кәбиров, Туфан Миңнуллин һ.б. язучыларның күп кенә әсәрләре шундыйлардан иде. Татар әдәбиятында бу «яңалык» ике төркемдә күзәтелә: постмодернистик текстлар һәм постмодернизм алымнары-формалары белән баетылган әсәрләр. З.Хөснияр романы икенче төргә карый. Чөнки әсәрдә постмодернизмның ике таләбе үтәлмәгән: автор фикере өстенлекле; өч катламны бер үк геройлар, урын-вакыт тоташтыра.

Шул ук вакытта романдагы күпкатламлылык үзе үк яңалыкларга ишарә ясый. Шартлы рәвештә бу катламнарны «дин фәлсәфәсе катламы», «җәмгыяви катлам», «сәяси катлам» дип атап булыр иде. Сюжеттан зуррак мондый мөстәкыйль катламнар текстны күпмәгънәле, ассоциатив, интеллектуаль романга әйләндерә.

Постмодернизмның олы формалардагы бер канатына хас булганча, текст серле сорауга җавап эзләүдән — детективларга хас төенләнешләрдән — башланып китә. Алар берничә. Беренче бүлекнең («Коръән серләре») исеме белән чагыша торган, Байбулатның чалгысы астыннан чәчрәгән ут, Байтимерне коткарган Зат турындагы уйланулар романның ахырына кадәр лейтмотив төсендә сузылып бара, дин фәлсәфәсен үз тирәсенә туплый. Икенче бүлекчә дә ике сорауны калкытып куя: Әллүки күленең суы нигә юкка чыккан һәм Борис Айсинны кем үтереп ташлаган? Һәм нәкъ менә яңа интеллектуаль романнардагыча, икенче бүлекчәнең беренче табышмагы символик, фәлсәфи гомумиләштерүләргә юл ача: Әллүки күленең саф суы — халыкның күзаллаулары, гадәтләре, яшәү рәвеше, әхлак-фәлсәфәсе кебек укыла башлый. Текстның җилеме, укучының игътибарын тотып тору вазифасын башкаручы сорау — Айсинның дошманын эзләү исә үлемнең очраклы, саксызлык аркасында килеп чыкканлыгын ачыклап төгәлләнә. Бу да яңа романнар өчен табигый күренеш.

Шунысын да искәртергә кирәк: тексттагы интертекстуальлек кызыклы гомумиләштерүләргә алып килә. Әйтик, Айсинның үлемен текстта «хәбәр итү» Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы белән тоташырлык итеп уйланылган. «Кем? Кемнәр? Нигә?!!» дигән сораулар бу бәйләнешнең очраклы булмавы, язучының аңа махсус игътибар юнәлтүе турында сөйли. Әлеге зур булмаган деталь, әсәр соңында Айсин үлеменең, Фәхри үлеме кебек, сәяси сәбәпләргә бәйле түгеллеге ачыклангач, заманның тамырдан үзгәргәнлеген күрсәтүче билгегә әверелә.

Романның төп максаты — бүгенге тормышка бәя бирү, бүгенге җәмгыятьтәге хәлләрне аңлату, постсовет чорының моделен төзү. Дини катламдагы күп кенә символлар һәм образлар да, ахыр чиктә, чынбарлыкны аңлатуга хезмәт итә. Язучы заманны тәмуг капкасы ачылган вакытка тиңли. Ул илне Гарасатка китерергә мөмкин. Гарасат мәйданы шулай ук күп кенә ассоциацияләр уята. Украинадагы мәйдан да, гарәп илләрендәге инкыйлаблар да күзаллана. Текстта моны булдырмауның бердәнбер юлы «акыллы патша» икәнлеге дә әйтелә.

Язучы һәр заманның үз коткысы, үз Иблисе булуга ишарә ясый. Бу Фәрит белән Байтимер сөйләшүендә ассызыклана. Хәзерге заманның Иблисе, котыртучысы исә — акча, матди байлык. Ахыр чиктә, сәяси кебек тоелган хәлләр: секталар оешу, урманда качып ятучы «террористлар», күлләрнең күккә очуы — бар да байлык өчен, шуны бүлешү планының бер өлеше булып чыга. «Ялрлыш фәлсәфәсе» бүлекчәсендә милләт-халыклар арасындагы ызгыш-талашның да сәбәбе шуңа бәйләп куела.

Текст күп кенә тарихи, дини, хәтта эзотерик мәгълүматлар белән баетылган. Батырша фетнәсе һәм баш күтәрүләр тарихы, чукындыру вакыйгалары, диннәрнең бүгенге янарышы бер җепкә тезелә. «Алма» белән бәйле сызыклар, «су» фәлсәфәсе, «алтын

эзләү», «сәхабә»ләр хикәяте һ.б. бербөтен тарихның аерылгысыз өлешләренә әверелә. Шул ук вакытта аерым детальләр артык булып та тоела башлый. Әйтик, фетнә сүзенең символик мәгънәләрен Фетнә Фәймә белән тоташтыру шундыйлардан. Аерым бер бүлекләрдә («Яшь алмагач ботагы кебек нечкә ай...», «Фетнә», «Адәм балалары хикәяте», «Яралыш фәлсәфәсе») күпсүзлелек, артыкка киткән шәрехләүләр текстны кабул итүне авырайта (мин моны З.Хөснияр әсәрләрендәге төп кимчелек дип атар идем). Яки Галин һәм Тәнзилә-Рәнзилә тарихы, әдәбиятта билгеле тарих булса да, заманны бәяләүгә хезмәт итсә, Камай һәм Байтимернең маржа кызлары белән мөнәсәбәтләре тарихы төп вакыйгаларда мөһим роль уйнамый, аларның вазифасы аңлашылып бетми.

Гомумән алганда, авыр укылса да, «Гарасат» романын татар әдәбиятының интеллектуаль, «яңа» проза тудыру юлындагы уңышы дип карарга мөмкин. Бу әсәр чор әдәбияты фонында үз урынын алыр дип уйлыйм.

Мавыктыргыч, укылышны тәэмин итүче сюжетка корылган әсәрләрдән Кәрим Караның 9 нчы санда дөнья күргән «Инга Мейтаның жинаять эше»н аерып күрсәтергә була. Рус әдәбиятында шундыйрак әсәрләр шактый тәкъдим ителсә дә, вакыты-вакыты белән әсәр телефильмнарны хәтерләтә башласа да, бездә мондый әсәрләрнең бөтенләй диярлек язылмавы аңа башка күзлектән, милли әдәбиятыбызның эзләнү офыкларын киңәйтү ягыннан карарга мөмкинлек бирә.

Казах әдәбиятыннан постмодернистик үрнәкләр тәкъдим итүне мин хуплар идем. Бер яктан, алар тугандаш халыклар әдәбияты хакында мәгълүмат җиткерә, шулай ук яшь язучылар өчен әдәбиятта барган процессларны күзәтү мөмкинлеге бирә.

Журналда биографик нигезле, публицистик текстлар буларак язылып та, матур әдәбият кебек укыла-кабул ителә торган әсәрләрне дә телгә аласы килә. Камил Кәримовның «Юморның соңгы төне», Рәйсә Юсупованың «Бүре елаган төндә» кебек язмалары гаять матур тәэсир калдырды.

Яшьләрнең журналга яңа сулыш алып килүен дә күрсәтү урынлы булыр. Әйтик, Гүзәл Сәгыйтованың мәдәният тарихына кагылышлы язмалары шундыйлардан. Тарихи һәм биографик фактлар мәдәният әһелләренең холкын-характерын ачарлык һәм аларның милләтебез-халкыбыз алдындагы олы хезмәтләрен күрсәтерлек итеп уйланылган матур тел белән язылган.

«Тарих» бүлегендәге мәкаләләрнең яңалыгы, актуальлеге, материалны җыйнап бирү осталыгы журнал укучыларның игътибарыннан читтә калмагандыр дип уйлыйм. Галәттә, татар журналлары «икенчел», фәнни әдәбиятта инде бер тапкыр дөнья күргән материал белән эш итә. Бу очракта материалларның яңалыгы күзгә ташлана. Шулар янәшәсендә «100 нче бит» сәхифәсе милләт гамен, милләт ваемын алга куюы белән хуплау таба.

Проза һәм публицистика белән чагыштырганда, әдәби тәнкыйтьнең алардан калышуын да билгеләп үтми булмас. Бу юлда да системалы эшне оештыру сорала торгандыр. Журнал битләрендә татар әдәбиятында бара торган процесслар хакында язучылар үзләре дә турыдан-туры катнаша торган сөйләшүләр уздыру яхшы булыр иде. Бигрәк тә журналда басылып чыккан әсәрләргә анализ бирү, әсәр хакында зур булмаган сөйләшүләр оештыру мастер-класслар вазифасын күпмедер үз җилкәсенә алыр иде кебек.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ, әдәбият тәнкыйтьчесе:**



2014 елда укылган зур күләмле проза әсәрләреннән Әмирҗан Моталлаповның «Гамь» романы, Нәбирә Гыйматдинованың «Нурулла» һәм Рафаил Газизнең «Тәрәзәләр», Рөстәм Зариповның «Милициянең йөз кызыллыгы» бәяннары бигрәк тә истә калган.

Ә ни өчен?

Тормыш дөреслеген, чынбарлыкны әсәрләрдә тәэсирле итеп тасвирлау, күрсәтеп бирә алу нәтиҗәседер бу, мөгаен. Үзәктәге геройларның хикмәтле һәм гыйбрәтле хәл-әхвәлләре, бай язмышы күрсәтелгәнгә шулайдыр ул.

Чыннан да, соңгы елларда безнең прозаиклар арасында уйлап чыгарып, чик-чамасыз фантазиягә бирелеп яисә экраннарда ешайган кинофильмнарга охшатырга тырышып язучылар ешаеп китте

бит. Яисә инде әйләнә-тирәбездәге әллә ни әһәмияткә ия булмаган вак-төякне әсәрләргә тутыру... Ә бүгенге китап укучының вакыты бик аз — андый чүп-чарга нишләп кадалып утырсын ди ул!

Әйе, үз янәшәсендә «телевизор», «интернет» дигән көчле көндәшләр барлыгын искә алмыйча булдыра алмый инде бүгенге әдәбият. Проза әсәрләреннән табигыйлеккә зыян итмәгән психологик тирәнлек тә, арзанлы шау-шуга якынаймаган вакыйгаларның мавыктыргыч агышы да, укылган китаплардан яисә күрелгән кинолардан түгел, ә нәкъ менә тормышның үзеннән килгән мәгънәви яңалык та күбрәк кирәк бүген.

Ә хикәяләр?

Узган елның май санында Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәясен яңадан бастырып журнал редакциясе бик тә дөрес эшләде. Хикәя остасы буларак әдәбият тарихына кереп калган классик әдипнең бу әсәре хәзерге иҗатчылар өчен бик күп яктан үрнәк булып тора.

Ә бу жанрда әлеге останың юлын лаеклы дәвам итүчеләр бармы соң? «Казан утлары»ның 2014 елгы гыйнвар санында Айгөл Әхмәтгалиеваның өч хикәясе басылган. Һич тә курыкмыйча әйтергә мөмкин: югары сәнгать дәрәҗәсендә иҗат ителгән әсәрләр болар! «Коткаручы» белән «Тау итәгендә» дигәне бигрәк тә көчле тәэсир итә.

Беренчесендә төп герой Ибраһимның (пәйгамбәр исеме) юлда авариягә эләккән һәм инде үлгән дип ярдәмсез калдырылырга тиешле кешене игътибарлы булуы аркасында (Ибраһим тегенең авызына көзге куеп, анын сулышы барлыгын белә) коткара алуы да ышандыра. Әле алай гынамы соң?! Үзе саклап калган кешене (ул бер бай коммерсант булып чыга) авылга ярдәм итәргә дә күндерә Ибраһим. Авыл исән калсын өчен, анда мәктәп һәм мәдрәсә төзергә булалар болар.

Менә бу инде коткаручы, ичмасам!

Безнең яшь авторыбыз шушы хикәясе белән бүгенге байларга һәм житәкчеләргә үрнәк тә күрсәтә кебек. Менә ничек чагыла ул әдәбиятның көче һәм мөмкинлеге!

Ә «Тау итәгендә» дигән хикәядә бүгенге яшәеш өчен үтә дә мөһим булган ситуация нинди психологик нечкәлек, тирәнлек һәм сәнгатьчә тәэсир көче белән күрсәтелгән!

Менә хикәянең башы. «Бу матурлыкны бер селтәнүдә юк итәргә ирнең кулы күтәрелмәде...» Әйе, бу ир чалгы алып печән чабарга чыккан иде. Әмма бүген авылда җыелыш булачак — яңа башлык сайлап куярга кирәк. Аны үгетлиләр... Шуңа күрә ирнең күңеле тыныч түгел...

Ирнең мондый халәтен автор бик тә оста тасвирлый — печән чапканда ул хәтта үз алдындагы кырмыска тумгәкләрен дә абайламый, теге мескеннәрнең ояларын тузгыта...Ә инде телефоннан хатыны шылтыратып: «Сине район башлыгы эзләтә бит», — дигәч, ул тагын да ашыга төшә һәм, әле бая гына үзе сокланып карап торган чәчәкләрне таптап, авылга таба ашыга!

Менә кеше ничек үзгәрә! Бу зур үзгәрешне язучы оста һәм тәэсирле итеп күрсәтә. Шәп бу! Булдыра Айгөл!

Яшь хикәячеләр арасында да өметле каләм ияләре күренә. Светлана Гыйләҗеваның «Һава торышы» хикәясе, мисал өчен, психологик нечкәлеге һәм, гомумән, матур лирик күренеш булуы белән истә кала.

Ә хәзерге проза турында безгә ешрак һәм һәр сөйләшкәндә аерым бер мәсьәләне үзәккә алып фикерләшеп торырга кирәк.

Редакция үзе дә проза әсәрләренә таләпчәнлекне нык арттырырга тиеш.

**Гүзәл НАСЫЙБУЛЛОВА, филология фәннәре кандидаты:**

Бүгенге көн татар прозасында геройның хис-кичерешләрен, эчке халәтен алгы планда ачкан әсәрләр өстенлек итә. Нәкъ менә психологик әсәрләр заман укучысын үзенә тарта да. XXI гасырның, аерым чор буларак, үз прозасы формалашты дип әйтергә иртәрәктер әле. Хәзерге татар прозасының нигезен классик чорлардан килгән закончалыклар, традицияләрне дәвам итү тәшкил итә. Татар әдәбияты шул ягы белән көчле дә. Әлбәттә, глобальләшү, аз санлы милләтләргә йотылу, юкка чыгу янаган, рухи кыйммәтләр матди байлыкка алмашынган, сүз сәнгате, китап белән кызыксынучылар көннән-көн кими барган бүгенге вазгыятьтә әдәбиятыбыз сыйфат ягыннан да, сан ягыннан да югалтулар кичерә.



«Казан утлары» 2014 елда укучыларны яңа биш роман белән таныштырды. Болар — Әмиржан Моталлаповның «Гамь», Зиннур Хөсниярның «Гарасат», Хәким Галиҗаннен «Патша солдаты Әхмәтнәсир», Ахирнең «Таш калада баш кала» һәм Анатолий Егинның рус теленнән тәрҗемә ителгән «Үзбәк хан» әсәрләре. Очраклылыкмы яки бу төр жанрга кытлык булу сәбәплеме, әллә бәлки әлеге проблеманың бүгенге көндә кискенлеге белән дә аңлатыладыр — идея-тематик яктан бик якын әсәрләр сайланган. Сүз авыл, аның язмышын чагылдырган Ә.Моталлапов, З.Хөснияр, Ахир романнары турында бара. Ләкин шунысы куанычлы: әлеге әсәрләр стиле, эшләнеше буенча шактый аерылалар һәм һәр автор проблемага, бер-берсен кабатламыйча, үзенчәлекле якын килә.

Ахирнең «Таш калада баш кала» романы үзәгендә гади авыл кешесенең язмыш тарафыннан төрле сынауларга дучар булуы сурәтләнә. Автор Нариманның сикәлтәле язмышы мисалында безнең илдә барган сәясәтне: колхозлашуны, ахыр чиктә аның таралуын, авылларның юкка чыгуын, җинаятьчелекнен инде авылларга да үтеп керүен тасвирлый. Нариман — җаны-тәне белән авылга берекkән кеше. Яшьли сөйгән ярына ияреп шәһәргә китү аның өчен фаҗигагә әверелә. Әсәрдә геройның җирсү хисе төрле образ-сурәтләр аша ачыла. Язучы Нариман язмышын сурәтләү белән генә чикләнми, ә аның улы Инсафның да төрле сынаулар, сикәлтәләр аша үтүен бәян итә. Бу җәһәттән әсәр замандашларыбыз тарафыннан яратып кабул ителә, бүгенге көндә телевизор экраннарында еш күрсәтелә торган «семейная сага» кебек сериалларны хәтерләтә. Язучы романга уңышлы исем сайлаган: «Таш калада баш кала» шигъри юл сыман тәэсирле яңгырый, нинди дер фаҗигаи төсмер белән үзенә җәлеп итә. Нариман язмышында автор укучысына бу гыйбарәнең коры сүз генә түгеллеген раслый, ләкин әсәрнең икенче өлеше әлеге исемнән, автор идеясеннән бераз читләшә сыман. Биредә композицион бөтенлекнең йомшаграк булуы сизелә. Инсафның тормышы белән бәйле вакыйгалар аерым әсәр кебек кабул ителә.

Бүгенге көн укучысын аеруча язмыш тарафыннан төрле сынауларга дучар булган гади кешенең тормышын, аның сынмый-сыгылмый алга баруын үзәктә сурәтләнгән әсәрләр җәлеп итә, шул ук вакытта әсәрдә детектив интрига, мистика, мәхәббәт белән бәйле үкенечле вакыйгалар да булсын. Бу җәһәттән Зиннур Хөсниярның шулай ук авыл язмышына бәйле романы — «Гарасат» замандашларыбызның ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Язучы заманыбызның гадәти күренешкә әверелгән, җир мәсьәләсендәге аңлашылмаучанлыкларны, җинаятьчел юллар белән бизнес коралына әйләнүен генә сурәтләп калмый, ә проблеманы фәлсәфи яктан да ачарга омтыла. Шулай ук биредә милләт, дин белән бәйле мәсьәләләр дә кискен куела. Беренче планда ике фермерның җир өчен үзара көрәше сурәтләнсә, язучы Коръән, Библия, хәтта әлеге диннәргә каршы булган секта тәгълиматлары аша шул конфликтны фәлсәфи нигездә ачарга тырыша. Романда автор тарафыннан кулланылган символ-билгеләр, бик үзенчәлекле роль башкарып, әсәрнең эчтәлеген тирәнәйтә.

Үзенчәлекле композиция, авторның фикерен Коръән сүрәләре, Библиядән өзекләр аша җиткерүе, Борис Айсинның үлемендәге билгесезлек, Сәхәби образына мифик мәгънә салу романны мавыктыргыч итә. Әсәр төрле образлы сурәтләүләр, кискен борылышлар, мифологик, аллегорик образлар белән дә укучының күңеленә кереп кала. Ләкин тизлеккә корылган заманда озын тасвирламалар укучының күңелен әсәрдән читкә этәрә. Шулай ук романда аның әдәби кыйммәтенә тәэсир ясардай кайбер төгәлсезлекләр дә очрый. Беренче карашка, бу вак мәсьәләдер, әмма, мәсәлән, Марфаның әтисе башта умартачы Геннадий дип бирелүе, соңрак авторның аны берничә урында умартачы Василий дип атавы әсәр белән танышканда аңлашылмаучанлык тудыра. Шулай ук Борис Айсинның да фамилиясе ике төрле яңгырый, әсәрнең шактый өлешендә ул Илсинга әйләнә. Байтимер Баймурзинның Сингапурга бердәнбер сәяхәтен төрле урында төрлечә шәрехләү

бик үк аңлашылып бетми. Фермер әсәр башында ук әтисенең, бәлки сина чит илгә китәргә кирәктер, диюенә «подпискасы»ның әле тагын ике елы барлыгын, илдән китәргә ярамаганлыгын әйтә. Ләкин соңрак автор аның хакимият җитәкчеләре белән Сингапурга баруы турында яза (№7, 34 бит). Шулай ук әлеге сәяхәт алга таба тагын бер тапкыр искә алына. Бу юлы автор Байтимернең анда космонавтлар отрядында вакытта ук «ничектер юл төшеп, әлеге илдә туристик сәяхәттә» булуы турында хәбәр итә (№8, 101 бит). Дөрес, болар вак детальләрдер, ләкин шулай да язучы укучыга сурәтләү ярдәмендә үз сүзен җиткерергә алына икән, ул үзе тасвирлаган дөньяны төгәл күзалларга һәм шул рәвешле үк укучысына җиткерергә дә тиеш. Әдәбият мәйданы язучыдан, иң беренче чиратта, төгәллек таләп итә.

Авыл проблемасын күтәргән тагын бер язучыбыз — Әмирҗан Моталлапов «Гамь» романында саланың янадан тернәкләнүен дә тасвирлый. Сугыш еллары авылы, тыл тормышын чагылдырган бу роман узган гасырда иҗат ителгән әлеге вакыйгаларга багышланган әсәрләр белән шактый аваздаш. Ә.Моталлапов сурәтләүне сугыш вакытындагы авыл тормышыннан ук башлый. Әсәрдә бу авыр еллар яшьлек, мәхәббәт белән бергә үрелеп бара. Төрле сынаулар үтеп, еллар аша сакланып калган беренче саф хисләр матур төсләр белән бирелә.

2014 елда «Казан утлары» безне шактый кызыклы һәм татар әдәбияты өчен яңа тема чагылдырган Хәким Галидәннең «Патша солдаты Әхмәтнәсир» романы белән дә таныштырды. Әсәр Пётр I идарә иткән чор вакыйгаларын, бу вакыт аралыгында татар халкының яшәешен чагылдыра. Беренче чиратта, роман укучы өчен әнә шул яктан кызыклы һәм кыйммәтле. Әмма әсәрдә билгеле бер чор, тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр сурәтләнсә дә, аны тарихи роман дип түгел, ә бәлки тарихи-маҗаралы роман (историко-приключенческий роман) дип атау дөресрәктер. Әсәрнең үзәгендә патша солдаты Әхмәтнәсирнең язмышы, аның белән бәйле маҗаралар сурәтләнә. Бу егет, тарихи шәхес булудан бигрәк, татар халкының типик, җыелма образы буларак кабул ителә. Авторның тарихны тирәнтен өйрәнгәнлеге сизелә. Хәким Галидән Әхмәтнәсирнең маҗаралы язмышы аша безне шул чорда халыкның яшәеше, көнкүреше белән таныштырып кына калмый, моңа кадәр тарихта бәхәсле булган моментларга, «ак тапларга» кызыклы гына үз версиясен дә белдерә. Бигрәк тә генерал-фельдмаршал Б.П.Шереметьев белән бәйле вакыйгаларда бу ачык чагыла. Шулай ук татар халкының рус дәүләтендәге яшәешен, патшага каршы сәясәттә аларның ролен тасвирлауга да зур урын бирелә.

Әсәрнең теле турында сүз алып барганда, роман күбрәк сөйләп бирүгә нигезләнгән. Дөрес, тарихка багышланган әсәр буларак, язучы күбрәк мәгълүмат җиткерергә, үзенең белеме белән уртаклашырга омтыла, ләкин образлылык, сүз белән сурәт тудыру әсәрнең эчтәлеген тагын да баетыр иде.

Бүгенге көндә татар әдәбиятын башка халыкларга җиткерү шулай ук иң авыр мәсьәләләребезнең берсе булып кала бирә. Һичшиксез, тәрҗемә әсәрләргә ихтыяҗ зур. Китап сөючеләргә генә түгел, әдәбият тарихын өйрәнүчеләр өчен дә мөһим бу. Тарихтан хәтерләсәк, гомер-гомергә төрле халыкларның сүз сәнгатьләре бәйләнештә, бер-берсе белән уңышлы тәҗрибәләр алмашып яшәгән. Дөрес, рус теленә, соңгы елларда төрек теленә тәрҗемәләр башкарылуы сөендерә, ләкин Европа телләренә тәрҗемә бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Классик әдәбиятыбызны инглиз теленә тәрҗемә итә алсак, ул мирас чит ил вәкилләре арасында үз укучысын тапмый калмас иде. «Казан утлары» журналы башка халыкларның әдәби мирасын, тәҗрибәсен укучыга җиткерүдә зур вазифа башкарып килде. Узган елда да төрки язучыларның әсәрләре белән танышу — әнә шундый матур мисаллардан. Телеэкраннарда (аеруча да «Орда» фильмы күрсәтелү), хәтта мәктәп дәреслекләрендә безнең әби-бабайларыбызны кеше ашаучы кыргый ерткычлар буларак тасвирлаган заманда рус язучысы Анатолий Егинның татар халкы тарихының шанлы сәхифәләрен яктыртуга багышланган «Үзбәк хан» романы белән танышу бүгенге көн укучысын битараф калдырмаска тиештер. Әлеге әсәр яшь прозаик Рөстәм Галиуллинның камил тәрҗемәгә сәләтен дә ачты. А.Егин сүз-сурәт ярдәмендә Алтын Урданың шанлы елларын тасвир итә. Язучы Үзбәк ханны белемле, оста сугышчы, акыллы, гадел идарәче буларак, Ислам динен таратуга, шәһәрләр төзү, илнең чәчәк атуына зур өлеш кертүен генә сурәтләп

калмыйча, төп игътибарын бу тарихи шәхесне, беренче чиратта, кеше буларак ачуга, аның эчке дөньясын, уй-кичерешләрен күрсәтүгә юнәлтә.

Әлбәттә, аерым бер әсәргә «шаһ әсәр» дип бүген бәя бирү бик үк дөрес булмас. Әсәрнең кыйммәтен әле вакыт та билгели бит. Узган ел журналда басылган романнар турында сүз алып барсак, аларның һәркайсы үзенчә үзенчәлекле һәм бүгенге татар прозасы өчен әһәмиятле.

**Ләйсән БӘДЕРТДИНОВА, филология фәннәре кандидаты:**



Соңгы еллар татар әдәбиятында повесть жанрында язылган әсәрләрне «бәян» дип атау киң таралыш алды. Бәян, жанр атамасы буларак, татар әдәбият белеме сүзлекләрендә теркәлмәгән, тәрҗемә иткәндә, ул «аңлату, телдән яки язма рәвештә ачыклап, төшендереп бирү» дигән сүз. Ягъни әлеге әсәрләрне жанры ягыннан тикшергәндә, әдәбият галимнәренә повестька куела торган таләпләрне истә тотарга кирәк яисә бәян жанрын әдәбият белемендә төшенчә буларак аңлатып бирергә. Моның өчен турыдан-туры язучылар иҗат иткән бәяннарга мөрәҗәгать итеп, бер гомуми күзәтү ясау сорала. Биредә әдәбият нәзариясенә артык кермәстән, 2014 елда «Казан утлары» битләрендә басылып чыккан берничә бәянга тукталып китик.

Узган елда журналда, кыска бәяннар конкурсына тәкъдим ителгән әсәрләрне санамаганда (чөнки әле нәтиҗәләр ясалмаган), берничә бәян басылып чыкты. Шулардан Айгөл Әхмәтгалиеваның «Таллыкүлдә былбыл бар», Клара Булатованың «Яшел яфрак — яшәү төсе», Рафаил Газизнең «Тәрәзәләр» кебек әсәрләрен карап үтик.

Рафаил Газизнең беренче санда басылып чыккан «Тәрәзәләр» бәяны мәктәп тормышын, аның мохитен киң планда яктыртуга корылган. Барлык вакыйгалар Зөлфәт исемле образга бәйле тупланган, аерым күренешләр рәвешендә бирелә. Әсәр сюжетының мондый формада оештырылуы вакыйгалар барышына бераз тәртипсезлек, кискенлек кертә. Әмма, икенче яктан карасаң, мәктәп еллары, яшьлек, беренче гашыйк булу һ.б. — болар барысы да кеше күңелендә аерым бер хис-күренешләргә бәйле теркәлеп бара, мизгел рәвешендә хәтердә туплана һәм яңара. Димәк, әсәрнең бәйләүче элементларын махсус рәвештә тудыру соралмый да. Автор да, бәлки, шулай фикер йөртәдер. Гомумән, мәктәп еллары, беренче эш тәҗрибәсе, яңәшәңдә сине кеше иткән шәхесләргә карата булган мөнәсәбәт — һәрбер инсанга якын хисләр. Әнә шулай, аерым бер мизгелләрне, хатирәләрне сөйләп бирү, бәяндагыча аңлату аша, Р.Газиз үз әсәрен тудыра алган. Бәянга тулырак бәяләмә бирү өчен, аның дәвамын укып чыгу да сорала.

Клара Булатованың унынчы санда басылып чыккан «Яшел яфрак — яшәү төсе» бәяны Анук исемле керәшен кызының гомер юлын яктырта. Әсәр эчтәлегендә берничә момент калкып чыга: керәшен һәм татар халкы арасындагы мөнәсәбәт, тарихи вакыйгаларга бәйле кеше язмышы. Нәкъ менә шулар Анук белән Миңлегалигә кавышу юлында киртә ролен үти сыман. Әмма калкытып куелган мәсьәләләрнең барысы да чишелеш таба дип әйтеп булмый, язучы андый максат куймый да кебек. Аның өчен Анукның кызганыч язмышын сурәтләү беренче урында тора. Шул ук вакытта сугыштан соң Миңлегали хакындагы мәгълүматның азлыгы бераз гаҗәпләндерә, бөтен гаеп бары тик анарда гына дигән нәтиҗәгә киләсең. Автор мәхәббәт тарихына ике яклап нокта куя: бердән, ике милләт, ике дин вәкилләре кавыша алмый; икенчедән, андый яшьләрне язмыш үзе аера.

Әсәр башында шактый киң планда алынган керәшеннәр яшәеше, җырлар һәм йолалар, ахыр чиктә, Анна Афанасьевнаның тормыш юлын тасвирлап бирүгә, бер-бер артлы вакыйгаларны санап чыгуга корыла. Һәм бу, һичшиксез, әсәрнең сәнгати көчен, кыйммәтен киметә.

Гомумән алганда, керәшеннәр турында безнең татар әдәбиятында әсәрләр юк түгел. Бу бәян да шулар рәтенә кертеп карала ала. Аның жанрын исә «хикәя» дип билгеләп тә булыр иде.

Айгөл Әхмәтгалиеванын «Таллыкүлдә былбыл бар» әсәре алдагы бәяннардан шактый аерыла. Гомумән, бу авторның иҗаты соңгы берничә елда күзгә күренеп үсеш кичерә. Әлеге фактны аерым китапларының басылып чыгуы һәм укучылар арасында популярлыгы гына түгел, язучының халыкара конкурсларда җиңүе дә раслап тора.

А.Әхмәтгалиеванын язу манерасы үзгә. Әйтергә кирәк, күпмедер дәрәҗәдә без аның әсәрләрендә XX гасырның икенче яртысында иҗат иткән авторлар тарафыннан күтәрелгән, калкытып куелган мотивларны, темаларны да очратабыз. Мисал өчен, табигатьне саклау, авылның бетүе, кеше холкының кырыслануы, эчүчелек, эшсезлек, ятимлек кебек мәсьәләләр авыл яшәешен прозада чагылдыручы язучыларыбыз иҗатында кат-кат күтәрелде. Шул ук вакытта, аның әсәрләре үзенчәлекле бәясен алырга да хаклы.

«Таллыкүлдә былбыл бар» бәяны, беренче чиратта, сюжет корылышы ягыннан кызыклы оештырылган. Биредә берничә катлам аерылып чыга һәм шулар аша әсәрнең жанр табигате дә билгеләнә. Бердән, бәяннның төп вакыйгалары Шамил белән Наилә тирәсендә җыйналып килә. Яшьтән бер-берсен яратып вәгъдәләшкән бу пар гомер юлларын бергә үтми. Язмыш алар өчен башка сынаулар әзерләгән булып чыга. Ләкин бу сынаулар, нигәдер, бары тик Наиләгә генә кагылып үтә. Хыялый кыз күңеле исә авырлыкларны җиңеп чыгарга әзер түгел.

Шамил исә тормыш сукмагын дөрес сайлап, муллыкта яши бирә. Әлеге герой гадәттән тыш дөрес булып күренә. Аның гаиләсе, яраткан хатыны, кызы, шөгыле бар. Ул кызгана, хаталарны таный белә һәм аларны төзәтә дә, яшьлек мәхәббәтенә ярдәм кулын сузарга әзер. Бу урында өлкән язучыбыз Габдулла Галиевнең «Язмышларны сайлап алмыйлар» повестеннан Исхак белән Рәхилә искә төшә. А.Әхмәтгалиеванын Шамиленнән аермалы буларак, Исхак Рәхиләне дөрес юлга күндерә ала (биредә иманлы юлга басу да үз ролен уйныйдыр). Әмма А.Әхмәтгалиеванын бәянында мәсьәләнең шулай аянычлы хәл кылынуы хәзерге заманның ачы хакыйкатен танырга мәҗбүр итә: хатын-кыз, чыннан да, яманлыкка тиз бирешә. Шул ук вакытта хатын-кыз бала күңелендә туган җиренә, тамырларына карата иң көчле тарту хисен сеңдерә ала (Шамил белән әбисен искә төшерик). Димәк, хатын-кызның гаиләне, нигезне тотуда уйнаган ролен безгә әле анларга кирәк. Анага карата таләпләр дә катгый: нәкъ менә шушы хатын-кыз балаларында изге хисләрне уятырга, яшәүнең асылына төшендерергә, үзенә, нәсел-нәсәбенә, туган нигезе, туфрагына хөрмәт, кадерле белүне баласының күңелендә тудыра белергә тиеш.

Әсәрдә автор-хикәяләүче каен образлары аша төп мәгънәне, язучы әйтергә теләгән фикерне җиткерә. Туган нигез, тамырлар, җан тарту кебек төшенчәләр — татар әдәбияты өчен таныш күренешләр. Әлеге мотивлар А.Әхмәтгалиеванын «Капка» хикәясендә дә ачык чагыла. Язучының әсәрләре белән танышкач, Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, А.Гыйләҗев, Р.Төхфәтуллин, Ә.Еники әсәрләрен тагын бер мәртәбә хәтердән уздырасың. Әлбәттә, бу күренеш безнең татар әдәбиятына хас үзенчәлекле яклар турында сөйли. Һәм шул ук вакытта әдәбиятыбызның традицияләрен дәвам иттерүче каләм әһелләре барлыгына сөенәсең. Сөенергә бәяннның ахыры да этәрә, чөнки укучы күңелендә өмет, яктылык хисе уяна. Шуңа да А.Әхмәтгалиева бәянының исемен рифмалаштырасы килә: «Таллыкүлдә былбыл бар – изге җанда иман бар, саф күңелдә өмет бар».

**Гөлнара МАНСУРОВА, филология фәннәре кандидаты:**

Бүгенге язучылар кырыс чынбарлык елгасын кичә. Борылып, үтелгән юлны күздән кичерә: әсәрләрендә ялган, икейөзлелекне фаш итә; акча потына табынып, чөлпәрәмә килгән хыяллар белән саубуллаша; тормыш арбасыннан төшеп калган, җебегән геройларга ясин чыга.

2014 елда «Казан утлары» журналында басылган чәчмә әсәрләрнең вакыйгалары гадәттә ретроспектив характерда тасвирлана. Ф.Абдуллинның «Чүл бүресе», Г.Әдһәмнең «Зәңгәр кашлы көмеш алка», А.Әхмәтгалиеванын «Коткаручы», «Таллыкүлдә былбыл бар», Х.Галидәннең «Патша солдаты Әхмәтнәсир», Р.Галиуллинның «Җиһан», Ә.Зариповның «Хатирәләрем — хәзинәләрем», З.Хөсниярның «Гарасат», Р.Хуҗиның



«Бер кәнди цемент», С.Якупованың «Әти моны» кебек әсәрләрендә төрле заманнарның үрелешен күрергә мөмкин. Вакыйгалар, каймалау алымына нигезләнеп, бүген-үткән-бүген эзлеклелегендә бирелә. Хәзерге эпик әсәрләрдә кулланылган төп композицион принциплар — көчәйтү һәм каршы кую. Язучылар үткән һәм бүгенге көн вакыйгаларын янәшә куеп бәяли. Иманнарын саткан, битараф соры бәндәләр өере янында күнел жылысына сусаган геройларны күрсәтә. Һәр деталь психологик эчтәлек белән баетыла, жентекләп сурәтләнә.

2014 елның чәчмә әсәрләрендә хикәяләүче образының бирелеше кызыклы. Ул автор образы белән дә берләшә ала: «Айдар Гаязовичның метрога килүенең *безнең хикәябезгә* бер катнашы да булмаганлыктан, *бу турыда сөйләп торуымны кирәк дип тә санамыйм*» (Г.Әдһәм, «Зәнгәр кашлы көмеш алка»); «Беркатлы, *дидек диюен*, әмма бер тапкыр да күрмәгән әтисе турында уйлаганда, ул житдиләнеп китә» (Р.Низами, «Тальян гармун кыйссасы»). Яисә текст эчендә, геройның фикер агышында «эри»: «Тик мулла абзый ялгышты: беркем дә «әүлия» янына килеп мангаен ормады. Адәм баласына фани дөньялыкта гел дөрес кенә яшәргә кирәк микән? Ялгышмыйча, читкә тайпылмыйча туры юлдан гына атласаң — табаныңа гөнаһ тузаны сыланмыйдыр һәм мин Аллаһ каршысына ак килеш, пакь килеш килеп басырмын дип өметләнәсендер. *А, юк, туган, бер нәни генә хатаң мең изгелеккә тиңләшергә мөмкин*» (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»).

2014 елда журналда басылган эпик әсәрләрнең күбесенә уртак алым хас: авторлар бер үк вакыйгага карата төрле геройларның фикерен ишеттерәләр. Бигрәк тә кыска күләмле әсәрләрдә әлеге «күптавышлылык» яңа яңгыраш ала (Р.Галиуллинның «Жиһан», Г.Гыймадованың «Пәрәвез жебе яки кыз әби кыйссасы» хикәяләре, Р.Габделхакованың «Соңгы сорау» бәяне).

Язучылар табигатьне жентекләп сурәтли (А.Әхмәтгалиева, «Таллыкүлдә былбыл бар», Р.Батулла, «Ике жүләр», Р.Газиз, «Тәрәзәләр», Н.Гыйматдинова, «Нурулла»). Хәтта табигать — галәм — Алла образы барлыкка килә (З.Хөснияр, «Гарасат»). Әсәрләрдә табигать һәм риваятьле, жырлы, моңлы авыл образлары мифологик катламны тәшкил итәләр. Авторлар яшәү бишеге булган, изге жир — табигатькә каршы тамырларыннан аерылган хәзерге авылны куялар һәм әлеге фажигане тетрәндергеч итеп күрсәтәләр (Р.Батулла, «Ике жүләр», Р.Галиуллин, «Жиһан», Н.Гыйматдинова, «Нурулла»). Элек-электән билгеле шәһәр-авыл каршылыгы исә XXI гасыр әсәрләрендә шәһәрнең «үсүе» һәм якындагы авылларны «йотуы» булып тергезелә.

Бүгенге татар прозасына хас үзенчәлекләрнең тагын берсе — тирән психологик анализ. Язучылар, пычак-каләм белән коралланып, геройларының жаннарын кисәкләргә телиләр. Гадәттә, чагыштырмача унай герой янәшәсендә жәмгыять, система, «винтиклар» күләгәсе ачыграк күренә (Р.Батулла, «Ике жүләр», Р.Газиз, «Тәрәзәләр», Х.Галидән, «Патша солдаты Әхмәтнәсир», Н.Гыйматдинова, «Нурулла», А.Егин, «Үзбәк хан», З.Хәким, «Сәер никрут», З.Хөснияр, «Гарасат»). Авторлар әсәрләрендә психологик анализ, үзанализ, аң агышы, жан хәрәкәте кебек алымнарны оста кулланалар. Детальләрне төрле төсләргә буйыйлар: «*Яшел* чирәм, *аллы-гөлле* чәчәкләр, *ак* мендәр болытлар йөзгән күк һәм *алтын* нурлар чәчүче түгәрәк кояш» (Р.Габделхакова, «Соңгы сорау»), «Бераз күзәтеп торгач, кар үзе дә *ак* түгел, *кара-кучкыл* булып күренә башлый» (Р.Галиуллин, «Жиһан»), «Чәчкәнең таж яфраклары арасында жемелдәп торган *зәңгәр* кашлы көмеш алка бит ул!» (Г.Әдһәм, «Зәңгәр кашлы көмеш алка»). Кыска репликалы озын диалоглар геройларның күнелен ачып бирә (Ахир, «Таш калада баш кала...», Н.Гыйматдинова, «Нурулла», Р.Рахман, «Көт син мине», З.Хәким, «Сәер никрут»). Мондый «операция»дән соң геройларның куык кебек буш күнелләре шартлый яки жан пычраклыгы ярларга сыймыйча ташып чыга. Укучы, язучының киләчәккә булган өметләре генә бу пычракны жылы яңгыр гөрләвекләре белән юып чыгара ала.

2014 елда журналда чыккан эпик әсәрләр бүгенге ялган фәлсәфәләрнең битлеген ача. Битарафлык (Н.Гыйматдинова, «Нурулла», Р.Хужи, «Бер кәнди цемент»), тамырларыннан аерылу, тормышта урын таба алмау (А.Әхмәтгалиева, «Таллыкүлдә былбыл бар», Р.Батулла, «Ике җуләр»), көчсезлек (Ф.Абдуллин, «Чүл бүресе», Г.Әдһәм, «Зәнгәр кашлы көмеш алка»), җан җылысына сусау (Р.Габделхакова, «Соңгы сорау»), хаклыкны ялган белән алыштыру (З.Хәким, «Сәер никрут», З.Хөснияр, «Гарасат») кебек мәңгелек темалар бүгенге татар прозасында мәйдан тота. Текстларда еш кабатлана торган ачкыч сүзләр дә моны раслый: *сәер, салкын, суык, шом, миһербансыз, караңгы, кара, соң, таш белән беррәттән ак, дога, каен, кояш, җылы, агач, җир, ут, Алла* кебек сүзләр дә килә. Ак һәм караның бәрелеше буыннар, аерым кешеләр арасындагы каршылыкка китерә. Язучыларның идеяләре аваздаш: тамырыңа, асылыңа хыянәт итмичә, үз җиреңдә яшәргә кирәк. Гамәлеңә карап кеше үз җәзасын ала, бәхете өчен үз бәясен түли.

Тема ярлылыгы исә бәян жанрында аеруча нык сизелә. Геройлар бер үк тормыш сукмакларын таптый, бертөрле каршылыкларга очрый. Язучыларга тормыш тәкъдим иткән бай материалны тирәнрәк һәм колачлырак өйрәнү җитеп бетми.

Хәзерге заман укучысы — бик акыллы, әзерлекле укучы. Ул укытучы да, галим дә, тәнкыйтьче дә, табиб та, икътисадчы да, тәрбияче дә, эшмәкәр дә. Күп сораулар бирә, уйланырга ярата. Тормыштагы бураннарга каршы торырлык көчне әдәбияттан эзли. Әсәрне укыганда, автор белән бергә бу укучы яңа әсәр иҗат итә: үз тормыш тәҗрибәсе аша вакыйгаларны, геройларны бәяли. Ана көчле, камил әсәрләр кирәк. Мондый әсәрләрне нык үзәкле, фикерле, сүз тәмен белгән язучылар гына бирә ала.

Бүгенге көндә игътибарга лаек тәрҗемә әсәрләр татар әдәбиятында бик аз. XX гасыр башында Россиядә «Аң» журналы дөнья әдәбиятының классик әсәрләрен татар телендә (рус тәрҗемәләреннән күпкә алдарак) бастыра. Нишләп? Чөнки безнең язучыларыбыз кимендә биш тел белә: төрек, француз, фарсы, гарәп телләрен су кебек эчә. Андый мирас белән без горурлана алабыз. Бүген исә таләпләр тагын да югарырак. Япон, кытай, испан, алман, швед, итальян һ.б. телләрдә иҗат иткән әдипләрнең әсәрләрен татар телендә уку ихтыяҗы бар. Мондый ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен, әлеге юнәлешне җитәкли алган белемле кадрлар, фәнни нигезгә утыртылган аппарат һәм проектлар кирәк. Болар барысы да Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында бар. Очар өчен ныгыган канатлар һәм колач кына җитми.

Иҗат бәйгеләре, билгеле, уңай күренеш, әдәбият үсешен җанландырып җибәрә. Язучылар бер-берсенең мөмкинлекләрен барлый, үзенә күрә иҗат остаханәсе барлыкка килә. Әлеге бәйгеләр язучылар өчен телгә алырлык матди ярдәм дә әле.

Мондый бәйгеләрнең абруйлы казые бар — укучы. Ул, мәсәлән, «Казан утлары»ның «Кыска бәяннар» бәйгесендә катнашкан әсәрләрне укый, журнал редакциясенә хатлар юллап, шалтыратып, фикерен әйтә ала. Әдәби барышның тулы хокуклы вәкиле булып санала.

Гомумән, «Казан утлары» үткәргән гадел, ачыктан-ачык бәйгеләр, укучы һәм язучы арасын якынайтып, татар әдәбиятын зәвыклы әсәрләр белән баета.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр бүгенге язучының иҗатына нык тәэсир итә. Ике телле даирәдә яшәү әсәрләрдә рус алынмаларының ешрак кулланылуына, калька җөмләләрнең артуына китерә: «*Заказлардан* арынган юк... Бик шәп түлиләр безгә, чөнки әти бик оста *плотник*», «Көннән-көн Булатның, уколлар тәэсирендә, *апатиясе* арта барды» (З.Хәким, «Сәер никрут»).

Заман тизлегенә ияреп, язучылар кыска репликаларны мул куллана; сурәтлелек кими, вакыйгалар агымы гына бирелгән, коры әсәрләр күбәя бара. Шуның белән бергә хәзерге татар прозасында һәр геройның тавышы аермачык мөстәкыйль яңгырый. Һәр персонажның үз интонациясе, «үз» сүзләре бар, шуңа бәйле әсәрләргә күптавышлылык хас: «*Жегетләр* яшендә әле без, улым. Моның сере ни дисеңме? *Хе-хе*, мин *дөнҗаны* чеметеп кенә күтәрдем. *Әнәгенәк*, минем кордаш Мидхәт утыз ел элгәресе үлде. Чөнки дә *дөнҗаны колачламактай кыланды*»; «Син Сәйдәгә ышандыңмы, *иптәш... дим прсидәтел*? *Матри*, көпә-көндез алдыйлар, имансызлар!

Кемне диген? *Иптәш... дим прсидәтелне*!» (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»); «*О боже*! Сез мине кая алып килдегез? Анын *пролеженьнәрен* юньле-башлы караучы да булмаган, чи иткә әйләнеп беткән!» (А.Әхмәтгалиева, «Таллыкүлдә былбыл бар»).

Авторлар, идея, проблемаларны тулырак ачу өчен, антоним, синоним, экспрессив лексикага еш мөрәҗәгать итәләр. Автобиографик (Ә.Зарипов, «Хатирәләрем — хәзинәләрем»), тарихи (Х.Галидән, «Патша солдаты Әхмәтнәсир», А.Егин, «Үзбәк хан») әсәрләрдә тарихи, һөнәри лексика урынлы кулланыла.

Язучылар персонажларына эчтәлекле исемнәр бирәләр: Нурулла (гар.: Аллаһ нуры, яктысы), Туйбикә («Мин аны абзыйнын туенда тапкан идем, атасы да исемен шуңа Туйбикә дип куштырды»), Сәҗидә (гар.: баш июче, кемнедер олылаучы хатын-кыз), Шәмсулла (гар.: Аллаһ кояшы), Вәкил (гар.: вәкаләтле, һәр изге эшне һәм гамәлне тапшырган лаеклы зат) (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»). Һәр исем әсәрдә символ, ачкыч сүз вазифасын башкара.

Бүгенге көн язучылары әсәр тукымасына сүрә, дога яки халык авыз иҗаты текстларын күпләп кертәләр. Әлеге алым белән авторлар үз идеяләрен укучыга үтемлерәк җиткерәләр, персонажларнын хис-кичерешләрен ачып салалар.

Хәзерге эпик әсәрләрне укыганда, сурәтләү чаралары тезеп бирелгән оазислар да очрап куя: «*Өрфия яулыктай* болытлар да, *төпсез* тоелган күк йөзе дә, *көйдерердәй* булып кыздырган кояш та, *кырмыскалар сыман* ыгы-зыгы килгән кешеләр тормышыннан бихәбәр кыяфәттә, һәрберсе үз вазифасында иде» (А.Әхмәтгалиева, «Тау итәгендә»), «Текәлеп карасаң, *кар аклыгына, кара төртке булып, каен алкалары сибелешкән*. Каен алкалары түгел, *канатлары каерылып, күктән егылып төшкән яралы кошлар...*» (Р.Галиуллин, «Җиһан»).

2014 елда «Казан утлары» журналында укучы күңеленә юл таба алырлык уңышлы башламнары булган әсәрләр басылды: «Бу матурлыкны бер селтәнүдә юк итәргә ирнен кулы күтәрелмәде» (А.Әхмәтгалиева, «Тау итәгендә»), «Әллә нинди шомлы төн булды бу» (Р.Рахман, «Көт син мине»), «...Нибарысы төш кенә иде ул...» (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»), «Зыкы суык» (Р.Галиуллин, «Җиһан»), «Сугыш тәмамланганда, Рәсим унҗиде яшьлек егет иде» (Ә.Моталлапов, «Гамь»), «Төн пәрдәсен ертып, көнчыгышта якты тасма күренде дә офыкны шәфәкъ алсулыгы төреп алды» (А.Егин, «Үзбәк хан»). Әсәрне кабул итү өчен авыр булган озын җөмләле яки артык гади башламнар да бу елда күренде: «Кызыл чәчәкле шәмәхә яулыгын артка чөеп бәйләгән, иллә дә калын пыялалы күзлеген киеп алган, сары төстәге, инде саннары танылмый да башлаган үлчәм тасмасын муенына аскан әнисе күлмәк кисәргә җыена» (С.Якупова, «Туй алдыннан»), «Сугыштан соңгы еллар...» (Р.Низами, «Тальян гармун кыйссасы»), «Сугыш арты еллары бу» (Р.Низами, «Коръән ашы»).

Бүгенге көн язучылары сөйләм оештыруның төрле стилистик формаларын кулланалар. Әсәрләрдә күпләп туры сөйләм, чит сөйләм, хәтта уртак сөйләм үрнәкләре бар (Н.Гыйматдинова, «Нурулла»). Авторлар тыңдаш кисәкләрне санау юлы белән әсәр идеясен ассызыклыйлар (Ф.Абдуллин, «Чүл бүресе», А.Әхмәтгалиева, «Таллыкүлдә былбыл бар»). Кыска интонацион җөмләләр ярдәмендә әкияти хикәяләү ритмикасы барлыкка килә (Р.Батулла, «Ике җүләр»). Аерым авазларның янәшә килүе образ тудыруда катнаша: «Якында гына, *ыңгырашып*, кар *шыгырдады*» (Р.Галиуллин, «Җиһан»).

Шул ук вакытта язучыларның хәтта җөмләләрдә бер үк грамматик формаларны кабатлавы (бер үк бәйлекләр, заман формалары) әсәрнең яңгырашын һичшиксез боза. Язучылар сурәтләү чараларына, тел байлыгына, аның мөмкинлекләренә игътибарлырак булсын иде.

Укучы буларак әсәрне бәяләгәндә, мин ышанычлы бер ысул кулланам. Әсәрне икенче тапкыр уку теләге туа икән, димәк, бу әсәр минем күңел кылларын ничектер тибрәткән. 2014 елда «Казан утлары»нда басылган әсәрләр арасында андый әсәр бар... Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе...

**Рамил ХАННАНОВ** *әзерләде.*

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

**Гадел Кутуй**
*(Кутуев Гаделша Нурмөхәммәт улы)*
*(1903–1945)*



Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаделша Кутуев (Гадел Кутуй). 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1917 елда Самара шәһәренә күчә һәм монда күренекле рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри, рус телендә үзенең беренче шигырьләрен яза.

1920 елда Кутуй Казанга килә һәм политехника институтына укырга керә. Ләкин ике курсны тәмамлагач аннан китә һәм Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенең клубында хезмәткәр булып эшли. 1925 елда ул Казан Көнчыгыш педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, 1929 елда аны уңышлы тәмамлап чыга. 1931-1936 елларда Г.Кутуй Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында гыйльми хезмәткәр, мәктәпләрдә һәм 1936-1940 елларда Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли. 1940 елдан — профессиональ язучы.

Татарстан Республикасының Милли архивында мин Гадел Кутуйның үз кулы белән язылган анкетасын һәм тәрҗемәи хәлен таптым: ТР МА. Р-7083 фонд. 3 тасвирлама. 62 эш. Төп нөсхә. Шунда ук Гадел Кутуйның Молотов район хәрби комиссариатына язылган гаризасы да саклана. Ул рус телендә:

*«Я, член Союза Советских писателей, занимаясь литературным трудом, в последние годы нигде не работал, не работаю и в настоящий момент. В грозные дни войны, когда против озверелых фашистов защищать социалистическую Родину встал весь советский народ, я не могу оставаться дома. Прошу принять меня в ряды действующей Красной Армии. Пером и штыком буду бить врага, отдам жизнь за дело партии Ленина-Сталина. Умею стрелять и писать фронтовые заметки. Готов выполнять любое поручение ком-политсостава (я родился в 1903 г., б/п).*

*Буду ждать вызова, не выходя из дома до 12 часов ежедневно.*

*Мой адрес: Казань, ул. Комлева, дом 33, кв. 1.*

*Кутуев Гаделша.*
*27/VI. 1941».*

1942 елның 25 маенда язучы Казанның Молотов район хәрби комиссариатыннан армиягә алына. 1942 елның 1 июленнән — Көнбатыш фронтында бер ел гади солдат. Анда ул партия сафларына кандидат итеп алына. 1943 елның гыйнвар-февраль айларында Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномёт бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә, монда ул ВКП(б) әгъзасы була. Аннары гвардия сержанты Г.Кутуй Брянск фронты 3 нче гвардия миномёт бригадасында командирның адъютантлык вазифаларын башкара. 1944 елда аның адресы: 24505-А кыр почтасы.

1944 елның 28 маенда гвардия берләшмәсенең командиры, гвардия полковнигы Михайлов гвардия старшинасы Г.Кутуйны Казанга озак вакытлы иҗади ялга җибәрә. Казанга кайткач, язучы балалар өчен «Рөстәм маҗаралары» исемле әсәрен яза.

Шул елның 11 сентябрендә Г.Кутуй Беренче Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә һәм анда хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Шул вакыттагы адресы: 48251-А кыр почтасы.

1945 елның язында Г.Кутуй, сәламәтлеге начарланып, хәрби госпитальгә эләгә һәм, шушы авыруыннан терелә алмыйча, 1945 елның 16 июнендә Польшадагы Згеш шәһәренең 2606 хәрби госпиталендә вафат була.

Фронттагы күрсәткән батырлыклары һәм хезмәтләре өчен ул Икенче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, «Батырлык өчен» һәм «Сталинградны саклаган өчен» медальләре белән бүләкләнә.

**Афзал Шамовка**

*Афзал дус!*

*Истән чыкмый торган Казанны, кадерле Казанны тагын бер тапкыр күз алдыма бастырган тәфсилле җылы хатың өчен мең кәррә рәхмәт.*

*Хатыңның минем өчен никадәр шатлыклы булуын шуннан бел: мин аны бөек бәйрәмнең икенче көнендә алдым һәм Москвада башланган бәйрәмне сөекле Казанда тәмам иткәндәй хис иттем үземне.*

*Матбугат йортының тарихи 5нче катында[1] төрле-төрле вакыйгалар булып узды: яхшысы да, яманы да. Шулай да якын ул миңа. Сагындырды. Дөрес, монда мин Әхмәтләрне (күзлекле Әхмәтләрне[2] ), Маннурны[3] һәм Разинны күрдем. Ләкин алар Казан турында күп нәрсә сөйли алмадылар. Менә шуңа күрә дә хатыңны йотылып укыдым. Сәрвәр Әдһәмова да шундый бер хат белән шатландырган иде.*

*Сүз уңае туры килгәндә әйтеп узыйм: Ватан сугышы, ил өстенә төшкән авыр көннәр, явыз дошманга каршы көрәш, изге көрәш кешеләрне үзгәртә. Без Маннур белән ике-өч көн очраша алмыйча йөрдек. Ул кабат-кабат мине сорашкан. Ахрысында очраштык. Бу юлы ул миндә яхшы тәэсир калдырды. Хәтта мине газетага күчерү турында Союзда[4] талашып та йөрде.*

*Кем әйтмешли, бәс шулай булгач, синең белән минем арада дуслык-иптәшлек мөнәсәбәте тагы да җылырак булырга тиешле.*

*Иҗат эчендәге сүлпәнлек йөрәкне әрнетә. Син хаклы: фронтта булмаган язучы яңа әсәрләр бирә алуы белән генә үзен сугышка катнашучы итеп хисаплый ала. Правлениенең бөтен эше дә шул юнәлештә булырга тиеш. Хисап докладлары җыелышлар, утырышлар саны белән түгел, халыкка барып җиткән хикәяләр, пьесалар, повестьлар, шигырьләр, очерклар, мәкаләләр саны белән ясалырга тиеш.*

*Акыл бирә дип уйлама. Юк. Москвада мин байтак язучыларны күрдем.*

*Үзара очрашканда, алар яңа әсәрләр укыйлар, шул турыда бәхәс алып баралар. Бездә дә, безнең әдәбиятта да шулай булсын иде дим.*

*Күпне белергә тырышкан балаларыңа һәм Гадиләгә[5] сәламемне тапшыр. Мин әллә ни батыр түгел. Һаман шул ябык чырайлы, чандыр Кутуй. Ләкин юкка гаҗәпләнәләр. Сугышның бик күп серләре бар. Безгә, гвардеецларга, акыл һәм батырлык биргән житәкчеләребез, менә дигән корал биргән халкыбыз бар.*

*Мин генә, без генә түгел, сез дә, нык тылда эшләүчеләр дә, дошманны кисәсез. Минем тарафтан үтерелгән фрицларны әнә шулай бүлә башласаң, гаҗәпләнергә урын да калмый.*

*Шулай да, минем турында яхшы уйда, изге теләктә булган иптәшләргә һәм гаҗәпләнеп сөйләүче гөнаһсыз балаларга рәхмәт укыйм.*

*Иптәш Сталинның тарихи докладлы сугыш әхвәленә яңа яктылык кертте, безнең көчебезне арттырды. Җиңү көннәребез якынлаша. Америка белән Англиядә дә хәрәкәт бүтән төс ала башлады шикелле. Вагыйгалар шуны күрсәтәләр.*

*Язарга, әдәби әсәрләр өстендә эшләргә вакыт юк. Бары тик Совинформбюро буенча чит ил өчен бер-ике мәкалә генә яза алдым.*

*Газета эшенә күчәрменме — белмим. Үзара әйткәндә, ул кадәр күчәсе дә килми. Сугышны рядовой килеш уздырасы килә. Син Перекопта булган кеше — үзең беләсең: сугыш эчендә булуның кыен яклары да, күңелле яклары да күп. Хәер, теләсә нишләсеннәр: үзем сорап йөрмим, ә приказ булса китәрмен.*

*Кем белә — төрле хәл булуы мөмкин. Сугыш бит! Дус итеп, якын итеп сиңа хәрби*

*рәсememне жибәрәм. Күнеләндә сакланып калган тавышым онытылса, рәсемемә карап хәтерләрсен.*

*Гази Кашшафның сәламен алдым һәм җавап итеп үзенә дә Татгосиздат машинкасы сәгать буена баса алган кадәр сәлам юлладым. Барлык иптәшләргә дә сагыну сәламемне тапшыр. Ф.Кәримнен иҗат уңышы — күңелле хәбәр. Бүтәннәргә дә уңыш телим.*

*Бу юлы Москвада мин озакладым. Китеп барсам да, хатыңны Москва, 100, часть №372 адресы буенча яз. Ике-өч ай узса да, хатың мине эзләп табар.*

*Хуш, туган, семья тормышыңа бәхет, иҗат эшенә уңышлык телим.*

*Ком. сәлам белән, Гадел.*
*9/X. 1942.*

**Хәмит Ярмигә**

*Фронтка китүем сәбәпле, мәкаләне очлап бетерә алмадым. Сездә булган театр тарихы турындагы очеркларымнан файдаланып, мәкалә оештыру хокукын сезгә — институтка бирәм.*

*Сәлам белән, Гадел Кутуй.*
*12/VIII. 1944.*

**Гомәр Бәшировка**

*Гомәр туган!*

*Вакыт иртәнге 5. Ә безнең йокларга ятканыбыз юк әле. Син, материалист кеше, бәлки «ник?» дип сорарсың. Урынлы соравыңа җавап бирәм. Башта үткән елның соңгы көнендә һәм төнендә эш күп иде. Өстебезгә йөкләнгән бурычны үтәдек. Кич җиткәнне сизми дә калдык. Аннары, арылган булса да, кызып янган тимер мич янында тәнебезне юк-бар нәрсәдән тазартып утырдык. Яңа ел керим дигәндә, табынга утырдык, сине дә искә алып, касәләребезне күтәрдек. Телләр ачылып китте. Житмеш тапкыр чәй кайнаттык. Эчтек тә соң, малай!*

*Гариф[6] бүген часть буенча дежурный, мин бу юлларны язганда, ул постлар тикшереп йөри. Үзе түзми, яныма кереп чыга, сәлам язарга куша. Менә Ярмакеев[7] та: «Мин дә аны беләм бит, миннән дә сәлам яз!» — дип утыра һәм Казанны сагынып, авыз эченнән генә нәрсәдер көйли. Ибрай Газый исә, әдәбият турында гәп алып арыды да йокыга талды.*

*— Мә, укы, — дип Гариф синең хатларыңны миңа да укытты. Хатларың җылы язылганнар; без шәрәфләрне дә искә алуың өчен чын күңелдән рәхмәт. Мин җавап итеп, сагыну сәламе юллыйм һәм Яңа ел белән котлыйм.*

*Гариф ул озын хат язарга ярата, кыска язарга күңеле бармый, ә озын язарга йә кәефе, йә вакыты булмый. Әмма сине искә бик еш ала. Шуның өчен дә син аны озак язмый торуы өчен кичер. Ул нечкә күңелле кеше (гаҗәп яхшы иптәш икән). Чын әдип шундый булырга да тиеш.*

*«Намус» дигәнең намуслы булып чыксын, тынып калган әдәбиятыбызга җанлылык кертсен. Үзең әйтмешли, сиңа бәхет китерсен, аны укыячак без бәндәләргә дә күңелле сәгатьләр алып килсен.*

*Эшебез гөрли кебек. Йокысыз төннәр нәтиҗәсендә туган хезмәт күңелдә татлы канәгатьләнү тудыра. Мин үзем вакытның иң күп өлешен алгы кырыйда уздырам. Җәфасы теңкәгә тисә дә, матур очрашулар бөтенесен дә оныттыралар. «Разин, исәнме? Землянкадагы төтен эченнән сине күреп, искә алдым да сәлам язарга булдым. Миннән сәлам, ә мин Ярмакеев булам». Хатымны кулымнан тартып алып, бу юлларны Ярулла язды. Янәсе сагынганын белдерәсе килгән. Хатымны дәвам итәм. Әдәби әсәрләр өстендә эшләргә вакыт бөтенләй дип әйтерлек юк. Шулай да уйланырга, киләчәктә язар өчен булса да тәэссоратларны кәгазьгә теркәп калырга тырышабыз. Гариф шулай да 2-3 хикәя язып ташлау җаен тапты. Шулардан берәрсен әлманахка җибәрер дип уйлыйм. Ибрай да, иҗат кыенлыкларын кичереп, хикәя тудырырга маташа. Миннән хикәя туармы, юкмы, туса, кайчан туар — белмим. Һәрхәлдә, үзем канәгатьләнерлек әйбер яза алсам, җибәрермен. «Менә сиңа, туган ил» дигән шигырь җибәрәм, шуңа тагын «Иртәнге уйлар» шигырен дә кушарга мөмкин (Ул «Кызыл Татарстан»да гына басылып чыккан иде). Хикәя бирү, әлбәттә, яхшырак булыр иде. Кем белә — бик ихтимал, илһам килеп язылып та куяр.*

*Әмма язасы килә дә соң! Ел түгел, 2-3 ай гына булса да язу өстәле янында утыру бик тә кадерле булыр иде. Каһәрләнгән немецларны тизрәк жинеп, өйгә кайтасы иде дә жин сызганып язып утырасы иде. Тизрәк тусын иде шул көннәр!*

*Сездә кыш, дисен, матур бураннар була, дисен. Ә биредә кар бөтенләй юк. Бары тик чеметеп ала торган салкын жил генә бар. Туган ил сагындыра. Карын да анын шикәр итеп ашар идем.*

*Хуш, туган. Иптәшләргә сәлам әйт.*

*Уңышлык һәм сәламәтлек теләп, сәлам белән, Гадел.*

*Бу хатка кушып, ике рәсем жибәрәм. Кирәк булса, кайсын булса да файдаланырсыз. Ләкин үтенәм: көлеп төшкәнен югалтмагыз, гаиләмә язылган хат ул.*

*1/I. 1945.*

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасв. 113 эш. 1, 1 әйл. бит. Төп нөсхә.

*2/III. 1945.*

*Гомәр туган!*

*Хатымны ничек итеп башласам да, канәгатьләнмәм төсле. Без бер табын кешеләре булсак та, бер-беребезне белмичә һәм, дөресен әйтим, шуңа омтылмыйча яши идек. Без бит укучылар гына, әдәбиятка кызыксынып караучылар гына түгел, әдип булырга тырышучылар да. Безгә бер-беребезне белергә, ижатта үзара булышлык итәргә кирәк. Мин сине, һич ялганламыйм, сүзгә саран, эчке кичерешләргә ярлы һәм коры (сухой) кеше дип ялгыш уйлап йөри идем.*

*Инде менә хатың килеп төште. Шигъри жылылык, тирән хис-тойгы никадәр бар анда! Хатыңны укып чыккач, ник мин анын белән элек-электән үк таныш түгел», дип әрнеп утырдым. Фикеремне дустым Гарифка әйттем. Ул: «Һәй, гажәп, ялгыш уйда йөргәнсең, бик сөйкемле кеше ул!» — диде. Минем дә, нәкъ син уйлаганча, бергә буласы, бергә утырасы, тәмле сөйләшәсе килде.*

*Сугыш кешеләрне генә түгел, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә үзгәртә. Хак сүз әйтәсең, сугыштан соң әдәбиятыбыз гөрләп үсәргә тиеш. Чәй дә эчтек, гәпләштек тә, хәтта жылаштык та дип әйтергә мөмкин. Мин кайтып төшкәндә, анын теше авырта, аягы сызлый иде. Терелеп киткәндәй булды. Инде сина хат язып утыра. Анын турында язып тормыйм. Ул булмаса, мина бик күнелсез булыр иде.*

*Эшебез ярыйсы гына бара. Әмма Казан сагындыра.*

*Бик каты зәмһәрир жил кузгалды. Мондый начар һавада йә жылы өйдә яхшы китап укып утырасы, йә театрда яхшы музыка тынлап ләззәтләнәсе килә. Менә кар да ява башлады (Россия карыдай матур түгел, ләкин жепшек, жир дә кабул итми үзен, жил очыртып әллә кая алып китә), агачлар сыкрый, түбә калайлары улый. Илгә кайтасы килә.*

*Хуш, туган, эшенә уңышлык телим. Сәламәт яшә, рухын күтәренке булсын.*

*Иптәшләргә сәлам әйт.*

*Иң яхшы теләкләрдә калып, сәлам белән, Гадел.*

*P.S. Ибрай һәм Гариф үзләре сина хатлар яздылар, хатынны жыйнаулап укыдык. Анда күтәрелгән мәсьәләләргә үзләре жавап язалар. Дүртебездән дә сәлам.*

ТР МА. Р -6529 фонд. 1 тасв. 113 эш. 3, 3 әйл. бит. Төп нөсхә.

**Искәрмәләр**

[1] Тарихи 5 нче кат — элек Татарстан совет язучылары союзы идарәсе урнашкан кат.

[2] Күзлекле Әхмәтләр — шагыйрьләр Әхмәт Ерикәй (1902-1967) һәм Әхмәт Фәйзи (1903-1958).

[3] Шәйхи Маннур (1905-1980) — язучы.

[4] Союз — СССР Язучылар берлеге.

[5] Гадилә — Афзал Шамовның тормыш иптәше.

[6] Галиев Гариф Закир улы (Гариф Гали, 1903-1985) — язучы. 1941-1946 елларда армия хезмәтендә. 1943 елның гыйнварыннан Мәскәү хәрби округының «Кызыл сугышчы» һәм Беренче Белоруссия фронты политидарәсе чыгарган «Кызыл Армия» фронт газетасы редакциясендә жаваплы сәркатип.

[7] Ярулла Ярмакеев (1905-1968) — «Кызыл Армия» газетасының мөхәррир урынбасары.

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

# КАБАТЛАНМАС ШӘХЕС



Кешеләр китап аша язучы белән танышалар, спектакль карап артистларны таный башлыйлар, еш кына сәхнәдә режиссёрны күреп, аңа кул чабалар, ләкин күпләр режиссёрның нәрсә белән шөгыльләнгәнен аңлап бетерми. Кемдер аны камчы тотып, артистларны камчылап йөри торган Карабас Барабас дип уйлый, кемдер артистның юбилеенда сәхнәгә чыгып, юбилярга акчалата бүләк бирә торган кеше дип күз алдына китерә. Әлбәттә, бу алай түгел, әлбәттә, бу ялгыш фикер.

Театр сәнгатендә режиссёр — төп фигура. Аның бер ягында автор иҗат иткән пьеса булса, икенче ягында — буш сәхнә белән бер төркем артистлар. Менә шул кәгазьгә язган текстка җан өреп, артистларны, композиторны, рәссамны, сәхнә эшчеләрен берләштереп, тиешле юнәлешкә җибәреп, залда утыручы җиде йөз кешене ышандырырлык спектакль тудырыр өчен, кендек әбисе кебек җиң сызганып, маңгай тирен агызып эшли торган кеше кирәк — ул кеше режиссёр була.

Бу эш — искитмәле ихтыяр көче, интеллект һәм бик зур рухи байлык таләп итә. Артистлар да, язучылар да күп, режиссёрлар исә бармак белән генә санарлык.

Марсель абый бу эшнең виртуозы иде. Алай гына да түгел, Ходай Тәгалә режиссёр сәләтенә юрист, оратор, дипломат, коммерсант талантын да кушып, нәтиҗәдә халкыбызның Марсель Сәлимҗанов дигән горурлыгын, милләтебезнең бөек шәхесен тудырган.

Без бит милли театрда эшлибез. Безгә туган телне сакларга, милли рухны үстерергә кирәк. Яшерен-батырын түгел, соңгы вакытта бик үк матур булмаган күренешләргә дучар булабыз. Теле ачылып килә торган бала белән әти-әнисе русча гына сөйләшәләр. «Нигә татарча да сөйләшмисез, нигә балагызга татар теле дә өйрәтмисез?» дип сорагач, «аннан ни файда, татар теле белән нинди институтка керә ала да, кайда бара ала ул», — дип җавап бирәләр. Аңлыйсызмы? Туган телдә сөйләшүдән файда эзли башладык. Өч тәңкәлек файда булмаса, туган телдә сөйләшмибез дә. Балаларыбыз инглизчә, французча, немецчә сөйләшәләр, русча сөйләшеп — русны сата, япон теле өйрәнәләр, ә туган телен өйрәнергә теләмиләр.

Марсель абый университетта юрфакта да укыган, Мәскәүнең данлыклы ГИТИСын да тәмамлаган, Россия күләмендә спорт мастеры да булган, төрле милләт кешеләре белән дә аралашкан, ә туган телне онытмаган, милли рухны югалтмаган. Каян килгән соң аңа көчле рух? Әлбәттә, совет мәктәбеннән түгел. Ул рух аңа әти-әнисенең, әби-бабасының тәрбиясе белән сеңгән.

Шунысын да онытмыйк: Марсель абыйның әтисе Хәким ага яшь чагында «ата комсомол» була. Утызынчы еллар, Сталин чоры... Ләкин Хәким абый баласын татар рухында тәрбияләгән, баласына татар теле өйрәткән. Ә Марсель абыйның әнисе Галия апа Нигъмәтуллина — «купец первой гильдии» гаиләсеннән. Революциягә кадәр яшәгән миллионер сәүдәгәрләребез мәчетләр салганнар, татар мәктәпләре ачканнар. Алар милләтпәрвәр булганнар. Ә бүгенге миллионер сәүдәгәрләребез, кызганычка каршы, балаларына милли тәрбия бирү түгел, алар белән татар телендә сөйләшә дә алмыйлар.

Ләкин милләт тел белән генә чикләнми. Аның башка яклары да бар. Әйтик, Марсель абый татар көйләрен үлеп ярата иде. Җәй көне балыкка баргач, учак янында утырганда: — «Әюп! Җырла әле!» — дип, Әюптән җырлавын сорый иде. «Әюп» дип без мәрхүм Наил Әюповка дәшә идек. Ул искиткеч тавышлы, тумыштан җырчы булып яратылган артист иде. Әюп җырлап җибәрә иде. Үкереп, улап түгел, шыпырт кына, йөрәгеннән чыккан хисләренә ияреп. «Ык сулары»н, «Кандыр буе»н җырлый иде. Әюп җырлый, Марсель абый елый иде. Үксеп, бәргәләнеп түгел, җырны тыңлап уйларына чума да ике күзеннән мөлдерәмә тулган яше агып төшә.

Күз алдыгызга китерегез: Марсель Сәлимжанов елап утыра. Анын жыры да матур инде, Әюп тә шәп жырлый. Ләкин бу — Марсель Сәлимжанов дигән шәхеснен ни дәрәжәдә нечкә күнелле булуын күрсәтә торган хәл.

Нечкә күнелле булса да, эш турында онытмый иде. Театр пьесадан башлана, пьесаны язучы ижат итә. Шуна күрә Марсель абый гел татар язучылары белән аралаша, алар белән дус иде. Туфан Миннуллин, Аяз Гыйләжев, Шәриф Хөсәенов анын гаилә дуслары булды. Алар йөрешәләр иде. Сөйләшәләр, киләчәккә планнар коралар, чөнки фикердәшләр иде. Аларнын дуслыклары ижатларында да чагылыш тапты. Ә күпме яшь язучыга юл ачты Марсель абый? Ризван Хәмид, Зөлфәт Хәким, Мансур Гыйләжев — барысын да театрга Марсель абый китерде.

Ярый, язучылар белән сөйләшеп, аралашып та була. Анда бит әле бер төркем артистлар күзенә карап тора. Һәрберсенә роль кирәк. Алар белән уртак тел табарга кирәк. Күп кенә театрларда режиссёр ин жинел юл белән китә. Камчылы Карабас Барабаска әверелә. Алай да эшләп була, алай да эш бара. Ләкин андый эшнен нигезе черек була. Көчләп, куркытып ижат кешесен эшләтеп булмый. Театрда фикердәшләр ижат итәргә тиеш. Бер-берсен хөрмәт итеп, анлап, тоеп эшләгәндә генә унышка ирешеп була. Марсель Хәкимовичнын уңышлы хезмәтенен сере дә шунда — ул коллективка үз гаиләсенә караган кебек карады, артистларны үз балалары кебек кабул итте. Шуна күрә артистлар да ана ихтирам, хөрмәт белән карадылар. Жан жылысы белән жавап бирделәр.

Гомер уза, нишлисен бит... 67 яшендә Марсель абый безнен арадан китеп барды. Күп театрлар, баш режиссёры китсә, тарала, сүтелә, һәрхәлдә пыскып яши башлый. Марсель абый үлгәч тә, күп кеше: «Театр белән ни булыр? Театр таркалмасмы, үлмәсме?» — дип уйлагандыр.

Монда да Марсель абыйнын бөеклеге чагылды. Ул күптән инде: «Мин киткәч, театр кем кулына калыр? Әти-әнием эшләгән, Тинчурин, Сәйдәшев ижат иткән театр ни хәлдә булыр?» — дип борчылды. Һәм ул театрда туган, сәхнәдә уйнап үскән Фәрит Бикчәнтәевнен режиссёр сәләтен күреп, башта театр училищесында укытып, аннан, Мәскәү институтына юл күрсәтеп, Фәритне режиссёрлыкка этәреп жибәрде. Фәрит укып кайткач: «Менә сина сәхнә, менә сина артистлар, нәрсә куярга телисен, ничек куярга телисен — үз эшен, рәхим ит!» — диде. Марсель Хәкимович хаклы булып чыкты, Фәрит анын өметләрен аклады. Театр үлмәде, киресенчә, яна сулыш алып, кан янартып алга китте. Колумбия, Төркия, Финляндия, Кытайга барды. Англиядә гастрольләр уздырып кайтты. Әлбәттә, Марсель Хәкимович чорындагы театр түгел бу. Анын эстетикасы, уйнау алымнары үзгәрде. Бу Фәрит теләге, Мәдәният министрлыгы таләбе түгел, бу — заман таләбе. Театр алга барырга тиеш. Алай булмаса, бер урында таптанса, ул тынчый башлый, сазлыкка әверелә. Ә Камал театры киресенчә яшәреп, алга омтыла. Димәк, Марсель абыйнын эше дәвам итә.

Бездә Туфан Миннуллиннын «Монлы бер жыр» пьесасы буенча куелган спектакль бар иде. Муса һәм жәлилчеләрнен үлеме турында. Финалда минем персонаж — Яшь шагыйрь — палачтан: «Син кем башларын кисәсенне анлыйсынмы?» — дип сорый. Палач Туфан Миннуллин сүзләре белән ана болай дип жавап бирә: «Әйе, мин кеше башларын кисәм. Кеше үлә инде. Кемдер бүген, кемдер бер елдан сон үлә. Үлемсез кеше юк! Үлем чүп ул! Менә үлгән кешедән сон идея кала. Идея яши. Аны бернишләтеп тә булмый. Идея — үлгән кешенен эшен дәвам иттерә, анын исемен яшәтә!»

Марсель абыйнын идеясе — татар театры иде. Татар милләте иде. Ул безгә һаман: «Театрны саклагыз. Татар театры яшәсә — татар халкы яшәр; татар театры булса — татар милләте булыр!» — дип әйтеп килде.

Кемнедер мактаганда, кайвакыт скептиклар тарафыннан: «Алыштыргысыз кешеләр юк», — дигән фикер ишетергә туры килә. Аларга минем жавабым: әйе, алыштыргысыз кешеләр юк, бар — кабатланмас шәхесләр. Безнен өчен кадерле кешеләр — Кариев, Тинчурин, Сәйдәш, Марсель Сәлимжановлар — кабатланмаслар!

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН,**
*Татарстанның халык,*
*Россиянең атказанган артисты*

# МӘГЪНӘ

## Фәрештәләр

*Иманның икенче шарты ул — фәрештәләргә ышану*

Жирдә тереклек итәр өчен су, туфрак хайванат — балыклар, кошлар, үсемлекләр мул. Хәзер кеше ясыйсы гына калды. Ләкин Кешегә кадәр Аллаһның гозерләрен үтәр өчен иң башта фәрештәләрне барлыкка китерергә кирәк. Аллаһы Тәгалә беренче кайсы фәрештәне яралтты икән?

Газраилнеме, Микаилнеме, Жәбраилнеме, Исрафилнымы, әллә кятибин-фәрештәләренме яки Һарут белән Марутнымы, бәлки Нәкир белән Мөнкирнедер, әллә Газазилнеме?

Мантыйкый фикер йөртеп карыйк. Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне нурдан яралткан, бары тик Газазилне генә уттан барлыкка китергән. Газазил — Иблиснең фәрештә чагындагы беренче исеме. Матур исем — Газазил! Ләкин шушы матур исемне йөртүченең эчендә хөсетлек, башкалардан көнләшү, үзен бүтәннәрдән өстен куюу тойгылары тулып ята. Алга таба аның исеме дә үзгәрәчәк — Иблис! Шайтан!

Матдәне, Кояшны, Әсманны барлыкка китергәнче фәрештәләр дә, Иблис тә була алмый, чөнки әле ут юк, яктылык юк, нур юк, димәк ки, фәрештәләрне бары тик галәм, ут белән яктылык барлыкка китерелгәч кенә ясау зарури. Аннан соң фәрештәләрнең һәрберсенең вазифасы бар, алар күбесенчә кешелек җәмгыятенә кагылышлы йөкләмәләр. Бәс, Жир йөзендә кеше булмыйча, фәрештәләр вазифалы була алмый. Әйтик, Газраилнең вазифасы — Аллаһның әмере илә кешеләрнең җанын алу. Кешеләр булмыйча торып, җан алучыга ихтыяҗ юк. Жәбраилнең вазифасы — Аллаһның вәхийләрен пәйгамбәрләргә ирештерү. Кешелек җәмгыяте булмый торып, бу вазифаны үтәү ихтыяҗы да булмый. Исрафил фәрештә кешеләр үлеп, Ахырзаман килгәч, Сур быргысына өреп, мәетләрне уятырга вазифалы. Заман әле башлана гына, Ахырзаманга байтак вакытлар бар. Исрафилның да кирәге күренми. Сорау фәрештәләренең дә кирәге юк, алар вазифалы булсын өчен, кешеләрнең үрчеше, үлеше кирәк. Ризван фәрештә җәннәттәге тәртипләр өчен җаваплы. Әле җәннәт юк, Ризванның да кирәге юк. Мөнкир белән Нәкир мәетне гүргә иңдереп, җирләүчеләр кайтып китүгә үк сорау ала башлыйлар. Мәет булсын өчен кеше кирәк.

Микаил фәрештәнең вазифасы — табигать күренешләре белән идарә итү. Жир йөзе бар, таулар, вулканнар бар, океаннар бар, Күк йөзе бар, болытлар бар. Микаил фәрештәнең эше житәрлек. Жир тетрәтүләр, янар тауларны аттыру дисенме, яңгырлы давыл, өермәләр белән идарә итү дә бик кирәк. Адәм галәйһи вәссәлам яралтылганчы ук Микаилгә вазифа йөкләтелгән булырга тиеш. Аллаһ тарафыннан яралтылган беренче фәрештә Микаил, дип фаразларга була.

Адәмгә җан иңгән вакытта фәрештәләрнең барысы да Алла хозурында була инде. Димәк ки, фәрештәләр Адәм ясалыр алдыннан бар ителгәннәр, һич югында бер мизгел алдан яки миллион еллар әүвәл. Без моны төгәл әйтә алмыйбыз.

Фәрештәләрнең вазифалары күп төрле, фәрештәләр үзләре дә бик күп, ләкин аларның вазифалары Аллаһы Тәгалә белән кешеләр, пәйгамбәрләр арасында хәбәр йөртүчеләр. Кайчакларда фәрештәләр кеше кыяфәтенә кереп, Жир йөзенә иңеп, Аллаһның әмерләрен кешеләргә тапшыралар, кайвакыт алар адәм баласының төшенә кереп, вәхий (хәбәр, Аллаһның әмерләрен) иңдерәләр.

Мәсәлән, тау мәгарәсе эчендә гыйбадәт кылып утырганда нур балкышы булып Жәбраил фәрештә Мөхәммәднең күзенә күренә дә «Галәк» сүрәсен Мөхәммәдкә сузып әйтә:

*Дәвамы. Башы 2014 елның 7нче санында.*

— Укы! — ди.

— Мин укый-яза белмим бит! — ди Мөхәммәд.

— Коръәнне халыкка өйрәтер өчен укы! — дип кабатлый фәрештә.

Ни гаҗәп, өченче тапкыр әйткәч, Мөхәммәд Җәбраил фәрештә артыннан кабатлап укый башлый.

Менә ул Җәбраил фәрештә алып килгән Аллаһның изге сүзләре, әйтерсең лә бүген сөйләнә торган сүзләр.

**Сине юктан бар иткән Раббыңның исеме белән укый башла. Аллаһ инсанны бер галәктән (аталанган күкәйчектән, кузәнәктән, яралгыдан) хасил итте. Укы! Раббың синең чиксез юмартлык иясе. Ул каләм белән язу язарга өйрәтүче. Кешегә элек мәгълүм булмаганнарны да өйрәтүче. Юк бит, кеше барыбер бозык юлда. Баеп алгач, мин (Аллаһка) мохтаҗ түгелмен, дип әйтер. И, адәм баласы! Җавап тотарга син Раббың хозурына кайтачаксың. Намаз укыганда берәүсенең икенчесен (намаздан) тыйганын күрдеңме? Намаздагы кешене намаз укудан тыю дөрес эш булырмы? Хәтта ул (намазны боздыручы) үзе кешеләрне: Аллаһның җәзасыннан куркыгыз, гөнаһлардан сакланыгыз, дип өндәргә алынган булса да. Күрдеңме, ул Хакыйкатьне ялганга чыгарды да, йөз чөерде. Ул бәндә Аллаһның барысын да күреп торганын белмимени? Бу эшеннән ваз кичмәсә, хактыр ки, аны маңгай чәченнән тотып, (җәһәннәмгә) өстерәп алып барырбыз. Ялганчы гөнаһкярның маңгай чәченнән. Тели икән, ул үзенең якыннарын ярдәмгә чакырсын. Без дә зобаниларыбызны чакырырбыз. Сак бул! Аңа буйсынма. Сәҗдә ит. Аллага якынлаш!**

96 (Галәк) 1–19.

Җәбраил фәрештә 23 ел буена Мөхәммәдкә Аллаһның аятьләрен индерә һәм Мөхәммәд пәйгамбәр гомере буе халыкка Коръәнне аңлата.

Фәрештәләр барлыкка килде һәм, әйтергә кирәк, Аллаһы Тәгалә фәрештәләр каршысында Адәм галәйһи вәссәламны барлыкка китерә.

**БАТУЛЛА**

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

*Котлыйбыз!*

## Мәгъсүм Гәрәевкә 80 яшь

1935 елның 7 февралендә Татарстанның Питрәч районы Шәле авылында туа. 1956 елда ул Шәле урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Икенче курсны тәмамлаганда, аны Татарстан радиосына даими эшкә чакыралар. Шул вакыттан ул киң даирә җәмәгатьчелеккә үзен журналистика аша таныта башлый. Төрле елларда «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Татарстан хәбәрләре», «Шәһри Казан» газеталарында, «Чаян» журналында хезмәт куя. Аның заманның иҗтимагый-социаль мәсьәләләренә, күренекле шәхесләренә багышланган очеркларын, мәкаләләрен Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан дистәләрчә китап-җыентыкларның һәркайсында диярлек күрергә мөмкин.

2004-2005 елларда язучы-публицистның сайланма мәкаләләре, хикәяләре, иҗат портретлары, юмор-сатира әсәрләре һәм автобиографик язмалары-истәлекләре тупланган «Мин, Чуен Гәрәй малае...» һәм «Җаның кыйбатмы, малыңмы?..» дигән китаплары дөнья күрә.

2005 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Робагыйлар

Картлык ни ул? Тиктомалдан колак тону,
Җәйнең кызу чилләсендә аяк туңу,
Боларына түзеп була, иң яманы —
Һәр чибәргә результатсыз гашыйк булу.

***

Язлар җитәр, бөреләр дә шешенерләр,
Яз каршылап, гүзәлләр дә чишенерләр.
Тагын ни дим? Нәрсә әйтим?.. Бәлки әле
Күздән чәчкән кишерләрем тишелерләр.

***

Әйдә әле, сүзне башлыйк шуннан, мадам,
Яратылган бит син минем кабыргадан.
Шул кабырга миңа бүген җитеп бетми,
Үз урыныңа, бәгырькәем, кер яңадан!

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН**

## Тмин

Поэзиягә Тмин *(Туфан Миннуллин)* килгәч, шигърият дөньясында паника, ыгы-зыгы башланды. Тәнкыйтьчеләр идән астына киттеләр. Әле кичә генә «мин шагыйрь!» дип күкрәк кагып йөргәннәрнең кулыннан каләмнәре төште, борыннары салынды. Әдәбият галимнәре дә куркуга калды. Чөнки Тмин поэзиясе галәм шикелле иксез-чиксез, аның кайда башы, кайда ахыры икәнлеген һич тә белерлек түгел иде. Бернинди кануннарга да буйсынмый иде бу поэзия, һәм шул ук вакытта үзе кыңгыраулы саратский гармун кебек гармоник, күкәй сарысыдай түгәрәк һәм камил иде. Җиде кат җиз иләк аша иләнгән ондай вак һәм йомшак, сигезләп үрелгән чыбыркыдай нәфис һәм куркыныч, салават күпередәй аллы-гөлле һәм ерак, роза гөледәй хуш исле һәм чәнечкеле иде бу поэзия.

Тмин шигърият мәйданына юкә сыбызгыдан җиз быргы тавышлары чыгарып, җәен авызына томырылган шыртлакадай атылып килеп керде.

Хәзерге көндә Тмин — шагыйрь — мөгезләрен алга таба төбәп, аяклары белән җир тырнап торган гайрәтле үгезне хәтерләтә.

*1978*

**Фәнис ЯРУЛЛИН**

## Көндәлектән

*29 май, 2005 ел.*

Фоат Галимуллин рәислеккә сайланып, бераз вакыт үткәч, аны ике урынбасары — Шаһинур Мостафин һәм Галимжан Гыйльманов белән өйгә чакырып, бик каты сүккән идем. Күбрәк Фоатка эләкте: «Нишләп сез, халык каршына чыгып баскач, түрәләр артында мескен балалардай басып торасыз. Билегез бөкрәйгән, сүзләрегез залдагы халыкка ишетелми, житмәсә, ике-өч минут саен борын сөртәсез. Болай итеп бит сез Язучылар союзының дәрәжәсен төшерәсез», — дидем. Алар минем сүзләргә үпкәләмәделәр. Фоат Галимуллин Президент янында да гәүдәсен туры тотып, сүзләрен кеше ишетерлек итеп сөйли башлады. Ә Галимжан Гыйльманов: «Фәнис абый, усал булсагыз да яратам мин сезне», — диде. Шаһинур Мостафинга ни әйтсәң дә: «Рәхмәт, рәхмәт», — дип үткәреп жибәрә, эшен эшләми...

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## «Вот и сдули...»

Кремльдәге Президент сарае. Татарстанда Свердловск өлкәсе көннәре бара. Актив белән очрашуга Минтимер Шәймиев белән губернатор Эдуард Россель килеп керә. Ашыга-ашыга президиум өстәле янынннан узганда, «Минтимер Шәрипович Шәймиев» дигән язу идәнгә очып төшеп китә. Моны күреп калган Президент шунда ук шаяртып ала:

— Вот и Шаймиева сдули!

Залдагы халык кына ни өчендер әлеге шаяртуны ишетмәмешкә салыша. Үз вазифасын яхшы белгән хезмәткәр идәндәге кәгазьне яшен тизлеге белән урыныннан алып куя. Очрашу башлана.

## Иван Грозный кебек

Чаллы Язучылар оешмасы төзелүгә 25 ел тулу уңаеннан язучылар жыелган. Оешма житәкчесе Вахит Имам кунак язучыларны мәктәптән мәктәпкә йөртә, тын алырга да ирек бирми. Хәлдән тайган Туфан Миңнуллин:

— Карагыз әле, бу Вахит Имам гел Иван Грозный кебек кылана башлады! — дип зарлана икән.

— Иван Грозный түгел инде, Имам Грозный! — дип төзәтеп куя аны Роберт Миңнуллин.

## Бүгенге эстрада

Татарстан телевидениесенең «Чулпан» программасыннан жырчы Салават Фәтхетдинов сөйли:

— Бүгенге татар эстрадасы бик түбән дәрәжәдә...

Роберт Миңнуллин, тапшыру тәмамлангач, Салаватка шылтырата:

— Мин бик аңлап бетермәдем, «эстрада бик түбән дәрәжәдә» дип, үзеңне дә кертеп әйттеңме, әллә инде башкаларны бөтенләй күздә тотмадыңмы?

**Камил КӘРИМОВ**

## Авылча

Язучылар оешмасында авыл темасына багышланган сөйләшү бара. Җыелышның олы кунагы, Премьер-министр урынбасары Марат Әхмәтов авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлар һәм проблемалар турында иркенләп чыгыш ясый.

— Вертолёттан карап йөрдем: бик күп авылларда әле юл юк, урамнарда быкырдык, фермаларны тирес күмгән...

Шулчак Камил Кәримов, сабырсызланып, министрны бүлдерә:

— Марат Готович, җәяү йөрсәң, авылда тагын да хуҗе әле ул...

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Өч татар башы

*(бер агай сөйләгәннән)*

Марат Әхмәтовның Казан артында, Балтач райкомының Беренче секретаре булып эшләгән чагы. Язгы чәчүләр бара. Районның төньяк тарафындагы бер колхоз рәисе чәчүгә чыгарга карышыпмы карыша икән. Сирәк була торган мондый «саботажлык»ның сәбәбен урында тикшереп, ачыкларга дип, Марат Әхмәтов икенче секретарьны һәм районның баш агрономын шул хуҗалыкка җибәрә.

Барып төшәләр болар. «Чәчүне башларга иртәрәк, җир өлгермәгән!» дип колхоз рәисе аяк терәп черәшә. Бергәләп кырга чыгалар. Дымсу туфракны учка алып, иснәп тә, уып та, кабып та карыйлар: «өлгергән-өлгермәгән» арасында бәхәс куба. Һич кенә дә уртак фикергә килә алмыйлар. Шул мәлдә, җигүле атын ялкау гына атлатып, кыр юлыннан чуваш агае килеп чыга.

— Син, агай, күпне күргән кеше, әйтеп бир әле безгә, — дип аны туктаталар. Чуваш агае, чалбарын төшереп, шәрә артын яктыртып, җиргә утыра, бераз шулай сәҗдәгә китеп алганнан соң:

— Өлгергән! Чәчәргә пула! — дип торып баса.

Икенче секретарь бу хәлне райкомга кайтып сөйләгәннән соң, Марат Әхмәтов:

— Да-аа, өч татар башы бер чуваш күтенә тормаган икән... — дип куя.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ**

## Ямаулы янчыктан

- Улым — ирәя, үзем — бабая, хатын әбия барабыз.
- Башына чүкеч төшкәч, кадакның күзеннән утлар күренде.
- Азалияләр аз иде, Азганияләр күбәйде.
- Күләгәмне күзәтеп барам — чит күләгә кизәнмиме?!
- Лыгыр-Лыбыр белән Лар-Лорлар янында Ләм-Мимне сагындым.
- Наркомнарны белә идек, инде наркоманнар...
- Ризык сыман, сүз дә ялгыш юлга киткәли.
- Халкым, халкым, диеп кем генә, ничек кенә шауламый. Түзә халык. Һаман да бер... халык башы!
- Сукырлар гел елмаеп йөри — эчпошыргыч нәрсәләрне күрмәгәнгәме әллә?

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

## Реплика

*«Казан утлары» журналының быелгы 1 нче санында шагыйрь Эдуард Мостафинның туууна 70 ел тулу уңаеннан Газинур Моратның «Күз калдырып китә кошлар» исемле язмасын зур кызыксыну белән укып чыктым. Анда шагыйрьнең 1997 елны гаип булуы хәбәр ителә. Язманың бигрәк тә шушы юллары гаҗәпсендерде:*

*«Дөресен әйткәндә, Эдуард Мостафинны без тәмам онытып бара идек инде. Ярый әле Марсель Галиев йокымсыраган хәтерләребезне сискәндереп уятып җибәрде. Аның «Безнең мирас» журналында (2014 ел, 5 нче сан) дөнья күргән «Бишенче фасыл» дигән мәкаләсе шагыйрьнең исемен кабат кайтаруга бәрабәр булды, дисәң дә ярыйдыр...»*

*Эдуард Мостафинны онытмау, оныттырмау мәсьәләсе алай ук аяныч түгел. Эдуардның якын дусты журналист Мөдәмил Әхмәтов (узган ел мәрхүм булды, авыр туфрагы җиңел булсын), китап чыгаралмаган, хәлбуки Зөлфәт үзе (Дөлфәт Маликов) олылаган талантлы шагыйрь иде. Аның беренче һәм соңгы китабын чыгару юнәлешендә бүген якташы, шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов шөгыльләнә дип ишеттем, шәп татар укучысына затлы, зәвыклы шигырьләре килеп ирешер. Мөдәмилнең Эдуард Мостафин иҗатын олылавы тәэсирендә 2006 елны, аның бер шигыренә минем тарафтан көй язылып, «Юлчы» дигән җыр туды. Аны Салават «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе аша һәм концертларында бик күп меңнәргә ирештерде, җырның сүзләре якташы Эдуард Мостафинныкы икәнен, шундый фаҗигале язмышлы татар шагыйре булуын, кирәк санап хәбәр итте...*

*Эдуардны искә алып, мин фәкыйрегезнең «Татарстан яшьләре» газетасында, 2006 елның 3 октябрь санында, «Изге җан, сизгер җан булсаң» дигән, «Звезда Поволжья» газетасының 9 нчы санында (2009 ел, 12-18 март) «Озябшие цветы» исемле мәкаләләре басылды. «Татарстан яшьләре» газетасының 2010 ел, 25 декабрь санында басылган «Ник белмиләр бөек шагыйрь Мөдәмилне?» дигән мәкаләдә дә Эдуардны сагынып искә алу бар.*

*Янә килеп, язучы Тәлгат Нәҗмиев «Татарстан яшьләре» газетасының 2006 ел, 28 октябрь санында «Ерак буыннардан килгән серлелек» мәкаләсендә һәм «Казан утлары» журналының 2009 ел, 6 нчы санында «Сабаның суында бар» мәкаләсендә Эдуардны искә ала. Баксаң, ул берара Сабада редакциядә эшләп алган икән...*

*Укучылар дөрес аңлый күрсен, мин бәгъзеләрнең бик тә соңарып шушы җәһәттә казгануларын янгыннан соң насос дип бәяләргә җыенмыйм. Шагыйрьне искә алганнары өчен аларга да рәхмәт, әлбәттә...*

*Ихтирамымны белдереп,* **Рөстәм ЗАРИПОВ.**

---

## Күптән язылясы калган

*Хөрмәтле баш мөхәррир!*

*Хөрмәтле мөхәррият!*

*Сәлам Башкортстаннан! Мин «Казан утлары»н 2013 елның икенче яртысыннан алдырам. Шундый шәп басма икәнен белсәм, күптән алдырган булыр идем. Һәр санны башыннан ахырына кадәр йотылып укыйм. Үземә бик күп яңалык алам, яңа татар әдипләре һәм әдибәләре белән танышам. Быелтыр журналда басылган «Патша солдаты Әхмәтнәсир (Х.Галидән), «Гарасат» (З.Хөснияр), «Үзбәк хан» (А.Гыйн) романнарын, «Таллы күлдә былбыл бар» (А.Әхмәтгалиева) бәянен яратып укыдым. Искиткеч шәп әсәрләр.*

*Кызганычка каршы, Татарстанда басылган китапларны, шул исәптән Сезнең журналны да безнең якта табып булмый. Хәтта район китапханәсе дә алдырмый икән. Кыскача үзем турында: миңа 38 яшь, милләтем — башкорт. Хатыным һәм улым белән бәләкәй генә бер авылда яшәп ятам. Укырга яратам. Китап, журналны кулга алмый уздырган кичләребез бик сирәк.*

**Илдар ЛОТФУЛЛИН.**

*Башкортстан, Учалы районы, Муса авылы*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

# ТӘҮГЕ КАРДА АК ЭЗЛӘР...

ХИКӘЯ

– Әти, әти, дим, миңа кайчан планшет алабыз инде?

Ял көннәрен сагынып көткән Әмирнең сыртына менеп утырган да, җемелдәп торган, үзләренә генә хас хәйлә белән ялтыраган күзләрен елкылдатып, җиде яшьлек улы йөзенә текәлгән.

– Соң, әти, Сабирлар алган бит, Сәйдәгә дә бүләк иткәннәр... Синең күпме акчаң бар? Планшет унбиш мең тора икән...

Әмир ирексездән күзен ачты... Йокы туймаган иде.

– Улым, борчыма инде! Алырбыз дидем бит. Йоклыйк, ә?! — диде ул, мыгырдап.

– Әти, син вечно шулай әйтәсең... Алмыйсың син миңа, алмыйсың! — елагы тыгылган Булат, Әмирнең өстеннән төште дә, сөмсере коелып, бүлмәдән чыгып китте.

Әмирнең инде күзенә йокы кермәде. Хатирәләр аны ерак балачакка алып китте.

...Еллар, еллар...

– Әби, әби, дим! Калдырыйк инде Караканатны нәселгә, киләсе елга тагын бәбкәләр күп булыр, быел әнә инкубаторда чыгардык, Маратларның да, Илшатларның да гел ата-ана казлары була. Утырып чыгаралар, бергә-бергә каз бәбкәләре саклар идек. Суймыйк инде, ә?!

Әбисенең сүзе бер иде:

– Гомер буе чиләнгән дә җиткән! Суябыз! Бернинди каз асрау юк! Туйдым! Әле быел түзгәнгә дә рәхмәт! Ашарга каян җиткерергә кирәк аларга? Эзли-эзли җан чыга, вакытында кайтмыйлар! Юк!

– Әби, Караканатны суймыйк инде!.. — Яшьләренә буылып, Әмир урамга чыкты. Күрше Хәмдия апасы эштән кайта иде.

– Әмир, ни булды? — диде ул, гаҗәпләнеп. Малайның күзендә гомерендә яшь күрмәгән хатынга бу хәл гаҗәп дәрәҗәдә ят тоелды. Әмир дәшмәде.

Иртән чишмәгә суга чыккан күрше Хәмдия белән Әмирнең әбисе арасында сөйләшү булып алды...

– Кичә Әмир бик моңсу иде, Хәят апай, нәрсә булган аңа?

– И-и-и... һаман шул бер сүз инде. Нәселгә каз калдырыйк, ди. Башларымны катырып бетерде. Чын күз яшьләре белән елый. Суйдыртасы килми шул Караканатны. Ничек кыш чыгарыйм. Абзар тулы тавык, сарыклар бар. Бер пенсиямә каян икмәк җиткермәк кирәк! Бәбкә асрап, аларны эзләп җәй буе тилмердем бит, үзең күреп тордың.

– Шулаен шулай да, Хәят апай, Әмир җәл бит. Бигрәк моңсуланып калган. Шат-күңелле булып йөргән малай... Әллә, мәйтәм, калдырасыңмы соң. Һич югы бездә икмәк бетмәгән, әле бер көнне генә сигез капчык бодай, унике капчык фураж китерделәр. Бик кытлык булса, алып чыгарсың.

– Аптыраган инде, Хәмдия, син сөйлисең дә, миңа интегергә бит...

Су тулы чиләген мөлдерәтеп болдырга җиткәч, Хәят әби туктап калды. Туйганчы бер уфылдап, болдыр баскычына утырып ял итәргә булды. Казлар уянып чыкканнар, таң кошы әтәч тә, тавыкларын иялртеп, хуҗа каршына җим сорап килгән.

Караканат чыннан да матур иде. Үзе ап-ак, бер канаты гына кара. Кыз туганы чем ак, ир туганнары дүртесе дә күк төстә, озын муенлылар, киң күкрәкле, көчле канатлылар. Ә Караканат алар арасында иң сылуы, чын бәбкә анасы инде менә. Гәүдәсе дә зур түгел. Ана каз артык зур булса, бәрәкәте шул хәтле генә. Моны Хәят әби яхшы аңлый. Гомере буе каз асрады ул. Икешәр оя да булды. Кара төс артык килешмәгәч, гел ак хайван, кош-корт асрарга тырышты. Күрше хатыннары көнләшеп карыйлар иде.

– Хәят, ничек уңа соң ул синдә, ә? Бер ана булса — унике бәбкә, ике ана асрасаң — егерме дүрт! Бер-бер хәйләң бардыр...

Әйе, казлары уңа иде. Хәзер картаелды да бугай инде. Әмир һаман каз да каз, ди. Беренче кар оча башлаган. Озакламый суясы булыр...

Әмир чәй табынында бик төксе иде. Әбисе белән дә артык сөйләшмәде. Идәндә бер-бер тәм-том эләкмәсме дип утырган күк песие белән дә артык җәелеп китмәде.

Хәят әби, оныгының моңсу йөзенә туры карап, сүз башлады:

– Улым, Караканатны калдырдык ди. Аңа бит иптәшкә ата каз кирәк була. Үзенең туганын калдырырга ярамый, бәбкәләре гарип чыгачак. Нәселгә кемнән каз сорарбыз? Кул китә дип, берсе дә тере ата каз бирмәс!

– Әби, әбием, табарбыз! Караканат кына калсын инде!

– Ярар, менә ата каз тапсаң, кышка парлап калдырырбыз.

Әмир, эчә башлаган чәен ташлап, әбисен барып кочаклады, идәндә мияулап утырган песине алып күккә чөйде, өстенә элдеме-юкмы — ишегалдына, Караканаты янына йөгерде.

– Ишетәсеңме, Караканат, сине суймыйбыз, син кышка каласың, — дип шатлыгын уртаклашты ул. Малайның кабаланып килеп чыгуыннан өркеп калган тавыклар, пырхылдап, әтәч тирәсендә тупланганнар иде.

...Кечкенә генә куллары белән зур күк ата казны кысып тоткан малай җирне шактый гына тереп өлгергән ак карлы юлдан югары очка таба атлый. Ул Бәдри абзыйларга бара — Караканатка кияү сорарга. Бирер микән? Бәдри абзый саран кеше түгел, тик әбисе, кул китә, ди бит! Тере каз бирергә ярамый, ди. Нәселгә әтәч биргәндә дә, гел йоннарын йолкып кала, әллә нинди серле сүзләр әйтеп, өшкереп, ул йоннарны абзарга алып кереп сибә, үзең китсәң дә, җаның бездә калсын, ди. Шуңа күрә Әмир күңелендә шик зур. Ә күк ата каз гел тынгы бирми, тыпырчына да тыпырчына.

– И-и-и, Әмир, исәнме! Нинди каз күтәреп йөрисең? — дип каршы алды аны Бәдри абзый.

– Бәдри абзый, Караканатны нәселгә калдырмакчы идек, әби ата каз кирәк, ди. Монысы бармый икән, яңа кияү кирәк ул казга, табып кайт, диде. Алыштырып кына бир инде шуны, ә?!

Мөлдерәп торган кара күзләрне күргәч, Бәдри абзыйның күңеле нечкәреп китте. Белә ул Әмирне, күптәннән белә, әти-әнисен дә белә, әбисе Хәятне дә белә. Кызы белән кияве юл һәлакәтендә үлгәч, ике яшьлек Әмирне Хәят әбисе йөрәк пәрәсе кебек карап үстерде, тел-теш тидермәде, инде мәктәпкә укырга бирде. Мал җанлы егет күренә, табигать баласы.

– Бирүен бирермен дә бит, улым, Караканат безнең малайны ошатыр микән соң? Мин берәр егетемне тәкъдим итеп карыйм сиңа... Караканатың куып чыгармасмы аны? — дип хәйләкәр елмайды Бәдри абзый. Бүген иртән ипигә төшкәч, Хәят әби, тел төбен чишеп, Әмирнең казга менәсен әйтеп куйган һәм

Бәдри абзый, нәселгә калдырырлык яшь ата казны сайлап, абзарның аерым бүлмәсенә япкан иде.

Әмир чыннан да кош тотты! Ап-ак, зур сакаллы, озын муенлы ата каз. Йоннары кояш нурында беренче кар кебек елык-елык килә! Әмирнең кулына менеп утыруга ук «гаң, гаң, гаң» килде. Янәсе: «Яшь, яңа хуҗам синмени инде ул?» Әмир бераз каушап та калды.

– Бәдри абзый, безнең сорыны кая ябарсың икән?

– Улым, борчылма, кич белән аны әбиең менеп алыр. Бездә казлар бик күп ул. Әлегә әнә теге читлеккә ябып торам. Үземнең явызлардан аны рәнҗеттермәм.

Картның ятим балага, аның әрнүгә, дөнья газапларына чорналган йөрәкле әбисенә чын-чынлап ярдәм итәсе килә иде.

– Бәдри абзый, йоннарын алып калдыңмы? Әби бит кул китә, ди, — дип сорады Әмир, рәхмәт тулы хушлашу сүзләрен әйткәндә.

– Калдым, улым, калдым! Караканатның бәбкәләре күп булсын. Киләсе яз су буенда бергә-бергә сакларбыз, яме!

– Ярар, Бәдри абзый! Рәхмәт сиңа!

Әмир очып диярлек урамга чыкты. Култык астында ап-ак ата каз, Караканатның кияве гаңгылдап куйды.

...Еллар, еллар... Хыяллар... Чорлар үзгә, без дә башка. Хәят әби дөньядан киткәнгә дә дистә еллар узган. Шәһәрдә үз тормышы белән яшәгән Әмирнең улы әнә нәрсә ди бит! Аны Караканат та, ак ата каз да кызыксындырмый.

...Яңа яуган беренче ап-ак карда ике эз кала: берсе — зур, икенчесе — нәни генә ботинкаларныкы. Әти белән улы чираттагы балачак хыялын тормышка ашырырга ашыгалар. Кибеткә...

**Рамил ХАННАНОВ**

---

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Ак ефәк

**Smsны укыгач, кыз бетте генә инде... Анда өч кенә сүз язылган иде:** «Сине яратмыйм. Алмаз».

Шушы өч сүз 20 яшьлек кызның йөрәген әллә бозга, әллә ташка әйләндерде.
— Әй, Аллам! Яшәүнең нинди мәгънәсе бар?! — дип кычкырды ул бөтен Казан елгасы буен яңгыратып. Янәшәдән кешеләр уза торалар. Кызга кызганулы караш ташлыйлар да, башларын иеп күздән югалалар. Боз йөрәкнең салкынлыгы һәр кешенең йөрәгенә күчә һәм адымнарның кызулануына сәбәпче булып тоела.

Алисәнең иптәш кызлары беркайчан да булмады. Озын, кара керфекләр эчендәге серле, зур, зәңгәр күзләр, кыйгач кашлар, озын толымнарга зифа гәүдә дә өстәлгәч, ул матурлык алиһәсен хәтерләтә иде. Янәшәдән шушы кыз атлаганда, бөтен егетләрнең дә күзе нәкъ менә Алисәгә төшә иде шул! Кызлар аннан гел көнләштеләр. Ә егетләр аңа ялгыз чакта якын килергә курыктылар. Бөтен кызлардан аерып күрсәтә торган тыйнаклыгы сәбәпче булгандыр, мөгаен. Алисәне әнисе ялгыз гына үстергән. Әти исемен ишетергә лаек булмаган ир-егетнең «Алмаз» исемен йөрткәнен, паспортына теркәлмәгән

булса, белмәс тә иде. Чөнки әнисе аңа бу турыда беркайчан да сөйләмәде. Гомумән, әнисе бик аз сүзле иде аның. 16 яше тулган көнне ананың кызына әйткән сүзләре: «Ак ефәк булып кал! Ак ефәкне сатып алганчы капшап карамыйлар. Бик чиста итеп юылган кулның да табы ак ефәктә барыбер кала. Таплы ефәкне моны инде берәү тотып караган, ошатмаган дип, сатып алмыйча китеп баралар. Сиңа насыйп ярың тормышта очрамый калмас! Бәхетле бул, кызым!» диюе, бәлки, Алиянең тыйнаклыгының сәбәпчесе дә булгандыр. Алмаз исемле бер егетне очратканчы, тормыш бер җайга гына ага торды. Ә бер көнне бөтен тормыш законнары буталды, әнисенең «ак ефәк» турындагы фәлсәфи киңәше дә истән чыкты. Шул көнне Алисә беренче мәртәбә гашыйк булган иде. Бүген укылган бер sms хәбәр «орбитасыннан ычкынган Җирне үз кучәренә кире кайтарды».

— Алмаз! Алмаз! — дип кабатлады Алисә. Кабатланган ике «Алмаз» исеме аңа тормыш законнарын ачарга ярдәм итте бугай.

Ике бүлмәле квартирларының кыңгырау төймәсенә имән бармагы белән сак кына кагылуга, ишектән борчуларын эченә яшерергә тырышкан әнисе килеп тә чыкты. Алисәсе киткәннән бирле ишек төбендә генә басып, көтеп торган дип уйларга да мөмкин иде.

Кыз әнисенең кочагына ташланды. Ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән: «Ак ефәгең тапланды, әнием. Кичерә алсаң, кичер мине!» — дип кенә әйтә алды. Ана белән бала кочаклашып елаштылар. Ихтыярсыз аккан күз яшьләре аларның җаннарына тынычлык иңдерде. Ана, кызыннан алда үзен кулга алып: «Кем?» — дигән сорауны бирде. Алисәсенең: «Алмаз!» — дигән җавабы аны сискәндереп җибәрде булса кирәк. Ул болай диде:

— Язмыштан качып булмый, күрәсең. Әниемнең бик яшь көе саргаеп гүргә керүенә мин үземне сәбәпче итеп, битәрләп яшәдем. Чөнки мин дә «ак ефәк» булып саклана алмаган идем. Кызым! Без бит әле синең белән икәү! Авыр тормыш сынауларын ике кешегә бергә-бергә үтү җиңелрәк ул. Аллаһы Тәгалә мине беркайчан да үзенең ярдәменнән ташламады. Икебезгә дә аннан сабырлык сорыйк. Алмаз кадәр алмазны да уалый, вата ала торган бердәнбер кодрәт иясе — Аллаһы Тәгалә! Синең әтиең бүгенге көндә синең кебек Алисәсе барлыгын белсә, үзен, бәлки, иң бәхетле әти итеп тояр иде. Син бәхетле булсын өчен мин синең әтиең Алмазга иң авыр чакларымда да бәхет теләдем. Синең Алмазың гына әтиеңнең ташлап калдырган тагын бер баласы була күрмәсен инде! Җан җанга тик торганда гына тартылмый. Абый-сеңелләрнең очрашып, бер-берсе белән якынлык кылуыннан да Аллаһы Тәгалә үзе генә саклый ала. Ананың — балага, баланың анага мәхәббәтен дә Аллаһы Тәгалә саклый. Ана мәхәббәтеннән мәхрүм калган балаларга да Җир йөзендә яшәргә Аллаһы ярдәм итсен! Тормыш дәвам итә, кызым! Алмазыңа икәүләп бәхет теләп, әйдә, тәмләп чәй эчеп алыйк!

Ана белән кыз, бер-берсенең кочакларыннан аерылмаган көенчә генә, аш бүлмәсенә юнәлделәр.

## Атасыз бала

**Ул аны йөрәгеннән мәңгегә алып атарга, ә баласын саклап калырга ант итте.**

**Язның ярсулы бер көне иде ул...**

Язмышны алдан фаразлап булмый, ә тормыш итәргә берәү дә әзер булып тумый! Күз яшьләре белән мендәр чылатып ятып кына баланы үстереп булмаячак! Кызының хәлен әнисе аңлар. Ана белән бала җаны бер-берсенә өзелми торган тылсымлы җепләр белән бәйләнгәнен әнисенең аңа әйткәне дә бар. «Ана булу бәхетеннән дә олырак бәхет юк!» — дип әйтә килде бит ул кызына. Ә бәхет күктән төшми! Ак белән кара төсләр аралашканда, матур

һәм ямьсез күренешләр чиратлашканда, югалтудан соң гына табу бәхетен аңларга була торгандыр.

Атасыз бала табасы килү ниятен үзен бик нык яратучы, күрсәткән бөтен фокусларына да күз йомып, түзеп торучы һәм акча белән тәэмин итүче, аратирә күз карашы белән өтә алу сәләтенә ия әтисенә ничек белдерергә?!Бу көнгә кадәр ул әле Аллаһы Тәгаләне әтисеннән дә югарырак биеклеккә менгереп карарга кирәклекне аңламый иде шул! 28 яше тулса да, әтисен алыштырырлык кияү булырдай ир заты офыкта күренми әле. Гөлчәчәк исемен дә аңа әтисе куштырган. Күз явын алырлык чибәрлеге дә әтисеннән күчкән. Холкына чәнечкеле кайбер сыйфатлар өстәлү исемгә яраклашып Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелмәдеме икән, дип үзен дә уйланырга мәҗбүр итә.

Әтисе аның кияүгә чыгып, ир бала табып куандыруын көтә. Ул бит тана түгел! Тананы үгез белән очраштырганда , бозау туарга да мөмкин. Ә кешеләр өчен язылган һәм язылмаган аерым кануннар төзелгән. Тормыш итү өчен «ярый» һәм «ярамый» төшенчәләрен бөтен күзәнәкләренә сеңдергәнче ныклап өйрәнергә, әбисе әйткәнчә, «бер пот тоз ашарга кирәк!» Ялгыш атланган һәр адым кешеләр язмышының икенче юнәлешкә борылуы өчен сәбәп булып тора. «Татар акылы төштән соң» дигән гыйбарәнең үзен аңлау өчен дә акыл кирәк! Төш күрелгән, аны дөрес юрап, акыл гына кирәсе калган дип аңларгамы, әллә вакыт узып, эшлисе хатаны эшләгәч, төштән соң, икенче төрле итеп әйткәндә, өйләдән соң гына кирәчәк акылны күтәргәме?!

Узган тугыз ай Гөлчәчәк өчен тугыз елны алыштырган кебек тоелды. Бу вакыт эчендә нинди генә уйлар уйланмады! Ананың һәр кичерешен тоеп яту туачак баланың холык-фигылен дә билгели торгандыр. Йөрәк астында йөрткән баласын тау-тау алтыннарга да алыштыра алмаячагын йокысыз төннәре арткан саен ныграк төшенде ул. Дөрестән дә, авырлы булу хәбәрен әтисенә белдергән көне хәтердән уелмаслык көн булып исендә калды аның. Тулгак тоту һәм бала табу бу сынау белән чагыштырганда күп мәртәбә җиңелрәк булып тоелды аңа. Ул бу авырлыкларга тешләрен кысып булса да чыдады. Шушы сынауларны узгач кына бәхет елмайды аңа. Беренче мәртәбә улына күкрәк сөтен имезгән көнне Гөлчәчәк үзенең җан җимешен инде бирәү белән дә бүлешә алмаячагын аңлады. Ә уртак җимешне яраткан кешең белән бүлешеп ашаганда авызда тәме озаграк сакланачагын аңларлык халәттә түгел иде әле ул.

**Флёра МӘРДАНОВА.**
*Тукай районы Күзкәй авылы*

## Яшьлек хатирәләре

**Мин аны йөрәгемнән мәңгегә алып атарга, ә баламны саклап калырга ант иттем.**

**Язның ярсулы бер көне иде ул...** Аны яңадан очратты.

Айсылу тукталышта озак кына троллейбус көтте, аяклары да туңып бетте, кулларына әбисе бәйләгән ап-ак йон бияләйне кисә дә, зәмһәрир суык барыбер үтеп керде. Менә ерактан троллейбус күренде, Айсылуның йөзендә нур балкыды. Троллейбуста кеше күп иде, алма төшәрлек урын да юк. Әллә ничек күзе арттагы урында утыручы бер кешегә төште. Бу кешедә ниндидер таныш чалымнар сизеп алды. Юк, юк, ул булырга мөмкин түгел, ул бит башка шәһәрдә яши дигән фикер яшен тизлегедәй башыннан йөгереп үтте.

Еллар агым сулар кебек үтә торды. Айсылуның да нәни йөрәгендәге ярасы төзәлә барды, үзендә көч табып, яшәвен дәвам итте ул. Хәзер бит алар икәү, ике йөрәк бергә тибә башлады. Әллә ничек сикәлтәле булды Айсылуның язмышы. Бер-берсенә гашыйк ике пар аккошка күз тидерделәр, ахрысы. Айнур күзгә

күренеп үзгәрде, кул күтәрә, кычкыра башлады. Хәтта Айсылуның карынында типкән нәни сабый да кызыксындырмый башлады аны. Өйләнешергә куелган туй көне үзеннән-үзе кичектерелде. Аралар суынганнан-суына барды һәм менә көннәрдән бер көнне Айсылу әйберләрен җыеп башка шәһәргә күченеп китте, сабыен саклап калырга уйлады. Ул анда мәктәпкә эшкә урнашты. Җир йөзендә яхшы кешеләр очрый шул ул, Айсылуга да булышучылар табылды. Акрынлап тормыш алга барды. Айсылуның яшәү мәгънәсе — нәни кызчыгы туды. Еракта Айсылуга күз атып, булышып йөргән Тимерхан үзенең ярдәм кулын сузды, мәхәббәтен аңлатты. Айсылу да мәхәббәтне кабул итте, аның кызы әтисез үсәргә тиеш түгел иде. Троллейбуста күзгә-күз очрашкан теге кеше турында юл буе уйланып барды Айсылу. Ул кеше белән көн саен шул бер үк троллейбуста бер үк вакытта эшкә бара торган булдылар.

Ләкин бүген троллейбуста Айсылу үзенең юлдашын очратмады, әллә берәр нәрсә булдымы икән дип йөрәге чәнчеп куйды.

Көннәр үтә торды, Айсылуның гомер йомгагы сүтелде дә сүтелде. Ул үзенең тормышыннан бик тә канәгать иде. Тимерхан да Айсылуны өзелеп яратты, аның баласын үзенеке кебек кабул итте. Хатын Тимерханга ияләшкәнен сизми дә калды. Тормышы үзеннән-үзе бер пазл кисәкләре кебек җыелды да куйды. Берәр кисәге югалса, ул пазлларны җыеп булмас иде сыман тоелды.

Менә бүген дә ул троллейбусны бик озак көтте. Утыргач та күзе һаман да теге кешене эзләде. Айсылуга нишләптер ул бик таныш кеше кебек тоелды. Бүген ул иң арттагы урында утыра иде. Айсылу озакка сузылган бу очрашуларны өзәргә булды... Чөнки үзенчә бик бәхетле иде! Бүген ул Тимерханга яхшы хәбәр әйтергә җыена иде.

**Алёна ФӘХРЕТДИНОВА,**
*Казандагы 37нче гимназиянең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Җыр

**«Там, там, там, тамуыңны яратам», — яңгыр астында шулай дип җырлап барганда, ул... уянып китте. Кайдадыр чалкан ята икән бит, ә аның өстенә ниндидер кыз иелгән. Теге җылы тамчылар шуның күзеннән тама икән ул.**

— Син кем? — дип сорады ир, ярым пышылдап. — Мин кайда?

— Мин — шәфкать туташы, исемем — Дилә. Сез хастаханәдә. Бер айдан артык яттыгыз биредә. Менә, ниһаять, күзегезне ачтыгыз, сез үлемне җиңдегез!

Ир янә күзен йомды, тик тынычлана алмады. Димәк, бер ай хастаханә койкасында ятып, тиешле җиренә барып җитә алмаган. Быел җәйгә чыккач, күптән вафат булган хатынының анасы аны Сөендек авылына чакыртып хәбәр җибәргән иде. Ни өчен икәнен әйтмәгән. Егерме ел элек бирегә эшкә килде ул. Авылның иң чибәр кызы Зилә белән тормыш корып җибәрделәр. Яратты ул аны, үлеп яратты, тик мәхәббәтләре генә гомерсез булып чыкты. Хатынын бала табу йортына илткәндә, алар авариягә очрады. Үзе бер атнадан соң гына аңына килде. «Хатының үлде, баласын табарга өлгермәде», — диде әби кеше. Их, аның урынына үзе үлгән булса соң... Әйтерсең лә җанын суырып алдылар. Ул сөеклесенең каберенә барып саубуллашты да, бу авылны ташлап, Себергә үк китеп барды. Аның монда беркеме дә калмады. Шулай да ник чакыртты икән әбисе? Әнә авылга да якынлашып килә. Кинәт тау итәгендә Зиләгә охшаган бер кызның җырлап килүе күренде: «Там, там, там, тамуыңны...» «Зилә, Зилә-ә-әм», — дип кычкырды ул. Аның тавышы борылыштан килеп чыккан йөк машинасы гөрелтесе астында өзелеп калды...

Димәк, аңсыз килеш бер ай яткан. Зиләгә охшаган кыз шәфкать туташы булып чыкты. Сөеклесенә охшаса да охшар икән. Ник соң ул аның җырын җырлый? Зиләсенең җырын ишеткәч, аңына килде түгелме соң ул? Әллә минем кызым исәнме икән? Бу сүзләрен кычкырып әйтте шикелле. Палатага кереп килүче Дилә: «Әйе, әтием, мин исән, — диде. — Үләр алдыннан әбием сөйләде. Әнием мине тапкач та вафат булган. Истәлеккә җыры гына калган, әбием өйрәтте аны. Мин шул җырны җырлап үстем. Әбием барын да синнән яшергән, мине алып китәрсең дип курыккан. Сине дә шуны әйтергә дип чакырткан булган». «Кызым, кызым, син әниеңә шундый да охшагансың! Мин синең исән булуыңны сизеп яшәдем бит. Төшләремдә гел әниеңнең җырын ишетә идем. Бүген дә шуны ишетеп, үлем тырнагыннан ычкындым. Син миңа яшәү бүләк иттең, балам. Мин яңадан тудым кебек, югалган бәхетемне эзләп таптым», — диде әтисе һәм кызын, аталарча иркәләп, кочагына кысты.

## Җиңү куанычы

**Рәмзия каршына кинәт сәер мода белән киенгән, озынрак колаклы егет килеп басты. «Фикс-Микс планетасыннан сине күрергә килдем!» — диде ул.** Кызның аптырап калуын күреп, Озын колак сүзен дәвам итте: «Сез, кешеләр, һәр уйлаган, һәр әйткән сүзегезнең материальләшеп чынга ашуын белмисез. Уй-сүзләрегезнең яманы яхшысыннан күбрәк. Без аларны сортларга аерабыз. Начарларын шунда ук тормышка ашырырга юл куймыйбыз, кешеләргә уйланырга, хаталарын төзәтергә вакыт бирәбез. Мин үзем матур уй-теләкләр өчен җаваплы. Җирдә яхшылыкка өстенлек бирелергә тиеш. Мин шуның өчен тырышам. Сиңа ярдәм итәргә телим, чөнки синең күңелең изгелектә».

Институтта күптәннән «Мисс-гүзәллек» бәйгесенә әзерлек башланды. Рәмзиянең дә катнашырга теләвен белгәч, кызлар кычкырып көлделәр. «Безнекедәй озын аякларың, буең булса иде, ичмасам», — диде Алсу. «Дөньяны матурлык кына коткарачак», — дип өстәде Луиза. Әйе, буе кыскарак шул. Булса соң, кешенең бар матурлыгы озын булудамыни? «Бәбкәм, күңелеңдәге игелек күзләреңдә чагылганга күрә матур син», — дия иде әбисе. Ул ялгышмас. Җиңү яулап, кулына акча гына керсен, Рәмзия нишләргә белер иде әле. «Мин — җиңәргә, ул бәхетле булырга тиеш, аның моңа хакы зур», — дип уйлады кыз.

Ул, уйларыннан арынып, Озын колакка карады. «Теләгеңә ирешерсең, сайлаган юлың дөрес, — диде кунак, аның уйларын укыган сыман. — Мин сиңа ярдәм итәчәкмен». Рәмзиянең гаҗәпләнүдән тыны кысылды. «Телепат икәнлегеңне күрәм, тик җюри мине аңлармы соң?» — диде ул. Озын колак: «Күңелең матурлыгын, йөрәгең сафлыгын аңлаучылар табылыр», — диюгә Рәмзия үзендә ышаныч артуын сизде. Шул минутта кыз уянып китте. Төш кенә икән. Ул аны яхшыга юрады: бүгенге көн аңа җиңү сөенече алып килер.

Залда алма төшәрлек тә урын юк. Кызлар үз һөнәрләрен күрсәтә башладылар. Рәмзия берсеннән дә калышмый. Алсуга багышланган алкышлар көчлерәк яңгыраса да, кыз күңелен төшерми. Бәйгенең соңгы туры. «Синең хәзерге хыялың нинди?» соравына җавап бирәсе. «Мин дөньякүләм сәяхәткә китәм», — диде Алсу. Башка кызлар да аннан калышмады. «Мин армиядә имгәнгән күршемә ярдәм итәргә телим. Аңа яхшы операция кирәк», — диде Рәмзия һәм сәхнә алдында инвалид коляскасында утыручы егет янына килде. Зал күпмедер вакытка тын калды, аннан торып басты һәм шаулатып кул чаба башлады. Җиңеп чыккан кызның күзендә шатлык яшьләре күренде. «Афәрин, эчкерсез матурлык һәм чын гүзәллек алдында баш иябез», — дип гөрләде зал.

**Гүзәлия ТАРХАНОВА**

## Яратам шул!

**«Камил Сәлимович! Мин сине яратам!» — кара тактага шулай диеп язылган иде! Яшь укытучы кулына акбур алды** да «Мин дә сине», дип, өч нокта куйды... Сыйныфта тынлык урнашты, бу вакытта тынлыкны бозарга бер кеше дә җөрьәт итмәде. Серле нурлар Айсылуның самими йөзендә чагылды. Сүзләр әллә ничек артык тоелды. Айсылу да көтелмәгән хәлдән уңайсызланып китте, үзенә урын тапмады һәм дәрестән чыгып йөгерде.

Әллә ничек бу вакыйганы Айсылу күп еллар үткәч, тәрәзәгә карап, ябалак-ябалак кар яуган вакытта исенә төшерде. Еллар үтсә дә, беренче мәхәббәте йөрәгендә урын алган иде. Күз алдына, энәгә тагылган җеп шикелле, Айсылуның тормышы килеп басты. Әйе, Айсылу аны мәктәпкә килгән көннән башлап күзәтеп йөрде. Аның һәр адымы, әйткән һәр сүзе, үз-үзен тотышы сокландырды. Гомумән, гашыйк булды ул үзенең Укытучысына!!! Айсылудагы үзгәрешләрне әнисе дә сизде, әмма кызына ничек ярдәм итәргә, нинди киңәш бирергә белмичә аптырап калды. Кыз Камил Сәлимовичның дәресләрен бер дә калдырмады, ул аларны зур түземсезлек белән көтте, сәгате тәүлеккә тиң иде. Һәрбер дәресне йотлыгып тыңлады, фикерләрен әйтеп, үзенә игътибар итүен теләде. Такта янына чыкканда, Айсылу ялгыш кына кагылып китү юлларын эзләде. Яратуы шундый көчле иде шул аның...Тик укытучы гына һаман күрмәмешкә салышты, нигәдер бу очракта үзен гаепле санады. Аның да йөрәгендә мәхәббәт уты кабынган иде инде, йөрәге сулык-сулык тибә башлады. Үзенең мәхәббәтеннән Камил курыкты, ул бит укучы сабый, ул бит укучы сабый, дип үзалдына кабатлый бирде. Авылда бу хәлне ишетсәләр, һич дөрес кабул итмәсләр, дип уйлады. Әмма кеше йөрәге бик тә үзенчәлекле. Аңа берничек каршы килеп, «болай ярамый!» дип әйтеп булмый шул. Камил үзенең яраткан җырын исенә төшерде:

Нигә диеп мин карадым
Син йөзгәндә ак җилдә?!
Укучым идең лә минем,
Нигә кердең күңелгә.

Мәхәббәткә бит яшь аермасы мөһим түгел. Әйтергә теләгән сүзләренә, белдертәсе килгән пакь мәхәббәтенә вакыт та, уңайлы очрак та туры килде. Айсылу инде үзе беренче булып тәүге адымын ясаган иде. Егеткә бу очракта йә кабул итәргә һәм үзенең дә сөюен әйтергә, йә араларны өзәргә кирәк иде. Ул мәхәббәтне шатлана-шатлана кабул итте.

Менә бит нинди саф, көчле мәхәббәт һаман Айсылуның йөрәген җылытып тора. Ишектә кыңгырау шалтырап, Айсылуны татлы уйларыннан уятып җибәрде. Ишектә ул иде, аның яраткан Укытучысы — Камил Сәлимович. Хәзер ул — Айсылуның сөекле ире, балаларының яраткан әтисе!..

**Әдилә НУРХӘМӘТОВА,**
*Казандагы 37нче гимназия укучысы*

***«Җилкәнче»**: Фикс-Микс планетасыннан килгән егет адәм балаларының акылы-хәтеренә тәэсир итә башладымы икән әллә? Әдиләкәй хикәяне... 2011 елның 9нчы санында бирелгән башламны дәвам итеп язган бит! Шәп язган. Бу башламны да көчендә калдырыйк мәллә?*

*Башламнарны **быелгы 1нче** яки **былтыргы 12нче саннан** карый аласыз.*

# «ТАНЫМЫШ» ДӘРЕСЕ

*Сөбханалла, өч туп-тулы, ягъни хәтта эпиграммаланган җавап килде! Бер генә җавап куелмаган һәм нибары берсе генә дөрес түгел. Кайсы? Моңа да җавап көтәбез.*




*Хөрмәтле «Казан утлары» редакциясе!*

*Мин, Әбүбәкерова Зөлфия, Минзәлә районы Татар Мөшегесе авылында китапханәче булып эшлим.*

*Сезнең 2015 елның 2нче санында басылган «Танымыш» дәресенә җаваплар һәм эпиграммалар җибәрәм.*

***1. Фәнзаман Баттал***
Кара эшләпә астына
Яшерелгән пеләш баш.
Бары Фәнзаманда гына
Сызылып киткән кара каш.

***2. Бәширә Насыйрова***
Челтерәп чишмә аккан кебек
Бәширәнең тавышы.
Сизелми, аны тыңласаң,
Гомерләрнең агышы.

***3. Илдус Әхмәтҗанов***
Тукаймы, Илдусмы бу, дип,
Мин аптырап утырам.
Әһә, белдем: Әхмәтҗанов!
Нишләп танымый торам?

***4. Нажар Нәҗми***
Бик күп шигырьләр язгансың
Илне һәм телне мактап.
Һәрчак йөртербез аларны
Күңел түрендә саклап.

***5. Рәдиф Гаташ***
Рәдиф Гаташ күзлек кия,
Шакмаклыны, олыны.
Шул күзлеге хәтерләтә
Миңа Туфан абыйны.

***

*Исәнмесез, кадерле редакция!*

*«Танымыш» дәресенә җавап юллыйм.*

***1. Фәнзамал Баттал***
Батмый торган Баттал, диләр
Синең турыда, агай.
Арттыралар, шыттыралар,
Мактанмыйк әле алай.

***2. Хәмдүнә Тимергалиева***
«Кияүгә барам...» — дип җырлый
Хәзер кызлар калада.
Ә кияүләр кызлар эзли
Бушап калган салада.

***3. Илдус Әхмәтҗанов***
Тукайны күрдек сәхнәдә.
Рольләр өстәлә торсын.
М.Туфанны да уйнарсың —
Пьеса гына тусын.

***4. Нажар Нәҗми***
Казан — Уфа арасы —
Нәкъ мич, казан арасы.
Шулай якын иттең син,
«Туган телне» сиптең син!..

***5. Рәдиф Гаташ***
Күпме кызлар елаттың
Робагый, газәл язып.
Шуңа бит инде кызлар
Китмәде артык азып.

**Рушания НИЗАМОВА.**
*Аксубай районы Яңа Дума авылы*

*Исәнмесез, кадерле редакция!*

*«Танымыш»тагы 3нче номерның шәхесен атый алмасам да, эпиграммалар язып карарга булдым әле.*

***1. Фәнзамал Баттал***
Үз фикерен төптән уйлап
Әйтә Баттал Фәнзаман.
Авыр уйлардан арынса,
Тартмый башлар берзаман.

***2. Хәмдүнә Тимергалиева***
Чын татарча җыр тыңларга
Концертына кил әле.
Хәмдүнәгә сүз әйтмәгез,
Кияүгә чыгар мәле.

***3.***
Әйтә алмыйм, кемдер син,
Карашың үткер, чая.
Сизеп торам, иҗатың бай –
Үтми гомерең зая.

***4. Нажар Нәҗми***
Йөрәкләрдә мәңге яшәр
Җырларың калды, Нажар
Нәҗми кебек, шигырьләрне
Меңнәрдән берәү язар.

***5. Рәдиф Гаташ***
Мәхәббәтнең сандугачы –
Ул Рәдиф Гаташ инде.
Аның шигырьләрен укып,
Сөюдән саташ инде.

**Зимфира ИСЛАМОВА.**
*Тукай районы Зур Шилнә авылы*

*Һәм янә биш шаржны танытмакчыбыз. Автор шул ук — Зөлфәт Хәйруллин.*

①


②


③


④


⑤


## ЮБИЛЕЙ

Татар халкының бөек җырчысы Илһам Шакировка 80 яшь тулды. Юбилярны Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итте. Ул ихлас котлауларын ирешләргәннән соң, бәйрәмдарга «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды һәм «Форд-Мондео» машинасын бүләк итте. Очрашуда Президент Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты.

Икенче көнне юбиляр хөрмәтенә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында зур кичә булды. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова олпат җырчыга ТРның беренче Президенты, ТРның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең котлавын җиткерде. Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстанның халык рәссамы, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Камил Муллашев Илһам ага белән бәйле истәлекләрен уртаклаштылар. Тантанада котлаулар җыр-музыка белән үрелеп барды. Сәхнәдә Зилә Сөнгатуллина, Римма Ибраһимова, Георгий Ибушев, Венера Ганиева, Рафаэль Сәхәбиев, Идрис Газиев, Резеда Галимова, Фердинанд Фәтхи, Бәширә Насыйрова, Әхмәт Агади, яшьрәкләрдән Филүс Каһиров, Руслан Сәйфетдинов, Айгөл Хәйри, Илүсә Хуҗина, Раяз Фасыйхов, «Казан егетләре» ансамбле һәм башкалар чыгыш ясады. Кичәдә ТРның мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты. Юбилей тантанасын Камал театры артистлары Фәнис Җиһанша белән Алсу Каюмова алып барды.

Илһам Шакировка 80 яшь тулу хөрмәтенә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә дә концерт булды. Олуг юбилейны Мәскәүдә, Кремль сараенда да зурлап билгеләп үтү күздә тотыла.

## КИҢӘЙТЕЛГӘН УТЫРЫШ

Татарстан Республикасының «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының киңәйтелгән утырышы булды. Анда еллык эшкә йомгак ясалды. Бүгенге көндә Татарстанда меңнән артык гаммәви мәгълүмат чарасы, шул исәптән 665 басма матбугат, 73 телеканал, 89 радиоканал, 137 интернет басма, 15 матбугат агентлыгы теркәлгән. Агентлыкның яңа җитәкчесе Айрат Зарипов үз чыгышында гаммәви мәгълүмат чараларының бүгенге хәленә бәя бирде, аларның интернетта ныклы урын били баруын искәртте, икътисади тотрыксызлык шартларында вакытлы матбугатка язылучыларны саклап калу мәсьәләсен күтәрде. ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республика Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова «Укый торган Татарстан» проектын гамәлгә ашырырга тәкъдим итте, ТР Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан — Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов республика телевидениесен үстерү концепциясенә тукталды.

Утырышта ТР Президенты Аппараты җитәкчесе, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе Әсгать Сәфәров катнашты һәм чыгыш ясады. Ул киләчәккә яңа бурычлар билгеләү белән беррәттән, ТР Президентының узган елгы әмерен үтәп, медиа тармагын үстерү стратегиясен булдыру максатында эшнең дәвам иттерелүен һәм тиздән төгәлләнәчәген хәбәр итте. Әсгать Сәфәров массакүләм мәгълүмат чараларының үсешенә зур өлеш керткәннәргә өчен «Татарстанның атказанган матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булучыларны игълан итте һәм котлады.

## КОНФЕРЕНЦИЯ

Әдәбият елы уңаеннан чаралар кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының йомгаклау конференциясе булды. Аны институт директоры Ким Миңнуллин ачып җибәрде. Пленар утырышта ТР Фәннәр академиясе президенты Мәкъзүм Сәлахов котлау сүзе белән чыкты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, театр тәнкыйтьчесе, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының әдәби-

драматик бүлеге житәкчесе Нияз Игъламов чыгыш ясады. Аннары 8 томлы «Татар әдәбияты тарихы»нын 1, 2нче томнарын тәкъдим итү булды. Конференциядә катнашучылар эшне секцияләргә бүленеп дәвам иттерделәр.

### ТАНТАНАЛЫ МИТИНГ

15 февраль — Муса Җәлилнең туган көнендә язучылар, җәмәгатьчелек вәкилләре, мәктәп укучылары каһарман-шагыйрьнең Кремль каршындагы һәйкәленә чәчәкләр китерде. Монда тантаналы митинг үткәрелде. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачты. Тантана ТР Милли музеенда да үткәрелде. Халыкка «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәсе тәкъдим ителде.

### ОЧРАШУЛАР

«Ватан» фиркасе Мәскәүдә Асадуллаев йортында кызыклы очрашулар үткәрде. Беренче көнне рус, итальян телләрендә төрки тамырлары турында фәнни хезмәтләр, монографияләр язган, Бәләбәйдәге татар гимназиясе директоры Нурмөхәммәт Хөсәенов, инженер-химик Нәсим Сәхапов, «Топонимический словарь Мещеры»ның авторы Мөхәммәт Миначев чыгыш ясады. Аларны тамашачыларга шагыйрь Айдар Хәлим тәкъдим итте. Икенче көнне шагыйрьләр Айдар Хәлим белән Әхмәт Саттар шигырь сөючеләр белән очрашты.

***

«Казан утлары» журналы редакциясе белән Тукай районы хакимиятенең мәгариф идарәсе арасындагы хезмәттәшлек кысаларында журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, галим, язучы Искәндәр Гыйләҗев Тукай районында булып, мәктәпләрнең тарих укытучылары һәм укучылар белән очрашулар үткәрде.

### КИЧӘ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында мөгаллим, мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 190 ел тулуга багышланган кичә булды. Кичәнең сценарие бәйрәмдарның «Кырык бакча» әсәре нигезендә язылган иде. Тамашачыларны ул бакчага К.Насыйриның бертуган энесе Габделкавиның кызы Гөлхәбирә Насыйрия ролендә нәфис сүз остасы Луара Шакирҗан алып керде. Кичәнең сценарий авторы, филология фәннәре кандидаты Раушания Шәфигуллина белән шагыйрә Эльмира Шәрифуллина Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында сөйләделәр.

### ЯҢА ДИРЕКТОР

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына яңа директор билгеләнде. Ул — ТР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, журналыбызның даими авторы Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәскәүдә А.Пушкин исемендәге әдәби музейда «Сүзгә һәм Ватанга тугрылык» девизы белән барган Александр Пушкинның дусты һәм көрәштәше, «Литературная газета»ның беренче мөхәррире Антон Дельвиг исемендәге Бөтенроссия премиясен тапшыру тантанасы булды. Җиңүчеләргә алтын, көмеш, бронза медальләр һәм дипломнар тапшырылды. Татарстанның халык шагыйре **Ренат Харис** соңгы еллардагы әсәрләре һәм «Алтын Урда» балеты либреттосы өчен алтын медальгә лаек булды. Бу мәртәбәле бүләк ана шигъриятендәге нык лы гражданлык позициясе, туган теленә тугрылык һәм тарихны тирәннән өйрәнүе өчен дә бирелде.

***

Филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Азат Әхмәдуллин** 8 китаптан торган «Татар драматургиясе тарихы» монографияләре һәм тематик җыентыклар сериясе өчен фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләгенә лаек булды.

***

Шагыйрь **Ринат Мәннан (Ринат Архипов)**, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Синең улларың, Россия» VIII Бөтенроссия әдәби конкурсында «Воздушный корабль» («Һава корабы») шигыре белән катнашып, РФ Кораллы Көчләренең М.Фрунзе исемендәге Мәдәният үзәге дипломына лаек булды.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик **Бадыйкшанов Локман Әхмәт улы (Локман Бадыйкшан)** 96нчы яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман-элегия К.КАРИМОВА «Жаворонки в облаках»;
стихи К.БУЛАТОВОЙ, Дж.СУЛЕЙМАНА, Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Л.ЯНСУАРА.
«Конкурс на повесть малого формата»: Г.ДАУТОВ. «Я к вам вернусь в песнях»;
Х.ГАРИПОВА. «Западня».
«Искусство»: Р.ЗАЙДУЛЛА. «Директор»; А.АЛМАЗОВА. «Фарид Яруллин и его окружение»; Г.САГИТОВА. «Тайны «Чёрной Палаты».
«100-я страница»: Г.МУРАТ. «Чтобы музы не молчали...»
«Литературная критика»: Актуальные проблемы современной прозы. Подготовил Р.ХАННАНОВ.
«Память»: Р.ФАЙЗУЛЛИН. «Тоска»; А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»; статья И.ХАЙРУЛЛИНА, посвящённая памяти М.САЛИМЗЯНОВА.
«Наши юбиляры»: статья Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, посвящённая к 60-летию Дж.СУЛЕЙМАНА; статья Р.ГАБДУЛХАКОВОЙ, посвящённая к 55-летию Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.
«Жизнь и религия»: БАТУЛЛА. «Суть» (прод.).
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: рассказы Р.ХАННАНОВА, Ф.МАРДАНОВОЙ, А.ФАХРУТДИНОВОЙ, Г.ТАРХАНОВОЙ, А.НУРХАМАТОВОЙ; «Узнавайка».
Из фотоархива журнала. Рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Каюм Насыри». Работа художника З.Гимаева;
парк «Чёрное озеро». Фото Г.Хафизова.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel-elegy by K.KARIMOV «Larks in the clouds»;
poems by K.BULATOVA, Dj.SULEYMAN, F.ZAMALETDINOVA, L.YANSUAR.
«Competition for a small-format novel»: G.DAUTOV. «I'll come back to you in the songs»;
H.GARIPOVA. «Trap».
«Art»: R.ZAYDULLA. «Director»; A.ALMAZOVA. «Farid Yarullin and his entourage»;
G.SAGITOVA. «Secrets of «Black Chamber».
«100th page»: G.MURAT. «To muses were not silent...»
«Literary criticism»: Actual problems of modern prose. Prepared by R.KHANNANOV.
«Memory»: R.FAYZULLIN. «Melancholy»; A.SHAMOVA. «Your fates are linked with the fire of war»; article byI.KHAYRULLIN dedicated to the memory of M.SALIMZYANOV.
«Our heroes of the day»: article by F.ZAMALETDINOVA dedicated to the 60th anniversary of Dj.SULEYMAN; article by R.GABDULHAKOVA dedicated to the 55th anniversary of F.ZAMALETDINOVA.
«Life and religion»: BATULLA. «Essence» (cont.).
«Pages of humor»: section is lead by M.GALIEV.
«White Sail»: stories by R.KHANNANOV, F.MARDANOVA, A.FAHRUTDINOVA, G.TARHANOVA, A.NURHAMATOVA; «Find-it-out».
From the photo archives of the magazine. Section is lead by R.FAYZULLIN.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: «Kayum Nasyyri». Work by artist Z.Gimaev;
Park «Black Lake». Photo by G.Khafizov.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Каюм Насыйри». *Рәссам* ***Зөфәр Гыймаев*** *эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Черек күл» паркы. ***Газинур Хафизов*** *фотосы.*

# БАТЫРЛЫК ЕЛЪЯЗМАСЫ

***Фатих Кәрим — фаҗигале язмышлы
иң талантлы шагыйрьләребезнең берсе.***



*Төрмәдә. 1938 ел.*



*Фронтта. 1944 ел.*

***Әбрар Кәримуллин — солдат,
татар китабы тарихы буенча иң күренекле галим.***



*Порт-Артур. 1946 ел.*



*Казан. 1986 ел.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)